КАЗАН УТЛАРЫ
www.kazanutlary.ru
ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Зиннур МАНСУРОВ. Чияләнде башымдагы бар уем. *Шигырьләр*. ....3
Рабит БАТУЛЛА. Илбашы. *Татарстан Республикасының Беренче Президенты, татар халкының олуг шәхесе Минтимер Шәймиев турында хикәяләр*. ....10
Салават РӘХМӘТУЛЛА. Чорлар узгач — дөнья беләчәк. *Шигырьләр*. ....63
Марсель ГАЛИЕВ. Тимә, яшәсен! *Роман-новелла*. ....66
Ибраһим БИЕКТАУЛЫ. Чын дусларым — сүзләр. *Шигырьләр*. ....113
Айдар ХӘЛИМ. *Хикәяләр*. ....116
Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА. Минем күңелемдә яңа яз. *Шигырьләр*. ....135
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. *Хикәяләр*. ....138
*100нче бит:* Камил КӘРИМОВ. Күтәрергә ярамый төшерергә. ....100

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. «Пристаньнар ярга ятып кала...» ....150

ЮБИЛЕЙЛАР

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Татар әдәбиятында реализм: Рәфкать Кәрами прозасы. ....154

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Тарих – сабак, тарих – гыйбрәт. *Академик Рафаэль ХӘКИМОВ белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе*. ....160

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. «Зур тәрәзә бар дип аңла дөньяга күкрәктә син». ....164

ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ

Алсу ХАСАВНЕХ. Мәшһүр вә укымышлы булган Фәрһад белән мәгъшукасы Ширин хикәясе *(Кереш сүз белән)*. ....166

СӘНГАТЬ

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Яшәү җыры. ....173

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Ибраһим ГАЗИ. Югалган Мәрзыя. *Фронт дәфтәреннән*. ....179

ЮБИЛЕЙГА БАРЫШЛЫЙ

Татар мәдәниятенең көндәлек дәфтәреннән. ....186

«Казан утлары» архивыннан. ....148
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**
*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Рәзилә Хәйретдинова, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1268).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.01.2017, график буенча 31.01.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70Х108^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-218. Тираж 5250.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210, П2365 (физик затлар өчен), 16262, П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2
© «Казан утлары», 2017 ел



Зиннур
Мансуров

# ЧИЯЛӘНДЕ БАШЫМДАГЫ БАР УЕМ

## Бөркет күләгәсе

Күккә карап җайлы форсат көттем,
ашкын җайдак ише чабып киттем
бөркет күләгәсе артыннан.
Япан кырда озак шәүлә кугач,
кисәк кенә ияр какшап куйгач,
мәтәлдем мин акбүз атымнан.

Кан-яшь йоткан хәлдә матур уйлап,
безгә насыйп җир-су юлы буйлап
атлап үттем алга өч адым, –
ачык күргән кебек шомлы төштә,
кара елан кабык салган төштә
кинәт ау-тозакка очрадым.

Үргә менеп, тирән урга төшеп,
тезне ташка бәреп, башны тишеп,
күпме киртә аша узылды.
Базлык булып чыкты һәрбер калкым,
авыз ачып торды ничә капкын –
алар мине шулай үз кылды.

Күңел кошын хәвеф белән сынап,
хәтәр мина кырын кичкән сымак,
гаҗиз кыяфәткә йөз кердем.
...Гыйбрәт өчен барча көчне куеп,
япан кырда тере шәүлә куып,
бөркет юлы буйлап йөгердем...

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) – *Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты; «Кул бирәм», «Җәрәхәтле йөрәк җылырак», «Күңелдә фидаи яшәсә», «Тукай белән әңгәмәләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Серле сәйях

Кальбең яхшы хәбәр көткән чакта,
ах, бу вакыт шундый тын ага, –
ерак юллар үтеп кайткан төсле,
сабый бала килә дөньяга.

Парылдаша тәрәз пәрдәләре,
гүя галәм кичәр ал җилкән.
Тәүге тапкыр аһлап куя бәби –
озын сәфәр тәмам алҗыткан.

Үзе җитди, әллә инде безгә
нидер тапшырырга ант эчкән.
Аннан... җәннәт исе аңкып тора –
әйе, ул чынлап та алыстан!

Түбән төшеп йөзә каурый болыт,
әйтерсең лә күкләр саярган.
 Япь-яшь затны лаек юньгә кертеп,
чәбәләнә тәндә сәйяр җан.

## Ефәк юлы

Тәрәз аша офык чиген күзлим,
ефәк пәрдә сыйпый битемне.
Һәрбер сурәт төштә күргән кебек –
безгә кәрван килмәс бит инде!

Сихри нурлар чәчкән кытат парча
чагып алды җанны җылытып.
Болгарымның затлы билбауларын
җиргә җәям озын юл итеп.

Кылкаланган дала кылганнары
кагылгандай була яңакка;
юмшан* исе аңкый әллә кайдан –
карангалап куям ян-якка.

Бозлы таулар тынын бөркеп тора
өленгенең көмеш җепләре.
Кызыл малга ничек сеңми калсын
хәтәр үткелләрнең җил-кары.

Йөзгә йомшак кына тиеп китә
ефәк пәрдәләрнең дулкыны.
Дымык күзгә кереп тулыр төсле
утлы көлдәй кызган чүл комы...

Сабый сыман офык чиген күзлим,
нидер көтеп – кәрван юк һаман.

* Юмшан – әремнең бер төре.

Аңышмастан илләр адашканда,
фөрьяд кылыр соңгы юламан.

Сатулашу дөнья сәхнәсендә
яулый бара яңа ярлыклар.
Ефәк пәрдә төшкәч дәвам иткән
уеннарда ачы гарьлек бар.

Ишетелә елан ышылдавы,
«Ау!» – дип аваз сала таш санәм...
Нигә әле шулай эчтән сызып,
көпә-көндез өндә төшләнәм?!

Сахраларда сусап саташкандай,
тоя башлыйм кан-яшь тәмен дә;
ярам теккән ефәк җепләр, имеш,
кыймылдашып ала тәнемдә...

Тәрәз аша олы юлны күзлим,
тузганакның башын җил кисә.
Пәрдәләргә орнып хушланырга
исәпләгән идем югыйсә.

## Чүп-чар тавы

Ничек инде гамьсез килеш калып булсын,
мәгыйшәтнең серләренә орын да.
Ачыш ясар кыяфәттә басып торам
көне-төне чүплек янган урында.

Ачы сөрем, утлы ташкын, шомлы күкрәү...
Яңа дөнья яралгандай тоела.
Уйчан күңел нигә шулай зурлап тиңли –
чынлап баксаң, монда пәри туе ла.

Алагаем ала-кола албастының
авызында тимер эреп, таш яна!..
Өтәсләнгән чүплек тавы итәгендә
җитмеш төрле әйбер күзгә ташлана.

Каткан күмәч, ертык әләм, дога бите,
шәрә курчак, зәһәр шешә бөкесе...
Культуралы катламнарда күтәрелгән
пычрагына батып бара бу кеше.

Яралгысын калдык-постык әрҗәсенә
ташлаучыга ничек өмет баглыйсың?!
Эссе кабар хәлгә килгән Җиргә дәшәм:
«Чәчәк атып яши алыр багмы син?»

Күпне күргән Идел-йортта озак еллар
чүп өстенә чүмәләләр өелгән...

Аста калган хуш ис бөркер яшел болын
гөлләр көтеп ята кебек ил-көннән.

...Көне-төне чүплек тавы янган төштә
чияләнде башымдагы бар уем.
Яңа дөнья яралуын күрдем монда,
ах, юк, сиздем Җирнең сызып баруын.

## Тамчылар төрлелеге

*Без сезне юк дәрәҗәсендәге сыеклык*
*тамчысыннан (орлыктан) яралтмадыкмы?*
Коръән, 77: 20

Ике тамчы кебек тәңгәл, диеп
әйтмә, телмәр, сүзең бар чакта.
Берәмтекләп кара бөртекләрен –
тыңдәшлекне сөйми борчак та.

Өлгең үзгәрт, акын, чынлык мөһим
купшы мәдхияләр җырлауда.
Хәл-халәтне ничек калыплыйсың?!
Төрле мәгънә ала елау да.

Хәсрәт ташы мәрмәр ташны тишә,
шатлык яше җанны эретә,
ә җан тире кемнән куркак ясый,
кемне гаярьләнгән ир итә.

Балдай тамган мәлдә чәчәк суты,
рия чәчрәп чыга кайманда*.
Каләм очын юар кара тамчы
кайчак өстен тора каннан да.

Җирне игез затлар басып алса –
гөман кылчы, хәким, чак кына.
Җем-җем килгән таңгы тетрек чыкта
дөнья чуар булып чагыла.

Күңеленә күкләр күндергәнне
үзенчәрәк ача бар иш тә.
Гамәлләрне шагыйрь галәмедәй
чачак-чуклап язмас фәрештә.

Ике тамчы кебек тәңгәл, имеш...

## Өстен калу

*Р.Я.ны искә алып*

Үзгәрергә теләп, үз-үземә:
«Аның чистарасы юк», – дидем.
Мөселманча госел коенгандай,
антлар эчеп махсус юындым.

* Кайман, ягъни крокодил күз яше истә тотыла. *(Автор.)*

Пычрак аткан мәңгә әйтеп килдем:
«Соңгы төкерегең чәч миңа!..»
Башны якты уйлар биләп торсын –
эркет суын койдым чәчемә.

Төрле янау җиле сеңгән йөзгә
бик сак кына баллы тоз яктым.
Ногыт оны белән озак итеп
һәрбер тырнак астын тазарттым.

Кирле-мырлы уен керләндерде –
дегетлесен алдым сабынның...
Аруландым шулай иренмичә,
гүя пакьлек аңкыр сабый мин.

Хәзер исә эшчән чиста кулым
сөткә манып яза каләмен.
Сәясәткә бүтән кагылмыйча,
инде биектәрәк каламын.

## Кочаклау

Үчле кеше күкрәгендә яши зәһәр көч саклап,
ниләр генә кылмый ханжа, безне дустай кочаклап.

Ике кулын җәеп атлый, үзе шундый очына;
көлемсерәп исәнләшкәч, тибеп китә эчеңә.

Кочкан саен җанга газиз күлмәгеңдә тап кала,
ах, пәйгамбәр чәчәкләре монафикътан таптала!

Күрешүче фарисейның бугазында үт тора;
кочаклаган кыяфәттә ул... буып та үтерә.

Зәнки затның күңелендә шиксез ялган ант ятар,
кочкан чакта керле җиңнән килеп чыга алтатар.

Кара уйлар уйнап торган кару тулы кочакта
үзен бәйсез итеп тоя канга сусар пычак та.

...Тукта, каләм, мәэюсләнеп, кәгазь битен кашыма –
әле генә тәпи баскан онык килә каршыма!..

## Вәгазь

«Төкерәм!» – дип, төксе җикерендең,
күңелемә капыл шик килде:
баштанаяк бакчы көндәшеңә –
селәгәең җитмәс шикелле.

Кабахәтлек нинди кабыкларга
төрми икән адәм кәмәшен?!

Сукыр черки кебек кермә күзгә,
чүпкә әйләндерер кан-яшем.

Әгәр миңа нәҗес кара ягып,
ишетмәкче булсаң аһ-зарым, –
каләмемне манып дегетеңә,
сиңа... шигъри вәгазь язармын.

## Ашау

Безгә сырхау тамак аша керә,
тәнгә бик күп тәгам килешми.
Нәфес корты зәһәр йоткан мәлдә
күңел кошы укшып гөл исни.

Берәүләргә баллы ярамыйдыр,
икенчеләр сөйми ачыны.
Иблис сыен гына сорап тора
китмәс хәстәлекнең ач җене.

Җанга ятмас ризык канны бозар,
хәрәм азык тартыр языкка.
Мондый чакта ярдәм итеп булмас
дәва күрсәтмәсе язып та.

Нинди генә сырхау килми икән
бары тамак өчен яшәүдән?!
Безнең төп чир куәт ала төсле
татар башын татар ашаудан.

## Аһәңдәшлек

Оркестрның сихри аһәңеннән
йөрәк ялкынланып, җан эри.
Тәмам оеп тыңлый моңчан халык –
Шопен музыкасы яңгырый.

Залда хушлык тулып ашкан мәлдә
син йөткереп куйдың сак кына.
Ошбу тыйнак ютәл туры килде
көйнең салмак аккан чагына.

Килештереп тамак кыруыңны
һәммә кеше ачык ишетте.
Сөбханалла, синең өн-авазны,
ахры, ноталар да иш итте.

Яңгырашның тоеп ятышлыгын,
хәтта күңелемә шик керде, –
композитор шушы йөткерүне
махсус бизәп язган шикелле.

Әсәрләндем сәер унисонга,
сиздем тәндә янар тау көчен!..
Инде синсез кабат тыңлый алмам
мәшһүр «Шопениана» тавышын.

## Ахырзаман галәмәте

Көчтер иргә канат куйган,
үчтер җиргә кан-яшь койган...

Япан кырда күккә багып,
яшь-җилкенчәк киңәш даулый:
«Кистерикче канатларны –
шуышырга комачаулый».

*

Теле барлар халык булган,
теле юклар балык булган...

Изге нигъмәт җуелганда
тешләү өчен ирен кирәк.
Көнләр хәлгә җитте милләт:
«Балык заты иреклерәк».

*

Ямь-тәм аслы төрлелектә,
җан-тән аслы тик берлектә...

Ә тән җанга шелтә ташлый:
«...Килә сөттә коенасым;
тынмас холкың аркасында
гомер буе кыен ашыйм».

## Җәза

Җанны тырнар андый җәза барын
шайтан колагына кем әйткән?
Кулдан төшмәс ап-ак кәгазь бите
бармагымны кисте кинәттән.

Үз-үземне белми өзгәләндем,
чынлап өнсез калдым беравык.
Канлы яуда алган насыйп яра
сызлар иде микән болай ук.

Әрле-бирле йөрткән әрнүләргә
вөҗдан сыкрануы өстәлде.
Төрле әмәл табар язмыш ханым
нигә әле шулай үч алды?!

Кичекмәстән ачы кисәтергә
теләгәндер миндәй кылтымны.
Иман нуры сеңгән кәгазь йөзен
пычратырлык гөнаһ кылдыммы?!

Каныккандыр, бәлки, күңелемнән
түгелмичә калган шигырьләр.
Очраклыга санап юаныйммы –
кырыкмаса кырык шигем бар.

Ишарәле гөнаһ шомлыгына
каршы тору юлын кем тапкан?!
...Кулдан төшмәс ап-ак кәгазь бите
бармагымны кисте кинәттән...

Рабит
Батулла

# ИЛБАШЫ

**Шәкерт**

Татарстан тирәсендә мәкерле гамәлләр, астыртын эшләр башланды. Илбашыбыз белән киңәш-табыш итмичә, ракеталарны Татарстаннан ашыгыч рәвештә алып чыгып киттеләр. Димәк, бу ракеталар башка өлкә, республикаларга чыгып, Татарстанга төбәп куелачак. Ярый, без беркем белән дә сугышырга җыенмыйбыз, алсыннар ракеталарын! Ләкин ракеталар өстенә ике танк дивизиясен Татарстан чикләренә китереп куйдылар бит әле. Ни өчен?

Сәясәтчеләр арасында Татарстан турында өзлексез имеш-мимеш тараттылар, имештер, Татарстан Казанны саклау өчен су асты көймәсе әзерли икән, диделәр. Ул вакытта Идел буе хәрби округы белән генерал Макашов идарә итә, Казанга һөҗүм итәр өчен бөтен нәрсә әзерләнгән иде. Ләкин һөҗүм булмый калды, шөкер. Ельцин бу ахмаклыкны тыйган булып чыкты.

Кем белә, әлеге гамәлләр, бәлки, Шәймиевне шүрләтер өчен генә дә кылынгандыр. Ихтимал. Мари Илендәге хәрби уеннардан куркып, бәлки, Шәймиев Татарстанда референдум уздырмас дип тә уйлаганнардыр. Әмма алар ялгышты. Инде дә булмагач, Шәймиевне үгетләргә Фикрәт Табиевны ризалаттылар.

Минтимер Шәймиев Фикрәт Табиевка үзгә-аерым мөнәсәбәттә була килде. Табиевның да Шәймиевкә мөнәсәбәте бик уңай, йогынтысы да гаять куәтле иде. Сәнәгать өлкәсендәге эреле-ваклы җитәкчеләр Табиевның күз карашыннан ук калтырап тора иде. Әмма никадәр генә кырыс булмасын, Фикрәт Табиев эш майтарган, сүзендә торган шәхесләрне күтәрә белә, аларның күңелен үстерә, хәтта кайбер ялгышларын да кичерә торган иде. Гайрәтле җитәкчеләрне ул хөрмәт итә, аларны кирәк чакта мактый, бүләкли иде. Ниндидер күләмдә Табиев шәхесендә Пётр Беренче, Сталин холкы да чагыла иде. Ул Шәймиевне эш оештыра белгәне өчен хөрмәт итте. Шәймиевкә исә Табиевның кырыс-таләпчән җитәкче булуы ошый иде.

Татарстанда узачак референдум турында сөйләшер өчен, Шәймиевне Мәскәүгә чакыртып алдылар. Дөресрәге, ул чактагы вице-премьер, Дәүләт хокук идарәсе башлыгы Сергей Шахрай арадашчылыгында Табиев белән Шәймиевне очраштыру оештырылган иде.

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

Шәймиевне каршы алырга Казан вокзалына Табиев үзе килгән иде. Аны вокзалда күргәч, Минтимер Шәрипович бераз каушабрак та калды. Ни әйтсәң дә, Табиев озак еллар Татарстанда олы җитәкче булды, аның Шәймиев алдында да, Татарстанда да абруе зур иде. Димәк, сөйләшү җитди булырга охшаган.

Чыннан да, Шахрай белән Табиевның максаты ап-ачык иде:

– Шәймиев Татарстанда референдумны уздырмаска тиеш!

Минтимер Шәрипович сабыр гына әйтеп куйды:

– Референдум игълан ителде бит инде! – диде.

– А ты отмени! – диде Табиев. – Всё же в твоих руках!

– Ә демократия, Фикрәт Әхмәтҗанович? Халык белән керделе-чыктылы уйнарга ярамый.

Тарткалаш озакка сузылды, Шахрай да, Табиев та Мәскәү Кремле сүзен сөйли һәм алар шулай сөйләргә мәҗбүр дә иде. Шәймиев яхшы аңлады: болар референдумнан курыкмый, ә Татарстанның Россиядән бөтенләй аерылып чыгуыннан шүрли. Гәрчә көн тәртибенә андый катгый мәсьәлә куелмаса да. Татарстан бары тик союздаш республика хокукларына гына дәгъва итә. Россиядә яшәүче бөтен халыкларның тигез хокуклылыгын яклый. Чын федерация идеясен алга сөрә. Яңа Огарёво җыены да шул тарафка юнәлтелгән иде бит югыйсә. Кайбер җитәкчеләр, автономиялеләргә әйтмичә генә, Союз килешүеннән соң алар белән ни кылырга дип фикер алышкан, ягъни автономиялеләр элеккеге шартларда калачак булып чыга. Менә ни өчен Татарстанда референдум уздыру бик кирәк, хәтта мәҗбүри иде!

Ихтимал, Шахрайның бар теләге, Табиевның абруена аркаланып, Шәймиевне референдум үткәрүдән ваз кичтереп, җитәкләшеп, Борис Ельцин янына кереп, зур җиңүне бәйрәм итү булгандыр. Алар алмаш-тилмәш, гел бер сүзне кабатлап, Шәймиевне нык үгетләде. Әмма Минтимер Шәрипович каты торды, аның бу мәсьәләдә хәтта икеләнүләре дә булмады: референдум узарга тиеш. Соңгы чиктә ул салмак, әмма нык тавыш белән әйтте:

– Нигә сез референдумнан куркасыз? – диде. – Сез бит демократиягә каршы түгелдер, Конституциягә дә каршы түгелдер, мөгаен?

Шәймиевне күндерүнең мөмкин түгеллеген аңлагач, барысы да тынып калды. Табиев үзенең элеккеге буйсынарына озак кына текәлеп, гаҗәпсенеп карап торды: ул каршысында йомшак холыклы, буйсынучан Шәймиев түгел, нык ихтыярлы, көчле рухлы олы җитәкче торуын аңлады һәм әйтә куйды:

– Упёртым ты стал, Минтимер Шаймиев!

– Мин – сезнең шәкертегез! – диде Шәймиев, аннары Шахрай да аңласын өчен урысча да өстәп куйды: – Я же ваш ученик, Фикрат Ахметзянович!

## Яһүд Гурион белән татар Шәймиев

Журналист Лев Овруцкийга бер сорау:

– Сез Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев эшчәнлегенә нинди бәя бирер идегез?

Овруцкий. Татарстанның Беренче Президентының ике тарихи казанышы бар. Беренчедән, ул Россиядәге федераль революциянең башында торды. Икенчедән, яһүд милләтенә Бен Гурион ни эшләгән булса, Шәймиев татарлар өчен шундый ук эшне башкарды: ул татарларга үз милләтен хөрмәт итү хисен кайтарды. Бу казанышларның берсен дә инкяр итеп булмый... Һәм шуларга ике зур проектны – Болгар белән Свияжскины өстәр идем. Өстәвенә,

үз халкың белән горурлану хисеннән тыш, Шәймиев татарларга карата бөтен җиһанның, бөтен инсаниятнең хөрмәтен дә кире кайтарды...

Әйе, Илбашыбыз Минтимер Шәймиевнең халыкара сәясәт мәйданында абруе үскәннән-үсә барды. Әллә соң Минтимернең тууы фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килдеме? Гап-гади инженер булып тугыз ай эшләгәч тә, аны үстерделәр, һич тоткарлыксыз, җәнҗалсыз, кешеләр белән бозылышмыйча, министр, обком секретаре, Илбашы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелүе бер могҗиза кебек тиз булды. Химаячесез, туган-тумачасыз, башлыклар алдында тәлинкә тотмыйча, ничек шундый дәрәҗәләргә ирешеп була икән? Шулай ансат кына күтәрелеп, ансат кына җимерелеп төшкән түрәләрне дә тарих яхшы хәтерли.

Акыллы җитәкче иң шөһрәтле вакытында үзе теләп тәхеттән китәргә тиеш. Тарихның сабагы юк бит аның. Ә күпләр түрә булып ала да мәңге шунда утырырмын дип ялгыша.

Минтимер, үзенең аек зиһене белән, бу мәсьәләне бик яхшы аңлый иде. Шуңа күрә ул үзенә алмаш әзерли килде һәм 2005 елда ук Россия Президенты алдына, Татарстан Президенты вазифаларыннан азат итүен сорап, мәсьәләне кабыргасы белән куйган иде. Кайсы шәхеснең үзен тәхеттән алуларын үтенеп гариза язганы бар? Кайсы шәхеснең үзе теләп хакимияттән баш тартканы бар?

Шул сәбәпле Минтимернең Илбашы булудан үз теләге белән китәргә теләвенә кайберәүләр ышанмады: уйный, бәясен күтәрә, оригинальничать итә, диделәр. Уйнау, оригинальничать итү Минтимернең табигатендә, холкында юк. Аңа табигыйлек хас.

Ул вакытта бөтен республикалар да үз конституцияләрендәге Президент сайлау турындагы маддәне юкка чыгарды, ә Татарстан ул маддәдән ваз кичмәде, вакытлыча гына туктатып торды.

Шәймиев, әлеге мәсьәләне хәл итәр өчен, Путин белән күзгә-күз очрашып сөйләшергә булды. Путин аны бик теләп каршы алды шикелле.

– Владимир Владимирович! – диде Минтимер Шәймиев. – Менә мине һәрвакыт сайлап куя торганнар иде. Бу мәсьәләдә мин каршылыкларга очрамадым. Халык мине ничек бар, шулай кабул итә. Мин һәрвакыт үз республикамда эшләдем һәм Татарстан халкының миңа булган мөнәсәбәте белән горурланам, ә нигә әле мине хәзер өстән билгеләргә тиешләр? Ни өчен мин хәзер, халык сайлауларыннан курыкканнар белән беррәттән, өстән билгеләнергә тиеш?

Путин аны дикъкать белән тыңлады, аннан соң үгетләгәндәй әйтә куйды:

– Минтимер Шәрипович, зинһар, өстән билгеләнергә ризалыгыгыз турында гариза языгыз, – диде. – Сез безгә бик кирәк, сез Татарстанга кирәк, үтенеп сорыйм, зинһар, өстән билгеләнергә риза булыгыз. Барыгыз, хәзер журналистлар каршысына чыгып, Президент үзе үтенде, дип әйтегез һәм ризалыгыгызны белдерегез...

Татарстан Республикасы Президенты буларак, дүртенче тапкыр Татарстан халкына һәм Татарстан Конституциясенә тугры булырга ант итте. 2005 елда Минтимер Шәймиев, Татарстан Президенты буларак, халык тарафыннан сайланып куелды. Һәм ул Илбашы вазифаларын 2010 елга кадәр тайпылышсыз башкарды.

Чыннан да, Шәймиевнең Президентлыктан китүенә 2010 елда да күпләр ышанмады: кем инде үз теләге белән властьтан китсен, диделәр.

Минтимер Шәрипович киеренке рәвештә уйланды, мәсьәләнең алдын да, артын да, ян-якларын да җентекләп тикшерде. Кемгә калдырып китәчәк ул Илбашының урынын?

Шөкер, Татарстанда сайлап алырлык шәхесләр бар! Ләкин тәхет тирәсендә борын-борыннан астыртын эшләр була килде. Астыртын эшләр өскә чыгып, халыкка ничек тәэсир итәсен дә Шәймиев чамалый иде. Аның идарәдән ваз кичүе аппаратта көтелмәгән каршылыклар китереп чыгарырга мөмкин. Ходаем сакласын! Бу үзгәрешне җәмгыять тыныч, табигый кабул итәргә тиеш. Кандидатлар да үзара дуслык-иптәшлек мохитеннән читкә чыкмаска тиеш. Аларны психологик яктан да, рәсми мөнәсәбәтләр җәһәтеннән дә әзерләргә кирәк. Алар бер-берсенә көндәш булмасын иде.

Шәймиевнең Татарстан Президенты урыныннан китәргә ныклы карар кылганына Русиянең сәясәт мәйданында абруй казанган олы шәхесләр дә ышанмады. Нигә, ни өчен? Дөреслекне белгәч, алар аптырап калды һәм бу эшне кылмаска, тагын бер срокка идарәдә калырга үгетли башлады. Үгетләүчеләр арасында Путин, Медведев, Сурковларның булуы Шәймиевнең бик тә югары абруе турында сөйли иде.

Минтимер Шәриповичның карары нык һәм нигезле иде. Табигый ки, ул олыгаеп та китте. Ә җитәкчеләрнең уртача яше отыры яшәрүгә таба бара. Үҗәт, эшне тамырыннан белүче яшьләр килә идарәгә. Аннан соң шактый арылды да. Чыннан да, Илбашының ничек талчыкканын ике генә кеше белә иде: хатыны Сәкинә ханым белән Минтимер үзе. Олы-олы мәшәкатьләрдән арынып, гаиләдә дә ешрак буласы килә иде аның. Тугарылып бер ял итәсе дә килә: сөекле эте Маһмай белән ауга чыгасы, балыкка йөрисе, туйганчы йөзәсе, болыннарда ауныйсы, урманнарга барып, чыршы-нарат төпләрендә, Тукай әйтмешли, хәл җыеп, күккә карап истирахәт кыласы килә иде...

Шулай да Минтимер Шәймиевкә Президент постын калдырып китү җиңел булгандыр дип уйламыйм. Чөнки халык аңа һәрчак теләктәш булды, үзе дә гамәленең халыкка, милләткә кирәклеген аңлап, бар тырышлыгын куеп эш майтарды. Кеше үз эшенең остасы булса, аңа яшәве дә рәхәт, үз эшенең остасын бер кеше дә ачуланмый, чөнки ул вазифасын төгәл вә сыйфатлы итеп башкара. Минтимернең бәхете дә шундадыр, мөгаен: аның эшен өстәгеләр дә, халык та хуплый, ярата иде. Ул – үзенә йөкләнгән эшне сыйфатсыз башкарырга күнекмәгән шәхес. Бу – аның яшәү мәсләге. Аның иң сөймәгән кешесе – үз вазифасына туры килмәгән, үз вазифасын дөрес аңламаган, үз вазифасын эштер-өштер генә, миннән киткәнче, иясенә җиткәнче, дип кенә эшләүче.

Аннары яшьләр дә үкчәгә басып килә, аларга да юл сабарга кирәк. Бәлки, ул инде моннан ары Илбашы вазифаларын яшьрәк вакытындагы кебек сыйфатлы итеп башкара да алмас, ни дисәң дә җитмеш өч яшь. Әйтик, эш башында калган тәкъдирдә, аңарда Рөстәм Миңнехановтагы кебек гайрәт, җитезлек, эшкә алгысып тору дәрте булырмы?

Президент Дмитрий Медведев Шәймиевкә турыдан-туры әйтте:

– Минтимер Шәрипович! Үзегезнең урынга каласы кешенең исемен әйтсәгез, Татарстан Президенты шул кеше булачак! Бу бары тик сездән генә тора! – диде.

Нинди ышаныч, нинди хөрмәт Илбашына!

– Рөстәм Нургали улы Миңнеханов! – диде ул.

Һәм ул хаклы булып чыкты! Илбашының үз сүзе белән әйткәнчә, без бит суга ыргытылган таш кузгаткан түгәрәк дулкыннарны гына күрәбез, ә су төбендә энҗе ятканын күрмибез.

Башка кандидатлар белән бүгенге Илбашыбыз Рөстәм Миңнехановның кулга-кул тотынышып уңышлы эшләве Минтимер Шәймиевнең зиһене төбендә энҗе ятканы турында сөйләмимени!

## Төп сәбәп

Күпкырлы вазифалар башкарыр өчен, Илбашына акыл да, хәйлә дә, үзсүзлелек тә, кай очракларда килешүчәнлек тә, сәясәтче-дипломат булу да бик кирәк.

Илбашының тормышында шатлыкларга, бәйрәмнәргә караганда бимазалы, мәшәкатьле чаклар күбрәк буладыр, шиксез. Ил белән идарә итү ул – йокысыз төннәр, җиде кат кына түгел, кырык кат үлчәүләр, шикләнүләр, хәтта шомланулар белән тулы. Ил белән идарә итү ул – шахмат уены. Фигураларны күчерер алдыннан, йөзләгән вариантларны барлап чыгу зарур.

Минтимер Шәймиев үзе дә чын шахматчы. Ул җиңелүгә дә, җиңүгә дә иммунитетлы кеше. Җиңелсә, кара көймәс, җиңсә, җиңелгән кешенең ачуын китереп, артыгын шатланмас. Җиңсә дә, җиңелсә дә, ул көндәшенә ихластан рәхмәт әйтер.

Кешеләр тарафыннан, бигрәк тә зыялылар ягыннан, обком секретаре вазифаларын башкарган чакта да, Илбашы итеп сайлангач та, Шәймиевкә тәнкыйтьләр, хәтта рәнҗетердәй сүзләр дә күп булды. Бу – табигый хәл. Аны заманында партия функционеры буларак кына кабул итәләр иде. Халык мәйданга чыкмаса, эндәшми калса, ул, бәлки, үзеннән алда эшләп киткән «партбосслар» юлыннан да киткән булыр иде. Әмма тәнкыйтьчеләргә, аңа каршы чыккан шәхесләргә Шәймиев үпкә-сапка сакламады, гәрчә үзен «татар җанлы» булмауда гаепләгәннәр аның күңелендә әче юшкын калдырган иде. Үз халкыңнан җан җәрәхәте алу җәһәннәм газабына тиңдер. Без су төбендәге энҗене күреп җиткермәгәнбез шул. Ничек инде Минтимер Шәрип улы Шәймиев, саф татар авылында туып үскән, саф татарча белем алган, татар китапларын укып рухи баеган кеше, татарга каршы гамәл кылсын ди?

Дөресен әйткәндә, Татарстан АССР төзелгәннән алып (Мулланур Вахитов, Минтимер Шәймиев, Рөстәм Миңнехановтан кала) безнең үз туфрагыбызда туып үскән, татар йолаларында тәрбия алган җитәкчеләребез булмады дип әйтерлек. Һәм бу хәл татарның тарих фәненә, мәдәниятенә тискәре йогынты ясады. Обком секретарьлары, министрлар сәхнәгә чыгып (хәтта мәгариф, мәдәният министрлары), радио-телевидениедән ана телендә сөйләргә курка, ояла яки татарча бөтенләй белми иде. Ә инде башлыклар да ана телен инкяр иткәч, бүтәннәр нишләсен?

Болар барысы да – Минтимер Шәймиевнең күз алдында булган хәлләр. Аның зиһенендә бу мәсьәләләр үз кардиограммасын сыза килде.

...Бервакыт Илбашыбыз Санкт-Петербург шәһәрендә яшәүче татарлар белән очрашкан иде. Сөйләшү арасында олы яшьтәге бер татар кешесе латин язуына күчү турында аңа сорау бирде. Күрәсең, ул балачагында латин имлясындагы дәреслекләрдән белем алгандыр.

– Минтимер Шәрипович, миңа инде үләр вакыт җиткән, без кайчан латиницаны куллана башларбыз икән? – дигән иде ул.

Шәймиев әлеге сораудан югалып калды кебек. Ничек җавап бирергә бу зыялы агайга? Күчәргә ярамый, дисә, ул сорау биргән агайның кәефен кырыр иде.

Әлбәттә, Илбашы латин язуының ана телебезгә иң ярашлы икәнен дә бик яхшы аңлый. Анда барысы да кулай, сүзләрне дөрес әйтер өчен, ана телебезнең гүзәллеген күрсәтер өчен бөтен тамгалар да тулы. Бу турыда бәхәснең булуы мөмкин түгел. Әмма Илбашы буларак ни әйтсен? Чынлыкта ул латиницаны кабул итәргә риза түгел иде. Гәрчә зыялылар, тел галимнәре латиницага күчәр өчен бик каты әзерләнә, уртак алфавитны камилләштерә, җыелышлар уздыра. Барысы да «Яңалиф» латиницасын яклый. Хәтта Илбашының үз киңәшчеләре дә латиница ягында иде.

Ярый, хуш, без латиницаны Татарстанда кабул да иттек, ди. Ә читтәге татарлар нишләр? Анда бит мәгариф системасы тулаем Россия кануннарына буйсына. Татарларның күпләп яшәгән урыны Россия бит. Федераль мәркәз латиницага каршы төшәчәк, бер генә губернатор да татарларның язуын латиницага күчерүгә кул куймаячак. Татарстан латин язуын кабул итсә, татарлар бер-берсеннән аерылачак, бүлгәләнеп бетәчәк. Татарстан читтә яшәүче миллионлаган татарлардан үзен аерып куячак. Илбашына латиница бик тә ошый, әмма сыкрап-сызланып булса да, ул бу эшкә кул куймаячак. Болай да татарларны бүлгәләү эше шактый актив алып барыла: мишәрләргә, керәшеннәргә, типтәрләргә, нугайларга, болгарларга, тагын әллә кемнәргә аерылырга котыртучылар бар. Хәзер инде «латиница» мәсьәләсе калкып чыкты. Бу да болгатучыларның тегермәненә су коя. Юк! Аеры-чөере килеп бетмәс өчен, латин язуы көн тәртибендә тормаска тиеш.

Ул шулай булып чыкты да: Мәскәү татарларга латин әлифбасын куллануны тыйды. Тыюның сылтавы – имеш, татарлар латиницаны кабул итсә, бу гамәл Россиянең бердәмлегенә зыян салачак икән.

Мантыйкый фикер йөртсәк, әлеге сылтау ишелә дә төшә. Россия составында яшәүче татарлар мең елдан артык гарәп имлясын кулланган, гарәп хәрефләре аркасында Россия таркалмаган-җимерелмәгән, көчәя генә барган. Татарлар совет чорында латиницага күчкән, татарлар латиница куллана башлады дип, СССР да таркалмаган, киресенчә, ныгый гына барган. Кыскасы, татарларга кабат латиницаны куллланудан тыйган фәрманның сылтавы нигезсез, мантыйксыз иде. Татар язучыларына нинди имля белән язарга кирәклеген Мәскәү түгел, ә Татарстан җитәкчесе белән татарлар үзләре хәл итәргә тиеш иде...

Оптимальләштерү шартларында Татарстаннан читтәге төбәкләрдә татар мәктәпләрен саклап калу да – бик кыен-катлаулы мәсьәлә. Ярый әле, Татарстан татар авылларындагы мәктәпләрдә ана телен укытуны, нигездә, саклап кала алды. Аз балалы мәктәптә бер укытучы дүрт сыйныфка дәрес бирә. Әгәр дә татар мәктәпләрен саклап каласыбыз, ана телен коткарасыбыз килсә, оптимальләштерү белән мавыкмаска кирәк!

Күп кенә регионнар белән чагыштырганда, Татарстан укучылары рус теле буенча БДИны чагыштырмача яхшы тапшырып килә. Шулай да, шатланганчы, иң элек бу турыда уйланырга кирәк. Татарстан укытучылары балаларны сыйфатлырак укытамы? Әллә соң Татарстан укучылары башлыракмы? Ай-һай, кодагый, шигем бар. Димәк ки, аларның имтихан алучылары яхшы... Бәлки, ана телебезгә караганда рус теленә артык дәресләр бирелүнең нәтиҗәседер бу?

Дөрестән дә Татарстанда рус теленә дәресләр күбрәк бирелә, һәм рус теле сыйфатлырак укытыла. Юкса әле һаман зарланалар, имеш, рус теленә дәресләр аз бирелә, диләр. Әлбәттә, ике дәүләт теле дә тигез укытылырга тиеш! Белем бирү стандартларын әзерләүче федераль хезмәткәрләр бу тигезлекне сакламый. Шулай итеп мәгариф системасында аксаклык барлыкка килә. Гадәттә, бу аксаклык татар теле файдасына булмый.

Ә без бит, Татарстанда яшәүче башка милләт балалары да татар телен белсен, дибез. Бу – конституцион норма. Монда башка юлның булуы мөмкин түгел. Илбашының әлеге нормадан ваз кичәргә хакы юк. Тел – дәүләтчелекнең беренче билгесе.

Димәк, безгә телгә өйрәтүнең үтемле ысулларын эзләргә кирәк.

Бу мәсьәләдә журналист Лев Овруцкий бервакыт Минтимер Шәймиевне шактый кыен хәлгә дә куйган иде.

– Ә кем эзләргә тиеш соң ул ысулларны? – дигән иде ул.

– Без – татарлар! – диде Шәймиев.

– Ә нигә эзләмисез ул ысулларны? – диде Овруцкий. – Миңа калса, сез эзләргә дә теләмисез кебек. Әгәр кешеләр ул ысулларны табарга тели икән, алар белгечләрне үз янына туплый. Аның үз алымнары, ысуллары бар. Психологлар, тарихчылар, социологлар тупланырга тиеш, «түгәрәк өстәл» янында фикер алышулар, конференцияләр оештырылырга, шул турыда китаплар нәшер ителергә, мәсьәләне уртага салып, барысы турында да тәфсилле бәхәсләр кайнап торырга тиеш, халыкка, җәмәгатьчелеккә идеяләр ташларга, бу эшкә Интернетны җигәргә кирәк... Мин әлегә татар теле өчен җан атучылар хәрәкәтен сизмим, күрмим.

Шәймиевнең җавабы конкрет түгел иде, чынлыкта аның катгыян җавабы да юк иде шикелле.

– Шартлар тудырырга тырышабыз, – диде ул. – Ләкин нәтиҗәле хәрәкәт итәрлек ысулларын әлегә таба алганыбыз юк.

– Сәяси мәсьәлә алга куелган, – диде Овруцкий. – Сез әйттегез: ысулларын табарга кирәк, дидегез. Ә Фәннәр академиясе кайда? Пиар-агентлык кайда? Тупас кына әйткәндә, пиар өчен ул сабын сату белән бер. Татар телен сатыгыз! Сез аларга менә шулай дип әйтергә тиеш идегез. Татар телен һәйбәтләп төрегез дә сатыгыз!.. Татарстанда тел сагында торучы андый кешеләр юк, әйтик, Олжас Сөләйманов, Чыңгыз Айтматов кебек...

Шәймиев үзенә хас сабырлык белән журналистка каршы төште:

– Сезнең белән килешә алмыйм. Мин мәсьәләне ул кадәр үк артык гадиләштермәс идем, монда ансат юллар юк – мәсьәлә комплекслы хәл ителергә тиеш. Хәтта сез исемнәрен атаган берничә атаклы шәхес тә бу төенне чишә алмас иде.

– Эш нәрсәдә соң? – диде Овруцкий. – Президентка мөрәҗәгать итегез, галимнәрне, остазларны җыйсын, җыйсын да аларның алдына мәсьәләне кабыргасы белән куйсын!

– Мин инде элеккеге Президент, Лев Мирович!..

Овруцкий үзе мәсьәләне кабыргасы белән китереп куйды:

– Турысын әйтик, Минтимер Шәрипович, – диде ул. – Бу бит сез чишәргә тиешле мәсьәлә иде. Сез бу мәсьәләне үзеннән-үзе хәл ителер дип уйладыгыз, бәлки, сез иллюзиягә бирелгән булгансыздыр?

– Мин алгарышның башланганын һәм аның дәвам итүен күрдем, – диде Шәймиев.

– Әйе, беренче елларда алгарыш булды, һәм сез аны шулай үзеннән-үзе дәвам итәр дип уйладыгыз.

Минтимер Шәймиев беравык сүзсез торды һәм:

– Мин алгарыш үзеннән-үзе дәвам итәр, дип уйламый идем, – диде. – Татар телен өйрәтү өлкәсендә аерым механизмнар, үзгә ысуллар кирәк. Кабатлап әйтәм: алар табылачак, һәм ватандашлар татар телен беләчәк. Менә сез бая гына «ул хәрәкәтне күрмим, сизмим» дидегез... Ә чынлыкта, фикер алышу мәйданында, идеяләр ташлау, бәхәсләр мәсьәләсендә Интернетта бу процесс шактый кыза бара. Нигездә, ул бәхәсләр татар телендә бара. Минемчә, бу – табигый хәл. Кызганыч, электрон ресурсларда татарча фикер алышуларны һәм галимнәребезнең, социологларыбызның, тарихчыларыбызның, яшьләребезнең бу тема буенча күтәргән тәкъдимнәрен сез укый алмыйсыз... Ни өчен? Чөнки сез дәүләт теле булган татар телен белмисез... Бик күп халыклар бер дәүләттә

яшәгәндә, реаль милли сәясәт һәрвакыт актуаль була килде. Беләсезме, дәүләтнең бердәмлеге өчен иң куркынычы нәрсә? Әнә шул факторны бәяләп бетермәү. Реаль милли сәясәт!

Россия җитәкчеләренең, сәясәтчеләренең Илбашыбыз Минтимер Шәймиевкә булган теләктәшлеге, Татарстан халыкларының да аны хөрмәтләве, тагын бер срокка Илбашы булып калуын теләүләренә карамастан, ни өчен Минтимер Шәрип улы үз теләге белән хакимлектән баш тартты? Бу гамәлнең төп сәбәбе, сере нидә икән?

Моны ул бары үзе генә беләдер. Бүтәннәргә юрарга гына кала.

Россияне тигез хокуклы, чын федератив дәүләт итеп корабыз, дип күпме көрәшеп тә, өмет-ышанычның акланмавы этәрдеме аны бу адымга? Әллә, чыннан да, Шәймиевнең олыгаеп баруы, арыганлыгы сәбәпче булдымы? Әллә ул картлык көнен, чыннан да, гаиләсенең җылы учагы янында каршыларга җыендымы?

Юк шул. Шәймиев учак янына елышмады. Ул дәүләт белән идарә итүне үзенең шәкерте Рөстәм Миңнехановка тапшырып, яңа вазифага – Дәүләт Киңәшчесе вазифасына кереште.

Татарстан Президенты кәнәфиен калдырып китү мәсьәләсе хәл ителгәндә, Дмитрий Медведев киңәше белән, Владислав Сурков Шәймиевкә Мәскәүдә яхшы эш урыны тәкъдим итте. Ләкин Минтимер Шәрип улы, Сурковка тәкъдиме өчен рәхмәт әйтеп, аннан катгыян баш тартты. Шәймиевне заманында СССР мелиорация һәм су хуҗалыгы министры урынбасары итеп тә, тагын әллә кемнәр сыйфатында да Мәскәүгә чакырып карадылар, әмма ул гел баш тарта килде.

Шуннан соң Сурков, югары җитәкчелекнең кушуына күрә, тагын тәкъдим кертте:

– Алайса, сезнең өчен махсус урын – Дәүләт Секретаре вазифасы! – диде.

– Бу вазифаның атамасы артык купшы, артык кычкырып тора, аннан соң Дәүләт Секретаренең кеше күзенә күренми торган мәшәкатьләре дә бик күп... – диде Шәймиев.

Килештеләр: бу яңа вазифаның атамасы – Дәүләт Киңәшчесе булды.

Юк, ялга китмәде Минтимер Шәймиев, үзенә тагын эш тапты: бу гамәл дә аның яраткан шөгыленә, бөтен татар халкының, Татарстан халкының горурлыгына әйләнде. Ул, җиң сызганып, республикабызның йөзек кашына әйләнәчәк тарихи һәйкәлләрне торгызу эшенә кереште.

Аның җитәкчелегендә тарих, сәнгать, архитектура өлкәсендәге эзләнүләр һәм ул эзләнүләрнең нәтиҗәсе, Болгар, анда төзелгән Ак мәчет, Казандагы Кол Шәриф мәчете, Зөя каласы мәңгегә калачак.

Шулай ук бөтендөнья татарларының беренче корылтаен, Казанның 1000 еллыгын үткәрү дә халкыбыз тарихына алтын хәрефләр белән язылды.

## Нәрсә булды, Минтимер?

*Журналист Лев Овруцкийның «Минтимер Шәймиев белән әңгәмәләр» дигән китабыннан*

О в р у ц к и й . *Ещё две, с Вашего позволения, избирательные загадки – особенно, когда их ставишь рядом. Голосование за Ельцина в первом туре президентских выборов 1996 года и голосование за Путина в 2001-м. Получилось следующее. Ельцин говорит: берите столько суверенитета, сколько сумеете*

*проглотить. Он подписывает с вами Договор-94. Все в восторге, и Ельцин на гребне популярности. Но в 96-м Татарстан в первом туре голосует примерно одинаково и за Ельцина и за Зюганова. С другой стороны, Путин в 2001-м заявляет, что он против республиканских суверенитетов, он обещает вернуть всех в правовое поле России, но Татарстан огромным большинством голосует за Путина. Парадокс?*

Шаймиев. Я и сам удивился в 96-м году. Как Президент Татарстана, я недооценил эти выборы. Считал, что у нас Ельцин «на ура» пройдёт, победит уверенно. Даже не сомневался, а на следующий день Ельцин мне позвонил: «Минтимер, что случилось?» – он всегда так ко мне обращался. Я не ожидал. Чувствовалось, что он был поражён: неужели даже Шаймиев не поддержал? Мне тяжело было объясняться, но я сказал честно, Ельцин любил прямые ответы. «Борис Николаевич, я могу объяснить только одно – мы недооценили, были уверены, что у нас в Татарстане вообще не будет проблем, мы же знаем, что вы для нас сделали».

Овруцкий. *И неблагодарность какая-то получилась. И это не в Вашем стиле.*

Шаймиев. Как угодно называйте. Было стыдно. Что бы он ни сказал, я бы воспринял. Конечно, мы сделали выводы, во втором туре раскрутились.

Овруцкий. *И надавили прилично. Колоссальный был разрыв между первым и вторым турами. Я смотрел по районам. Татарская деревня в первом туре проголосовала за Зюганова. А во втором туре она вдруг проголосовала за Ельцина. И, конечно, все понимали, что это были первые нечестные выборы России. В 93-м были честные выборы, в 95-м были честные выборы в Думу, в 96-м – и в этом упрёк демократам – нечестные. Хотя у Карла Ясперса я встретил прекрасную спорную мысль: иногда надо жертвовать процедурами демократии – во имя самой демократии.*

Шаймиев. Вопрос судьбоносный решался. Или возвращаемся опять в коммунистический строй, или вперёд... У нас, наверное, был такой психологический момент. Договор был уже заключён, все в этом плане успокоились, а на первый план вышли экономические проблемы... Коммунисты говорили: вас ограбили, зарплаты не платят и так далее. Этот популизм имел успех в 96-м. Это было моим упущением. Шаймиев недооценил, так будем говорить. Мы были слишком уверены.

Овруцкий. *Ошибка Президента.*

Шаймиев. Да. Потом опомнились, и всё встало на место.

Овруцкий. *Поработали – две недели было до второго тура.*

Шаймиев. Поработали. И многие главы были удивлены, что не было грубого нажима с моей стороны.

Овруцкий. *А теперь пережали, надо бы немножко обратный ход дать.*

Шаймиев. Теперь урны прозрачные, камеры наблюдения – голосуйте, товарищ Овруцкий.

Овруцкий. *Я думаю, всё равно чиновники придумают что-нибудь.*

## Хәмер мәсьәләсе

Минтимер Шәймиевнең өскә күтәрелә баруы коммунистик режимның гөрләгән чагына, совет властеның иң куәтле дәверенә туры килде. Колхоз-совхозлар гөрли, нефть миллиардлап кына суыртыла, заводлар корыла, анда-

санда бөек төзелешләр барлыкка килә. Социалистик илләр белән дуслык шәп. Ләкин иң гаҗәбе шунда ки: шушы шау-шулы уңышлардан баш әйләнгән чагында, эчкечелек арта барды илдә. Бер генә бәйрәм дә, бер генә рәсми җыен да хәмерсез узмый торган иде. Дипломыңны ю, яңа костюм алгансың икән – аны ю, футбол-хоккей командаң җиңгән икән – аны бәйрәм ит. Балаң туган икән – атналар буе аның тәпиен ю. Кайгысын да, шатлыгын да хәмергә салып чайкый иде халык.

Ни гаҗәп, соңгы елларда эчкечелек күзгә күренеп кими башлады, шөкер. Бигрәк тә яшьләр эчми. Сабан туйларында да сугыштан соңгы чордагы кебек егылып эчүче, сугышучы юк.

Обкомнар вакытында партия җитәкчелегендә эчми кара! Бөтен кеше аракы чөмергәндә син генә эчми утырасың икән, димәк, син чирле яки әләкче.

Минтимер Шәймиевнең Минзәләдә «Сельхозтехника» директоры булып эшләгән чагы иде. Ул чагында Түбән Кама ГЭСы белән Түбән Кама Нефтехимы корыла башлаган вакыт. Бөтенсоюз төзелешләренең чәчәк аткан чоры! Ә машиналарга, тракторларга запас частьлар «Сельхозтехника» аша уза. Минтимер Шәймиев – төбәкара куәтле «Сельхозтехника»ның япь-яшь яңа директоры, бөтен запас частьлар – аның кулында. Шул ук вакытта яшь директор да кайбер нәрсәләргә кытлык кичерә: йә торбалар, йә металл әйберләр җитешми. Сөйләшә-килешә башлыйсың, ахырда эш барыбер шешәгә килеп төртелә. Шулай кирәктер, күрәсең, дип, Минтимер дә башкалар салган сукмактан барырга мәҗбүр иде. Шөкер, ул үз вакытында аңлады: бу – аның юлы түгел. Эчәргә кыстаган саен, яшь җитәкче хәйләли башлады. Шуннан соң аны мәҗлесләрдә кыстамый башладылар: янәсе, аның фәлән җире авырта, аңа эчәргә ярамый. Юк, ул үзе тимер кебек нык, әмма хәмердән башкача котылыр чара юк иде. Бу афәттән котылыр өчен, ул «чирләшкә» булырга да риза иде. Гөнаһсыз ялган – шулдыр инде ул!

Обкомга эшкә күчкәч тә, Министрлар Советында эшләгәндә дә, барысы да белә иде: Шәймиевне кыстарга ярамый. Бетте-китте! Үзеңне ничек куясың бит?!

Аның нәселендә хәмер эчкән кеше булмады.

Ил өстенә килгән сәрхушлек афәтеннән Минтимер әнә шулай котылып калды. Ә ул афәт күпме булдыклы кешеләрне үзе белән алып китте.

Минтимер, егерме биш яшендә директор булып алгач, Минзәлә «Сельхозтехника»сында 1962 елда ук «коры закон» кертте. Һәм аның нәтиҗәсе дә күзгә күренде. Эшче-белгечләрнең хатыннары, рәхмәт әйтергә дип, директор янына агыла башлады. Иң мөһиме: эчкече ирләр хатыннарына да, бу «коры закон»ны чыгарган җитәкчегә дә үпкәләмәде. Димәк, ирләр үзләре дә хәмердән ничек итеп котылырга белми йөргән, кемдер килеп аларны айнытыр дип көтеп яткан.

Ягулык аппаратын, гидронасос, электр җиһазларын көйләү буенча осталар сирәк була, «Сельхозтехника»да да аларны санау өчен өч бармак җитә. Бөтен төбәгенә – шул өч-дүрт мастер. Уникаль белгечлек. Аларны анда чакыралар, монда чакыралар, машина төзәттерергә чират торалар. Абруй бар, үзләрен әллә кемгә куючылар да юк түгел, аларга еш кына ялынырга, мәгәрич куярга кирәк була торган иде. Кайберләре атналар буе эчеп ята, әмма эштән дә куып булмый, чөнки куллары алтын. Аларны эштән кусаң, ике кулсыз каласың. Димәк, син дә сәрхушлекне яклаучы булып чыгасың! Сәрхушлекне якларга түгел, якаларга кирәк! Ә ничек якаларга? Шәймиев ысулы белән!

Андый осталар үзенә күрә өстенлекле катлау иде инде.

Минтимер эчкечеләрне эштән чыгармады, артык кырыс ысуллар да кулланмады, әмма коллектив сафланды,囲эштә тәртип урнашты. Хатыннар да, балалар да бәхетле иде.

## Җимерелү

Моннан егерме биш-утыз еллар элек Советлар Союзының таркалачагы, коммунистик режимның җимереләчәге турында сүз әйткән кешене шундук зинданга ябып куярлар яки юләрләр йортына олактырырлар иде.

Коммунизмга ихлас ышанган кеше өчен бу җимерелеш – фаҗига. Гомерең буе парторг, райком секретаре, обком секретаре, комиссар булып, ертылаертыла кычкырып, утны-суларны кичеп, коммунизм идеясе өчен кан коеп, гөнаһсыз җаннарны кыеп та, бер сәгать эчендә синең хыялың, киләчәккә өметең юкка чыксын әле! Моннан да олы бәхетсезлекнең булуы мөмкинме?

Карьера өчен генә коммунист булып, коммунизм идеяләренә ышанмыйча гына партиягә кереп өскә үрләгәннәрнең бу җимерелешкә әллә ни исе китмәде бугай. Алар партбилетларын тиз генә сандык төбенә яшереп, тагын да шул төшемле урыннарга кереп оялады.

Үзгәртеп кору (халык арасында бу гамәлне «үзгәртеп кыру» дип тә атыйлар) үзе дә өстән башланды бит. Барысы да хакимият кулында иде: реформалар ясаргамы, әллә юкмы?

Карагыз сез, Кытай ничек үсә! Озакламый бу дәүләтнең нинди иҗтимагый корылышта икәнен дә аера алмабыз, шәт. Кичәге капиталистик илләрне инде «капиталистик» дип атап та булмый. Бөтен дөнья үзгәрештә. Без «капиталистик» дип атаган илләрнең иҗтимагый төзелеше отыры «социалистик»ка охшый бара.

Яңартылган Союзны саклап калып була иде әле. Ләкин без ул форсатны кулдан ычкындырдык, бәс, алга таба вакыйгалар ничек алмашыныр иде икән, әйтүе кыен. Шулай килеп чыкты ки: СССРның җимерелүе социализмның һәлак булуына китерде.

Ул вакытта (1991 елда) СССР Конституциясенә үзгәрешләр кертелгән иде. СССР халык депутатлары корылтае Минтимер Шәймиевнең тәкъдимен кабул итте. СССР Президенты катнашында Яңа Огарёвода яңа Союз килешүенең текстын әзерләү өчен көн-төн тырыштылар, һәм Шартнамә нигездә расланды. Бөтен союздашлар да бу текстны яклап кул куйды, бары тик Украина гына имза салмады. Кравчук әйтте:

– Минем бу документка кул куярга вәкаләтем юк. Көз көне парламент эшли башлагач хәл итәрбез! – диде.

Минтимер Шәймиев яңа Союз килешүенә имза салды, ләкин бер шарт белән.

Килешү нигезендә, әгәр союздаш республика составында автономия бар икән, иң башта аңа союздаш республика җитәкчесе кул куя, аннары гына, вертикаль буенча, автономияләр кул куя булып чыга иде. Шәймиев, Татарстан моның белән риза түгел, Татарстан ул вертикальдә торырга теләми, дип игълан итте. Татарстан союздашлар белән тигез хокукта горизонталь кул куярга тиеш. Украина кебек үк, Татарстан да парафлауга әзер түгел иде.

Шәймиев ул вакыттагы Россия Федерациясе Югары Советы Рәисе Ельцин белән очрашырга тиеш, һәм алар ике якны да канәгатьләндерерлек уртак бер фикергә килергә бурычлы иде.

Аннан алда Минтимер Шәрипович Михаил Сергеевич Горбачёв белән киңәшеп алды.

– 20 августта Татарстан Союз килешүенә кул куячакмы? – дип сорады Горбачёв.

– Шартыбыз бар, Михаил Сергеевич! – диде Шәймиев. – Әгәр дә Татарстанга горизонталь буенча кул куярга рөхсәт булса, кул куярбыз.

– Татарстан белән Украина мәсьәләсе һаман кала бирә, – диде Президент.

Ләкин 20 августта гына имза салырга димәгән бит. Соңыннан да кул куеп була лабаса.

Шәймиев 19 августта Ельцин белән очрашырга тиеш иде.

Союздашлар белән автономиялеләрнең җитәкчеләре, Килешүгә кул куярга дип, барысы да Мәскәүгә җыелды. 20се көнне кул куелырга тиеш иде.

Нәкъ шуның алдыннан, 19 августта ГКЧП дип аталган фетнә башланды.

## Шаукым

Имеш, бу фетнәчеләр – коммунистик режимны торгызырга алынган төркем, дигән хәбәр тараттылар.

Куркыныч хәбәрләр Казанга да килеп җитте. Татар тарихына кагылган китапларны, тарихи романнарны, корректуралары әзер булуга карамастан, бастырудан туктатып, авторларына кайтарып, яшереп куярга куштылар. Имеш, цензура тагын кире кайта, диделәр. Әдәбият цензурасының җитәкчесе итеп, имеш, Мансур Хәсәновны куйганнар. Имеш, тиздән кулга алулар да башланачак икән.

Фетнә оештырган комитетның гомере 18 августтан 21 августкача гына булды. Өч көнлек гомерендә дә ГКЧП бөтен Советлар Союзын куркытып өлгерде.

Шуннан соң ил буйлап ГКЧПда катнашканнарны кулга алу, аларга теләктәшлек белдергәннәрне эзәрлекләү башланды. Бигрәк тә Татарстан Президенты Шәймиев өстендә кара болытлар куера барды. Имеш, безнең Илбашы да шушы фетнә яклы булган, дип коткы тараттылар.

Мәйданга җыелып, көннәр, атналар буе «Шәймиев! Шәймиев!» дип, Илбашыбызны алкышлаган, яклаган меңләгән халык, шушы коткыга ышанып: «Долой Шаймиева!» – дип кычкыра башлады. Бу – шовинистлар һәм Татарстанның мөстәкыйльлегенә каршылар тегерменәнә су кою иде, билгеле. Әлеге «долой»га хәтта татар милләтчеләре дә кушылды.

Бу бик шомлы, шаукымлы вазгыять иде. Бер-берсенең бугазына ябышырга торган ике көчнең берләшүе гарасатка китерергә дә мөмкин иде.

## Альфа

Ельцин тагын ашыгыч киңәшмә җыйды. Һәм «Альфа» командиры Головановка үзенең «бөркетләрен» җыярга кушты. Киңәшмәдә Россия Президентының яраннары – РСФСР Югары Советы Рәисе Руслан Хасбулатов, Сергей Шахрай һәм Сергей Филатов утыра иде.

– Почему я вас срочно собрал? Потому что дело срочное и безотлагательное! Сегодня утром в Казани начнётся сессия народных депутатов Татарстана. Пора покончить парадом суверенитетов! Шаймиев который раз нас подвёл? Этот Чингиз-хан – участник ГКЧП, преступного террористического заговора,

который намеревался совершить государственный переворот и взять власть в свои руки! Никто не должен избежать строгого наказания! Трое из этих преступников покончили собой, остальные ждут суда, соучастники, пособники тоже будут строго-настрого наказаны! Твои орлы готовы, Василий Михайлович?

– Так точно, Борис Николаевич! – дип кычкырды Голованов.

– Жду ваших мнений, господа присяжные!

Хасбулатов тамак кырды.

– Говори, Руслан Имранович! – диде Ельцин.

– Привезти Шаймиева, как Пугачёва, в железной клетке! Давно пора с этим Пугачёвым поговорить тет-а-тет!

Калганнар шаулашып алды.

– Борис Николаевич! – диде Президент администрациясе башлыгы Сергей Филатов. – Ашыкмаска иде. Как бы не наломать дров. Да, Шаймиев вёл себя неоднозначно... Надо без «Альфы» поехать в Казань... чего гусей дразнить... надо поглядеть, что там творится...

Киңәшә торгач, уртак тел таптылар: Сергей Шахрай белән Сергей Филатовны Казанга юлларга! Карасыннар, баксыннар. Әгәр дә кирәк булса, Шахрай белән Филатов шундук «Альфа»га хәбәр бирә. «Альфа» аэропортта хәбәр көтеп утыра, хәбәр килүгә, шундук Казанга оча да, Шәймиевне кулга алып, Мәскәүгә кайта...

Шахрай белән Филатов Казанга очты.

Мәскәүдәге киңәшмәдә ниләр булганы, чакырылмаган кунакларның Татарстанга киләсе Казанга да хәбәр ителгән иде.

Табигый ки, Шәймиевнең үзенә дә бу турыда хәбәр килеп ирешкән иде.

Хәлнең бик тә мөшкел икәнен Минтимер яхшы аңлый иде. Ләкин ул сабырлыгын җуймый, чәбәләнми. Ә эчендә ут яна. Үзе өчен курыкмый ул. Ә менә Татарстан өчен нык борчыла. Эшләнгән күпме эш әрәмгә китәчәк.

Мәйдандагы халык та чакырылмаган кунакларның сәгать уникедә Казан аэропортына килеп кунаклаячагын белә иде.

– Минтимер Шәймиевне кулга алырга киләчәкләр! Хасбулатовның хыялы тормышка ашты! Президентны читлеккә ябып алып китәчәкләр! – дигән сүз бөтен мәйданга таралды.

Мәйданга утыз меңләп халык җыелган. Мәйдан тирәли БТРлар, эт җитәкләгән ОМОНчылар, милиционерлар шыплап тутырылган. Яңа хәбәрне ишеткәч, халык аптырап калды. «Демократ» шовинистлар гына аптырамады: алар икеләтә куәт белән «Долой Шаймиева!» дип кычкыра һәм, әйтергә кирәк, татарларның да яртысы «демократлар» белән бергә «долой» кычкыра, яртысы дәшми. Мәйдан Шәймиевкә каршы котыртылган иде. Эш бик тә хәтәр төс алды.

Шәймиевне алып китсәләр, аның урынына вице-президент калачак, ә бу Мәскәүгә бик тә кулай булыр иде. Президентсыз калгач, Татарстанны Россиянең бер губернасы итеп кенә калдырачаклар. Икесе дә Мәскәүгә кулай. Ә Татарстанга – фаҗига! Ләкин мәйдандагы татарлар моны әлегә аңламый иде.

Шәймиевнең кыен вакытлары күп булды: Казанга танклар, гаскәр кертү ихтималы барлыкка килгәч, аның җаны өшеде. Йөзе агарды, учларына, бөтен тәненә салкын тир бәреп чыкты. Монысы тагын да шөбһәлерәк иде.

Шулай итеп, яңартылган куәтле илне саклап калыр өчен бөтен мөмкинлекләр дә харап булды. Әгәр саклап кала алсак, ялгышлар да азрак булыр, халык та азрак җәфа күрер иде. Союзның таркалуы аркасында, БДБ дәүләтләре

икътисади кыенлыкта калды, элемтәләр өзелде. Без тарихи форсатны кабат кулдан ычкындырдык.

Кыскасы, фетнәчеләр, Союзны саклап калырга теләп, аны җимерде генә.

«Ура» кычкырып башладылар, «каравыл» кычкырып харап булдылар.

Путчистларның эше барып чыкмагач, Ельцинга хакимиятне үз кулына алудан башка чара калмаган иде.

Фетнә вакытында Ельцин үз яраннары белән җәйлек йортында ябылуда, һәм ул Шәймиев белән күрешә дә алмый иде. Автономиялеләр СССР Югары Советы Рәисе Лукьянов белән очрашырга булды. Ул чагында Мәскәү урамнарында танклар йөри иде инде.

– Урамда нинди танклар ул? – дип сорады автономиялеләр.

Лукьянов үзе дә белми иде, дөресрәге, соңрак мәгълүм булганча, ул белмәмешкә салышкан икән.

Шулчак Минтимер Шәймиев әйтте:

– СССР Югары Советын җыярга кирәк! – диде, автономиялеләр аның белән килеште.

Бу карарны ишеткәч, Лукьянов премьер-министр Валентин Павловка шылтыратырга булды. Ләкин телефоннары эшләмәдеме, башка бер мәгълүм булмаган сәбәпләр килеп чыктымы, Лукьянов, канәгатьсез чырай белән, телефонны урынына куйды. Берни дә барып чыкмагач, автономиялеләр үзара киңәште дә:

– Янаев янына йөгерергә кирәк! – диде.

Алар баш гэкачепист Янаев белән очрашты. Ул әйтте:

– Михаил Сергеевич авырып тора, димәк, мин, вице-президент буларак, Конституциядә каралганча, ил белән идарә итүне үз кулыма алырга тиеш!

– Алайса, – диде Шәймиев, – Горбачёв авыргач, аның авыруы турында мәгълүмат булырга тиеш.

– Хөкүмәт каршындагы медкомиссия Горбачёвның сәламәтлеге турында рәсми нәтиҗә чыгарырга тиеш, – диде Коми Республикасы җитәкчесе Юрий Спиридонов.

Бу сорауга җавап икеле-микеле генә иде. Алга таба Дәүләт комитетының күрсәтмәләрен күтәргә куштылар.

Эш болайрак тора. Әгәр дә ГКЧПның халыкка мөрәҗәгатен укып карасагыз, анда барысы да конструктив рәвештә тәфсилләп аңлатылган. Мөрәҗәгатьтә демократиягә каршы, шәхес хокукларын чикләү турында бер генә сүз дә юк. Шушы этапта бөтен гамәлләрне гадәттән тыш хәл кысаларында башкарырга, дигән сүз бу. Монда «теләктәшлек» дигән сүз урынлы түгелдер, бәлки.

Татарстанның хәле киеренке вә шөбһәле иде. Төбәкләрдә гадәттән тыш комиссия төзергә, дип телеграмма килгәч, Татарстан алар кушканны үтәмәде. Гәрчә безнең премьер-министр Мөхәммәт Сабиров ашыгыч рәвештә гадәттән тыш комиссия төзү ягында иде. Минтимер Шәрипович шул чакта әйтте:

– Комиссия төзүнең кирәген күрмим! – диде. – Хәзергә барысы да тыныч. Урамнарда болганыш күренми. Массакүләм мәгълүмат чараларын кыскартмадык. Хокук саклау органнары һәм башка структуралар белән тиешле эшләрне башкардык.

Бу вазгыятьтә иң мөһиме – сабырлыкны, тынычлыкны сакларга кирәк иде.

Әлеге вакыйгага караш та гел бертөрле генә түгел иде, әлбәттә. Фикерләр соңрак, көн азагында гына формалаша башлады. Ә безгә бер якка да катнашмаска кирәк иде. Сабырлык! Саклык кирәк! Шулай гамәл кылу яхшырак, дип уйлады Минтимер Шәймиев.

Ельцин, демократик хәрәкәтнең байрагын йөртүче буларак, халыкка ошый иде. Менә ни өчен, илдә демократия шытымнары күренүгә, Татарстан иң беренче булып мөстәкыйльлек таләп итә башлады. Халык үзе күтәрелде көрәшкә. Башка республикаларга караганда, татарлар иртәрәк уянды. 1917 елгы революциядән соң өч тапкыр бер үк мәсьәлә күтәрелә: Татарстан белән Башкортстаннан союздаш республикалар ясаргамы, әллә алар автономияле генә булып калырга тиешме? Менә шул сәбәпле, Татарстан Союз килешүенә өметләнә иде. Ельцин, һичшиксез, Татарстанның Россия Федерациясендә калуы ягында тора, ә монда Татарстан тулы мөстәкыйльлек таләп итә. Бу ансат кына чишелешле мәсьәлә түгел иде.

Горбачёвның гайрәтле Ельцинга ниндидер күләмдә каршы чыгарга тырышуының үз сәбәпләре булгандыр. Ул, әлбәттә, автономияләр уенын оста башкарды, Татарстанның аерым бер статуска ия булачагын инкяр итмәде. Ул чакта Татарстанның тулы мөстәкыйльлеге турында сүз юк иде әле. Барысы да яңартылган Союзны сакларга ыргылды, ә Татарстан, Союз килешүен тәртипкә китергән вакытта ук, башка автономияләргә караганда, мөстәкыйльлекне киңрәк алып калырга тырышты. Горбачёв Татарстанның теләгенә каршы килмәде.

Шаккаткыч вакыйга иде ул, шундый бөек куәтле илнең таркалуын беркем дә күз алдына китерә алмый иде. Бу эш путчтан соң үзеннән-үзе килеп чыкты. Ельцин яңа Союз составында Россиянең тулырак мөстәкыйльлеген тели иде. Асылда, Союз килешүе чып-чын федераль килешү иде. Ә кайберәүләр, бу конфедератив килешү иде, ди. Юк, әлбәттә, ул алай түгел иде.

Армия, КГБ, разведка, Эчке эшләр министрлыгы, бердәм көч буларак, үзәктән идарә ителергә тиеш. Союз таркалганнан соң да әле, Татарстан җитәкчелеге килешү тәртипләре турында Ельцин белән күп тапкырлар очрашты. Бу сөйләшүләр путчка чаклы ук башланган иде инде. Исегездәме, «мөстәкыйльлекне теләгәнегезчә алыгыз» дигән иде ул. Аның батырлыгы җитте, путчтан соң да, Татарстан җитәкчелеген путчка теләктәшлек белдерүдә гаепләгән чакта да, ул килешү турында онытмады. Бу – әле безнең тарих тарафыннан бәһаләнмәгән чынбарлык.

Ни сәбәпле путч килеп чыкты соң? Союз килешүен төзү бер-ике көн дәвамында гына түгел, айлар буе эшләнде ләбаса. Язов та, Лукьянов та, Крючков та ни кылынганын, нинди документ әзерләнгәнен – барысын да күреп торды бит. Алар Федерация Советында әйтте, Союз зәгыйфьләнә, диде. Рыжков та, Крючков та Михаил Сергеевичка күп тапкырлар ирештерде: процесс идарәгә буйсынмаячак, диде. Власть тирәсендәге кешеләр унитар фикерләүче шәхесләр иде. Аларны да аңлап була. Кинәт кенә шундый хөрлек килде: ирекле рәвештә берләшкән зур федераль дәүләт корыла башлады. Ләкин бу фикерләүнең путчка әвереләсен Горбачёв күз алдына китермәгәндер. Путчистлар Союзны иске хәлендә саклап калырга маташты. Путч барып чыкмады, һәм Союз таркалды.

Путч җиңгән очракта да, үзгәрешләр аз булыр иде. Бәлки, яңа Килешүнең әзер тексты үзгәртелер, һәрхәлдә, ул чорда илдәге мөнәсәбәтләр барыбер яңартылган булыр иде, чөнки җәмгыять яңалык, үзгәреш көтә иде. Бу – Горбачёв башлаган ачык мөнәсәбәтләр заманы иде.

Минтимер Шәймиев Россия турында, Татарстан һәм башка милли җөмһүриятләр хакында һәрчак уйлана килде. Аның фикере утырган, урнашкан, ул фикерне какшатып булмый. Россия демократик юл белән барганда да, бер

куркыныч яный – ул аның унитаризм юлына салулап китү ихтималы. Россиядә яшәгән халыклар структурасы, аның тарихы, аның күпмилләтлелеге – уникаль күренеш. Россиядә яшәүче һәр халыкның үз тавышы, үз тарихы булырга тиеш. Демократия үсеш кичергәндә, бу халыкларның тавышы ныграк ишетеләчәк. Бәлки, ул тавышлар ниндидер канәгатьсезлек рәвешендә, милли шартлардан ризалашмау шәкелендә дә булырга мөмкин. Шуңа күрә үз-үзеңне алдарга кирәкми, түземлек, сабырлык белән хакыйкый федерализмга әзерләнергә кирәк. Әйе, бу – унитар дәүләтне саклап калуга караганда, шактый катлаулы гамәл. Ләкин, ахыр чиктә, Россиянең, цивилизациягә барганда, бүтән сайлар юлы юк.

## Салым

Россия Федерациясенең салым турындагы кануннарында, Россия составына кергән республикаларның салым салырга хокукы юк, диелгән. Минтимер Шәймиев Татарстандагы тузган торакларны бетерер өчен салым кертте. Татарстанда керем күләменнән бер процент салым ала башладылар. Россия кануннары буенча, бу гамәл Минтимер Шәймиев тарафыннан кылынган җинаять булып санала. Федеральлекне ихлас яклаучы Илбашыбыз, аңлы рәвештә, федераль кануннарны боза түгелме? Шәймиевнең төрле якны тәфсилләп тикшергәч кенә гамәл кылуы яхшы мәгълүм, әмма бу очракта ничек итеп ул канун бозды икән? Гаҗәп. Шул турыда сүз чыкса, Шәймиев болай җавап кайтара:

– Мин һәрвакыт әйтә килдем: бу эшем өчен мин суд эскәмиясендә утырырга да әзер!

Татарстан Президентының гаепләнүче сыйфатында суд залында утыруын күз алдына китерү кыен, әлбәттә. Ләкин ул судтан курыкмый иде. Әгәр дә хокук кагыйдәләреннән чыгып кына эш йөртсәң, билгеле, бу гамәл канун бозу булып тора. Ә инде әхлак кагыйдәләре һәм халык мәнфәгатьләреннән чыгып гамәл кылганда, Шәймиевнең әлеге фәгалиятен аңлап та, аңлатып та була. Димәк ки, республиканың һәм анда яшәүче халыкның мәнфәгате Шәймиев өчен кимчелекле федераль кануннардан өстен тора! Татарстан Президенты мәсьәләнең әхлакый ягын шулай хәл итте. Ә сәяси яктан бакканда ничек? Татарстан кебек субъектлар бездә дистәләгән. Әгәр дә һәр республика шулай эш кыла башласа? Сәяси яктан бу гамәл бик күп аңлаешсыз хәлләр туугa сәбәпче булыр иде. Кануннарны бозмас өчен, ни дә булса уйлап чыгарырга кирәктер ләбаса? Әйтик, закон начар икән – судка бар, бу законның халык мәнфәгатьләренә каршы килүен исбат ит! Ә кем белән судлашырга соң? Федераль үзәк беләнме? Әгәр Минтимер Шәймиев федераль канунны бозган икән, аны хөкемдарлар үзләре судка куярга тиеш булып чыга.

Бик яхшы принцип бар, ул – Россия Конституциясендә язылган тулы вәкаләтләрне чикләү принцибы. Бар Федерациянең махсус-аерым вәкаләтләре, бар уртак вәкаләтләр, менә шунда без киңәшергә һәм уртак-килешенгән законнарны кулланырга тиеш. Бар субъектларның махсус-аерым вәкаләтләре, монда инде мәсьәләне без генә хәл итә алабыз, безнең бу гамәлебезгә беркемнең дә килеп катнашырга хакы юк.

Татарстан бюджеты ул – республиканың тулы вәкаләте. Ә Россия Федерациясенең Салым кодексында язылган: субъектлар салым җыярга

хокуксыз, диелгән. Ничек инде ул алай булырга тиеш?! Бу – мантыйкка сыймый торган канун. Бюджетны Татарстан хәл итә, ә керем акчасының язмышын Татарстан хәл кыла алмый. Вәкаләтләрне чикләү принцибы белән бу берничек тә яраша алмый. Конституцияне ачып карагыз, кайда, кайсы урында шулай язылган?

Бәлки, Татарстан предприятиеләренең керем күләменнән бер процент алып, республика башка кешеләрне кыен хәлгә куйгандыр? Элек җимерек торакларны бетерер өчен тотыла иде акча, хәзер социаль ипотекага китә.

Безгә килгән инвестор безнең эш шартларын кабул итә – бернинди проблема юк. Җир бүлеп бирүне дә, коммуникацияләр мәсьәләләрен дә Татарстан хәл итә. Соңыннан 50 процент торак аның хезмәткәрләренә бирелә. Бизнеста бу аңлашыла, анда ахмаклар утырмый: аның хезмәткәре җимерек йортта түгел, уңайлы фатирда яшәсә, ул яхшырак эшли. Моннан да акыллырак эшнең булуы мөмкин түгел!

Шуңа күрә Татарстан Президенты шушы эшне башларга җөрьәт итте дә. Ләкин Мәскәү бу эшне канунлаштырмады, керем күләменнән бер процент акча алырга башка субъектларга рөхсәт итмәде.

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевне (үзенең үтенече буенча) Россия Президенты Владимир Путин Барвихадагы җәйлек эш урынында кабул итте. Очрашу вакытында Шәймиев ничек итеп җимерек торакларны бетерү эшен башлаганы турында да сүз кузгалтты:

– Владимир Владимирович, без бер генә ел эшләдек, бик күп гаиләләрне яхшы торак белән тәэмин итәргә өлгердек, – диде. – Кешеләр туры мәгънәсендә тормышның иң төбендә яши иде бит, ниһаять, алар подваллардан чыкты.

Путин кунагын игътибар белән тыңлап бетерде дә әйтте:

– Хәзер монда Фрадков килеп җитәр, – диде. Фрадков ул вакытта премьер-министр булып эшли иде. – Без аның белән бергә бу мәсьәлә турында тагын сөйләшеп алырбыз.

Фрадков килгәч, Минтимер Шәймиев барысын да тәфсилләп кабат сөйләп чыкты.

Путин белән Фрадков икесе беравыздан:

– Шәп бит бу! – диеште.

– Михаил Ефимович! – диде Путин. – Уйлап карагыз, бу эш безгә күпмегә төшәр икән? Бәлки, безгә Татарстан юлы белән китәргәдер? Ә?

Минтимер Шәриповичны гаҗәпләндергәне шул булды: Путин аның федераль законны бозуы турында ләм-мим бер сүз дә әйтмәде.

Әгәр дә Татарстан дотацион республика булса, ихтимал, эшләр мөшкелләнер иде, ярый әле Татарстан читтән мал алмый, үзе мал бирә.

Ни өчен Минтимер Шәймиев җае чыккан саен:

– Законны бозганым өчен, мине судка куйсыннар! Ләкин ул суд ачык булырга тиеш! – ди.

Суд булмаячагын белеп әйтә ул. Әгәр дә Татарстан Президентын суд эскәмиясенә утыртсалар, халык ни әйтер? Менә Шәймиев картларны яхшы фатирларга күчереп утыртты – шуның өчен ул хөкемгә тартылды, ә губернаторлар безне юеш подвалларда черетә, алар законны бозмаган, алар иректә йөри, дип әйтер иде.

Һичшиксез, бу игелекле гамәл Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге хөкүмәтнең сәяси ихтыярыннан килә иде.

## Фәрит Хәбибуллин

*Фәрит Хәбибуллин (1941-2006) – үзе оештырган Татар яшь тамашачы театры директоры һәм режиссёры. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Хәзер бу театр, дәүләт театры буларак, Габдулла Кариев исемен йөртә.*

– Бар иде шундый бер кеше – Фәрит Хәбибуллин, – дип искә ала Минтимер Шәймиев. – Ул шундый ихлас милләтпәрвәр, гыйсъянчы-бунтарь кеше иде. Бер митингны да калдырмый йөри, ярсып сөйли торган иде. Ул үзен Татар яшь тамашачы театры директоры һәм режиссёры буларак күрсәтте. Шулай бервакыт Фәрит минем кабул итүемне теләде һәм үзенең театры ничек, кайда урнашасын барып карарга чакырды. Островский урамында иде ул бина, рус ТЮЗыннан ерак түгел. Бик тәвәккәл, үҗәт иде ул. Мин аның ялваруларына түзмәдем, әйдә киттек, дидем. Үзебез белән Казан шәһәре башлыгы Камил Исхаковны да алдык. Килеп җиттек, ишегалдына кердек. Ниндидер ярымҗимерек дивар. Тирә-юньгә тәмсез ис таралган... Бу – аерым бер ис, мин бит авылдан килгән кеше, күпне күргән кеше, ә бу ис – аерым бер ис, шәһәр исе, миңа таныш булмаган ис иде. Кешеләр йөгерешеп чыкты, Президент килгәнне күрделәр. Кайсысыдыр баласы белән чыккан. Кычкырышмыйча гына, усалланмыйча гына сөйләшәләр. Миннән бина эченә кереп каравымны үтенделәр. Беркайчан да онытасым юк: анда коммуналка. Коридорда бер олы яшьтәге хатын караватта ята. Сорадым, синең фатирың бармы, дидем. «Прописка бар, ләкин анда миңа йокларга урын юк, – диде хатын. – Менә хәзер шушында ятам. Суларга һава юк». Мин тетрәнеп киттем. Моны берничек тә күз алдына китереп булмый. Мин аптырап хәйран калдым. Бу күренеш башыма сукты, шаккаттым. Үз күзең белән күрү ул кәгазьгә язганны уку түгел икән. Без бит адәм балалары. Без Камил Исхаков белән киңәштек тә, Югары Совет белән бергәләшеп, законлымы, законлы түгелме, кешеләргә ныклап ярдәм итәргә кирәк, дигән фикергә килдек. Бичараларга ярдәм итәргә булдык. Бу кешеләр үзләре генә беркайчан да моннан чыга алачак түгел.

Фәритнең урыны оҗмахта булсын! Ул чын татар җанлы, затлы шәхес иде.

## Атама

«Президент» атамасын башкасына алыштыру-алыштырмау – ул республикаларның үз вәкаләте.

– Әгәр дә аны өстән алыштырырга кушалар яки мәҗбүр итәләр икән, без референдум оештырырга яки халык фикерен тупларга һәм халык ихтыярына буйсынырга тиеш булачакбыз, – диде Минтимер Шәймиев. – Бу бик принципиаль мәсьәлә. Әлеге эшкә килеп катнашырга беркемнең дә хакы юк.

Хәтта Советлар вакытында да Татарстан АССР СССР Конституциясендә «дәүләт» дип атала иде. Формаль генә булса да, шундый статусы бар иде. Бүген дә «республика-дәүләт» статусын Конституциядән беркемнең дә алып ташлаганы юк. Бу – Россия Федерациясенең Конституциясе. Һәм без аның кануннарын бозмыйбыз.

*Лев Овруцкийның «Минтимер Шәймиев белән әңгәмәләр» дигән китабыннан*

Овруцкий. *Я часто слышу, что татар выдвигают ещё потому, что они владеют двумя языками.*

Шаймиев. Допустим, есть две равнозначные кандидатуры, но один

из них знает русский и татарский, а другой – только русский. Кого бы вы назначили?

О в р у ц к и й . *[...] Ваш «центризм» прошёл главные испытания в конце 80-х – начале 90-х, когда шла борьба вокруг суверенитета Татарстана. Эпоха бури и натиска...*

Ш а й м и е в . Когда люди выходили на площадь, критиковали меня, что я ненастоящий татарин, мне было обидно. Как будто я меньше татарин, чем крайние националисты, которые требовали полной независимости. Но в данном случае, как человек и как Президент, я болел не только за свою нацию, я болел за всю республику. Я же за неё отвечаю! Есть русские, есть другие, есть смешанные браки. Я исходил из этого. Как же с этими людьми не считаться... Иногда просыпался среди ночи, жутко бывало. Я всегда опасался какой-то дикой случайности. Эти митинги... Как бы кто-то кого-то не пырнул. Русский – татарина, или татарин – русского. В такой переломный момент не заявлять о своих правах было бы непростительной ошибкой. Тем более, что у татар была своя государственность, память об этом живёт и передаётся из поколения в поколение. Мы в 90-е годы прожили очень короткий, но ответственный революционно-эволюционный период времени.

О в р у ц к и й . *Мне кажется, имеет место и разочарование.*

Ш а й м и е в . Немало таких, которые говорят: мы приняли Декларацию, объявили суверенитет, но ничего не вышло, всё повисло в воздухе и так далее. Кто-то пренебрежительно относится. А ведь это неправильно. Что дали эти годы? Главное – рост самосознания татар. Когда что-то достигнуто, значимость этого познаётся со временем.

О в р у ц к и й . *Я писал, что к татарам вернулось самоуважение.*

Ш а й м и е в . И не только самоуважение. Уважение со стороны остальных народов... Это ценное достижение... Я и раньше говорил, что в России должна быть национальная политика. Её нет. Это дело президентское... Если ты Президент, ты должен заниматься национальной политикой, больше некому. Министерство может быть как инструмент – собрать информацию, мнения экспертов, подготовить варианты, но решать должен Президент. Отсутствие понятной всем национальной политики – это фактор риска, особенно в таком многонациональном государстве, как Россия.

О в р у ц к и й . *Отсутствие политики – это тоже политика.*

Ш а й м и е в . Но в чью пользу такая политика? Когда есть национализм большинства, он подогревает национализм меньшинства, он делает его качественно другим.

О в р у ц к и й . *Это воспринимается как внешняя угроза.*

Ш а й м и е в . Отчасти, да.

О в р у ц к и й . *Вы всегда настаивали, что России необходимо Министерство по делам национальностей.*

Ш а й м и е в . Министерство, агентство – неважно. Какой-то государственный орган, который будет готовить решения. Как я уже говорил, там должны быть эксперты, специалисты, ресурсы, чтобы развязать тот или иной вопрос. А принимать решения должен Президент. Он – всенародно избранный. Он должен этим заниматься. Обязан! В таком государстве, где более ста национальностей, этим должен заниматься лично Президент. Я в этом убеждён... Мы жили с вами в Советском Союзе. Помните, были Декады национальных культур в Москве, обмены и так далее. Вы в последнее время видели выступление каких-либо

национальных коллективов на российском телевидении? Мы видим русскую культуру, ещё больше – американскую. А где татарская, башкирская, якутская и так далее?

Овруцкий. *У нас 150 народов. Как всех показать?*

Шаймиев. А сколько каналов? Раньше было всего два – однако показывали, а сейчас сто каналов...

Овруцкий. *Мы что-то зациклились на показах культуры, самодеятельности. Если брать проблему крупно, целиком, то это «мелочь».*

Шаймиев. Лев Мирович, не могу с вами согласиться, что это мелочь. Тут мелочей нет.

Овруцкий. *Я не смог выразить это интонацией – «мелочь», конечно, в кавычках.*

Шаймиев. Часто подчёркивается, что у нас страна православная. Я согласен: подавляющее большинство – православные, в этом некого винить, так исторически сложилось, но нужно об этом говорить очень тактично. Чтобы не задевать чувства других. Представьте себе, что было бы в Америке, если бы там каждый день напоминали, что в этой стране большинство белых. Как себя чёрные чувствовали бы?

Овруцкий. *Американцы – политкорректная нация.*

Шаймиев. А мы ещё нет. В этом и дело. Это настолько тонкая материя, нужно сто раз подумать, прежде чем сказать. Ты выпячиваешь, что Россия православная, а другой это воспринимает остро, иногда даже как оскорбление. Я как всегда говорил? Когда мой народ критикует татарина, мы на него не обижаемся. Но когда татар критикуют другие, мы воспринимаем это болезненно. Может быть, это неправильно, но такой уж менталитет, и не только у нас.

Овруцкий. *...естественная человеческая реакция.*

Шаймиев. Например, хотели в армии ввести институт священников. А если солдат, к примеру, мусульманин – ему что, креститься вместе со всеми или в стороне стоять? Или взять преподавание православной культуры.

Овруцкий. *Нам не помешало бы ведомство по внедрению политкорректности и деликатности.*

Шаймиев. Обо всём нужно говорить и тон должен задавать Президент. Он должен обозначить принципиальную позицию государства. И слова подобрать такие, чтобы никого не обидеть.

Овруцкий. *Ленин предсказывал, что националы потонут, как мухи в молоке, «в море великодержавной швали».*

Шаймиев. Ну, это вы очень сильно выразились.

Овруцкий. *Не я – Ленин. Получается так: мы татар, их культуру и язык 450 лет дискриминировали, а теперь все равны. Как же можно быть равными, если один развивался, а другой – дискриминировался? Нужны годы и дополнительные ресурсы, чтобы выпрямить ситуацию. Это и есть национальная политика, как я её понимаю. Сначала надо признать, что есть очень серьёзный дисбаланс и неравенство!*

Шаймиев. Главное, надо признать, что такая политика должна быть. Никто сегодня не ответит, что и как делать, но важно заняться. Уверен, решение будет найдено.

Овруцкий. *Условно говоря, садятся вместе с татарами и выясняют, что им мешает, что беспокоит, раздражает и так далее. Составляют*

*перечень проблем, ранжируют его и начинают работать. То же самое – со всеми национальностями России. В моём понимании это и есть национальная политика.*

Шаймиев. Я бы к этому добавил – не множить проблемы. Для этого и ресурсов никаких не надо. Учёт интересов не всегда требует каких-то трат. Скажем, не писать и не говорить, что в России все должны быть русскими или, как вседозволенный Жириновский и ему подобные говорят: «Россия – для русских». Когда нам из Москвы пытаются навязать сколько и как обучать родному языку в национальной школе, это нас обижает.

Овруцкий. *Вы думаете, что здесь не какая-то национальная спесь, а просто привычка или глупость?*

Шаймиев. Есть и то, и другое. Национальная политика – это сложно. Это деликатная среда, во многом предопределяющая стабильность такой федерации, как Россия.

Овруцкий. *Ваш тезис о сложности наводит на мысль, что у нас очень мало подготовленных в этом плане людей. Кому работать в Министерстве по делам национальностей, если даже интеллигентные, вполне тактичные люди из Минобраза вам спускают программу для национальных школ? И где министра такого взять?*

Шаймиев. Почему, у меня был конфликт, когда Фурсенко приехал с руководителем Центра национальных проблем образования Федерального института при Минобразе РФ Ольгой Артеменко. Русская женщина, которая вообще не хотела признать, что есть необходимость уроков на татарском и так далее. У меня скандал даже вышел... Я человек сдержанный, но тут не выдержал. Промолчала бы ещё, я и не узнал бы, но хорошо, что она заговорила. Она же определяет образовательную политику в изоляции от всех нас.

Овруцкий. *Она ещё и доктор наук.*

Шаймиев. Вот вам один из штрихов отсутствия в стране национальной политики. Видимо, до приезда к нам она не сталкивалась с такой жёсткой, но справедливой позицией.

## Иго

*Мы в ответе за тех, кого приручили.*
Антуан де Сент-Экзюпери

Минтимер мәктәптә укыганда да, институтта чакта да «иго» сүзен сөймәде. Тарих дәреслекләрендәге «татар-монгол игосы», «монгол-татар игосы», «татар игосы» гыйбарәләрен аның күңеле кабул итми иде. «Иго» сүзенең гаебе-гөнаһы юк анысы, бу кәлимәнең тамырында татар сүзе ятмыймы икән әле? «Игә китерү» (яхшы итеп тәрбияләү, акылга утырту) гыйбарәсендә «и» сүзе – исем-тамыр, «гә» – кушымча. Баш и (буйсын, игә кил), и-гелекле (яхшы кеше), игәүләү (шомарту, яхшылау). Кире мәгънәсендә, сатирик мәгънәдә «игәүләү» талауны, изүне аңлата: «Абыстай белән икәүләп, Мужикның сыртын игәүләп...» (Кандалый). Бу очракта «игәүләү» эксплуатация, иго мәгънәсендә килә. Димәк, татарлар русларны игә китерергә тырышкан. Чынлап та, Русь, Алтын Урда составында яшәгәндә, татарлардан бик күп нәрсә алган: сүзләр (иң башта рус теле татар теле хисабына байый башлаган), дәүләт-идарә системасы, гаскәр төзелеше, халык санын алу тәртибе һ.б.

*Лев Овруцкийның «Минтимер Шәймиев белән әңгәмәләр» дигән китабыннан*

Овруцкий. *Я нередко встречал татар, которых обижает упоминание о Татаро-монгольском иге. Если бы мне сказали, что некогда в древности евреи покорили полмира, я бы скорее гордился, нежели сердился.*

Шаймиев. Я не согласен с тем, что таких татар много. Вы меня спросили, как татарина, и я вам, как татарин, скажу: наоборот, многие гордятся. Если и есть обида, то потому, что в школьных учебниках роль татаро-монголов показывали односторонне. Только как варваров и разрушителей. Мол, дикари, татары. А я сказал бы, что сильных не всегда любят.

Овруцкий. *Кто в те времена не был жестоким – по нашим сегодняшним меркам? Иван Грозный? А крестовые походы? Такие были нравы... Вообще, сейчас набирает силу концепция, что исторически Россия стоит как бы на двух «китах» – это Киевская Русь и Золотая Орда. В самом деле, иначе непонятно.*

Шаймиев. Да, как Орду триста лет не замечать? Как быть с Евразией, великим переселением народов и так далее?

Овруцкий. *Казалось бы, где ещё сказаться предрассудкам о Татаро-монгольском иге, как не в Татарстане?*

Шаймиев. Само слово «иго» мне не нравится. Нехорошее какое-то слово. Там ведь за триста лет всякое бывало. Во многих вопросах роль Орды была положительной. Исторических фактов в подтверждение тому предостаточно. Главное – не смотреть на это через жёстко идеологизированный взгляд прошлого... Мы однажды приехали в Испанию. По протоколу у нас была встреча с мэром Мадрида. Мы познакомились, началась беседа, и он говорит: «Вы представители такого великого народа, который чуть ли не весь Запад завоевал». А у нас за протокол отвечала ныне покойная Флюра Зиятдинова, она раньше в горкоме КПСС занималась идеологией. Такая активная. И вдруг она встревает и говорит: «Это не мы!»

Овруцкий. *Мэр хочет вам сделать комплимент, а она...*

Шаймиев. Он говорит: «Мол, вы, татары...» Человек хочет нам сказать приятное. Я ей по-татарски шепчу: «Ты что?!» Такой момент был. Это частично ответ на ваш вопрос: кто гордится, а кто стыдится.

*...Бу вакыйга 1971 елда Мәскәүдә, Кремль сараенда, Совет язучыларының V корылтаенда булды. Корылтайда катнашучы совет язучылары текә баскычлар буйлап төшеп килә. Каршы диварга алагаем зур картина эленгән, рәсемдә татарлар белән руслар арасындагы сугыш – Куликово сугышы сурәтләнгән. Татар сугышчылары ямьсез чырайлы, кәкре аяклы, трахома күзле, алама-сәләмә киемнән. Кыскасы, без кыргый татарларны күрәбез. Ә руслар баһадир, бай киенгән. Уртада ап-ак атта Дмитрий Донской татар яугирләре мәетләрен таптап бара. Алгы планда бер чибәр рус сугышчысы ямьсез бер татарны акыртып суеп маташа.*

*Арттан төшеп килүче грузин язучысы шунда татарларга әйтеп куйды:*

*– Как ви терпите такой издевательство? – диде.*

*Шулчак татар язучысы Гази Кашшаф:*

*– Это не мы! – дип куйды.*

*Грузин тагын сорады:*

*– А кого же русские на картине режут?*

*– Мы – другие татары! – диде татар язучысы.*

*– Да, ви жсе, я вижсу, красивые люди, а там адни уроды!*

*Шулчак яшь язучы Батулла өстәп куйды:*

*– Ямьсез татарларны ясар өчен, рәссам натурщикларны руслар арасыннан эзләп тапкандыр.*

*Бөтенесе шаркылдап көлде.*

*Дөрестән дә, русның яулап алуларына каршы көрәшкән халыклар барысы да «кәкәй» итеп тасвирлана иде. Хәтта Пушкин да бу гамәлдән читтә кала алмаган. Ул Кавказга басып кергән рус солдатларын кисәтә килгән: «Не спи, казак, во тьме ночной, злой чеченец ходит за рекой». Лермонтовта да бар андый юллар: «Злой чеченец ползёт на берег и точит кинжал». Генерал Ермоловның көндәлегендә исә болай язылган: «Я не успокоюсь до тех пор, пока не истреблю до единого чеченца». Чит халык җиренә басып кергән солдат «тәтәй», үз азатлыгы, үз җире өчен көрәшкән кеше «злой». Татарлар белән дә шул ук хәл. Биш йөз ел буена яман атын сату аркасында, татарларда мескенлек, кимсенү кәсафәте барлыкка килде.*

Ш а й м и е в . Но сейчас мы видим, что пошли уже иные публикации и русских историков...

О в р у ц к и й . *Более взвешанные?*

Ш а й м и е в . Да. Уже абсолютно другое...

О в р у ц к и й . *Если сегодня, через 500-700 лет, кому-то по-прежнему важно, кто кого завоевал, значит, есть какие-то глубинные межнациональные проблемы.*

Ш а й м и е в . Это действительно важно. У наших народов история сложная. И разом всех учёных ведь не обвинишь, на них сильно давила идеология. У каждого свои ученики, уже столько трудов издано, ему тяжело отказываться от своих учений. Вывод таков: нужны исследования в условиях свободы.

О в р у ц к и й . *Когда читаешь историю вражды с Казанским ханством, скажем, того же Худякова, то видишь, что ханство предпринимало походы на Москву, они забирали в плен, продавали пленных и так далее. Тут не только Иван Грозный был такой-сякой. Просто, в конце концов, русские оказались сильнее – вот и всё.*

Ш а й м и е в . Становлению империй и их распаду, как правило, предшествуют завоевания, военные конфликты, революции и так далее.

О в р у ц к и й . *Но меня смущает, когда историю Казанского ханства идеализируют, а историю Руси, соответственно, принижают.*

Ш а й м и е в . Это – зеркало. Вы о нас так, и мы о вас так. Какая-то историческая конфронтация на этой почве. Надо от этого уходить через объективное изучение, освещение нашего прошлого.

*Ләкин монда бер нәрсәне искәртергә кирәк: Худяков язганча, Мәскәү белән Казан арасындагы соңгы ун олы орышның җидесе Казан капкасы төбендә барган, калган өчесе Казан ягыннан җавап яулары булган.*

## Янәшәлек

Мөселман халыклары телендә Иерусалимның атамасы «әл-Кодес» була. Шуннан татар исеме Котдус, рус фамилиясе Кутузов килеп чыга. Кот – бәхет, җан мәгънәсендәге гарәп сүзе. Кодес – игелек, мөкатдәс, изге. Бәлки, «кодекс» сүзе дә шуннан яралгандыр әле. Кодекс – кануннар җыелмасы, тәртипкә, бәхеткә, котка ирештерүче кагыйдәләр, дип тә шәрехләргә була.

Иерусалимны зиярәт иткән чакта, бигрәк тә «Зар дивары» («Стена

плача») янында үзеңне күк капусы ачылганны күргән кебек хис итәсең. Гыйбадәтханәнең ишегалдына килеп керүгә, кешене ниндидер могҗиза урап ала, таш диварның эче шомлы да, серле дә гүелдәү белән тулган. Әйтерсең лә бу гүелдәү күктән – Тәңредән килә. Баксаң, инанганнарның Тәңрегә ялваруы-зарлануы шулай гүелдәү авазы чыгара икән. Яһүдләрнең изге китап тотып, диварга йөзләре белән басып гыйбадәт кылганнарына битараф калып булмый. Инанучы яһүд халкының гасырларга сузылган фаҗигаләрен уйлап, ул фаҗигаләрнең тагын да кабатланмавын теләп Аллаһка ялваруларын күреп күңел тула, тамакка әче төер утыра.

«Зар дивары» янында ук Йосыф мәчетенә алып чыга торган баскычлар бар. Моңа Минтимер дә, аның белән килгән якыннары да шаккатты.

Яһүдләрнең фөрьядын тыңлаганнан соң, Татарстан вәкилләре Йосыф мәчетенә алып бара торган баскычтан йөри башлады.

Минтимернең вөҗүдендә аңлатып булмас тойгылар, хисләр пәйда булды. Ике бөек дин янәшә яши. Тыныч, дустанә яши. Гасырлар буе яһүд белән гарәп халкы үзара сугышып гомер иткән. Әмма монда изге урын, котлы урын, ике халык та Бөек Кодрәт иясенә баш орган. Алар тигез.

Бу тойгылар, бу хисләр зиһниятне кузгатты. Менә шушы тигезлекне, тәңгәллекне үз Казанында да сакларга тырышкан көне иде Минтимер Шәймиевнең.

Кол Шәрифнең изге рухын, Кол Шәриф мәчетен, Кол Шәриф һәйкәлен мәңгеләштереп калдыру, Изге Болгар хәрабәләрен яңадан торгызу фикере дә Минтимернең зиһенендә әл-Кодес шәһәрендә яһүд әхрамыннан изге Йосыф мәчетенә күчкән чакта уянгандыр, бәлки.

Уянуын уянган, әмма тора салып Кол Шәриф мәчетен торгыза башласаң, Казандагы христианнар, руслар ни әйтер?

Минтимер Шәриповичның иңенә бик авыр, чишелмәслек мәсьәлә килеп төште. Кырыкмаса кырык сәяси мәсьәләләр, халыкны торак белән тәэмин итү мәшәкате, Мәскәү һәм чит илләр белән катлаулы мөнәсәбәтләр хәттин ашкан...

Хәлбуки, борынгы биналарны торгызу Минтимернең башка вазифаларыннан бер дә ким түгел. Дөресен генә әйткәндә, Кол Шәрифкә һәйкәл салу, Болгарны торгызу башка бөтен проблемалардан да өстен иде. Боларны җиренә җиткезеп эшләү өчен, ул бөтен вак-төяк һәм артык катмарлы проблемаларны да чишәргә, сират күперен узарга, уртак бер фикергә килеп хәл кылырга тиеш иде. Һәм, яшерен-батырын түгел, ул «эт өрә торыр, бүре йөри торыр» принцибы буенча эш йөртергә мәҗбүр иде.

Әгәр дә Шәймиев җитәкчелегендә иң башлап сигез манаралы Кол Шәриф мәчетен төзергә керешсәләр (сүз иярә сүз чыккач, әйтик: бу мөселман-татар архитектурасының гүзәл үрнәген җимерсәләр дә, аның сызымнарын Мәскәүгә алып китәләр, Кол Шәриф мәчетеннән күчереп салынган Василий Блаженный чиркәве Мәскәүдәге Кызыл мәйданның иң күркәм архитектура истәлекләреннән санала), нигә Шәймиев үз татарын гына кайгырта, нигә рус һәйкәлләренә игътибар итми, дип, ихтимал, буза куптарырлар иде.

Һәм 1995 елда берьюлы, бер Указ нигезендә, Казан Кирмәнендә Кол Шәриф мәчетен һәм Благовещение соборын торгызу эшләре башланды.

Бу хәбәрне ишеткәч, Казанда яшәүче руслар чиксез куанды, ә татар милләтчеләре өчен әлеге хәбәр утка керосин сибү белән бер булды, алар:

– Ни эшли ул Шәймиев? Шәймиев татар җанлы түгел! Аңа чиркәү төзәтергә кирәк! – дип ризасызлык белдерде.

Шәймиев шулай буласын алдан ук белә иде. Ул эчтән янса да, тыштан сабыр булды. Вакыты җиткәч, аны татарлар аңлаячак. Һичшиксез, аңлаячак!

Һәм аңладылар да! Благовещение соборы яңартылгач, олы бәйрәм ясап соборда литургия узып киткәч, Кирмән уртасында, иң калку урында гүзәл бина – Кол Шәриф мәчете калкып чыккач, татарлар аңлады: Шәймиев акыллы эш йөртә, ул ике якны да тигез тотарга тырыша.

Казанның – Татарстанның ике символы булды: Сөембикә манарасы һәм Кол Шәриф мәчете.

Бу гамәл татарларның горурлыгын арттыра төште, аларның Илбашына хөрмәте дә икеләтә артты. Читтән килгән кунакларның Кол Шәриф мәчетен күреп соклануы татарларның иелгән башын бераз күтәрә төште.

Бу фагыйлияте белән, Минтимер Шәймиев үзенә дә мәгънәви һәйкәл салды.

## 600–800–1000

Фикрәт Табиев хакимлек иткән чакта, бөтен Татарстан, бөтен татар халкы, Казанга нигез салынуга 800 ел була, дип ду килде, рәсемле букчалар, открыткалар, түш билгеләре ясап сата башладылар. Ләкин бераздан сүз таралды: имеш, Казанга 600 ел гына икән, имеш, Табиев бу бәйрәмне тыйган икән, диделәр. «Ура» кычкырып башлаган идек, «каравыл» кычкырып тын калдык.

Табиев, чыннан да, бер җыелышта (сорауларга җавап вакытында) әйтте:

– Мәскәүдән дә борынгырак буласыгыз киләмени? (Вы что? Хотите быть древнее Москвы?) – диде.

Әлбәттә, бу – Табиевның үз сүзе булмагандыр, аны Мәскәүгә чакыртып, Казаныңа кайтып шулай әйт, дип шелтәләгәннәрдер.

Минтимер Шәймиев Илбашы булганнан соң, бу мәсьәлә яңадан калыкты. Җитди археологлар, тарихчы галимнәр, нумизматлар Казан каласына нигез салынган вакытны ачыклый алды: пайтәхет 1005 елда корыла башлый. Һәм Казанның меңьеллыгы гөрләп, шаулап, тантана белән узып китте. Машалла! Чыннан да, Казан Мәскәү салыначак урында җилләр уйнаган чакта ук төзелә башлаган икән.

## Кол Шәриф һаман көрәшә

Мәскәүдәге Кызыл мәйданда илне тышкы дошманнардан коткарып калган ике каһарманга куелган һәйкәл тора.

Россия Президенты Владимир Путин әйткән сүз (2010 ел, 27 декабрь):

*Чит ил яулап алучылары (ул чагында – поляклар) Мәскәүне басып ала, һәм рәсми идарәчеләр, йомшак кына әйткәндә, тулысынчы каушап кала. Ватанны сакларга-якларга кем күтәрелә соң? Гап-гади кешеләр. Каян килеп чыга соң алар? Аларны бергә туплаучы җитәкчеләрнең берсе – гражданин Минин, аның һәйкәле Кызыл мәйданда тора. Хәтерлисезме Минин белән кенәз Пожарский һәйкәлен? Кем соң ул Минин? Гап-гади бер гражданин, чыгышы белән – татар. Ул бөтен малын ватанны сакларга бирә, кешеләрне көрәшкә күтәрә, кенәз Пожарский белән Мәскәүне коткарырга яуга чыга. Һәм алар Мәскәүне дошманнардан азат итә!*

Сүз иярә сүз чыккач әйтик: Дмитрий Пожарский – үзе дә болгар-татар нәселле кенәз. Ул – Кубрат ханның турыдан-туры торыны. Аның анасы Кубратның улы Котрактан килә, Пожарскийның атасы – кыпчак ханының оныгы.

Татар кешесе Көҗмә (Кузьма) Минин (Миңлебай) Урта Идел буенда башлап җибәргән ватанпәрвәрлек хәрәкәте тиздән бөтен мәмләкәтне каплап ала. Мәскәүне дошманнардан азат иткәннән соң, Минин, керәшен татары буларак, чиркәүгә кереп, татарча гыйбадәт кыла. Аның үз исеме Кириша була, ихтимал, ул «керәшен» сүзеннән килеп чыккандыр.

Алдарак искәртелгәнчә, Кызыл мәйданда татарларга кагылышлы тагын бер гүзәл бина басып тора. Ул – Василий Блаженный соборы. Күз явын алырлык матур бина бу. Манаралары чалма кебек ясалган. Рус тарихчысы Михаил Худяков «Очерки по истории Казанского ханства» дигән китабында язганча, Кызыл мәйдандагы бина – Кол Шәриф җәмигъ мәчетенең күчермәсе икән. Ул мәчет сигез манаралы булып, хәзерге Благовещение соборы урынында торган. Җиңүчеләр, гүзәл мәчетне җимереп, сызымнарын Мәскәүгә алып китеп, Василий Блаженный соборын корып куйган, имеш...

Илбашыбыз Минтимер Шәймиев, ярдәмчеләре белән киңәш-табыш иткәч, тарихи биналарны, һәйкәлләрне саклау өчен, Казан Кирмәнен музей-тыюлык итү максатын куйды. Форсаттан файдаланып, Кол Шәриф җәмигъ мәчетен дә торгызмак булды. Шушы теләк белән ул тиешле оешмаларга, Мәскәү, Европа белгечләренә, ИКОМОС белән ЮНЕСКОга, Венеция Хартиясенә дә мөрәҗәгать итте.

Әмма җавап-нәтиҗәләр куаныч китермәде. Борынгы биналар уртасында Кол Шәриф мәчетен корып куйсагыз, Казан Кирмәнен, музей-тыюлык буларак, ЮНЕСКО кабул итмәячәк, диделәр.

Монда халыкара хокук белгечләренә дә, үзебезнең тарихчыларга да эш җитәрлек иде. Кол Шәриф мәчетен торгызып музей-тыюлык ясау өчен, бөтен зиһниятне, акыл шәрифләрен эшләтергә кирәк иде. Кайчандыр баскынчылар җимергән мәчет урынында чиркәү утыра. Благовещение соборын без яңартырбыз, әмма Кол Шәрифнең рухы рәнҗеп ятар бит. Гаделлек хакына, бәлки, искәрмә буларак, Кол Шәрифнең рухын кайтарырга кирәктер.

Казан белгечләре дә, халыкара хокукчылар да әйләнеч юллар белән булса да җаен тапты, шөкер: Благовещение соборы да, Кол Шәриф мәчете дә, Сөембикә манарасы да, Кремль дә музей-тыюлык булып теркәлде, Аллага шөкер!

Гомумән, Кол Шәриф җәмигъ мәчете белән Сөембикә манарасы, Болгар тарих-археология комплексы – Татарстанның, юк, Татарстанның гына түгел, бөтен татарларның йөзек кашы.

Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең каһарманлыгын киләчәк буыннар бәяләр. Әмма бүген үк икърар итик, егетләр: Татарстанның кайсы җитәкчесе Кол Шәриф җәмигъ мәчетенә җан өрде? Казанның хәзер ике бөек символы бар: манара очына алтын һилял (яңа туган ай) куелган Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете! Казанга килгән кунаклар да, транспортта узып барган мосафирлар да Сөембикә белән Кол Шәрифкә карамыйча уза алмый. Бу – безнең горурлыгыбыз!..

Җимерелеп беткән, хәрабә хәленә килгән Болгарны кайсы җитәкче торгызырга алынды? Бүген Болгарга чит илләрдән, бөтен Россиядән халык агыла. Бу – безнең горурлыгыбыз!..

Минтимер, тарихи һәйкәлләрне торгызырга алыныр алдыннан, алар

турындагы тарихи-фәнни материалларны тәфсилләп өйрәнә башлады. Ул Казан Кирмәне буйлап сәгатьләр, көннәр дәвамында йөрде. Кем ул Кол Шәриф? Башка кеше ихтыярындагы колмы ул? Әллә Аллаһның колымы, бар вөҗүде белән дингә бирелгән шәхесме? Казан яулап алынган вакытта, ул кайда булган? Аның язмышы ничек тәмамланган? Әлбәттә, рухи җитәкче, шәйхелислам, сәедләр токымы Кол Шәриф илгә афәт килгәндә кул кушырып утыра, качып китә алмый. Минтимер тарихчылар, археологлар күрсәткән җирләрдә күп уйланып йөрде, һәм аның зиһенендә ватан азатлыгы өчен көрәшчеләрнең сурәте җанлана башлады... Кол Шәриф качып китмәгән, дошман ягына чыкмаган, ул халыкны азатлык сугышына – җиһадка күтәргән һәм батырларча һәлак булган!

## Шәһидлек

1552 ел, 2 октябрь.

Баштанаяк коралланган сәед Кол Шәриф сигез манаралы мәчетенә таба йөгерде. Шәкертләрнең барысы да, коралланган килеш, аны көтә иде. Ике рәкәгать намаз укылды, аннан соң сәед Кол Шәриф хәзрәтләре соңгы вәгазен сөйләде.

– Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим, бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әссәламәгаләйкүм!

Фарыз залы гүелдәп җавап кайтарды:

– Вәгаләйкүмәссәлам!

– Шәкертләрем, бүген дәрес булмый. Сез бүген дарелфөнүн шәкертләре түгел, сез бүген – яу ирләре! Барыгыз да яу киемнәрен киегез! Сөембикәбез үзен корбан итте, Ядигәр хан да әсир төште. Яугирләребез кырылып бетте. Авыр туфраклары җиңел булсын. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун. Мәскәү күз яшьләренә ышанмый! Бары бер юл кала – кылыч! Кылыч белән кергән – кылычтан кичәр.

Сөекле шәкертләрем! Мин сезне кылыч тотып Мәскәү капкасына барырга өндәмәдем. Мәскәү үзе килде Казан капкасына. Мин сезне Өстүк, Муром калаларын таларга да өндәмәдем, Өстүк белән Муром үзе килде Казанга яу белән. Мин сезне җиһад өчен кылыч тотарга өйрәттем. Вакыт җитте, шәкертләрем. Коръәнне янга куеп, Коръәнне җанга алып калкынырга форсат җитте. Капка төбендә дошман тора. Казан эче тулы кяферләр өере йөри. Кырым безгә ерак, ярдәм килмәс. Бүген Кырымның үз хәле хәл. Нугай килмәс, анысы – Мәскәү тарафдары. Башкорт та килмәс ярдәмгә, арабызда – Урал таулары. Көчебез дә аз, дарыбыз да юк, тупчыларыбыз да үлеп бетте. Кошчакны саттылар. Сөембикәбез корбан булды. Нишләмәк кирәк, шәкертләрем! Ләкин һәрберегезнең кулында икешәр кылыч бар. Кылыч сынса, билхәнҗәрләр кынысыннан чыгар. Хәнҗәр сынса, тешегез, тырнакларыгыз, нәфрәтегез бар. Безгә бүген җиңү булмас. Җиңү булмасын белгән көенчә, ни өчен бикяр шәһид китик яшьләй, дип әйтүчеләр дә бардыр арагызда. Вак җаныгыз бәрабәренә коллыкмы сатып алырсыз, шәкертләр? Мордар Камай мирза кеби, ике яклы пәке Ядигәр кеби, нәҗес Харис мирза кеби, Мәскәү әнчекләре Ширин Булат, Солтан бәк кеби? Шуны телиме кайберәүләр?..

– Әстәгъфирулла! – дип гүләде мәчет.

– Аллаһ исеме белән әйтәмен ки, андый кеше булса, китсен Иван ыстанына, аңа юл ачык. Валлаһи, димен ки, аңа кагылучы булмас. Аңа үпкәләүче дә булмас. Мин әчтән генә уйлармын: ничәмә-ничә еллар мин бу кешегә вәгазь сөйләдем, вәгазем бикяр, бифайда булган икән. Мөэмин кабыгы астында

монафикъ, мөшрик, кяфер, потпәрәст асраганмын икән, дип сызланырмын. Бармы арагызда исән калмак эстәгән берәүсе? Исән калып, гасырлар буена кол булып яшәргә теләгәннәр бармы?

– Юк! – диде шәкертләр.

– Машаллаһ! Балаларым, ачыгыз Коръәни Кәримне, табыгыз «Бәкарә» сүрәсенең 154 нче аятен. Дөрес, сез аны яттан беләсез: үә ләә тәкъуулүү, лимәй юкътәлү фии сәбилилләһи әмүәәтүм әхйәәүү – Аллаһ юлында һәлак булганнарга «мәет» димәгез. Алар үлми, алар, шәһид китеп, турыдан-туры Аллаһ хозурына барачак. Без дә шәһидләр. Без изге сугышта, җиһадта, Аллаһ юлында шәһид китәчәкбез. Аллаһ әмер итеп, ичмасам, берәрегез генә исән калып, иманын ташламаса, сөйләсен балаларына, оныкларына, сөйләсен торыннарына: без сугышып, аягүрә шәһид киттек. Әйе, җиңү безгә булмас. Дошман изге мәчетләребез өстенә хач кадаклар, ата-бабаларыбызның баш сөякләреннән үзенә һәйкәл салыр. Салсыннар! Вәхшилеккә дә гыйбрәт һәйкәлләре кирәк. Казан каласыннан таш өстендә таш калмас. Әмма вәхшилек дәлиле, нәҗеслекнең шаһиты буларак, каберләребез өстендә алар салган һәйкәлләр калыр. Ләкин безнең рухны, безнең җанны алар кимсетә алмас! Кимсенгәннәр, чыдый алмаенча, шул хачларны, тәреләрне, шул һәйкәлләрне шартлатырга, көлен күккә очырырга теләр. Шартлатмагыз дошман һәйкәлләрен! Зинһар, шартлатмагыз! Без вәхшиләр түгел. Шартлатмагыз каберләребез өстенә салынган чиркәүләрне. Алар – вәхшилекнең тере шаһитлары. Шартлатмагыз тере шаһитларны! Әмма сез, исән калганнарыбыз, оныкларыбыз, шул чиркәүләрдән дә, шул һәйкәлләрдән дә биегрәк, мәһабәтрәк мәчетләр салдырыгыз. Без – җимерүче халык түгел! Без – төзүче халык! Аларның үз дине, безнең үз динебез, әлхәмдүлилләә! Ләәкум диинүкум үәлийәддиин. Рухыбызны җиңә алмагач, дошман әнчекләре гайбәт тарата безем падишаһларыбыз турында. Сафа Гәрәй хан, имеш, сәрхуш булган. Сөембикә, имеш, фәлән-төгән кылган икән. Ышанмагыз сез нәҗесләрнең сүзенә. Ышанмагыз!

– Әстәгъфирулла! Ышанмабыз! – дип кычкырды шәкертләр.

– Балаларым, торыннарым, сезнең арада да булыр Мәскәүгә ярарга тырышып динебезне сүгүчеләр, хан-падишаһ һәм тарихыбызны хурлаучылар, изге ханбикәбезне дә кимсетерлек лаф оручылар. Ышанмагыз сез андый нәҗесләрнең сүзләренә. Без шаһит аларның сафлыгына. Без шәһид Аллаһ юлында. Биззат хирыс адәмнәр вак җаннары хакына олуг җаннарны сатып көн күрә. Иле барның – Иблисе булыр. Казанны җимерерләр, яугирләребез кырылып бетәр. Ләкин узар заманнар, шушы урында, безнең кан коелган җиребездә рухыбыз, манараларыбыз янә калкыр.

– Янә калкыр!

– Инанамын ки, торыннарым, менә шушы җирдә, без шәһид киткән урында, Кол Шәрифнең рухы сезгә вәгазь укыр! Аллаһу әкбәр!

Бөтен шәкертләр дә аякланды, аларның кулында кылыч, ук-җәя, сөңгеләр иде. Беравыздан тәкбир яңгырады:

– Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр! Ләә иләәһә илләллаһу, Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилл хәмде!

Бу яшь егетләрнең барысы да һәлак булды, Кол Шәриф үзе дә җиһадта шәһид китте. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун! Урыннары җәннәттә булсын!

Җиһад сугышында үлгәннәргә мәет димәгез, алар мәет түгел! Алар мәңге-мәңге үлемсез! Алар Аллаһ янында!

## Без җимерүче халык түгел

*Татарлар Һиндстанны җимерер өчен түгел, төзер өчен яулап алды.*

Җәвәхәрлал Нәһру

Элек, имеш, Казандагы ял бакчасының капкасына «Татарларга һәм этләргә керергә ярамый» дигән язу эленгән булган. Татарларны Казанга да кертмәгәннәр. Авылларыннан куптарып, шәһәрдән 40 чакрым ераклыкка куганнар.

Әле 50-60 еллар чамасы элек кенә, Казанны яулап алганда һәлак булган рус сугышчылары каберлеге өстендәге һәйкәлгә ат башы кадәр хәрефләр белән «В честь победы над татарами» дип язылган иде.

Ярый, халык сүз әйтә башлагач, ул язуны цинк йөгертелгән калайлар белән каплап куйдылар. Ләкин халык барыбер әледән-әле бу һәйкәлгә үзенең ризасызлыгын белдерә килде. Аннан соң татар зыялылары, теге һәйкәл янәшәсендә шәп мәчет корып куярга кирәк, дип тәкъдим итте.

Ләкин Шәймиевнең фикере башка юнәлештә иде. Ул күп уйлады бу хакта, уйлый-уйлый башы катты, күп тарихи китаплар укый-укый, ниһаять, бер нәтиҗәгә килде. Һәм ул инде тарихи шәхесләребезне хыялында күрә, алар белән сөйләшә, алардан киңәш сорый иде.

## Хыяллар тормышка ашканда

2009 елның 30 декабре, сәгать кичке алты.

Яңа елның үз вазифаларына керешер вакыты җитеп килә, Мәскәү Кремлендә хөкүмәт әгъзалары Яңа елны каршы алырга җыена. Шунда Россия премьер-министры Путин Татарстан Президенты Шәймиевне кабул итте.

Керә-керешли дип әйтерлек, Минтимер Шәрипович сүз башлады:

– Владимир Владимирович! Сез беләсез инде, мин Президентлыктан китәргә булдым, – диде. – Беләм, Казан сезгә бик ошый, Казан Кремлендә собор чиркәве белән янәшә мәчет басып тора. Сез безгә чит ил вәкилләрен, чит дәүләт башлыкларын юллыйсыз. Без толерантлык үрнәге булып торабыз, төрле дин тоткан милләтләрнең үзара дус, тату яшәү үрнәге башкаларга да бик кирәк. Бездә ике һәйкәл, федераль әһәмияткә ия ике дин йорты. Әйдәгез, шуларны торгызып, матурлап бөтен җиргә күрсәтик әле! Иделгә сәяхәтчеләр күпләп килә, шулай эшләсәк, сәяхәтчеләрнең саны күпкә артачак. Ә сез бүлеп биргән 15-16 миллион сум акча биналарны җимерелүдән туктатыр өчен дә җитми. Ә бу һәйкәлләр бит федераль әһәмияткә ия. Әйдәгез, иллегә илле булсын!

– Ничә сум кирәк? – дип сорады Путин.

– Өч-дүрт ел дәвамында, һич югында, яртышар миллиард.

– Һәр бина өченме?

– Юк, еллык бюджет. Аермаенча. Без Кремльне дә шулай аякка бастырдык. Бу бик тә кирәкле гамәл. Без фонд оештырырбыз, калганы халыкның ирекле рәвештә кергән акчасына булыр. Мин ышанам, халык безгә терәк булыр, дим.

– Әйдәгез болай итик – бер елга 400 миллион! Федераль бюджеттан һәм тәңгәл күләмдә Татарстан бюджетыннан.

Шәймиев сүзне озакка сузмыйча риза булды.

Менә шуннан Бөек Болгар белән Зөя каласын торгызу эше башланды.

Бу гамәлләр Татарстанны килеп күрергә теләүче сәяхәтчеләрнең санын күпкә арттырды. Ә иң әһәмиятлесе – Шәймиевнең әлеге гамәлләре халык күңеленә хуш килде!

## Эшләмәгән закон зарар эшли

*Кабул ителеп тә, закон эшләмәсә,*
*ул – җинаять.*

Минтимер Шәймиев

Татарстан Республикасы Конституциясенең 14 нче маддәсендә: «Татарстаннан читтә яшәүче татарларның милли мәдəниятен, ана телен, үзенчәлекле йолаларын сакларга Татарстан ярдәм итәчәк», – дип язылган.

Конституциядә маддә бар, ләкин закон юк. Ун ел узып китте бит инде югыйсә. Бу бит Илбашының республика күләмендәге тулы вәкаләтенә керә.

Советлар Союзында яшәүче татарлар бик күп иде. Бигрәк тә Урта Азиядә. СССР таркала башлауга ук, идея килде: барлык татарлар да Татарстанга кайтсын. Халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова әйтте:

– Татарларны Татарстанга кайтару өчен закон кабул итәргә кирәк! – диде.

Шәймиев бу тәкъдимгә каршы төште. Һәм халык хадимнәренең күбесе Илбашы яклы иде. Ни өченме?

– Кайткан татарларга без нәрсә тәкъдим итә алабыз? – дип сорады Илбашы. – Карагыз сез: фатир алыр өчен озын чиратлар, балалар бакчасына чиратлар һәм авыр чишелә торган башка мәсьәләләр... Әгәр дә Татарстанга миллионнан артык кеше кайтып төшсә? Алар зур өметләр белән кайтыр, өметләре акланмаса, күңелләре төшәр, безгә үпкәләр. Безнең җирле халык та алардан риза булмаячак. Өстәмә киеренкелек килеп чыгачак. Уйлашырга кирәк, кулдан килгәнне эшләрбез, җаен табарбыз. Конституциядә каралган юнәлештә даими эш алып барырбыз.

Шуңа күрә ул турыда закон кабул ителмәде. Законны кабул итәсең икән, аны үтәргә кирәк. Нигә, үти алмаган көенчә, халыкны өметләндерергә?

## Иман нуры

*Аллаһ (диненең) нурыннан кайсы (диннең) нур(ы) күркәмрәк? Без Аллаһ (диненә, Коръән) нурына коендык.*

Коръән, 2:138

*– Шәймиев Советлар вакытында коммунист иде, хәтта Татарстан коммунистларының җитәкчесе дә иде. Коммунист ул – дәһри, динсез кеше дигән сүз. Хәзер әнә дөньяда булмаган зурлыктагы Коръән эшләтте, Кол Шәриф мәчетен төзетте, Болгарны яңартты...*
*– Шәймиев Зөя каласын да яңартты, әмма ул христиан булды дигән сүз түгел бит әле.*

Үзара сөйләшүләрдән

Минтимернең бу сорауга җавабы күп кешене канәгатьләндермәс, бәлки. Әлбәттә, ул – мөселман ата-анадан туган шәхес. Моның өчен «кем ул мөселман кешесе?» дигән сорауга җавап бирергә тырышырга кирәктер. Кем намаз укый,

кешеләргә игелек кыла, кем шәригатьчә яши... Шәймиев, башка бик күп татарлар кебек үк, бу кагыйдәләрнең барысын да үти алмый.

Шәймиевнең җавабы:

«Әгәр дә Аллаһы Тәгалә, мөселман ата-анадан туганыма күрә, мине ничек бар, шулай кабул итсә, мөселман буларак, мин үземне бәхетле санар идем. Бу мәсьәләне Тәңре хәл итә! Мин башка бер динне тотмыйм. Анам динле гаиләдә үскән, аның бабасы да, атасы да динле, энесе хәтта мулла булган.

Безнең Татарстан – күп динле дәүләт. Дин дәүләттән аерылган. Мин югары дәрәҗәдәге җитәкчеләрнең мәчеткә, чиркәүгә йөрүен һич гаепләмим. Ихластан ышансалар, йөрсеннәр. Президент буларак, мин ниндидер күләмдә урталыкны тотарга тырыштым. Ә адәми зат буларак, күп кеше катнашкан гыйбадәтләргә бара алмыйм, мин әле бу эшкә әзер түгел. Минем иманым – күңелемдә, һәм ул иман җаныма куаныч өстәп тора. Мин үземне мөселман дип саныйм, гәрчә шәригать кануннарын төгәл үтәп бара алмыйм. Ни өчен әле мин ялганларга, үз-үземне алдарга тиеш? Бу иң башта үз намусым каршында монафикълык булыр иде. Ә Аллага ышануым бар, шөкер. Ләкин ихлассыз гына мәчеткә йөрү әхлаклылыкмы икән? Әтием атеист булса да (бәлки, ул атеист булып күренергә генә тырышкандыр), авыргач, шәригатьчә яши башлады...»

Ислам җәмгыять, дәүләт һәм башка диннәр өчен куркыныч түгел. Коръәндә язылган: кем Коръәнгә ышана, Аллага да, ахырзаманга да ышана һәм башкаларга игелек кыла, шуңа савап булыр, аны Алланың әҗере көтәр. Ислам, нигездә, тынычлыкка, толерантлыкка өнди. Беренчедән, ислам дине Идел буенда 922 елга чаклы ук киң җәелгән була. Бу безнең илебезгә очраклы гына китереп кертелгән дин түгел, Россия җәмгыятенең нигезе булган православие белән беррәттән урын алган дин. Ислам дине бөтен кешелек өчен васыять әйтә: кеше җанын кыйма, якыннарыңны сөй, гаиләңне ныгыт, хезмәт ит.

Библиядә: «башка илаһларга табынма, потларга (кумирларга) табынма, кирәксә-кирәкмәсә дә минем исемем белән ант итмә, ял итәргә (Аллага гыйбадәт кылырга) онытма, ата-анаңны хөрмәт ит, гөнаһсыз кешене үтермә, зина кылма, урлама, ялган шаһитлык кылма, башкалар йортына басып кермә, көнләшмә», диелә. Ислам да, христиан дине дә әнә шундый әхлаклы кешеләрне тәрбияләргә тиеш. Аларның максаты уртак...

Исламны көч белән кертеп булмый. Ислам ягыннан нинди куркыныч янарга мөмкин кешелеккә? Янәсе, ислам байрагы астына сыенып җинаять кылучы террорчылар бар. Алар олы гөнаһ кыла... Инанамын ки, террорчыларның максаты – төрле дин кешеләрен чәкәштерү, дөньяны мөселманнарга каршы котырту. Без бу котыртучылар ягына авышырга тиеш түгел...

Анысы шулай, тик менә безнең кайбер муллалар, имамнар ни өчен Пәйгамбәребез васыятен тотмый икән? Алар иң кыйммәтле иномаркаларда җилдерә, миллион долларлар торган коттеджларда яши, балаларына, оныкларына кыйбатлы машиналар, фатирлар бүләк итә. Сәдака акчасынамы, әллә мәчетләр салдырыр өчен Гарәбстаннан җибәрелгән акчагамы шулай кылана алар?

Динебез тирәсендәге каршылыклар Илбашы өчен еш кына аерым бер катлаулы мәүзугъ була килде.

Канатлы барс сынын кабул итәр алдыннан, ул имамнарны киңәшкә чакырды. Имамнар барс сынын мәчет янына куюга катгыян каршы төште.

– Әгәр дә сез бу сынны мәчет янына куярга риза түгел икән, шулай булсын! Сез хәзер ислам, дин, Болгар турында күп сөйлисез, бик яхшы, сез бу һәйкәлләр турында кайгыртасыз икән, мактау сезгә!.. – диде Илбашы.

Беләсезме, җыелган имамнар арасында күбесе мәгънәви кыйблабыз Болгар белән кызыксынып та карамаган булып чыкты. Бер Тәлгат хәзрәт Таҗетдин генә Болгарга озак еллар буе шәкертләре белән барып гыйбадәт кылды. Ә исламны рәсми кабул итү урынына имамнарның күбесе барып та карамаган. Гаҗәпләнергә генә кала!..

Тукай да диннән түгел, аерым ишаннардан көлгән. Шагыйрь үзе динне бар вөҗүде белән кабул иткән. Вакытында аерым милләтчеләр шушы мәсьәләдә Тукайга кара ягарга да маташып карады. Юк, Тукай дингә каршы түгел, ул кайбер динчеләрнең ярамаган якларыннан көлә. Тинчурин да диннән түгел, әдәпсез, демагог, әхлаксыз ишаннан көлә. Тукай да, Тинчурин да саф динне әнә шул кибәк башлы ишаннардан тазартырга теләгән.

Дин җитәкчеләренә ана теле, татар тарихы сабакларын өйрәтәсе бар. Алар, Гарәбстанга барып, гарәп телен, динне өйрәнеп кайта, ә ана теле юк, татар тарихы юк. Андый мулла ничек итеп тулы мәгънәле вәгазь сөйли алсын? Шуңа күрә инде хәзер муллалар урыс телендә вәгазь сөйли башлады.

– Болгарда шәп мәчет төзелде, югары уку йорты – академия корыла, – диде Минтимер Шәймиев. – Һәм очраклы гына түгел. Болар – бик озак һәм күп уйлануларның нәтиҗәсе. Теләк изге, монда, имамнарны сыйфатлы тәрбияләү максаты белән, шундый яхшы шартлар тудырыла. Без төрле мәдрәсәләрдә укыган ихлас инанучы егетләрне бер урынга тупларга һәм, аларга ныклы белем бирүне максат итеп, абруйлы дин әһелләрен, дин галимнәрен чакыртырга тиеш.

Бирсен Ходай! Амин, шулай була күрсен берүк!

Россия Ислам институты имамнар әзерләү белән актив шөгыльләнә. Болгардагы академия турында сөйләгәндә, без, дин әһелләренә тагын да тирәнрәк белем бирү өчен, мәркәз корабыз.

Кеше имансыз яши алмый. Иң мөһиме: изге хисләрдә уйнап, халыкның башын катырмаска иде. Кеше өмет, иман белән яшәргә тиеш. Иман башка диндәгеләргә каршы эшләргә тиеш түгел.

Бер дин эчендәгеләр дә төрле мәзһәпләргә, секталарга бүленеп, фанатикларга әверелеп бетәргә мөмкин. Коръәннең үзендә язылган: диндә артыгын кыланмагыз, хәттин ашмагыз, диелгән...

Чыннан да, Татарстан мөселманнары арасында да төрлелек бар иде, кем әйтмешли, хәтта һәр имам аерым-аерым мөфтиятләр корырга тәдбир тоткан иде. Кемдер, намаз укыганда кулларны кендек тирәсендә түгел, йөрәк турысында тотып укырга, дип өйрәтә; кемдер, мәрхүмнәр кабере янында Коръән укылырга тиеш түгел, дип сөйләнә; хәтта кайбер муллаларның Коръән ашына түбәтәйсез килгән яшь егетләрне Коръәнне тыңлатмыйча мәҗлестән куып чыгару очраклары күбәйде. Беренче карашка кечкенә кебек күренгән аермалыклар да кешеләрне бер-берсеннән читләштерә, ызгыштыра, абыстай белән абыстай, мулла белән мулла аш мәҗлесендә «син дөрес укымадың, син дөрес әйтмисең», дип гауга куптара икән, бу инде бернинди кысага да сыймый.

Дингә кайту, тәүбә итү, җимерелгән мәчетләрне кайтару, яңадан торгызу чорына килеп җиттек, шөкер. Советлар вакытында Татарстанда нибары унөч мәчет эшли иде, Казанда – берәү. Бүген исә һәр авылда, һәр мәхәлләдә яңа мәчет балкып тора.

Дин иреге килгәч, берничә имам Татарстанда мөфти урыны өчен көрәшә башлады, үзләренә аерым мөфтият кору белән мәшгуль булды. Дин дәүләттән аерылган аерылуын, әмма дин җәмгыятьтән аерылмаган бит. Әгәр дә һәр имам үз мөфтиятен оештыра калса, мөселманнар аеры-чөере килеп бетәр иде.

Илбашы бу очракта ни кылырга тиеш? Милләтнең таркалуын, бердәмлеген югалтуын кул кушырып, битараф рәвештә күзәтеп утырырга тиешме?

Инде дә имамнар аерым ике корылтай җыярга ниятләгәч, ул аларны чакырып сөйләште.

– Бездә ислам бер, Коръән бер түгелмени? Без сөнниләр түгелмени? – диде аларга Илбашы. Татарларга, болгарларга, мишәрләргә, тагын әллә кемнәргә аерылырга торган халыкны инде дини секталарга да аерыйкмы?

Имамнар тарткалашты, киреләнде – кыскасы, алар риза түгел иде.

Илбашы шунда үз холкына хас булмаган кырыслыкка күчте.

– Татарстан мөселманнарының бер корылтае булачак, Татарстанда бер генә мөфти булачак! – диде ул. – Аңлашырга теләмисез икән, корылтай да үтмәячәк. Сезнең корылтайга бер генә вәкил дә килмәячәк! Төбәк башлыклары бер генә автобус та бирмәячәк, юллар ябылачак!

Ни өчен Илбашы әлеге эшкә килеп катнашты соң? Чөнки муллалар үзләре сәясәткә кереп китте. Президент бу эшкә битараф кала ала идеме?

Әгәр җәмгыять берничә дин һәм секталар аркасында фанатиклар өеренә әверелә икән, моның өчен Президент җавап бирергә тиеш, шул исәптән, яңа законнар кабул итеп булса да.

Шулай итеп, Татарстан вак мөфтиятләргә бүленүдән котылып калды.

## Ватанпәрвәр

«Патриот» кәлимәсен ана телебездәге «ватанпәрвәр», «илсөяр», «ватансөяр» кебек сүзләр белән алыштырып булыр иде.

Минтимер Шәймиев, хакимияттә утырганда, ватанпәрвәрлек, йорт җанлылык, илсөярлек хисләре тәрбияләү максаты белән, бик күп чаралар уздырган иде.

Ә нәтиҗәсе кайда?

Шәһәр буйлап барганда, Шәймиев һәрвакыт уфтанып куя иде. Уфтану гына түгел, көрсенү иде ул. Көрсенмәслекмени, урам чүп-чар белән тулган: трамвай, автобус тукталышлары кулланылган билетлар белән түшәлгән; кеше автобустан төшкән, әмма билетын якындагы чүп савытына ташламаган; эчкән, әмма шешәсен чүплектә калдырмаган. «Шулай бервакыт, шәһәр читендәге табигать, ял бакчалары чиста булсын дип, чатырлар куеп, яшьләрне табигатьне чистартырга чакырдык. Яшьләр көлешә-шаярыша җыештырды инде, шунысына рәхмәт, ләкин чатырлар белән генә чисталыкны саклап буламы икән? Хакыйкать тирәндәрәк ята булыр – безнең миебездә», – дип искә алды бу җәһәттән Шәймиев.

Әйе, күмәк мал ул беркемнеке дә түгел, ә хосусыйлык, «минекелек» канда булырга тиеш. Уртак малны эт җыймас!

Дөрестән дә, бу гамәлләр, чаралар ватанпәрвәрлек тә, эчке культура да тәрбияләмиме. Яшьләргә кушканнар, алар мәҗбүр, аларны оештырып җибәргәннәр, җитмәсә – ял көне. Алар бу эшкә күңел ачу дип кенә карый. Ә үзгәрер өчен... Монда бер генә буын дәвамында түгел, күп еллар буе башка, үзгә мохиттә тәрбия алырга кирәк...

Чит илгә күчеп яки мәҗбүри качып киткәннәр патриотмы, түгелме? Әйтик, Йосыф Акчура, Әкъдәс Курат, Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Муса Биги, Зәки Вәлиди, София Гобәйдуллина, Чыңгыз Әхмәров, Латыйф Хәмиди, Рудольф Нуриев... Алар ватаннарын сөймәгәнме, аларда туган илгә, Татарстанга

тартылу, җирсү булмаганмы? Ничек кенә җирсегәннәр әле! Монда иҗат итәргә мөмкинлекләр кысан булганга, аларга сөекле ватаннарын ташлап китәргә туры килгән. Ә күбесе совет властен кабул итмәгән, алар ватанга түгел, режимга нәфрәтле булган.

Ә Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете, хәрабәләр арасыннан калыккан Болгар бер ватанпәрвәр татарлар өчен генә түгел, ул – ЮНЕСКО, бөтен инсаният байлыгы.

Йорт җанлылыкны өйдәге мохит, гаилә һәм халык йолалары тәрбия кыла.

Шәһәр җанлыларны шәһәр мохите үстерә.

Илсөярне, ватанпәрвәрне бөтен ил тәрбияли.

Ватанпәрвәрлекне тарих, каһарманнарыбыз, легендаларыбыз, әдәбиятыбыз, йолаларыбыз шәкелләштерә.

*«Минем инануым, традицион мәдәниятем, анам теле, ни генә булса да, юкка чыгарга тиеш түгел.*

*Баланың дөньяга килүе, аерым алганда, һәрберебезнең тормышы – саф очраклылык, Алланың бүләге. Фәнчә аңлатканда, ул болай: чагыштырмалылык теориясе нигезендә, минем урында башка бер кеше утырыр иде. Соң, шушы бәхетле форсаттан файдаланып кал: башкаларга игелек кыл. Һәр фанатизм ул – башкаларга зыян, димәк, ул тыелырга тиеш. Сез миннән фанатик ясый алмыйсыз инде. Һәм миннән фанатик ясарга тырышмагыз да. Димәк ки, мин сабый чагымнан ук рөхсәт ителгәннәрне генә кылырга тиеш».*

*Минтимер Шәймиев*
*2013*

## Кантарлы милләт

– Без – аерым милләт! Безгә аерым дәүләт бирегез! – дип, янәмәсе, татарлар, керәшеннәр, башкортлар, нугайлар, мишәрләр, Кырым татарлары, типтәрләр Сталин янына кергән, ди.

Сталин, боларны тыңлый-тыңлый, төрепкәсенә тәмәке төя икән. Төрепкәсен тутыргач, халыклар атасы, ниһаять, сүз башлаган:

– Я нэ знаю таких наций как кряшены, типтары. И у русских есть тоже разнавидности: киржаки, кацапы, что, по-вашему, мы дадим атделную Киржакскую и Кацапскую автономию? Я знаю мошный единый татарский народ. Нэ надо делить единый татарский народ!

Сталин, төрепкәсен кабызып, тирән итеп төтен суырып, татарлар, керәшеннәр, типтәрләр күзенә төтен җибәргән һәм: – «Приём окончен!» – дип чыгып та киткән.

Хәйләкәр Сталин, барысына да автономия бирә калса, ни буласын чамалаган, билгеле. Кырым АССР, Башкорт АССР, Татар АССР, Нугай АССР, Мишәр АССР, Керәшен АССР төзелә калса, барысының да Академия театры, Фәннәр академиясе, җыр-бию ансамбльләре, судлары булыр иде. Тугандаш телдә сөйләшүче алты дәүләт барлыкка килер иде.

– О-о, атабыз Сталин акыллы икән, ул халкыбызны вакларга теләми, олы халык итеп күрә икән, – дип, татарлар шатланышып кайтып киткән, ди.

Шулай итеп, нибарысы өч автономия: Татар АССР, Башкорт АССР, Кырым АССР барлыкка килә. Тора-бара Джугашвили татарларны Кырымнан сөреп чыгара, аннан соң Казан татарларын куарга план кора.

Сталин өргән төтеннән татарларның күзеннән әле һаман яшь ага, ди...

## Ут күршеләр

*Күрше хакы – Тәңре хакы.*
Халык мәкале

*Лев Овруцкийның «Минтимер Шәймиев белән әңгәмәләр» дигән китабыннан*

О в р у ц к и й . *Я очень хочу расспросить о ваших отношениях с Муртазой Рахимовым и вообще о татаро-башкирской проблеме. Ведь Вы вместе с Рахимовым входили в состав руководства «Единой России», Вы как бы одной крови, тяжеловесы и всё такое. Но мне вот говорили, Хакимов говорил, что у Вас личные отношения очень неважные. Я говорю: «Что, он боится испортить отношения?» А Хакимов выразился так: «Нет, мол, не боится, там уже портить нечего».*

Ш а й м и е в . Так и сказал?

О в р у ц к и й . *Да, Хакимов.*

Ш а й м и е в . Знаете, у нас человеческие отношения плохими не могли быть, мы друг друга не знали.

О в р у ц к и й . *Нет, речь не о человеческих отношениях, о политических...*

Ш а й м и е в . Рахимов – хороший хозяйственник...

О в р у ц к и й . *Да, у него же сходная с Вашей карьера. Он тоже хозяйственник*.

Ш а й м и е в . Нет, нет. Весь вопрос в том, что у нас несколько разные пути в жизни. Хотя и я в молодости стал руководителем, потом была серьёзная обкомовская и правительственная школа. А он всю жизнь был успешным руководителем нефтехимического комплекса. То, что в Башкортостане мощный нефтеперерабатывающий комплекс, это, конечно, всегда было заслугой первых секретарей обкома КПСС. Пробивать же надо было строительство, и они пробили. Самый крупный нефтеперерабатывающий комплекс, состоящий из нескольких заводов – в Башкортостане. Они могли до 60 миллионов тонн нефти в год перерабатывать.

О в р у ц к и й . *Страшно представить – 60 миллионов!*

Ш а й м и е в . Муртаза – крупный авторитетный руководитель нефтепереработки Башкортостана. Я его впервые увидел, когда к нам, кажется, на юбилей Татарстана приехала башкирская делегация. Он был в составе делегации – первый секретарь, председатель Совмина, писатель Мустай Карим и Муртаза. Просто так человека в такую делегацию не возьмут. Я тогда был, кажется, председателем Совмина. Я с ним познакомился в то время. Потом годы перестройки, он был избран Президентом. Почему Муртаза Губайдуллович очень прямой, резкий в заявлениях?

О в р у ц к и й . *Даже грубый.*

Ш а й м и е в . Я не хочу использовать это слово. Дипломатической жилки у него не было?

О в р у ц к и й . *По-моему она не выработалась. Что ещё хочу сказать? Татарстан по своему развитию в то время отставал от Башкортостана, надо это признать.*

Ш а й м и е в . Да? По экономическому, социальному развитию? Конечно, Татарстан уступал. Во-первых, там же кроме нефти и золото есть, и уголь, и металл. Богатая республика. И в два раза больше по территории, значит, и природных богатств больше. К тому же мне, может быть, неудобно об этом

говорить, но в Башкортостане всегда были очень авторитетные, опытные руководители, первые лица республики.

Овруцкий. *До Рахимова?*

Шаймиев. Да, конечно, до Рахимова. Все сильные личности. Отношения между руководителями Татарстана и Башкортостана никогда не были простыми. И при Табееве антагонизма не меньше было. Фикрят Ахметзянович пришёл молодым, и они с Гумером Исмагиловичем за два десятка лет для республики сделали очень много. Пробивной силы, хозяйственной жилки у башкир на каком-то этапе было больше. Это объясняется ещё и тем, что они мощно воспользовались нефтяной промышленностью. По сельскому хозяйству мы и близко не могли подойти к башкирам.

Овруцкий. *Да? У них лучше было?*

Шаймиев. Мы постоянно ездили к ним учиться. И зависть у нас была – белая зависть. Завидовали тому, как они развивали сельское хозяйство. Конечно, мы за последнее годы их обошли... Да, мы обошли. Хотя у них земли больше. По сбору зерна даже обошли и по животноводству, по всем показателям. Может быть, у них нефть раньше начали осваивать, и она быстрее выработалась – это возможно. И то, когда я уже Президентом стал, мы обсуждали, что должны упасть по добыче нефти к 2010 году на 17 миллионов тонн в год.

Овруцкий. *А пока идёт нормально – 30.*

Шаймиев. 32 даже. Мы и не хотели особо форсировать, по расчётам должен был объём добычи придерживаться порядка 30 миллионов тонн в год. Мы неоднократно обсуждали, как приостановить падение добычи нефти. Башкортостан, я не хочу за них отвечать, но они слишком резко упали по добыче нефти. Нам вскоре удалось остановить падение через налоговые послабления и внедрение новых технологий.

Овруцкий. *Соответственно, в этой связи и лоббистские возможности изменились. Вы в политике выскочили вперёд. Теперь уже они шли за вами.*

Шаймиев. Это да. За все годы перестройки они раньше нас ни одного политико-экономического решения не принимали.

Овруцкий. *А ревность сохранялась, теперь уже с их стороны.*

Шаймиев. Состязательность сохранялась... А как иначе? Повторю, нам удалось остановить падение добычи нефти. Тут надо отдать должное нашим учёным, специалистам и руководителям «Татнефти». Конечно, жёсткий у нас был план – остановить падение и начать подъём, использовать новые методы и так далее. Башкиры этого не смогли сделать. У них сейчас половина нашей добычи. Ни по сельскому хозяйству, ни по ряду других отраслей они не смогли реализовать долгосрочных планов... Что я хочу сказать? Когда существовал Союз, там политических вольностей не было, интересов было больше из-за экономики. Эти две республики боролись, куда посадить КамАЗ. То, что он у нас – это победа Фикрята Табеева. Башкиры тоже претендовали по ряду вопросов. Состязательность была во всём.

Овруцкий. *Вследствие соцсоревнований.*

Шаймиев. Да. А потом уже пошли политические проблемы. Декларация о государственном суверенитете появилась. Тут на первый план вышли проблемы национальностей. Раньше они не настолько обострёнными были.

Овруцкий. *Раньше вообще не было национальных проблем.*

Шаймиев. Национальный вопрос всегда был и будет. Когда началась перестройка, пошли волнения, башкирские татары стали собираться на том

берегу реки Ик – она берёт начало на границе Татарстана с Башкортостаном, по-моему, на башкирской территории. Они заявили, что эти земли должны отойти Татарстану.

Овруцкий. *Я не знал про это.*

Шаймиев. Это было.

Овруцкий. *Почему-то нет работ на эту тему.*

Шаймиев. Мы не хотели, чтобы информация особенно распространялась. В тот момент это было архиопасно.

Овруцкий. *Да, националы... Башкирские националы тогда солидарствовали с нашими, как я понимаю.*

Шаймиев. Когда это началось, я звоню Рахимову, он тоже обеспокоен. Я говорю: надо встретиться. Говорю: учитывая, что татар больше в Башкортостане, чем башкир у нас, будет более понятным, если я к тебе прилечу. Я полетел к нему, мы подготовили договор – договор о дружбе в новых условиях.

Овруцкий. *Я Ваше выступление читал.*

Шаймиев. И мы тогда подписали этот договор, как ответ националам, мол, ребята, не бушуйте.

Овруцкий. *Хотели снять вопрос.*

Шаймиев. Во всяком случае мы сделали тот шаг, который должны были сделать в тот момент. Не случайно я туда полетел. Если бы Рахимов сюда прилетел – а тогда у нас было, по-моему, 11 тысяч башкир в Татарстане, – то смысла большого не было бы. У них же татар больше, чем башкир. Башкиры у них в республике – третья нация по численности, без приписок. Когда свобода началась и так далее, Муртаза резко изменил отношение к татарам. Начал их по языку притеснять. Во время Всероссийской переписи населения эта работа шла самым непозволительным образом, татар просто заставляли записаться башкирами, такие у нас сведения. Но мы не могли вмешаться.

Овруцкий. *Почему?*

Шаймиев. А как вмешаться, в какой форме?

Овруцкий. *Можно было инициировать какие-то статьи в центральной прессе, ещё что-то.*

Шаймиев. Это было, но мало могло повлиять. Рахимов никого не слушал. В то же время, ради объективности: а как бы я поступил на месте Рахимова? Я этот вопрос сам себе задавал. Хотя об этом открыто нигде не высказывался. Могу ответственно заявить: я никогда не пошёл бы на запрет татарстанского телевидения в Башкортостане. Или башкортостанского телевидения в Татарстане. В наш век пойти на такой шаг – выше моего понимания.

Овруцкий. *Вы были как враждебные государства.*

Шаймиев. Только при Президенте Хамитове разрешили.

Овруцкий. *Когда пришёл новый Президент. А что, спутниковый канал «ТНВ» нельзя было принимать там?»*

Шаймиев. Нельзя было. Они вышки не ставили, кабель не разрешали.

Овруцкий. *Я не знал.*

Шаймиев. Это объяснимо.

Овруцкий. *То есть татары запада Башкирии не могли слушать даже татарское радио?*

Шаймиев. И это в условиях развивающейся свободы. Я задумался: когда в республике, где ты являешься Президентом, русских и татар больше, чем коренной нации, как бы ты вёл себя?

О в р у ц к и й . *Я очень рад, что Вы задавали себе этот вопрос. Было бы интересно услышать Ваш ответ.*

Ш а й м и е в . Да, я задавал себе этот вопрос.

О в р у ц к и й . *Что бы Вы делали на месте Рахимова? Запретили бы телевидение? Записывали бы татар башкирами?*

Ш а й м и е в . Нет, запрещать телевидение мне и в голову бы не пришло. Мне кажется, наше телевидение он запрещал больше из-за информации по экономике.

О в р у ц к и й . *Из-за экономики? В каком смысле?*

Ш а й м и е в . Он человек самолюбивый, а показатели наши...

О в р у ц к и й . *Что, можно утаить показатели?*

Ш а й м и е в . Да. Чтобы информация была не каждый день. Татар же много, да и башкиры будут смотреть, есть смешанные браки. Он очень ревностно относился к нашим показателям.

О в р у ц к и й . *Зависть, о которой Вы говорили, свойственна и башкирам.*

Ш а й м и е в . Он болезненно воспринимал это. Может быть, из-за того, что всю жизнь был успешным директором.

О в р у ц к и й . *Понятно, для него это особенно чувствительно.*

Ш а й м и е в . Что тут возобладало, даже трудно сказать. Во всех своих выступлениях постоянно твердил, что у нас в Башкортостане лучше, чем в других регионах России. Иную информацию просто не пропускали. В части численности населения руководитель любой республики проявил заботу. Но нельзя же было работать, ущемляя права человека, настаивая на том, чтобы он отнёс себя к определённой нации.

О в р у ц к и й . *А как бы Вы работали? Как бы за численность нации боролись? Как тут можно бороться? Кто хочет, тот и записался. Вы бы какие-то льготы для башкир сделали бы, наверное?*

Ш а й м и е в . Мои размышления об этом сводятся к такому выводу – лучше не вмешиваться в процесс. Во-первых, татары и башкиры – очень близкие народы. У нас много общего, нежели различий. Во-вторых, вмешательство властей в перепись населения оставляет неприятный осадок у многих.

О в р у ц к и й . *Вы извините, но у нас же множество таких республик. Марийцев меньше, чем...*

Ш а й м и е в . Это вызвано тем, что татар в Татарстане порядка двух миллионов, и в Башкортостане – более миллиона человек, в других областях – сотни тысяч. Но попытки реально поменять баланс – дело бесполезное...

О в р у ц к и й . *Ну да, это другое дело.*

Ш а й м и е в . И сказать, что в сложившихся отношениях только Рахимов виноват, так тоже ведь не скажешь. Я к чему это говорю? Нам хочется, чтобы татарский язык там был, татарские уроки в школах не сокращались. Я эти вопросы неоднократно перед ним ставил...

О в р у ц к и й . *Он же обещал даже, но не сделал.*

Ш а й м и е в . Да, когда выборы были. Более того, Муртаза Губайдуллович не прошёл в первом туре, у нас был разговор с Сурковым. Сурков же поехал туда. Я говорю: Владислав Юрьевич, он обещал, что рассмотрит статус татарского языка, вы этот вопрос поставьте перед ним, пожалуйста. Это было перед вторым туром выборов. Тогда Сурков вмешался. Рахимов обещал и ему. Сурков мне потом звонил и говорил: мы договорились, найдут решение по повышению статуса татарского языка. Но Муртаза не сдержал своего слова.

Овруцкий. *А Вы ему напомнили? Мол, ты же обещал нам?*

Шаймиев. Конечно, напомнил.

Овруцкий. *И что?*

Шаймиев. Став Президентом, он спустил проблему на тормозах. Хотя во втором туре, после обещания, татары его дружно поддержали.

Овруцкий. *Кинул, по-нашему.*

Шаймиев. Кинул.

Овруцкий. *А Вы пытались на него воздействовать через федеральный центр?*

Шаймиев. В федеральных кругах есть политики, которые по поводу наших республик придерживаются принципа «разделяй и властвуй».

Овруцкий. *Поэтому Вы к истории с переписью так эмоционально отнеслись. Я не очень понимал, что это за проблемы, то есть я знал, что идёт раздробление, но всегда считал, что численность – это десятое дело. И если человек себя чувствует татарином, он татарин и есть.*

Шаймиев. Уменьшение численности татар одним разом на триста тысяч – без радикального вмешательства это нереально!

Овруцкий. *Ваш аргумент был не очень корректным. Вы говорили: перепись при советской власти проводили, было так, а зачем, откуда теперь взялись эти?..*

Шаймиев. Почему некорректно? По их переписи получается, что татары и башкиры – народы одной религии и общих традиций, но при этом как будто резко отличаются по рождаемости. Наивно!

Овруцкий. *Но по какому принципу эти переписи проводились? Там – по советскому принципу, тут – по европейскому.*

Шаймиев. Ничего подобного.

Овруцкий. *А в чём была идея – ослабить татар?*

Шаймиев. Рахимову хотелось, чтобы башкир стало больше.

Овруцкий. *Это я понимаю. А почему Тишков и другие люди? Я просто не видел в том злого умысла. Меня Хакимов убеждал. А я не могу разобраться. Я не понимаю, в чём умысел против татар? Татары – вторая государствообразующая нация, они останутся второй нацией при любой переписи. И кто следующий, украинцы?*

Шаймиев. А почему мы должны терять по 300 тысяч только из-за того, что кому-то так захотелось?

Овруцкий. *Нет, а кто следующий? Евреи!*

Шаймиев. Как вы мне рассказывали, евреи берут качеством.

Овруцкий. *Что изменится – люди перестанут себя чувствовать татарами?*

Шаймиев. Люди не перестанут. Вы же демократ, вы же не хотите, чтобы заставляли людей менять национальность.

Овруцкий. *Там заставляли, я согласен. С этим-то у меня нет никаких проблем – там вообще гнусно было. Насчёт башкир никаких возражений нет. Полностью согласен. Наоборот, я говорю, я Вас не упрекаю в бездействии, как и националы.*

Шаймиев. Каким образом я ещё должен был действовать?

Овруцкий. *Я не знаю. Вы же задавали себе вопрос. Не знаю, как действовать – через федеральный центр, который мог какими-то санкциями заставить их вести себя прилично.*

Ш а й м и е в . Писать-то писали. Вы спрашиваете, были ли статьи? Были, но далеко не всегда доходили до читателя. Могли ли они как-то повлиять при таком грубом давлении?

О в р у ц к и й . *Мне казалось, Вы тогда проявили очень большую осторожность, слишком большую.*

Ш а й м и е в . Вы упускаете из виду важный момент: было ли когда-либо в Башкортостане так, чтобы руководителя республики удалось избрать только со второго захода...

О в р у ц к и й . *Ведь всё-таки речь шла о миллионах людей, Ваших, как говорится, татар.*

Ш а й м и е в . В ходе выборов Президента Башкортостана татары сыграли важную роль.

О в р у ц к и й . *Я бы, честно сказать, дал бы ему понять дипломатическим путём, что мы поддержим национальные движения башкирских татар на воссоединение с Татарстаном – или ты дай им статус. Как угрожали Москве в этом плане. Мол, ребята, у нас очень сильная национальная организация...*

Ш а й м и е в . Коль Муртаза во втором туре заявил, что статус татарского языка в Башкортостане повысят, я должен был поверить его заявлению. У нас так принято.

О в р у ц к и й . *Может быть, тут общая проблема, которая заключается в том, что нет национальной политики?*

Ш а й м и е в . Отсутствие национальной политики – это всегда основная причина.

О в р у ц к и й . *Не хотят усиливать татар, да? Боятся усиления татар?*

Ш а й м и е в . Мне показалось, своим вопросом вы уже ответили.

О в р у ц к и й . *По вашему ощущению.*

Ш а й м и е в . Это не ощущения.

О в р у ц к и й . *Какие есть факты?*

Ш а й м и е в . Ну, вы историю, наверное, знаете. Или, может быть, вы этим конкретно не занимались. Ведь после революции 1917 года был предрешён вопрос о создании Татаро-Башкирской республики... Это же очень серьёзно. Идея была совместная, Татаро-Башкирская... Вы представляете, что такое Татаро-Башкирская республика?

О в р у ц к и й . *Кошмар. А ведь вроде бы родственные народы, почти один язык.*

Ш а й м и е в . Без проблем, один язык фактически, культура вообще одна.

О в р у ц к и й . *Хакимов вообще говорит – башкир нет, мы их придумали.*

Ш а й м и е в . Я сказал бы так: есть прекрасный братский башкирский народ. У нас языковая разница между татарами и мишарами, пожалуй, не меньше, чем между татарами и башкирами. Долгое время у нас был один, общий литературный язык.

О в р у ц к и й . *Мы, Хакимов говорит, алфавит создали, язык придумали. Почему об этом нужно молчать, если это правда?*

Ш а й м и е в . Это дело историков-исследователей. Политики же исходят из сегодняшних сложившихся реалий.

О в р у ц к и й . *Я читаю Аксакова – он купил земли в Башкирии, и там были татарские селения. По уровню развития, видно по описанию разница была колоссальная. Татары – совершенно цивилизованные крестьяне, а башкиры – дети кочевников. Язык один и культура одна, Вы говорите, но непонятно, как*

*культура может быть общей? У одних оседлая жизнь, другие – кочевники. Это просто два разных уклада жизни.*

Шаймиев. Уклад жизни, может быть, не разный, оседлость позже пришла.

Овруцкий. *Какая культура без оседлости?*

Шаймиев. Так было в далёкие времена, сегодня обе республики высокоразвитые, с мощным потенциалом... Безусловно, Татаро-Башкирская республика была бы очень сильной. Со временем она стала бы союзной республикой.

Овруцкий. *Почему же такая родственность и такая конфронтация?*

Шаймиев. Народ тут не при чём. Это политика. И политика не башкир и не татар.

Овруцкий. *Этот вопрос – лакмусовая бумажка. Если Вы скажете: мы сейчас соединимся с Башкирией...*

Шаймиев. Ответ прозрачен: нет, мы к крупным мелких присоединяем...

Овруцкий. *Если оба региона проведут референдумы? И соединитесь.*

Шаймиев. Если бы и федеральный центр поддержал, зная проблемы изнутри... Нет, я не верю в такую возможность.

Овруцкий. *Соединяться можно только после референдума.*

Шаймиев. Да, только через референдум. И это правильно.

Овруцкий. *Конечно, на это должно быть согласие федерального центра, это понятно, Вы сами изменить свой статус не можете... Скажите, как сейчас в связи с тем, что два новых Президента и у башкир, и у татар – Минниханов съездил, вроде бы они там обнимались...*

Шаймиев. От души поздравляю обоих Президентов, подвижка есть!

Овруцкий. *А со статусом языка как? Так же? Новый Президент не решает этот вопрос? Он хорошо выступал по этому поводу, сказал, что это дикость. Но это пока чисто дипломатическое, подвижек нет реальных.*

Шаймиев. По языку – нет.

Овруцкий. *Какой у Вас прогноз в связи с этим? Постепенно татары станут башкирами – и всё? И снимется проблема.*

Шаймиев. Они опасаются, что, наоборот, часть башкир татарами станет. Точнее, за счёт тех, кого в своё время под давлением в башкиры приписали.

Овруцкий. *И это тоже.*

Шаймиев. Нет, не тоже, это так.

Овруцкий. *И Ваши политические и экономические успехи на это работают. Башкиры думают: что мы там отсталые...*

Шаймиев. Башкиры не отсталые, это трудолюбивый, успешный народ. Они любят свою республику.

Овруцкий. *Да, они стали заложниками ситуации, того, что так нарезали республики...*

Шаймиев. В какой-то степени все мы – заложники. Эта история идёт с царских времён. Мы фигуранты бородатой политики.

Овруцкий. *Да, заложники.*

Шаймиев. Фигуранты. Со времён взятия Казани Иваном Грозным в середине XVI века судьбы наших народов оказались на разных плоскостях. Тогда Казань сопротивлялась. Казань завоевали, а башкиры сдались как бы добровольно. Чтобы их не уничтожили, земли не отобрали, знать предложила – давайте добровольно объединимся. Уже это заложило раскол. И этот фактор оказался долгоиграющим.

Овруцкий. *Ваше соединение дало бы другую конфигурацию внутренней политике. Один Бабай доставил Москве столько головной боли, а тут ещё к ним мощная Башкирия присоединится.*

Шаймиев. Не спорю.

Овруцкий. *Это серьёзно. Половина Поволжья, половина Урала.*

Шаймиев. Это очень серьёзно. Тут не обвинишь национальные организации, татарских, башкирских националистов, их тоже можно понять. Я к этим вещам отношусь довольно-таки объективно.

Овруцкий. *Мне импонирует, когда Вы говорите: «А что бы я делал на месте Президента Башкортостана?» То есть Вы не твёрдолобно смотрите, а со всех сторон.*

Шаймиев. Невозможно иначе смотреть, мы же разумные люди. И вы задали вопрос, какая динамика будет именно по вопросам языка? Я сказал Вам, что скорее не жду существенной подвижки, имею в виду в пользу татар. Хамитов – новый человек, демократичный, просвещённый, но он Президент Башкортостана. Я же внимательно слежу за его выступлениями, особенно по вопросам образования и культуры. На мой взгляд, необходимо, чтобы два родственных языка свободно развивались, от этого выиграют оба народа. Такова моя точка зрения... Недавно «Система» купила «Башнефть», а сейчас всё это объединили, всё это уже у Евтушенкова оказалось, все компании его, кроме – «Уфаоргсинтез»…

Овруцкий. *А для Вас путь всегда был не тем? Меня это смущало – почему Вы так боитесь московского менеджмента?*

Шаймиев. Я сейчас объясню. Вот думаю сейчас, например, о Президенте Башкортостана... Ведь нам удалось не продать «Татнефть», «Нижнекамскнефтехим» и так далее.

Овруцкий. *Сохранили собственность республики.*

шаймиев. Сохранили.

Овруцкий. *И у Вашего суверенитета есть экономическая основа.*

Шаймиев. Это да, базис для декларирования. Но вот программа ветхого жилья – это же беспрецедентная социальная программа, и она реализована только в Татарстане.

Овруцкий. *Да, башкирский Президент уже не может на «Башнефть» возложить эту добровольную повинность…*

Шаймиев. О чём и речь. Если бы не «Татнефть», если бы не наши «крупняки»! Мы же всех вовлекли. Такие объёмы средств мы разве могли бы собрать без них? Один процент с оборота – сказали «Татнефть», а это 4 миллиарда! Такие куски, вы понимаете? Мы финансировали программу ликвидации ветхого жилья в объёме порядка 16–17 миллиардов рублей в год. Но когда мы делаем такие вещи, и если предприятие не республиканское, то я должен просить у хозяина компании и так далее.

Овруцкий. *К примеру, Евтушенков сказал бы: а ты мне что дашь?*

Шаймиев. Вот именно, хотя мы с ним в хороших отношениях. Потом, после программы ветхого жилья, началась ипотека. Ведь, я вам скажу, ни у кого такой программы нет. Как я уже говорил, до сих пор руководители мощных регионов пытаются подобраться к этому, но ничего не получается. Мы же сохранили те права отчисления, за что меня хотели осудить – вы знаете об этом. Действительно, там есть некие нарушения. Без этих крупных компаний мы ничего бы не сделали. Вот есть Президент республики, есть премьер-министр,

необходимо решать возникающие внеплановые проблемы, не предусмотренные бюджетом. В таких случаях мы же всегда к «крупнякам» обращаемся.

Овруцкий. *Но Вы могли не проводить эту политику, Вы могли не сносить трущобы и так далее. Другие же не делают этого – вот и Вы бы не делали. Ничего, жили бы как-нибудь.*

Шаймиев. Это не по мне. Под лежачий камень вода не течёт. Если бы не было программы ветхого жилья, что бы мы говорили о Казани? Это же всё на наших глазах...

## Җир

*(Минтимер Шәймиев фикерләре)*

*Моннан 2225 еллар чамасы элек яшәгән, исеме тарихта калган татар түрәсе Багатур аксакалларын җыеп әйткән:*
*– Киңәшегез кирәк, аксакаллар! Күрше патша минем иң яхшы чабышкымны сорый. Биримме аңа дөнья бәһасе торган атымны? – дигән.*
*– Бирмә! – дигән аксакаллар.*
*Ләкин Багатур аксакалларның киңәшен тотмаган: күрше хакы – Тәңре хакы, дип, иң яхшы атын биреп җибәргән.*
*Икенче юлы Багатур түрә, тагын җыен җыеп:*
*– Күрше патша минем иң сөекле хатынымны сорый, биримме? – дип мөрәҗәгать иткән.*
*– Бирмә! – дигән аксакаллар.*
*Ләкин Багатур аларның киңәшен бу юлы да тотмаган: күрше хакы – Тәңре хакы, дип, иң гүзәл хатынын күршесенә биргән.*
*Өченче юлы да Багатур сораган:*
*– Анау анда үлән дә үсми торган коры җиребезне сорый күрше патшасы, биримме? – дигән.*
*– Бир! Ул – кысыр җир! – дигән аксакаллар.*
*– Күрше хакына ат та бирергә була, хатынны да бүләк итәргә була, ә менә җирне, туган туфракны читләргә бирү – иң зур җинаять! – дип, Багатур түрә сүзен өзә һәм җирне ятларга бирергә киңәш иткән бөтен аксакалларның башын чаптыра.*

Эдуард Паркер,
«Тысяча лет из истории татар»

• Без әтиләребез, бабаларыбызның бабалары васыятен беркайчан да онытмаска тиеш: җир – иң кадерле бүләк, аңа Аллаһы Тәгаләнең тиңсез бүләге дип карарга кирәк. Мин болай дим: җир ул – кешелек дөньясының әхлакый башлангычы.

• Мин кечкенә чагымнан ук җирне кайчан һәм ничек сөрергә, нинди көннәрдә чәчә башларга кирәген билгеләргә өйрәндем, басулар исе һәм үз сиземләвем буенча, арышны, бодайны кайчан ура башларга кирәклеген билгели беләм.

• Бүген республикада авыл кешеләренең кәефе шәһәрдә яшәүчеләрнекенә караганда яхшырак. Чөнки хәзер Татарстанны йөз процентка газлаштыру төгәлләнеп килә, быел һәр авыл йортында газ булачак... Шуның нәтиҗәсе буларак, кешеләр авылдан күчеп китми.

• Быел уңыш ничек булыр икән, дип, мин гомерем буе борчыла килдем. Мин бу уйларымнан һич аерыла алмыйм. Авыл хуҗалыгын – җирне яратканыма күрә, кайчакларда мине «колхозник-сельхозник» дип тә аташтыргалыйлар. Һәм бу сүз гаепләү буларак та яңгырый. Кимсетергә тырышуларымы икән? Ә мин шуның белән гел горурланам. Һәрбер кешегә дә бераз колхозник булып карау бер дә комачау итмәс иде. Шул чагында алар тормышны тирәнрәк аңлар иде.

Әлбәттә, җир-туфрак белән язмышы бәйләнмәгәннәр гаепле түгел. Гомумән алганда, алар – тормышның кызыклы ягыннан мәхрүм калган кешеләр.

• Ельцин колхозларны бетерү турында фәрман чыгарды. Ул җирне-туфракны һәм колхозларның хәлен аңлап бетерми иде. Җирнең чын хуҗаларын – кулакларны җирдән мәхрүм итү һәм аларны каторгага сөрү, утызынчы елларда күмәк хуҗалыклар оештыру иң олы ялгышларның берсе булды, ләкин бүген күмәк хуҗалыкларны җимерү авыл хуҗалыгына тагын да хәтәррәк зыян салды. Без колхозларны саклап калдык һәм оттык.

• Күмәк хуҗалык җирләрен фермерларга тараттык ди, ә ул җирне ни белән эшкәртәсең? Техника юк, ягулык юк, чәчүлек орлык юк. НЭП барып чыкмады.

• Безнең инвесторларның барысы да үзебезнеке, үз кешең беркайчан да туган туфрагына хыянәт итмәс.

• Мин үзем – авыл баласы. Әтием гомер буе колхоз рәисе булып эшләде. Ихластан әйтәм, мин һәрвакыт җирдә хуҗа булырга, үз хуҗалыгымны корып мөстәкыйль эш итәргә хыялландым. Шуңа күрә һич риясыз әйтәм: авылның киләчәге – фермерлыкны үстерүдә, җирне шәхси милек итүдә.

• Бездә – Татарстанда эшкәртелмәгән бер генә гектар җир дә юк... Без елына уртача 4,5 миллион тонна ашлык җыеп алабыз. Миллион тонна орлык маяда кала... Без саф сөтнең сигез процентын Россиягә бирә барабыз.

• Мин – авыл җирендә туып үскән кеше, ә бүген Татарстан Республикасы Конституциясе гаранты сыйфатында, авыл кешесенең мәңгелек хыялын – үз җиренең чын хуҗасы булуны тормышка ашыру өчен, бар көчемне куярмын.

• Бүген икътисад әйбәт бара, шөкер, әгәр иртәгә кризис башланса? Ә җир – ул мәңгелек байлык, мәңгелек кыйммәт.

• Илне туендырган кеше үзе ашаткан кешеләрдән фәкыйрьрәк яшәргә тиеш түгел.

• Бүгенге авыл ике юнәлештә эшли. Инвесторлар алагаем олы-олы фермалар сала. Шул ук вакытта хөкүмәтебез вак фермаларны, шәхси хуҗалыкларны да хуплый. Әллә соң бездә авыл хуҗалыгы товарларына кытлыкмы? Юк, әлбәттә, Татарстанда кытлык юк, шөкер. Вак фермалар, хосусый хуҗалыклар һәм олы фермалар алар икесе ике ысул белән эшли. Шәхси каралты-кура, мал-туар ул – кешенең үз дөньясы. Балалары шәһәргә китеп урнашкан, ата-анасын шәһәрдә яшәргә чакыра, ләкин ата-ана төп нигезне ташлап калага күченергә теләми. Кала тормышына караганда, авыл тормышы авыррак бит югыйсә.

• Эре аграр комплекс нәрсә ул? Бу – чиста икътисад, саф бизнес-малтабарлык. Малтабар башта сәрмаясын (төп капиталын) сала һәм шул сәрмаядан табыш алырга тырыша.

• Авылда туган, авылда гомере буе яшәгән кешене тамырыннан каерып алып китеп булмый. Ул мал-туарын, кош-кортларын карый, үзенә шөгыль таба. Гомере буе эшләгән кешене шәһәрдә озак тотып булмый. Аның җаны-тәне авылын сагыначак.

• Авылда әхлакый мохит бар. Юк, калада әхлаксызлар яши икән, дигән нәтиҗә чыгармагыз. Анда да, монда да төрлесе бар. Авыл кешесе – җир кешесе, аның элек имана җире булган, ул шуңа ябышып яткан. Бүген исә аның каралты-курасы, мал-туары бар. Ул аның үзенеке, хосусый милке, шәхси маллары. Күмәк хуҗалык – барыбер кешенең үз малы түгел.

• Җир-туфрак өчен сугышканнар. Җир – иң кадерле мал.

• Һәр дәүләтнең үз җире булган, ул шул җир өчен көрәшә. Бер карыш туфрагын бирмәс өчен, ул кан коярга риза. Әмма ул җир эшләргә тиеш. Сөрү

җирләре кешеләрне туендырырга, киендерергә тиеш. Җир ул – алыштырылмас валюта. Татарстандагы барлык җир дә эшкәртелә, бу – республика халкының яшәү чыганагы.

• Авыл – иҗтимагый-әхлакый нигез.

• Авыл яңадан крепостное право ысулына әйләнеп кайтмасмы?

*Советлар вакытында чын җир хуҗасын – крестьянны җирдән биздерделәр, күмәк хуҗалыклар аны җирдән биздерүнең башлангычы иде. Күмәк хуҗалыклар тора-бара ярыйсы гына нәтиҗәләр бирә башлады, инде күмәк хуҗалык системасы ныгыды дигәндә генә, аларны тараттылар, җирне шәхси кулларга биреп карадылар, ике-өч буын җирдән биздерелгәч, җирне алырга риза булучылар юк дәрәҗәсендә иде.*

*Татарстанда дистәләгән-дистәләгән авыл мәктәпләре ябылды. Мәктәп булмаса, авыл да бетәчәк, мәктәп бетсә, ана телебез дә бетәчәк. Ана теле бетсә, татар халкы, милләт булудан туктап, әби-бабасын, ата-анасын, тарихын танымаган маңкортлар өере генә булып калмасмы?*

## Сәяси сәхнә

*(Минтимер Шәймиев фикерләре)*

• Дәүләтебезнең мөстәкыйльлеге турындагы Декларацияне кабул итеп, без дөрес эшләдек.

• Суверенитетны без йөрәк аша кичердек. Ул – республиканың казанышы, киләчәгебез дә шуңа бәйләнгән.

• Республика баштан ук бәхәсле мәсьәләләрне хәл итүнең цивилизацияле юлын сайлады. Әмма безнең инициативага җавап итеп, федераль хакимиятнең барлык структуралары да референдум үткәрүгә каршы төште. Республика ватандашларын ни сәбәпле һәм нинди нигездә үз ихтыярын белдерү хокукыннан мәхрүм итәргә тырышуларын аңлау кыен иде.

• Ельцин 1990 елда ук: «Суверенитетны йота алган кадәр алыгыз», – диде. Без моны җитди кабул иттек. Бүген Борис Николаевичны, әлеге гыйбарәсе өчен, күпләр көчсезлектә гаепләргә маташа. Иманым камил: Россиянең беренче Президентының көче нәкъ менә шунда иде. Субъектларга хокук һәм ирекләр бирү аркылы гына, империядән ирекле, чын федерациягә күчәргә мөмкин. Бүген бөтен Европа субсидарлык, ягъни хакимиятнең түбәндәге органнарына мөмкин кадәр күбрәк вәкаләтләр бирү принцибына таянып эш итә.

• Без төп кыйммәтләре түземлелек һәм телләр, культуралар, конфессияләр тигезлеген саклау булган гражданлык җәмгыятенә нигез салдык.

• Россиянең, үзенә хас Евразия рухын икенчел факторга санап, башкаларны читкә какмавы кирәк. Ул үз-үзе булып калырга, ягъни үзенә төрле мәнфәгатьләре һәм мәдәниятләре, төбәкләре һәм диннәре белән бай, куәтле держава булу мөмкинлеге бирергә тиеш.

• Мин инанамын ки: аерым бер чорда, хакимияттә урыны ныгыганнан соң, Президент Путин алдына децентрализация һәм чын федерация төзү мәсьәләсе килеп басачак.

• Сәясәтче булмасам, мин җир кешесе булыр идем.

• СССР оборона министры, КГБ рәисе СССРның таркалуына каршы иде, алар Горбачёвка СССРны таркатмаска киңәш итте. Ләкин Горбачёв тәртәгә типте, һәм Советлар Союзы җимерелеп төште. Ельцин теше-тырнагы белән

Союзны таркатмаска тырышыр, һәм ул Союзны беркемгә дә беркайчан да бирмәс иде.

• Ельцин белән авылларда, шәһәрләрдә йөрдек, халык шыгрым тулы, ирек сорыйлар. Шуннан соң Казанга кайткач, ул әйтте: «Берите суверенитет столько, сколько сможете проглотить», – диде.

• СССР Конституциясенең 127 нче маддәсе, 4 нче пункты нигезендә, Татарстан Федерация Советына тулы хокуклы әгъза булып керергә тиеш иде.

• Югары хакимият төбәкләрнең үзенчәлекләренә яраклашырга тиеш.

• Без судларның эшен тикшереп торырга тиеш түгел. Аңлагыз, бу – минем катгыян фикерем, ышанычым. Әгәр дә бәйсез судлар юк икән, бездә беркайчан да демократия булмаячак.

• Мәйданга чыккач, син чын татар түгел, дип, халык мине тәнкыйтьли башлады. Мин моңа бик нык рәнҗегән идем.

• Заманча мәмләкәттә дин нигезен саклап калуда Төркиянең зур тәҗрибәсе бар. Шул җәһәттән дә алар безне кызыксындыра. Аларда дин белеме бирү өлкәсендә гасырлар буе ныгыган система бар.

• Рус теленә минем исемем «Я – железный» дип тәрҗемә ителә. Ә кайберәүләр мәйданга «Син тимер түгел, син камыр, ә менә Җәүһәр Дудаев – тимер!» дигән язу күтәреп чыккан иде... Ул, генерал буларак, үзенә чигенергә юл калдырмады. Ул уптым илаһи бөтен юлларны да ябып бетерде. Ул моңа (тулы мөстәкыйльлеккә. – *Р.Б.*) ирешүнең тормышка ашмасын алдан ук белергә тиеш иде.

• Арттырырга, күпертергә кирәк түгел. Нинди пантюркизм тагын?.. Биология дәресләре аша, җитмәсә, инглиз телендә, пантюркизм идеяләрен кертү... Көлке бит бу!

• Чарабыз калмагач, без сәясәтче булып китәбез.

• Федераль структураларда шундый сәясәтчеләр бар ки, алар «бүлгәлә дә чәйнәп йот» принцибында гына эш йөртә.

• Рас Россиядә туганбыз икән, димәк, без туганнан бирле коралланырга дучарбыз. Бу – безнең тәкъдиребез.

• Россиянең куәте – нәкъ менә төбәкләрнең көчендә һәм мөстәкыйльлегендә. Дәүләт тотрыклылыгының нигезе – төрлелектә, ә барысын да бер туры сызгыч белән тигезләүдә түгел.

• Татарстанның статусын саклау ул – Россиянең федерализмын саклау.

• Хөкемдар (судья) вазифасын үтәр өчен, пәйгамбәр кебек кеше кирәк, ә без андый кешене каян алыйк?

## Тарих, ана теле, милләт вә дин

*(Минтимер Шәймиев фикерләре)*

• Тарихны шомартып күрсәтүнең хаҗәте юк. Теләсә нинди чорда, теләсә нинди халыкта рәхимсезлекне дә, игелекне, күтәрелешне дә, түбәнлекне дә табып була. Бүген исә тарихта башканы – кеше акылы ирешкән казанышларны, сәүдә элемтәләрен, культураларның бер-берсен баетуын күрү мөһим.

• У нас у всех должна быть уверенность, что мы на верном пути и что язык свой спасём. Традиции сохраняются, но без языка – это фольклор для праздничных концертов. Правда, у меня есть определённая надежда, что возрождение религии даст какой-то импульс для сохранения языка.

• Теләсә кайсы милләт турында аның культурасына, фән һәм техника казанышларына, күренекле лидерларына, сәясәтчеләренә, язучыларына, шагыйрьләренә, галимнәренә карап фикер йөртәләр. Бу яктан без – бәхетле милләт.

• Нельзя пренебрегать спецификой кряшен или других граждан татар, но было бы ошибкой любую особенность и тем более религиозные различия возводить в принцип, разделяющий нацию.

• У нас же была такая идеология, что связана с монголо-татарами. Во всех учебниках такая вражда, такая ненависть к татарам. К счастью, из русских учёных, что это так важно, из русских учёных осмысливают и лучше освещают историю более справедливо.

• Мин – татарларның гына Президенты түгел, ә күпмилләтле Татарстан Президенты.

• Допустим, есть две равнозначные кандидатуры, но один из них знает русский и татарский, а другой – только русский. Кого бы вы назначили?

• Есть прекрасный братский башкирский народ. У нас языковая разница между татарами и мишарами, пожалуй, не меньше, чем между татарами и башкирами.

• Әгәр бөтен халык та «рус» булып язылса, «Россия – для русских» дигән шигарьне кая куярсыз?

• Кешеләргә исламның асылы турында дөреслекне җиткерү, аны тыныч, толерант, чор куйган сорауларга уңай җавап таба белүче заманча дин буларак таныту – безнең бурычыбыз.

• Диннәрне маңгайга-маңгай чәкәштерү, бөтен халыкларны мөселманнарга каршы котырту террорчыларның төп максатларыннан берсе булып тора. Без бу котыртуларга, бу шантажга бирелергә тиеш түгел.

• Ислам түгел, ә бәлки наданлык дөньяны шартлата һәм аны куркыныч хәлгә куя. Тома наданлык белән бары тик белем-хәбәрдарлык ярдәмендә генә көрәшеп була.

## Ак мәчет

Болгар язмышы Минтимернең зиһенен тулысы белән биләгән иде.

Илбашы вазифасыннан китәр алдыннан ук инде, аның уйлары әледән-әле Болгар, Биләр, Зөя калалары тирәсендә бөтерелә башлады.

Изге Болгар җире татар халкының үзенә күрә мәгънәви кыйбласы була килде. Патша заманнарында да, Совет хакимияте вакытында да мөселманнар һәр җәйне шушында намаз укырга җыела торган иде. Ураза, Корбан гаете кыш көненә туры килгән чакларда да, әрвахлар өчен дога кылырга, борынгы бабаларыбыз рухына Коръән чыгарга алар изге Болгарга бара иде.

Йөзләгән манаралы Болгар кәрвансарайлары, җәмигъ мәчетләре, җәмәгать мунчалары, ташпулатлары, төрбәләре булган гүзәл шәһәрдән ике-өч манара басып калган, ләкин халык шушы хәрабәләргә дә эзен суытмый, шушы хәрабәләрне зиярәт итә иде. Мондагы һәр манара, һәр ташпулат калдыклары, хәтта кирпеч ватыклары да изге, кадерле безгә.

965 елда рус кенәзе Святослав Болгарны җимереп, халкын талап китә. 1391, 1395 елларда Аксак Тимер Болгарны нигезенәчә җимереп, халкын кырып, исән калганнарының күбесен коллыкка сата. 1431 елда, рус кенәзе Чуар Василий явыннан соң, Бөек Болгар чынлыкта яшәүдән туктый. Әмма ул

татар күңелендә үлем җәрәхәте алган баһадирдай яши бирә. 1722 елда Пётр I, Идел буйлап Персия явына барганда, Болгар шәһәренең исән калган җитмеш манарасын саный. Әби патша Бөек Болгарны зиярәт иткәндә, манаралар саны егерме алтыга кимеп, кырык дүрте генә торып калган була. Күрше-тирәләргә күчереп утыртылган христианнар, манараларны сүтеп, чиркәү төзи. Бүген инде без анда бер-берсеннән шактый ерак урнашкан ике-өч манара гына күрәбез.

Аксак Тимернең Болгарны харап иткәненә 600 ел тулган көнне, 1995 елның 20 февралендә, Россия Президенты Борис Ельцин Указы нигезендә, Бөек Болгар шәһәре – тарихи-архитектура музей-тыюлыгы – федераль әһәмияткә ия объектлар исемлегенә кертелде.

Менә шуннан башланды инде Бөек Болгарны тернәкләндерү эшләре. Бу изге эшнең башында, әлбәттә, Илбашыбыз Минтимер Шәймиев торды.

Казан Кирмәне, Болгар хәрабәләре арасында сакланып калган манаралар, төрбәләр белән Зөя каласындагы иске чиркәүләр үзләренең тарихи кыйммәте җәһәтеннән Татарстанда да, Россия Федерациясендә дә аерым урын тота.

Бөек Болгар могҗизалы рәвештә яңадан терелде. Изге җирдә, бабаларыбыз кабере өстендә үскән кылганнар урынында Болгарның рухы калкып чыкты.

1998 елда Минтимер Шәймиев бу объектларны ЮНЕСКО исемлегенә теркәтү хәстәрен күрә башлады.

– Борынгы бабаларыбыз кулы белән төзелеп, могҗиза белән сакланып калган шушы аз гына ядкярләребезне, шул исәптән, XIII гасырда төзелгән Хан сарае хәрабәләрен дә киләчәккә җиткерәсебез килде! – диде Минтимер Шәймиев. – Шуңа күрә аның өстенә саклагыч корылма төзеп кую фикере туды. Шунысы куанычлы: безнең табигать шартларында бу корылманың зарурлыгы ИКОМОСның тәҗрибәле белгечләре тарафыннан танылды.

Мәгълүм ки, борынгы Болгарда мәчетләр күп булган. Иң әһәмиятлесе, XII-XIII гасырларда төзелгән Җәмигъ мәчете, кызганыч ки, хәрабә хәлендә генә сакланып калган. Аның Олы манарасы, Кече манара белән Төрбәсе бүгенге көндә Болгарның иң төп борынгы ядкярләре булып тора. Аларны күреп, борынгы диварларына орынып дога кылыр өчен, бөтен дөньядан күп санлы мөселманнар килә. Һәм, әлбәттә, шушы ике манара иң беренче чиратта яңартылды.

Әмма, Җәмигъ мәчетенең ачык һавада урнашканын исәпкә алып, Болгарга килүче күпсанлы мөселманнарга уңай булсын өчен, елның теләсә кайсы фасылында, теләсә нинди һава торышында дога кылырга, намаз укырга мөмкинлек бирүче яңа мәчет төзү кирәклеге турында фикеребез ныгыды.

Ләкин экспертлар иске биналар сакланып калган борынгы тарихи җирлектә яңа биналар кору ЮНЕСКО тарафыннан тыелганлыгы турында әйтте. Сука ташка терәлде! Инде нишләргә дип торганда, җае табылды: без, яңа мәчетне тарихи шәһәрлектән читтәрәк корып куярга кирәк, дип, үз тәкъдимебезне җиткердек.

Ике ел буена сузылган бимазалар, кәгазь-документлар әзерләү, хокук белгечләре белән бәхәсләр нәтиҗәсез калмады.

Шулай итеп, ЮНЕСКО кагыйдәләренә туры китереп, тарихи шәһәрлектән читтә мәһабәт Ак мәчет калкып чыкты. Ул – бөтендөнья ислам архитектурасы үрнәкләренең җыелма образы.

Шәһре Болгар ЮНЕСКО исемлегенә кертелде – татар халкының чын тарихы дөнья күләмендә танылды. Татар-монгол ярлыгы тагучыларга көн

бетте! Моның белән килешмәүчеләр үз фаразларын ЮНЕСКО каршында исбат итәргә тиеш хәзер.

Бөек Болгарда яңадан торгызылган Ак мәчет – ул изге җиребезнең йөзек кашы, архитектурасы ягыннан бердәнбер, нур чәчеп торучы, кабатланмас һәйкәл.

Без борынгы шәһәрне торгызабыз икән, аның рухи тирәлеген дә тергезергә тиешбез. Ислам динен кабул икән урында мөселманнар өчен иң мөкатдәс һәм иң кадерле нәрсә – Изге Коръән куелмаса, дөрес булмас иде. Шул рәвешле, Болгарга дөньядагы иң зур басма Коръән кайтарылды, ул X гасырда гарәпләрдән кабул итеп алынган Коръәнне гәүдәләндерә.

...Болгарны ЮНЕСКО исемлегенә кертергәме, юкмы, дип, төрле илләрдән килгән экспертлар хәрабәләрне карап йөргәндә булды бу хәл.

Кайбер экспертлар, Минтимер Шәймиевнең шушында яңа мәчет корырга теләвен белгәч:

– Нигә кирәк бу мәчет? – диде. – Ул иске биналар арасында аерылып торачак һәм Болгар каласының борынгылыгын бозачак, аңа ямау булып кына күренәчәк!

Бу – өйлә намазы җиткән вакыт иде. Шулчак Шәймиев кинәт әйтеп куйды:

– Әфәнделәр, кунаклар, әйдәгез, өйлә намазын укып алыйк! – диде.

Кунаклар да, экспертлар да аптырап калды:

– Ә кайда укырга өйлә намазын?

– Менә күрдегезме инде! – диде Шәймиев. – Намаз укырга мәчет кирәк!

Килгән кунакларның, экспертларның күбесе мөселман илләреннән иде, алар әйтте:

– Әйе, намаз укыр өчен, монда яңа мәчет кирәк икән шул! – диде.

Өйлә намазын хәрабәләр өстендә укыдылар...

Кыш көне ап-ак кар яугач, Ак мәчет аеруча гүзәл күренә. Аяк астында – зәңгәрсу ак кар, зәңгәр күктә асылташлар җем-җем итә, Ак мәчетнең барлык тәрәзәләрендә дә яп-якты ут балкый. Чыннан да, кар илендәге бу могҗизаны күргәч, Болгарны зиярәт итүчеләр сокклануларын яшерә алмый.

Машалла!

## Холык

*Үземә һәм туганнарыма карата чиксез игелекләре өчен тирән ихтирамым һәм олы рәхмәтем авылдашларыма барып җитсен, әткәй белән әнкәй рухына дога булып ирешсен иде.*

Минтимер Шәймиев

*Президентлыкны үзенең шәкерте Рөстәм Миңнехановка тапшырып киткәч, Минтимер Шәймиевнең абруе кимедеме?*

*Юк! Татарстан халкы алдында да, Россия, чит ил җитәкчеләре каршында да аның абруе элеккечә югары калды.*

*Минтимер Шәрип улы – балигъ булганнан бирле гел уңыш казанган, гел эше уңа торган, беркайчан да эш урыныннан алынмаган, гел үсә генә барган бәхетле кеше.*

● 1941 ел. Миңа дүрт яшь. Хәтергә уелып калган беренче вакыйга – әткәйне сугышка озату. Әти инде ул вакытта ук колхоз рәисе иде. Кояшлы көн, әти һәм

тагын берничә кеше тарантаста утыра, атлар аларны Әнәк һәм безнең авыл янәшәсендә үк урнашкан район үзәге Пучы урамнары буйлап җилдертә. Алар, җырлый-җырлый, авыл белән хушлаша. Әти мине алдына утыртып, кулыма гармун тоттырды. Күрәсең, башка уйнар кеше булмагандыр. Алар җырлый, ә мин, берни аңламыйча һәм уйный да белмәгән килеш (дүрт яшьтә каян килеп гармун уйный белү ди инде!), гармун төймәләренә басарга маташам, көч-хәл белән күреген тартам. Әле үземчә җырларына «иярергә» тырышам...

• Гомер буена тынычлык бирми торган сораулар бар. Мәсәлән, югары математикадагы чиксез кечкенә һәм чиксез олы зурлыклар. Фән көннән-көн алга бара. Без укыганда, әүвәл молекула, молекуладан атомнар китә иде. Ә хәзер атомның өлешләрен өйрәнәләр: һәрбер өлеш бүленә дә бүленә, бүленә дә бүленә. Һәр бүленгәненең үз орбитасы, үз энергиясе бар, бүленеш процессы чиксез бара. Моның чиге бар, дип, бүген беркем дә әйтә алмый. Бинийая нәни чиксезлек нольгә омтыла, әмма ул барыбер ноль түгел. Менә шуннан соң инде уйлана башлыйсың. Моның чиге булмагач, фән аны танып бетерә алырмы, юкмы? Кеше үзеннән-үзе җавап эзли. Ә җавап табылмый, бары тик ышанырга гына кала.

• Китап уку дигәннән... Тормыш ничек кенә авыр булмасын, ун ел буе татар мәктәбендә уку бездә ана телебезгә, татар китабына гомерлек мәхәббәт уятты. Мин моны олы бәхет дип саныйм. Дөрес, аның авырлыклары да булды. Чөнки ун классны татарча укып тәмамлап, Казанга килеп, имтиханнарны рус телендә тапшырырга кирәк иде. Монда тагын язмыш төшенчәсе килеп баса... Нинди яхшы укыган егетләр бар иде! Күбесе, институтка керә алмыйча, кире кайтып китте. Саф татарча укып, башкалага килеп, рус теленнән имтихан бирдек, инша яздык. Менә нинди дискриминацияләр аша уздык. Татар телен, ана телен онытырга тырышу омтылышы интеллигенция арасында да бар иде. Мин моны институтка керү имтиханнарын биргәндә күзәттем. Татар милләтеннән булган кайбер укытучылар, безнең белемебез барлыгын күрә торып, рус телен начар белгән өчен газаплый иде. Менә шундый язмыш. Халкыбыз язмышы. Яшь чакларда укыганнар хәтердән дә, күңелдән дә китми. Ә элек бик күп укыла иде. Мин үзем укырга нык ярата идем. Иң четереклесе – өйдәгеләрнең, керосинны бетерәсең, дип тиргәүләре иде. Укыр өчен, мин башка әйбер уйлап таптым. Яңа күренә башлаган радиоалгычлар зур батареялар белән эшли иде. Мин аларны өч ваттлы лампочкага тоташтырдым да, укыр өчен үземә яктылык булдырдым. Әнкәй мәрхүмә сөенә иде: «И булдырасың, улым, керәчинне саклыйсың», – дип. Төне буе укыйм да, иртән батареяларны үз урынына куям. Берникадәр вакыт узгач, әткәй, ник бу радио сөйләми башлады соң әле, дип аптырады. Әле күптән түгел генә шатлана-шатлана алып кайткан иде югыйсә. Мин эндәшмәдем инде...

• Әгәр дә мин бу яки теге эшнең яхшылыгына ишанам икән, ул эшне, бар күңелемне биреп, азагына чаклы башкарам. Юк икән, мин ул эшкә алынмыйм. Һәр очракта да мин хаклымы – әйтүе кыен, ләкин мин үземнең хаклыгыма бик нык ышанган булырга тиеш, башкаларны ышандырыр өчен.

• Мәсьәлә югалтуларсыз гына хәл ителә икән, һәркемгә дә проблема булмаган да кебек күренә.

• Әйдәп баручы төп предприятиеләр Татарстан милке булып калды.

• Президент үзе дә, шулай ук иң югары вазифада утыручы Президент атамасы да халыкка бик ошый!

• Миңа Татарстанда яшәве бик тә рәхәт, халык миңа терәк булып тора.

• Ихтимал, мин инде Президент булып эшли алмыймдыр. Мин эштер-өштер генә эшләргә күнекмәгән.

• Балалар – оттырышсыз вариант. Сабыйларның йөзендә барысы да күренә. Әгәр сабый кәефсез чыраен синнән читкә борып сүзсез торса, димәк, гаиләсендә минем турыда ата-анасы начар сөйли. Әгәр дә алар сиңа елмайса, кулларын сузса, димәк, гаиләдә сиңа ышаныч бар дигән сүз.

• Нервларың какшау булса, син властька үрмәләмә.

• Гомумән, намус – бөек сүз. Үзенең намусын саклап-яклап калыр өчен, кешеләр ниләр генә эшләми.

• Тормышта миңа гел вакыт җитмәде. Мин гомерем буе вакыт кытлыгы кичердем.

• Тормыш бездән зирәгрәк.

• Мин, астымдагы урындык какшар дип, беркайчан да курыкмадым.

• Менә хәзер, үткән юлны анализлаганда, мин шундый нәтиҗәгә киләм: ничек кенә гаҗәп булмасын, безнең бер генә зур ялгыш та кылмаска акылыбыз җитте.

## Минтимер Шәймиев турында

Хәдичә Әхмәдуллина *(Миңкәйнең беренче укытучысы)*. Минтимернең шигырь сөйләве яхшы чыга, бик матур итеп сөйли иде. Биюе дә бик матур иде. Ул концертлар да алып бара торган иде.

Владимир Путин *(РФ Президенты)*. Шәймиев – яңа цивилизацияле Россиягә нигез салучыларның берсе.

Борис Ельцин *(первый Президент РФ)*. Какую он оказал помощь и поддержку, когда решался национальный вопрос! Когда мы были на границе национальной розни в России. Ведь мы с ним договорились, и сразу все республики это поддержали и подхватили.

Коитиро Мацуура *(Генеральный директор ЮНЕСКО)*. Уникальность Казани, на мой взгляд, в мирном альянсе представителей более 100 национальностей, и этот факт достоин подражания. Президент Минтимер Шаймиев может гордиться тем, что достигнуто в Татарстане в сфере национальной политики. В этом отношении республика может стать примером гармонии для всего мира.

Туфан Миңнуллин *(язучы)*. Гади татар авылында туып үскән малайдан Илбашы дәрәҗәсенә күтәрелү өчен, гаҗәп зирәк акыллы, мәгънәле һәм тагын бик күп асыл сыйфатларга ия булырга кирәктер. Ә бит бәйләнеп куелган дәүләтнең Президенты булу бәйсез дәүләт башлыгы булудан күпкә авыррак.

Сергей Кашанов *(историк)*. Есть сильные ребята, а вот этих губернаторов-тяжеловесов язык не поворачивается назвать отцами, а вот Минтимер Шаймиев – отец народов!

Лев Гущин *(журналист)*. Ельцин выгнал всех приближённых, но Шаймиева не трогал. Он чувствовал Шаймиева равным себе.

Рамазан Абдулатипов *(политик)*. Никогда Шаймиев так вопрос не ставил: отделиться от России. Как мой друг Газеев сказал, он проводил в жизнь скрытый федерализм. Как ни парадоксально, именно в эти годы Шаймиев спас Россию.

Евгений Фёдоров *(депутат Госдумы)*. Шаймиев рисковал. Но его

твёрдая позиция помогла сохранить Россию. Шаймиев – человек, оценить которого Российское государство должно будет на высочайшем уровне.

Александр Славутский *(режиссёр)*. Шаймиев в душе художник, по должности – политик!

Александр Венгеровский *(политик)*. Минтимер Шаймиев – элита нации!

Андрей Караулов *(тележурналист)*. Шаймиев создал политическую, нравственно-политическую школу России.

Владимир Жириновский *(депутат Госдумы)*. Шаймиев? Да он не пикнет, когда я стану Президентом России и вместо республик у нас будет пятнадцать губерний!

Фоат Галимуллин *(галим)*. Кеше батырлыкка гомере буе килә, диләр. Әгәр дә ул гомере буе батырлык кылып яшәсә, бу очракта аны батырларның батыры дип атарга мөмкиндер. Минтимер Шәрипович инде ничә еллар буе күкрәген хәтәр җилләргә каршы куеп бара, иң мөһиме, алардан өстен чыга килә, чөнки ул үзенә ышанган халыкның йөрәк тибешен сизгер тоя. Бу олуг шәхеснең акыл һәм ихтыяр көченең чыганагы шунда.

Роберт Миңнуллин *(шагыйрь)*.

Син һәрвакыт халкың белән булдың,
Тора белдең әйткән сүзеңдә.
Татарларны күккә күтәрдең син,
Күтәрелдең бергә үзең дә.

Моннан соң да булыр микән татар
Милләтләрнең данлы, санлысы?!
Син булдырдың! Татарларыбызның
Үзләреннән тора анысы.

Рәдиф Гаташ *(шагыйрь)*.

Илбашыбыз юлы инде – Иранга!
Җаны тартып, кагылырмы Ширазга?
Ул Хәйямнәр, Хафизлар илендә:
Шагыйрь булып кайтып килә Казанга.

Иван Родин, Ульяна Махкамова *(журналисты)*. Праздничные дни России завершились резкими политическими высказываниями одного из лидеров партии «Единая Россия», Президента Татарстана Минтимера Шаймиева. Он высказался против нынешного порядка назначения глав регионов. Но если с ним Шаймиев ещё согласен как временной мерой, то право Президента России и распускать парламент субъектов РФ региональный руководитель считает неприемлемым, глава Татарстана предупредил об опасности великорусского шовинизма и навязывания православия, что в дни России прозвучало особенно громко.

Николай Сванидзе *(тележурналист)*. Минтимер Шаймиев – человек, который пользуется моим огромным уважением, всегда пользовался и продолжает, независимо от того, будет ли он Президентом Татарстана, не будет ли. Просто как человек. Я считаю, что он по-настоящему масштабная личность. Причём не просто масштабная, а позитивная. Потому что бывают масштабные мерзавцы, и тьму мы их знаем и в истории и не только. А Минтимер Шаймиев масштабен, но при этом с большим знаком «плюс»... Я думаю, что, если Шаймиев вот такой, какой он есть, был не Шаймиев Минтимер Шарипович, а там Сидоров

Пётр Кузьмич, условно говоря, уже давно всерьёз рассматривался бы на пост Президента России. Потому что по своему личностному масштабу, конечно, несомненно, годится. Несомненно!

Рузия Гыйльманшина *(икътисадчы)*. Башка берни кылмаса да, бер Кол Шәриф мәчетен генә корып куйган булса да, Минтимер Шәймиевнең исеме мәңгегә тарихта калачак.

Сәкинә Шәймиева. Шәһәрдә яшәүчеләрнең күбесе бу турыда белми. Минтимер, эшчеләр яши торган пүчинкәләрне яхшырту эшендә башлап йөргәне өчен, каты шелтә алган иде. Имеш, Шәймиев төзелеш материалларын әрәм-шәрәм иткән, сметадан артык акча тоткан... Әгәр дә төп-төгәл сметага гына карап эш йөртсәң һәм фондларның өстән төшерелүен көтеп ятсаң, бу бистәләр әле дә төзелеп бетмәгән булыр иде.

Мөхәммәт Мирза *(шагыйрь)*.

**М**ең елга бер пәйгамбәр килде
**И**хтыяры белән бер Хакның.
**Н**уры бөтен җиһанга иңде,
**Т**уры юлга чакырып халкын.
**И**маны нык, акылы камил;
**М**әгыйшәткә тотып кыйбласын,
**Э**ше белән күтәрә халкын,
**Р**аббысына кылып догасын!

## Соңгы сүз түгел

Ихтимал, аның ялгышлары да булгандыр, эшләп бетермәгән эшләре дә бардыр, бер адәми зат та хатадан хали түгел. Ләкин халык Минтимер Шәймиевнең игелекләрен һич онытмас!

Кешенең кылган миһербанлы гамәлләре бу дөньяда калыр, һәм алар башкаларны инсаниятькә игелек кылырга өндәр.

Адәм балалары! Кешеләргә игелек кылырга ашыгыгыз!

Аллаһы Тәгалә Минтимер Шәймиевкә, Сәкинә ханымга озын гомер, халкыбыз өчен тагын да күп игелекләр кылырга насыйп әйләсен! Амин!

Актаныш төбәгенең Әнәк авылында туып үскән Чаптын Шәймөхәммәтенең оныгы Миңкәй – Минтимер Шәрип улы Шәймиев ничек итеп Татарстанның беренче Президенты дәрәҗәсенә ирешкәне турындагы язмама шушы урында нокта куям. Аңа хәләл җефете Сәкинә ханым, балалары һәм оныклары янында озын, куанычлы, сәламәт тормыш кичерүен теләп калам!

Моңарчы беренче Президентыбыз турында язылган китаплар әдәбият сөючеләр арасында тиз арада таралып бетте. Ышанамын ки, Минтимер Шәймиевкә багышланган бу китап та соңгысы булмас, алга таба да беренче Илбашыбыз турында китаплар язылыр, фильмнар төшерелер әле, иншалла!



Салават
Рәхмәтулла

# ЧОРЛАР УЗГАЧ – ДӨНЬЯ БЕЛӘЧӘК

***

...Укытучыбыз дәфтәрләр
Таратты: «Бүләк!» – диде.
Дәфтәрләр тышларындагы
сурәтләрдә – Ленин бабай,
Сталин бабай иде.

«Ленин, Сталин бабайлар
Бәхетле тормыш бирде!» –
Укытучыбыз сүзләре
мәктәптә ун ел буена
җанымда гына йөрде!

Югары уку йортында
Алдым югары белем:
«Ленин, Сталин бабайлар
Бәхетле тормыш бирде!» – дип,
Укучыларга сөйлим.

...Чор – башка, исемнәр – башка,
Юллар да башкачарак:
«И-и-иң бәхетле тормыш» эзләп,
Әллә кайларга киттек бит,
Әллә кайларга карап.

---

Салават РӘХМӘТУЛЛА (1942) – *шагыйрь; «Әйтелмәгән әйтер сүзләрем», «Яңгыр, яу, яу!», «Күперләр» һ.б. китаплар авторы. Башкортстан Республикасының Стәрлетамак шәһәрендә яши.*

## Очлытау*

И Очлытау –
Минем үз тавым син
(Син һаман да җанга, һай, якын!):
Көндезләрен мендем – Кояш якын!
Төннәрендә мендем – Ай якын!

...Кала ташларына
Бәреләсугыла,
Шигырьләрем елый... тау сорап:
Көндезләрен – Кояш ерак монда,
Төннәрендә – монда Ай ерак...

«Уралым!» – дип, дала малайлары
Кунаклаган Уфа тавына...
Очлытавым!
Кала ташларына бәреләсугыла,
Шигырьләрем сине сагына!..

## Туган көнеңдә

*Самолётлар да очалмый,*
*Автобуслар да йөрми.*
*«Кышкы челлә...» – таксистлар да*
*Минем хәлләргә керми...*
*Уйлап та булмас берни...*

...Йоклый алмый таң аттырдым,
Уйларда – «юллар буйлап»:
Туган көн – елга бер!..
Кышкы
Челләне ятам уйлап...

Арада – 100 километр
(Түгел «ун километр!»):
«Кышкы челлә...
Килалмас!» – дип,
Берүкләр уйламый тор...

«Килмәс!..» – дип,
Керфекләреңне
Берүкләр чылатмый тор...
...Таңда – монда, кич – яныңда:
Пүчтәк 100 километр!..

## Сукояр

Дөрес сөйләү – һич мактану түгел
(Дөрес сүздән мине кем тыяр?..):
Мин – йолдыздан,
Йолдыз затыннан мин,
Йолдызлыгым минем – Сукояр!

Дөрес сүзләр сөйлим
(Юк, мактанмыйм:
Халык чуар – төрле уй туар...):
Шигырьләремдә дә тамчы су юк,
Мәгәр үзем... үзем – Сукояр.

## Алмачуар

*Г.Ибраһимовның шул исемдәге*
*әсәре тәэсирендә язылды.*

– Атлар килә!..
Беркем белми әле –
Алмачуар алдан киләчәк:
Моны әле бер Галимҗан белә,
Бәйге узгач – мәйдан беләчәк!..

Беркем белми әле –
Алмачуар
Йөрәккәе ярылып үләчәк:
Моны әле бер Галимҗан белә,
Чорлар узгач – дөнья беләчәк!..

*Очлытау – туган авылымдагы биек тау. *(Автор.)*

## «Уен»

*(Яшьлек елларымнан бер хатирә)*

... «Уен» – дидем,
«Уен гына!» – дидем
(Берәү хәтта: «...ике, өч!» – дия...):
«Җиңәм!» – дидең, көлдең...
Мин (шаярып):
«Миңа, – дидем, – җитә «ничья»!

Тәҗрибәле,
Тәкәббер дә идең...
«Җиңелмәскә!» – дидем уемнан:
«Уен», – дидем,
«Уен гына!» – дидем.
Уймаклары чыкты «уен»нан.

«Җиңдем!» – дидең...
Эх,
Яшь идем ул чак
(Еллар узган – һаман эч көя!):
Сизмәгәнмен – аяк чалгансың ич,
Җиңмәгәнсең – булган «ничья»!

## Һәр заманда...

...Хәерче булсаң –
учыңа
Хәер салучылар бар...

...Байый башласаң –
һәрвакыт
Аяк чалучылар бар...

...Баесаң –
бар байлыгыңны
Тартып алучылар бар...

***

...Мактадылар: исемнәрен
Данлап күккә чөйделәр:
Миңа җиткәч, тагын (та-гын!)
«һәм башкалар», диделәр.

«Һәм башкалар» булып, бәлки
Гомер буе йөрелер...
Хәер... мактау-данлауларга
Үлгәч тә өлгерелер...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Марсель
Галиев

# ТИМӘ, ЯШӘСЕН!

РОМАН-НОВЕЛЛА

**Логика дигән сөзгәк тәкә**

Дивизия штабының оператив бүлеге (мозговой центр) икенче катта, зур гына бүлмәгә урнашкан. Стена яклап өч өстәл артында өч офицер утыра. Тәрәзә яклап түрдә киң өстәлнең хуҗасы – гадәти киемдә йөрүче, сызымнар сызучы олы яшьтәге Матвей Трофимович (аны «Трофимыч» дип кенә йөртәләр икән), тагын да зуррак өстәлне рядовой Володя Железняков били. Нижний Тагил университетының өченче курсына ул көз аенда кайтып китәргә тиеш, әгәр дә үзенә алмаш тапса... Таба алмый икән, декабрь азагына кадәр аны җибәрмәскә мөмкиннәр...

Кайчандыр, ни сәбәптәндер кызып китеп, миңа: «Ты – потомок Чингизхана, вы держали нас триста лет под игом!» – дип кычкырган бу егеттән мин сагая идем. («Иго»... дип, башка сугып торгач, татар кешесе үзен гаепле санап, бер башка үсми, тәбәнәк кала. Ялган тарих белән халыкны кимсенеп яшәү хәленә дә китерергә мөмкин. Югыйсә, «иго» ул, таркау рус кенәзлекләрен игә, тәртипкә китерү дигән мәгънә буларак кабул ителергә дә мөмкин бит. Мин ул чакта моны белгәнмени...)

Калын күзлекле Володя Железняков, якыннан белсәң, алай дорфа, тупас холыклы түгел икән. Ул мине оператив бүлеккә алып килеп таныштырды, (сынау срогы белән) эшкә җигәргә уйлыйлар мине.

Чибәр йөзле капитан Астафьев иң түрдә утыра, Гоголь әсәрләрендәгечә әйтсәк – «столоначальник» икән. Ул калын амбар кенәгәсенә баш күтәрми нидер яза. Икенче өстәл артында капитан Комбаров. (Гамбәревтән бозылган фамилия ахрысы.) Өченче өстәл артындагы майор Мезенко миңа беренче күрүдә үк ошамады. Төксе карашлы. Солдаттан чирканган кебек сөйләшә. Текәлеп карый да... сыңар күзе, аерымланып, йөзеп тора, син шул күз алмасы артыннан ияреп, әле сулга, әле уңга тайпылырга тиеш кебек уңайсыз хәлгә каласың...

Матвей Трофимович сугыш чорында ТБ-3 самолётында укчы-радист булып хезмәт иткән. Авиацияне үлеп ярата. Үткән хатирәләр белән үзен сугарып яшәүче тере тарих...

Күрше кабинеттан хуҗаларча килеп кергән подполковник Журавлёв, штаб

*Ахыры. Башы 2016нчы елның 10-12нче, 2017нче елның 1нче саннарында.*

начальнигы урынбасары буларак, әлеге бүлекнең турыдан-туры җитәкчесе икән. Ул мине баштанаяк күзләп алды да, кырыс, чатнап торган тавыш белән:

– Монда эш бик катлаулы. Шактый четерекле документлар кулдан үтә. Кайчакта төннәрен дә эшләргә туры киләчәк! – дип, «юатып» чыгып китте.

Мин курка калдым. Янәшәмдә торган Железняков, астан төртеп: «Не ссы! Научишься. Привыкнешь. Нам, татарам, всё равно!» – диде шыпырт кына.

Ничә күз карап торганда, «сыналу эшафотында» кыен мизгел иде бу. Астан гына йодрыкны кысып, үземә көч бирдем, боларга караганда миңа, татарга, икеләтә сәләтле булу, икеләтә зирәк булу, икеләтә эшчән булу кирәк – мин моны исбатларга тиеш! Болар бит минем оялчанлык битлеге астында баш бирмәс үҗәтлек ятканын чамаламыйлар әлегә...

Володяның өстәл тартмасында гаҗәеп тәртип: һәрбер карандаш, циркуль, каләм һәм башка шундый кул эше әйберләре оя-оя итеп, тәртип белән тезелгән. Өстәл тартмасын ачып, күзеңне йомып та тапмалы. Ул хәтта минем өчен дип тә кирәк әйберләрне аерым бүлеп куйган.

Чүп чиләге кәгазь кисәкләре белән бик тиз тула икән. Атна азагында, секреткадан ачкычны кул куеп алып, чүпне крематорийга яндырырга илтәм. Бер-ике тапкыр шулай барганнан соң, башның уйлап табарга маһир күзәнәкләрен эшләтеп алдым. Зур табаклы, каты картоннан метр ярымнар биеклектә итеп, төпләп, цилиндр ясадым, гуашь белән чәчәкләр төшереп бизәдем дә, стенага терәлеп бетмәгән шкаф почмагына утыртып куйдым. Чүпне хәзер айга бер генә яндырырга була. Капитан Астафьев: «Моңа берәүнең дә башы җиткәне юк иде әле», – дип мактады. Майор Мезенко, чыраен сытып, бәйләнергә сәбәп эзләп карады да тынды.

Нишләп шулай икән бу тормыш, тыныч кына яшисе даирәңдә дөньяга аркылы туган берәр бәндә пәйда була да синең тынычлыгыңны бораулый башлый. Көнеңне, кәефеңне боза. Ошамый бу кеше миңа. Аңардан күзгә күренмәгән салкын-кара дулкын бәреп тора шикелле.

Малай чакта авылда шундый бер егет бар иде. Мине күрде исә, кеше алдында «аксөяк» дип мыскыллый да шаркылдап көлә. Көлгән чакта күзләре кысылып бетә, чукмар борыны дугайланып өскә чөелә, калын иреннәре алагаем ерылып, үшән колак очларына кадәр җәелә. Мин аны күралмыйм, кешеләр җыелып торган җирдә ул булса, тизрәк таю ягын карый идем. Нинди аксөяк булыйм инде мин, җәйге каникулда йөк машинасында комбайннан журна (зерно) ташыйбыз, ындыр табагына кайткач, әрҗәсеннән агач көрәк белән көрәп бушатабыз. Ә ул – «Чаян» журналындагы сурәткә охшаган Әгъдәс – ындырда йөкле ат, машиналар кереп баса торган зур үлчәүдә эшли иде. Аның үртәп, бөркелеп көлүеннән һич котылыр чара юк.

Кышкы каникул вакытында Фаварисларда аулак өй иде. Өч апасы ишекне бикләгәннәр дә без малайларны Фаварис янына кертмиләр, югары очтан егетләр төшкән, аларга да ишек ачучы юк. Арада теге... Әгъдәс тә бар. Аның Фаварисның иң чибәр апасы – Илгизәгә күз атып йөргәнен без белә идек. Шул төндә, яңадан үртәмәс бәлки дип, Әгъдәскә ярарга тырышып, ишекне ачып кертергә булдым. Кесәмнән пәке чыгардым да (эчтәге элгечнең ни рәвешле икәнен белә идем), – азаплана торгач, ачып җибәрдем бит. Рәхмәт әйтәсе урынга, Әгъдәс абый, үзенең яшьтәшләренә борылып:

– Менә бит, егетләр, аксөяк булып юкка йөрми бу малай, кеше чыга моннан, – дип шаркылдап көлде. Минем ачудан күз алларым караңгыланып китте. Атылып урамга чыктым. Ишелеп төнге кар ява. Кар ябалаклары

арасыннан каядыр күз төбәп барам да барам. Эчтән күңел әрнеп сулкылдый. Әмма җебеп төшәргә ярамый. Авыл башына чыктым, тегермән ягына таба барам. Күз алдымда – Әгъдәс абыйның киерелеп авызы ерылган чырае... Ул мине эзәрлекли... кәефемне боза, күз каршымда үртәп, үчекләп тора. Шул Әгъдәс күземә күренмәсә, миңа нинди рәхәт булыр иде. Ул мине туктаусыз мыскыллый, юлыма аркылы төшә, яшәү дәртемне сүндерә-томалый. Тегермән турына җиткәч, борылып кире авыл башына чаклы кайтам, тагын борылам; үзалдыма сөйләнә-сөйләнә, ачынып, эчемә җыелып килгән бөтен рәнҗүемне чыгарам.

Кәефемне җимерә, сулышымны буа торган бу бәндә минем юлыма аркылы килергә тиеш түгел. Шушы төн карасы, шушы кар аклыгы шаһит, каһәрлим мин аны, каһәрлим...

Бер көннән соң микән, иртән күршебез Рәшидәттәй белән әнинең мыдыр-мыдыр сөйләшкәнен ишетеп уяндым. Тавышларында нинди дер шом бар сыман. Әгъдәс исеме дә чыккач, мин торып утырдым.

– Өйләнмәгән дә... япь-яшь килеш харап булган...

Ничек харап булган? Бу соравым тел очыннан төшә алмыйча, тамакка тыгылды.

Әгъдәс абый, иртән чәй эчеп утырганда, печенье капкан да... урындыгыннан артка китеп, тынсыз калган. Кинәт йөрәге туктаган икән...

Бу хәбәр мине тетрәтте, зиһенемне чуалтты. Әллә соң минем гаебем бармы монда, дип, үз-үземне талкыйм, кабат-кабат искә төшереп, аны терелтергә теләп әллә нинди тылсым-фаразлар кылам...

Әлбәттә, минем гаебем булмагандыр. Мин, малай кеше, аның тәкъдиренә ничек тәэсир итә алыйм инде. Әмма мин шуннан соң беркайчан да, беркемгә карата да каһәрле уйга бирелмәскә, бәгырьгә төшеп рәнҗемәскә дигән карарга килдем. Нахак бәла ягудан кала... үзеңне саксыз рәнҗеткән аяусыз кешене дә аңлап, кичереп карарга омтылу – гаделлеккә беренче адым түгелме!

Менә хәзер, кискен холыклы үсмерчакның шул хәлләре искә төште дә, майор Мезенконың да берәр уңай ягы бардыр бит инде, мин генә күреп бетермимдер, дип уйга калдым. Бер кабинетта алты кеше без. Күз карашлары, уйлар, холыклар кисешә... Бигрәк тә миңа, хокукы тәгаенләнмәгән оялчан егеткә кыен...

Штабның оператив бүлегендә эш чынлап та күп икән. Беренче плакатны ясарга алынгач, сизеп торам, Володя Железняков бик дулкынланды, бәлки минем шушы эшем аның язмышын хәл итәр, рәтле алмаш калдырса гына, аны вакытында кайтарып җибәрәчәкләр бит...

Буе – дүрт, иңе – алты биттән торган ватман кәгазьләрен (А1 форматлысын) җыеп ябыштырсаң, өстәл өстенә сузып яткырырга сыймый. Шуңа күрә барын да алдан чутлап, исәпләп, бөтен бер схеманы күздә тотып, өлешләп, аерым-аерым ясарга кирәк. Соңыннан гына ватман битләрен тоташтырасың. Карандаш эзеннән калын перо белән линейкасыз гына туп-туры сыза алуымны күзәтеп торган Володя, мактау сүзенә саран икәнен онытып, «невероятно!» дигән булып, гаҗәпләнүен белдерде. Һәм бүтәннәргә ишетелмәслек итеп кенә, теш арасыннан: «Ашыгып эшләмә!» – дип кайгыртучан ысылдап китте.

Гадәтем шундый: бер-бер эшкә тотындыммы – тизрәк азагына барып чыгасым килә. Юк, ордым-бәрдем кабалану түгел, үз шөгылеңнең серенә төшенеп, логик эзлеклелектә, секундларны минутка, минутларны сәгатькә үрә барып, вакытны юкка сарыф итмәү сәнгате бу!

Икәү генә калгач, Володя болай диде:

– Ашыгып эшләмә, диюемне дөрес аңла. Солдат спит, служба идёт, дигәнне беләсең бит. Моны бетерүгә, икенче эш китереп төртәләр, анысын бетергәч – өченчесен.  Гел шулай бара, өзлегерсең бит. Бер көндә бетәсене ике-өч көнгә суза белү, һәм шуның табигый икәненә начальствоны күнектерү – менә кайда хикмәт!

Шулай итеп, Нижний Тагил университетында укыган, физика-математика факультетының өченче курсыннан армиягә алынган Володя Железняков миңа дивизия штабының оператив бүлегендә ничек эшләү «фәнен» гади генә төшендереп бирде. Миңа хәзер билгеле бер ритмга корылган кан йөрешен, йөрәк тибешен, кул җитезлеген, холык кайнарлыгын ничек үзгәртергә – менә монысы үз җаның-тәнең каршында хыянәткә бәрабәр...

Штабта эшли башлагач, мин Володя Комаров белән якынаеп киттем. Ул майор Сорокин белән бер кабинетта, кәгазьләргә чумып утыра, язу машинкасы да бар. Дивизиянең баш писаре  Володя Комаров һәрчак үзалдына җырлап йөри. Казармада аның барлыгы сизелми дә. Ә монда, эш урынында ул – башка. Төрле яктан агылып килгән әллә нинди җитди документлар аның кулы аша уза.

Безнең этажда генерал Дудаков һәм штаб начальнигы полковник Шестопал кабинеты. Шестопалның гадәтен бөтен кеше белә: әгәр аңа «Товарищ полковник», дип кенә эндәшсәң – беттең. «Товарищ гвардии полковник», дисәң инде, рәхәт елмаюы бөтен йөзенә сирпелә.

Безнең кабинет ишеге каршында  гына дивизия һәм берничә полк байрагы постаментта, пыяла эчендә тора. Автоматлы сакчы һәрчак уяу, ишекне ачып кергән-чыккан чакта аңа честь биреп тормас өчен, баш киемен салып кулга тотам. Ишекне ачып чыгуга, посттагы солдатның автоматын кысып, үрә катуы ошый да кебек миңа.

Эштән соң, үзем генә калып рәсем ясыйм, шигырьләр язган сыман итәм. Ике рәсемем Минскида «Во славу Родины!» газетасында басылып чыкты. Гаҗәпкә калдым: гонорар җибәргәннәр: беренчесенә – 13 сум, икенчесенә – 15 сум (кабат искәртәм: минем айлык жалунье – 2 сум 72 тиен). Гонорарларны алгач, бу кадәр сумманы кесә төбендә йөртеп булмас дип, акчаларны сберкассага салып, кенәгә ачтырдым.

Газетада чыккан рәсемнәрне игътибарлап күзәтеп барам. Кайберәүләр төрле журналлардан файдаланып, әзер рәсемне «хәрбиләштереп», күчереп кенә җибәрә. Мондый да ялганга бару, кеше хезмәтен урлауны мин аңлый алмыйм.

Берсендә, төп рәсемне табып, күчерелгән икәнен әйтеп, редакциягә хат юлламыйча түзә алмадым. Аннан шушындыйрак эчтәлектәге хат килде: имеш, бу рәсемне ясаган авторны плагиат  дип әйтеп булмый, дөрес, кешедән күчергәнлеге сизелеп тора, шуңа күрә аңа кисәтү ясалды...

Икенче бер рәсемне кайдадыр күргәнем бар, дип гел уйлап йөрдем. Туган якка кунакка кайткач, үзем охшаткан рәсемнәрне журналлардан кисеп җыеп барган папкаларны бөртекләп карап чыктым. Тәки таптым бит! 1953 елда чыккан «Агитатор блокноты» журналы тышлыгындагы (Мәскәүдә басыла иде ул журнал) рәсемне тәрәзәгә куеп, аңа газетада басылган теге рәсемне куеп карыйм – суйган да каплаган, диюләре нәкъ менә шушы очракка карата әйтеләдер инде ул. Юлладым мин бу табышымны «Во славу Родины» редакциясенә. «Ул чын карак, бу автор  плагиат, бүтән безнең газетада басылмаячак», дип минем исемгә рәхмәт хаты килде. Канәгать калдым. Гаделлек түтәленә мин дә бер уч туфрак сала алдым бит.

Оператив бүлектә «өйрәнчек» булып эшли башлауга бер ай вакыт үтеп тә китте. Бу вакыт эчендә Матвей Трофимовичтан мин, көн белән тышлап, зур-зур альбомнар ясап, төпләргә өйрәндем. Володя Железняков исә, нинди сызымга тотынсам да, астан, әкрен генә киңәшләрен бирә торды. Шулай итеп, мин дивизия штабының иң четерекле эшләр кайнаган бүлегендә беренче чиратта үзем каршында ышаныч яулап барам. Нинди генә эш тәгәрәп килсә дә, аның куәте астында тапталып калмаска, чигенмәскә, дип үз-үземне чыныктырам. «Ах, не смог татарин!» дигән өмет өзү сүзен ишетмәс өчен, мин борчаны дагалый, филне тезләндерә беләм икәнне исбатларга тиешмен.

Бер айдан минем «Дело»ны Мәскәүгә җибәрделәр. Бу инде монда сынау срогының беренче адымын үтү иде. Хәзер инде Мәскәү «секретно», «совершенно секретно» дигән мөһер сугылган документлар белән эш итәргә яраклымы-юкмы икәнемне, бөтен нәсел-нәсәбемнең архивларда калган эзен актарып чыгарып, энә күзеннән үткәзеп ачыклаячак.

– Кире борырга мөмкиннәрме? – дип сорыйм капитан Астафьевтан. Ул, гадәтенчә, тыныч кына әйтеп куя:

– Полно таких случаев...

Володя Комаров бу хакта борчылмаска куша, бар да әйбәт булыр, ди. Эшкә без аның белән бергә йөрибез. Якшәмбе көнне шәһәргә ун сәгатьлек ялга бергә чыгабыз. Мин аның үзалдына җырлап йөрүен тыңларга яратам. Әллә нинди шәп көйләр белә ул. Кайбер сүзләре хәтергә эләгеп кала:

Воздух Родины – он особенный,
Не надышишься им...

Сизәм бит, егетне вакыт-вакыт нindидер моңсу уйлар баса. Сәбәбен сорасаң, эчке моңының серен кешегә фаш итмәгәем, дигәндәй, сүзне бүтән якка бора.

Шулай да... Шәһәргә ялга чыккач, шоколад кимерә-кимерә Үзәк паркта йөргәндә, бераз ачылып китте егетебез. «Авыш юкәләр арасыннан барганда күңел турая», дип уйлап куйдым мин.

Комаровның торган җире – Донбасс өлкәсе, Снежное шәһәрендә яшәүче яраткан кызы Женя язмышы борчый икән. Нindидер бер егетнең аңа күз атып йөрүен Володяга хәбәр иткәннәр. Ул ышанган. Миңа карата суына башлавын хатларыннан сизә идем инде, ди. Их, кайтып килергә иде, әле соң түгел, барысын да җайлап булыр иде... Юк шул, майор Сорокин җибәрми, узган ел гына кайтып килдең, ди.

Ничек тә Комаровка ярдәм итәсе иде бит. Башымда уйлар тармаклана. Нишләргә була? Шахмат уенындагы кебек ничә йөрешне алдан уйларга кирәк? Логика дигән мөгезсез тәкәнең бөдрә йонын уңайга сыйпап, күңел аранынnan чыгарып җибәрәм. Бар, табышсыз кайтып керә күрмә! Синең зирәклегеңә таянам мин...

Штабның беренче катында команда пункты урнашкан. Мин аның ачык ишегеннән башны тыгып кына караганым бар. Стенада пыяла астында әллә нинди утлары җем-җем янып торган бинinfoһая зур карта куелган. Рация тавышлары өзлексез ишетелеп киткәли, өстәлдә уннарча телефон ята. Серле бер кабинет. Аннан ерак түгел генә элемтәче кызлар-солдаткалар утырган зур гына бүлмә. Анда язу машинкасына охшаган линотип артында унлап солдатка утыра. Келтер-келтер эшләүче линотип тавышлары, идәндә – такта

ышкылаганда бөтерелеп чыга торган йомычка сыман, язулы кәгазь тасмалары уралып ята. Солдатка кызлар линотип аша төрле хәрби частьлар белән тоташып, нәкъ телеграф тасмасы кебек тар кәгазьләрдә «сөйләшүне» тәүлек буена язып баралар.

Мин шунда дежур торучы солдаткалар арасыннан берсе белән танышып алдым. Бронислава исемле. Мин төнгә калып эшләгәндә, ул кытай термосын күтәреп кабинетка керә, «мендәр» кәнфит белән чәй эчеп алабыз. Увольнениегә чыккач, аның шәһәр үзәгендәге борынгы, тәбәнәк йорттагы фатир тәрәзәсен шакыйм. Пәрдә чите ачыла, Брониславаның елмаюлы йөзе, озын бармаклы кулы күренә. Бераздан йортның бизәкле, калын ишеге ачыла, тимер култыксалы баскычтан Бронислава тротуарга сикерә. Паркта йөрибез, кино карыйбыз. Казарма тормышы еракка чигенә. Биленә каеш буган, пилоткасын кыңгыр салган соры бертөрлелекне берничә сәгатькә онытып, яшәп алу да язык түгел ич.

Мине һаман бер уй борчый: Володя Комаровка ничек ярдәм итәргә? Бердәнбер юл – телеграмма эшләү... Ике көн буена кул-бармакларыма сөял чыгарып, резина кисәгенә почта штемпеле уеп, ясап карадым. Берне ясыйм, икене, өчне... Юк, булмый гына бит. Фальшивомонетчик чыкмый миннән...

Иртән эшкә килгәндә, штаб ишеге төбендә Бронислава белән бәрелешә яздым. Шул мәлдә башыма ачык бер уй килде. Бу кызый белән Ходай Тәгалә мине кирәккә таныштырган ич. Барын да алдан белеп, күреп, тоеп бер-беребезнең сукмакларын төенләштергән. Менә хәзер... Дустым Володя Комаровның хәленә кереп, сөйгән кызын саклап калып, мәхәббәт газабыннан коткаруда Брониславаның да ярдәме тиячәк...

Володя белән киңәшләшәм. Туган шәһәреннән «Поздравляю с днём рождения» дигән гөнаһсыз телеграмма килде ди. Телеграмма кәгазендәге тасманы кубарып алабыз да Бронислава линотибыннан чыккан тасманы ябыштырып куябыз. Анда хәтәр сүзләр язылган була: «Срочно приезжай отец тяжело болен мама».

Андый хәвефле телеграмманың артында почта хезмәткәрләре тарафыннан кулдан язылган нindider сүзләр булырга тиештер дип, Володяның шкафындагы папкаларны актарып, иске телеграммаларны табып карыйбыз. Барысы да тиз, ашыгыч һәм төгәл эшләнә.

Эчтән борчылуымны сиздермәскә тырышып, үз өстәлем артында эшләп утырам. Таза гәүдәсен җиңел йөртә белгән майор Железняк килеп керә:

– Ишеттеңме әле, дустың Комаров телеграмма алды, юлга җыена... – ди.

– Шулаймыни?! – дигән булам.

Кабинетыбызның бер як стенасында СССР картасы эленеп тора. Хыялыйрак күз белән карасаң, аның сурәте галәмәт зур динозаврны хәтерләтә сыман. Камчатка ярымутравы – Тын океанга очлаеп сузылган динозаврның койрыгы. Башына исә Скандинавия илләре ялганган. Бу динозаврга аерым бер кеше язмышы чүп кенә; сыта, изә, таптап китә, җелеген суыра. Минем бу биниһая зурлык каршында һәрдаим чүгеп каласым килми, кайчакларда үземнең бар икәнемне искәртеп, ым кагып алгалыйм. Моның төбендә бернинди хөсетлек тә ятмый, бары тик уенчак холыкның, акыл зирәклегенә дәгъва кылып, бер уйнап алуы гына...

Комаровны туган ягына капылт кына озата алу комбинациясе – шуның бер мисалы. Яшьлектә бер генә була торган мәхәббәтне саклап калу өчен кыек юлга кереп алырга да була. Ил каршындагы безнең төп бурычыбыз аңа

карап какшамас. Динозавр аерым кеше бурычын һәрчак искәртеп тора, ә үз бурычына килгәндә, хәтер капчыгы ертык ятьмәгә әверелә... Бу динозаврның сөмсез аягы астында калып тапталмас өчен, вакытында тайпылып кала белү зирәклеге кирәк...

## Мезенко

Майор Мезенко миңа карата нигә шулай авыр карашлы микән, яшьлегендә әллә татарлар берәр ничек рәнҗеттеләр микән үзен, дигәч, капитан Астафьев:

– Нигә алай дип уйлыйсыз? – диде.

Мин Сталинны мисалга китердем.

«Сосо» дип йөртелгән малай чагында аны, акча урлаган өчен, Ялта базарында кырым татары бик каты кыйнап ташлый. Сыңар кулы шуннан коргаксып кала. Сосодан үсеп, Сталин булып өлгергәч инде, кырым татарларыннан аяусыз үч алуны оештыра. Мәчет манарасына охшап калкып торалар дип, Ялтадагы өч мең кипарисны төптән кистертә...

Астафьев минем сүзләрне ышанмыйчарак, көлемсерәп тыңлады да:

– Мезенко бик күңелле кеше иде. Инсульттан соң шулай калды. Сез аңа рәнҗемәгез инде. Документлары әзер булганын гына көтә, тиздән отставкага чыга ул, – диде.

Сүзсез калдым. Уңайсыз тынлык иңгән бу халәттә тәндәге кан тибеше ишетелерлек иде. Менә бит ничек, үз каланчаңнан торып кына кешегә бәя бирү, хәленә керә белмәү – күпме аңлашылмаучылыкка сәбәп була...

Атна-ун көн үтте микән, майор Мезенко белән саубуллаштык. Армия хезмәтеннән китүне авыр кичерми иде шикелле. Ачылып сөйләште, хәтта елмаеп та куйгалады. Үзенең туган шәһәренә – Ростов-Донга кайтып китәсен әйтте. Мин бит Рейхстагка байрак кадаган өчәүнең берсе – легендар шәхес Алексей Берест белән бер урамда яшәдем, дигәч, өнсез калдым. Байрак кадаучылар өчәү булган, мин шулай ишетеп калганмын, йә мин саташам, йә кешеләр хәтерсез, дип күпме икеләнеп, аныклый алмыйча йөрүемә майор Мезенко менә гади генә әйтеп биреп, чик куйды түгелме!

Чишелмәгән төен йөртү күңелне кимсетә. Рәхмәт майор Мезенкога. Бу хакыйкать артында нинди гаделсезлек ятканына, билгеле бер идеологияне алга сөргәндә, кайбер язмышлар рәнҗетелеп кала икәнгә мин хәзер төшенә башладым шикелле...

*Берлинны штурмлау, ничә ел барган канлы сугышның соңгы аккорды – һәр частьның үз байрагын Рейхстаг бинасына беркетү белән тәмамлана. (Дүрт дистәгә якын байрак элені). Лейтенант Рәхимҗан Кошкарбаев белән рядовой Григорий Булатов (30 апрель, 14 сәгать 25 минутта) Рейхстагның төп ишек турындагы колоннага беренче булып байрак беркетәләр. Ләкин боларның батырлыгы легендага керми кала. Сугыштан соң, Булатов истәлекләргә бирелеп карый, әмма аның рәсми легенда белән сипләнмәгән хатирәсеннән көләләр генә, хәтта «Рейхстаг» дигән кушамат та тагалар. Булатов гарьлегеннән асылынып үлә.*

*Капитан В.Н.Маков, өлкән сержант Г.К.Заһитов, А.Н.Максименко, А.Б.Бобров һәм сержант М.П.Мининнан торган штурм группасы беренчеләрдән булып, Рейхстаг түбәсенә чыгып, «Җиңү алиһәсе» һәйкәленә байрак беркетәләр (30 апрель, 22 сәгать 30 минутта). Болардан соң берничә минут кала, лейтенант Алексей Берест, кызылармеец Михаил Егоров һәм*

*сержант Мелитон Кантария группасы Рейхстагның Көнчыгыш ягындагы түбә фронтонына, атлар һәйкәленә байрак беркетә. Хәрби совет алдан ук, тугыз байракны махсус эшләткән була. Берест кулында – шул рәсми байракларның бишенчесе. Ул вакытта әле тирә-якта атышлар бара. Түбәгә менү юлында урыны-урыны белән баскычлар җимерелгән була. Таза гәүдәле, буе ике метрлы Алексей Берест иптәшләрен җилкәсенә бастырып, өске катка күтәреп менгезешә, аннары тегеләр үзен тартып алалар. Рейхстагның төп гөмбәзенә ул мәлдә якын килеп булмый. Гөмбәз котырып яна, ут ялмаган була. Алар Хәрби советның Җиңү байрагын 2 май көнне генә гөмбәз түбәсенә күчереп беркетәләр.*

*Бер елдан соң бу өч кешенең икесенә Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Алтын Йолдыз ордены белән бүләкләнәләр. Ә политрук Берест фамилиясе геройлар исемлегеннән сызылган була. Ул Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.*

*Шулай итеп, Алексей Берест тора-бара легендадан төшеп кала. Бу гаделсезлекне ул бик авыр кичерә. Аны кыерсыталар, юк сәбәп тапкан булып, төрмәгә дә утыртып алалар. 2005 елда гына аңа «Украина Герое» исеме һәм Алтын Йолдыз ордены белән бүләкләнүе хакында Украина Президенты Ющенко указы басылып чыга. Туган җирендә һәйкәл куела. Ростов-Донда урам исеме бирелә. Әмма Алексей Берестка боларны күрү насыйп булмый. 1970 елда, оныгын күтәреп өенә кайтып барганда, ул рельста торган бер баланы күреп ала, ажгырып поезд килә... Берест оныгын җиргә бастырып куя да баланы коткарырга ташлана. Баланы читкә этеп өлгерә, әмма үзе, оныгы күз алдында, поезд астында кала...*

*Әйе, батырлык кылган, бүләк биргән җирдә тулы дөреслек, гаделлек була алмыйдыр ахрысы... Ясалма каһарманнар, ялган легендалар, мәңгегә дип куелган вакытлы һәйкәлләр... Болар бар да тоталитар җәмгыятьнең үз-үзен исертеп яшәү рәвешеннән киләдер...*

*Күкрәген пуля тишкән килеш, Рейхстаг түбәсенә байрак тотып менеп җиткән татар Заһитовның кемгә кирәге бар?! Легендага өчәү – рус, украин, грузин милләтеннән булса шәп бит, икене генә калдырсаң, тагын да шәбрәк килеп чыга. Әгәр илбаш Сталин милләте белән чукча булса, байрак кадаучыларның берсе, һичшиксез, чукча булыр иде кебек. «Күзгә кырып салырлык» кына чукча милләтеннән берәр солдатны фронт буйлап эзләтеп, Рейхстаг ишеге төбенә минуты белән китереп җиткерерләр иде. Әгәр инде табылмый икән, бүтән милләт кешесен чукча итеп, батырлык хакына, тудырган анасын да оныттырырлар иде.*

*1976 елда Мәскәүдә, Яшь әдәбиятчыларның Бөтенсоюз семинарында катнашкан чакта, кызыклы шәхесләр белән очрашу вакытында миңа Мелитон Кантарияне якыннан күрергә туры килде. Зур башлы, чәче такыр итеп кырылган, Эльбрус тау сырты шикелле борынлы таза гәүдәле грузин. Рейхстаг түбәсенә байрак кадавы хакында ул саран гына бер-ике сүз әйтте:*

*– Командир кушты да... Егоров белән икәү элдек инде... – дип, Грузиядә ике катлы йорты, җимеш бакчасы турында тәфсилләбрәк сөйләде. Бәлки, аны мондый очрашуларга еш чакырып, тәмам алҗытып бетергәннәрдер. Бәлки, өченче каһарман хакында – үз иңендә боларны Рейхстаг түбәсенә алып менгән лейтенант Берестны телгә алырга кушмаулары аның намусына тигәндер...*

*Төптән уйлап карасаң, легендалар кешенең сабыйлык акылына исәп тотып тудырылган...*

Володя Комаровның туган ягыннан кайтып төшүе үзе бер бәйрәм булды. Егетнең шатлыгы – үзе генә күтәрерлек түгел, күзләре чаткыланып яна, сүзләре сәйлән кебек сибелә. Яраткан кызы Евгения белән аңлашканнар. Бу кайту аның гомерендә онытылмас бәхет булып калыр, мөгаен.

Икебез генә калган арада, икебез генә аңларлык өзек-төтек сүзләр алмашабыз: «Уйлаганыбыз барып чыкты бит, ә!», «Рәхмәт инде сиңа, гомердә онытмам!», «Бу хакта беркемгә әйтмә!»

Әмма... нишлисең, эчкәре яшерелгән сер черем итеп ятмый шул, тышка бәреп чыгарга ясканып, тибенергә ярата. Бу очракта да шулайрак булды.

Безнең дивизиядә, дәүләт эчендә дәүләт дигән кебек, алты йөз кешелек аерым бер «рота охраны» дигән часть бар. Боларның төп хезмәте – «через день – на ремень, через два – на кухню». Авиаторларның иминлеген тәэмин итеп, болар төрле объектларны саклап каравылда торалар, кухняда аш-су әзерләү дә алар карамагында. Бу частьның командиры – полковник Рябинович иде. Штабта, менә шул полковник кул астында эшләүче писарь егет Комаровның якташы икән. Туган ягына кайтып килү шатлыгыннан иләсләнгән Комаров тишкән бит моңа икебез генә белгән серне. Якташы шул ук схема буенча эш йөрткән. Телеграмма... Туган көне белән котлату... Текстны кайгылы хәбәргә алыштыру... һәм... кинәт аяз көндә күк күкри... Полковник Рябинович бүтән камырдан шул... Телеграмма кулына кергәч, тота да почта бүлекчәсенә чылтырата, авыр хәбәр булганда аерым теркәлә торган телеграмма килмәгәнен белеп ала, писарь егетне чакыртып, келәмгә бастыра. Сүгә, кычкыра, яный.

Комаров ни үле, ни тере, агарып чыккан, кичер инде мине, ник әйттем, ник әйттем... дип өзгәләнә.

– Булган булган инде, – дим мин. – Якташыңны коткарырга кирәк. Җылы урыныннан тибеп төшерергә мөмкиннәр бит.

– Ә ничек ярдәм итәргә?

Тагын уйга калам, тагын логика дигән бөдрә йонлы тәкәне күңел аранынннан чыгарып җибәрәм. Бераздан ул, җим кабып, әйләнеп кайта. Комаров минем ике каш арасына җыерчык чыгарып, уйланып торуымны кәефем төшенкелеккә юрап, һаман гафу үтенә.

– Егетең Рябинович кул астында писарь булып күпме эшли?

– Бер елдан артык.

– Алайса, җебеп төшмәсен. Бер ел буена аның кулыннан нинди генә документлар үтмәгән. Рябинович та фәрештә түгелдер. Әйтсен егетең: «Әгәр мине батырсагыз, үзегез дә чиста кала алмыйсыз», дисен.

Ул көнне Комаров казармага соң гына кайтып керде. Сизеп торам, атлавында ук тере өмет сизелә. Иңемнән кочып, аркадан сөйгән кебек итте дә:

– Барып чыкты... Син әйткәнчә булды. Полковник белән аңлашканнар, – диде.

Беркөнне төштән соң Володя Комаров белән һава суларга дип парк, стадион буйларын әйләнеп чыктык. Штабка кайтып барганда, безне җиңенә кызыл бәйләгән өлкән лейтенант һәм ике солдат туктатты. Гарнизонның эчке патруле иде болар. Имеш, без Уставны бозып, эш сәгатьләрендә эленке-салынкы йөрибез. Аңлатып карыйбыз, ишетергә дә теләми өлкән лейтенант. Алып киттеләр безне КППга (контрольно-пропускной пункт). Себеркеләр тоттырып, дежур торучылар бүлмәсен себереп чыгарга куштылар. Идәне эре ярыклы, күптән инде юылмаган. Володя – дивизиянең баш писаре: «Мин моны болай гына калдырмыйм!» – дип, өлкән лейтенант белән бәхәсләшә торгач, якага-яка

килә яздылар. Миңа кызык, көләсе килә. «Төкер, әйткәнен тыңлыйк та, тизрәк котылыйк болардан», дип, Володяны тынычландырган булам.

Себеркеләрне тапшырып киткәч тә, соң дәрәҗәдә кимсенгән Володя озак кына игә килә алмады.

Штабка кайткач, мин гимнастёрканың түш кесәсенә сыярлык итеп кенә күн белән тышлап, келәйләп, икебезгә ике кенәгә ясап, калын тимер белән бастырып кибәргә куйдым. Хәзер инде эченә кечкенә фотоларыбызны ябыштырып, дивизия штабында эшләүче сотрудниклар буларак, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында гарнизон эчендә йөрергә рөхсәт ителә, дигән язу кирәк тә, гербլы мөһер кирәк. Анысын инде бер папка документлар белән штаб начальнигы Шестопалга кереп, кул куйдырганда, мөһерен дә суктырып чыгуны Володя Комаров эшли ала. Һәм ул аны башкарып чыкты да. Шыкырдап торган документларны кесәбезгә тыгып куйдык. Берәр мокыт лейтенант кисәге бәйләнеп карасын хәзер!

Икенче көнне үк документның көчен сынар өчен, төшке аштан соң, гарнизон урамнарында юри киләп сарып йөрдек. Патруль җиңсәсе кигән капитан юлда очрап бәйләнмәкче булган иде дә... күн тышлы документларыбызны тегенең борын төбендә уйнатып кына алдык.

Ял көннәрендә шәһәргә ireккә чыгу, ягъни увольнительный кәгазен учка сыярлык кына итеп Володя Комаров машинкада кирәкле санда бастыра. Аннары гербլы пичәт суктырып, старшина Осипенкога кайтарып бирә.

– Шестопал документларга мөһерне үзе сугамы? – дип сорыйм Володядан.

– Бик мөһимнәрен карап, кул куеп чыга да мөһерне миңа тоттыра.

– Алай булгач, увольнительный кәгазьләрен күбрәк бастыр, – дим. – Безнең кесәдә унлап данә йөрсен. Кирәк чакта, вакытын күрсәтеп язасың да... Әллүр – шәһәргә!

Шулай итәбез дә... Теләгән чакта ireккә ыргылу кәгазе кесәдә хәзер, барлыгын сиздереп, күкрәкне җылытып йөри.

***

Сентябрь башында Железняков белән саубуллашу көне килде. Ул өстәлен бөтен эчке байлыгы белән миңа калдыра хәзер. Кабинет ишеген бикләгәч, махсус җепне пластилин түгәрәк аша тарттырып баса торган бронза мөһергә бәйләгән чылбырны минем чалбар каешына беркетеп, кесәгә салды да:

– Күз карасы кебек сакла. Пичәткә син хуҗа! – диде.

Мин аңа әни биреп җибәргән йон оекбашларны бүләк иттем. Әни бәйләгән, дигәч, Володя Железняковның күз төпләре дымланды. Оекбашны йөзенә куеп иснәп торды. Ул әнисез генә, ятим үскән икән...

Перронда ул Минск поездының соңгы вагонына утырып, арткы ишек тәрәзәсеннән безгә кул болгап китеп барды. Шунда Комаров, тирән сулап куйды да, иңемнән кагып:

– Киләсе елга син мине шулай озатып калырсың, – диде.

***

Ниһаять, Мәскәүдән миңа оператив бүлектә эшләргә рөхсәт язуы килгән икәнен әйттеләр.

Капитан Астафьев мине котлады да, ниндидер альбом тышына ябыштырырга дип, дивизиянең чын номерын (без конверт тышына яза торганы 40401 иде), ике генә санлы, сер итеп саклана торган номерны язарга кушты. Ватман кәгазенә

кара тушь белән бизәкләбрәк яздым да мин моны, өстәл өстендә калдырып, төшке ашка китеп бардым.

Ике сәгатьтән килсәм, язулы кәгазем өстәл өстендә күренми. И эзлим, и бәргәләнәм – беркайда юк. Капитан Астафьев, гадәтенчә, үз язуына багынып утыра. Капитан Комбаров та ниндидер кәгазьләр арасына чумган.

– Шушында, өстәл өстендә калдырып киткән идем! – дип, үз-үземә сөйләнгәндәй, гасабиланып әйткәч, капитан Астафьев башын күтәрде дә:

– Бик начар иткәнсең, өстәл өстендә калдырып! – диде. – Ул бит дивизиянең сер итеп тотыла торган номеры. Аны бер чит кеше дә белергә тиеш түгел!

Капитан өстәл тартмасыннан алып, язулы кәгазьне миңа сузды. Бу минем өчен тәүге сыналу, итәгеңне җыеп йөр, дигән олы бер сабак булды. Рөхсәт язуы килгәннең икенче көнендә мине КГБ бүлегенә, майор Корниловка чакырттылар.

Гөнаһлар түтәлемдә нинди шайтан таяклары бардыр инде, шуларны күңелемнән йолкып, үземне фәрештәләр янәшәсендә торырга тиешле санап, барып кердем кабинетына.

Дәһшәтле булып тоелган майор Корнилов тимер киемле дә, күн киемле дә түгел, гадәти кительдән, карап торуга ягымлы гына күренә икән үзе.

Ул миңа Мәскәүдән «допуск» килгәнлеген, Оператив бүлектә эшләүнең җаваплылыгы хакында озынга сузмыйча гына аңлатты. Яшерен сергә ия документлар белән эш иткәндә сак булырга кирәклегенә басым ясап әйтте.

Аннары казармадагы тәртип, үзара мөнәсәбәтләр турында йөгерек сораулар бирде дә, кинәт кенә:

– «Америка тавышы»н тыңлаучылар бармы? – дип куйды. «Спидола» кебек кыйммәтле радиоприёмникның сержант Шульгинда гына икәнен беләдер, әлбәттә, мин дә тыңлаштыргалыйм, дигәнне ишетергә теләгәндер бәлки. Әмма мин «белмим» дигән саран җаваптан уза алмадым.

– Генерал шофёры кая барганнарын сөйлиме?

Бу сорау бөтенләй җитлекмәгән иде. Чөнки генерал шофёры иртүк китә, соң гына кайта, һәм, гомумән, югары начальствоны йөртүче шофёрлар күбрәк үзара гына аралашалар иде.

Миннән илһам ала алмаганны сизгәч, майор Корнилов торып басты:

– Оператив бүлектә әйбәт эшләрсез дип ышанам, – дип кулны кысып, ишеккә кадәр озата килде.

Бүтән ул мине бер тапкыр да борчымады.

***

Искеләр китә тора, яңалар килә.

Хәзер инде кореялы егетләр – Чагайлар юк. Тенниста Царьков дигән егет белән өзешәбез. Без – якташлар. Ул – Азнакайга чиктәш Шаран районыннан. Кап-кара чәчле, калын иренле, каратут йөзле, мулатка охшаган чибәр егет. Спорт белән шөгыльләнә. Шәһәргә бассейнга йөри. Җилкәләре калын, тыгыз тәнле. Брасс алымы белән йөзү буенча беренче разряд алуга ирешкән.

Бервакыт ул Минскига ярышка китеп барды. Ул әйтеп калдырган вакытта бөтен казармабыз белән телевизор каршына өелештек. Көтәбез. Менә йөзүче спортсменнар, бер-бер артлы чыгып, бассейн тирәли әйләнеп чыктылар. Безнең Царьков нишләптер күренми, көтәбез, юк кына бит. Китте төрле фаразлар:

– Туалетка кереп киткәндер, – ди кайсыдыр.

– Шаярткандыр гына, бөтенләй бармагандыр ул анда...

– Кызлар янында ятадыр әле...

Ярышлар башлангач кына Царьковның таныш фигурасы күренде. Су белән көрәшеп, каерып ишеп килгән егетебезгә экран аша көч биреп, калкына-калкына, бердәм кычкырабыз.

Нишлисең, яуланган икенче урын һәрчак нигә беренче түгел, дигән ризасызлык тудыра...

Берничә көннән кайтып төште Михаил Царьков. Һәркемнең телендә котлаудан тыш бер генә сорау иде:

– Теге чакта кайда идең, нишләп телевизордан күренмәдең?

Царьков кучкылт-кызыл иреннәрен җәеп, самими елмайды да:

– Гафу, егетләр, туалетта идем, – диде.

Менә шул егет белән теннис уйнау – үзе бер хозур. Чын күңелдән уйный, әмма җиңелгәндә дә ярсымый, җиңсә дә тыныч кала. Кеше осталыгын да таный, бәяли белә.

Ул миңа һәрчак «земеля» дип эндәшә.

– Армиядән соң күрешербез бит. Син миңа, мин сиңа кунакка килермен, – ди.

Очрашырга сүз куешабыз.

*Күп булса өч ел үтәр. Казанда университетта укыганда, мин кышкы сессиягә килгән читтән торып укучы Шаран егете белән танышырмын.*

*«Шаран» дигән яңгыравык сүз миңа шунда ук Михаил Царьковны искә төшерер.*

*– Беләсезме андый егетне? Сәлам әйтегез миннән, – дигәч, теге егет башын түбән ияр: «Царьков Михаил юк шул инде бу дөньяда», дияр. «Ничек юк! Андый егет югала димени, ул бит безнең ротаның утлы егете иде?!» Шуннан соң тетрәндергеч кыйсса ишетермен. Миша Царьков өйләнергә ниятләгән кызын әти-әнисе белән таныштырырга дип өенә алып кайткан. Бу хәлне көтмәгән ата-анасы көмәнле кызны мыскыллап, куып чыгарганнар. Царьков, ата-анасына рәнҗеп, үзе дә чыгып киткән. Гарьлегеннән бәргәләнеп йөргән дә поезд астына ташланган. Поезд тәгәрмәчләре астында калып, ике аягы да төптән өзелгән, үзе исән калган. Каны бозылып, бөтен тәненә тарала башлагач, өч көн буена: «Миңа агу бирегез, яшисем килми!» дип табибларга ялынган һәм дүртенче көнендә җан тәслим кылган.*

*Нинди егет иде бит! Тавышы хәзер дә колагымда яңгырап тора, чибәр йөзе, кызларның һушын ала торган елмаюы – күз алдымда...*

*Ә теге кызны... Царьковның әти-әнисе өенә алып кайтып, үзләре янында яшәтәләр, Мишага охшап туган оныкны үстерешәләр икән.*

*Соңлап килгән нинди үкенечле язмыш сабагы...*

***

Матбугатта басылып чыккан рәсемнәр шактый җыелып бара. Көндез, эш сәгатьләрендә, үз шөгылең белән мавыгып утыруны күз алдына да китереп булмый. Дөньяның бөтен четерекле эшләре миңа килеп ялгана кебек.

Шахмат буенча калын гына алты китап туплаган идем, аларны ленкомнатага алып кереп, өстәлгә өеп куйдым. Кем кызыксына, шул укый, өйрәнә ала. Нигәдер, бу хикмәтле уенга элеккеге дәрт сүнә, суына бара, ахрысы. Бөтен көчне рәсем ясауга, шигырь язуга бирәм. Әлбәттә, эштән соң калып, төннәрен генә, ялгызлыкның үзе бер бәхет икәнен тоеп, күңел мәгарәсенә төшеп актарынам...

Әле менә өлкә газетасы «Во славу Родины» редакциясеннән тагын бер хат килеп төште. Анда болай дип язылган:

*«Уважаемый тов. Галеев!*

*Решением редколлегии Вы приняты в заочную школу военкоров окружной газеты. 16 января в «Во славу Родины» напечатана первая страница в помощь слушателям (наш учебный план, консультация о заметке, первое задание). Посылая свои материалы в дальнейшем, ниже подписи добавляйте «слушатель заочной школы военкоров».*

*Начальник Отдела писем и массовой работы М.Гурьев.»*

Сурәтле фикерләүгә көчем җитмәсә, күңелдә кайнаган уйларны сүз көче белән белдерергә омтылып, шигырьгә тотынган булам. Ләкин минем баш очымда үрелеп кенә алырга сүзләр болыты җыелып тормый, сүз байлыгы каршында мин хәер сорашып торган фәкыйрь бер сукбай кебек.

Нидер расларга, бирешмәскә теләп алгысынган күңел ялгызы гына тыпырчына шул. Их, кырыеңда бер киңәшчең, остаз, акыл иясе булса иде, мине бу үзешчәнлек баткагыннан тартып чыгарыр иде, дип хыял йөртәм дә... Андый бәхет килеренә өмет өзеп, җитлекмәгән иҗат җимешләрен, аптырагач, редакциягә юллыйм. Анда инде баштан сыйпап кына тормыйлар, менә шушындый эчтәлектәге хат та язып җибәрәләр:

*«Уважаемый товарищ Галеев!*

*Ваш рисунок, при возможности, постараемся использовать в газете. А вот стихи явно не удались. Вы не владеете по-настоящему ни ритмом, ни рифмой, многие строки очень прозаичны. Много стилистических погрешностей. Вот Вы пишете:*

*Всюду светят огни, прожектора...*

*Одно слово здесь явно лишнее: прожектора – это ведь тоже огни. Вы рифмуете совсем нерифмующиеся слова: «Сыны – Родины». Помните, что стихи требуют большого труда.*

*С приветом, начальник Отдела культуры и быта подполковник М.Алексанов.»*

Төн... Кабинетымда мин дөньядан аерылып, күңел ireгeн тоеп, үземә калса, илһамланып, иҗат газабы кичерәм. Бу – үз-үзеңне яралап та, дәвалап та карый торган ләззәтле интегү газабы. Моның асыл мәгънәләрен мин аңлап та бетерә алмыйм әлегә, ерактa, бик тирәндә тавышсыз яшенен – тоның җемелдәгән аҗаганын гына тоям... Сизәм дә, тоям да кебек; күзгә күренми торган нинидер ишекләр берәм-берәм ачыла башлар да, мин, гаҗәеп дөньяга килеп чыгып, күңел җиһанындагы серләрнең асыл мәгънәсен төшенү тылсымына ирешермен кебек. Бу ишекләрнең ачкычы сүзләрдән коелган...

Төн... Тып-тын ялгызлык. Юк, колак салсаң, әллә нинди тавышлар саркып китә. Хәрби тормышта тынлык сүрүе дә хәвефле җепләрдән тукылган, ул һәрчак уяу, сак, йокысыз.

Аскы каттан әнә команда пунктыннан сөйләшкән тавышлар, нинидер аппаратларның үз ритмында чыкырдавы ишетелә. Штабның йөрәге тибә. Кан юллары меридианнар, параллельләр аша әллә кай ераклыкларга тоташкан.

Кинәт якында гына шапылдаган тавыштан сискәнеп, ишеккә ташланам. Байрак янында сакта торган солдат автоматын кулыннан төшереп җибәргән, басып торган килеш йокыга китеп алган, бичара. Кыяфәте куркынган, миннән гафу үтенгәндәй уңайсызланып, ул автоматын җәһәт кенә үрелеп ала да,

билендәге каешын төзәтеп, тагын, кыл кебек тартылып, урынына баса. Төнлә калып эшләгәндә, ничә тапкыр кичердем инде моны. Беләм югыйсә, шапылдап төшүеннән үк беләм, әмма бер-бер хәл булгандыр, бәлкем сакчының йөрәге тоткандыр дип хәвефле уйлыйм да, ишекне ачып карамыйча түзә алмыйм.

Уяулык сагында торган штабның бер бүлмәсендә, төн тынычлыгыннан файдаланып, бәләкәй генә дөнья булып, үз уема уралып утыруым мәзәк тә, бер карасаң. Мин бит мондый вакытны йокы хисабыннан әҗәткә алам. Югыйсә, җир катламын казып-казып та, ватык чүлмәк кисәге дә тапмаган археолог кебек, нәүмиз ымсынып каласымны да беләм. Якутлар табыладыр вакыт белән, дигәннәр әнә.

Өйрәнчек чакның да үз табышлары, үз югалтулары бар.

Менә «Во славу Родины» редакциясеннән тагын бер хат:

*«Уважаемый тов. Галеев!*

*Один из Ваших присланных рисунков «Цель поражена», возможно, поместим на страницах газеты. Другие Ваши рисунки имеют ряд недостатков. Рисунок «Перехват» – неудачное композиционное решение, надуманное. Старайтесь хорошо рисовать то, что видите на земле. Рисунки «Вести из Ташкента» и «За решением шахматной задачи» – имеют нарушения пропорции, не чувствует движения, статичны. Лучше продумывайте темы, которые хотите выразить в рисунке. Нам приятно получить от Вас хороший рисунок. Не забывайте о полевой учёбе воинов – это одна из важных тем.*

*Желаю творческих успехов. С приветом художник-ретушер Л.Дрозд.»*

Шулай итеп, рәсемнәр чит күзләргә барып ирешә, сынала тора. Ә менә шигырьләр... алар, очарга өйрәтелмәгән кош балалары кебек, дөньяга чыгарга куркып, оясында утыралар. Ул чакта әле мин, сүзләрне интектереп, шигырь читлегенә сыйдыра алмыйча азапланган малай, тәнкыйть дигән чукмар барын белми идем. Аның чәнечкесе дә, мамыгы да, киңәше дә, миләше дә үзендә икән бит...

Әзер бул, егет, әгәр син иҗат дәрьясының текә ярына килеп баскансың икән, курыкма, сикер билгесезлек упкынына!

***

Генерал Дудаковны Мәскәүгә, Хәрби һава академиясенә алалар икән, дигән хәбәр таралды. Сәбәбе – башкалада хәрби белгечләр, укытучылар җитмәгәннән түгел, әлбәттә. Дивизия командиры ничә полкны туплаган самолётлар кәрванына үзе баш булып, алгы рәттә очарга тиеш. Моның өчен медкомиссия үткәндә, шик калдырмаслык дәрәҗәдә сәламәт булу кирәк. Сугыш утларын кичкән кырык сигез яшьлек генерал, шулай итеп, белорус күгендә соңгы очышын ясады.

Без, ротадан алты-җиде егет, генералның фатирына, әйберләрен контейнерга төяргә дип бардык. Биш катлы йортта өч бүлмәле гадәти фатир. Төп мебельләре инде Мәскәүгә озатылган. Монда – Могилёвта яшәүче кызына җибәрергә дигәннәре генә калган икән. Генерал үзе, хатыны вак-төяк әйберләр белән кайнаша. Без төрле мебель, өй җиһазлары ташыйбыз.

Ике чиләк коньяк истә калган... Эреле-ваклы, купшы этикеткалы, яссы, йомры шешәләр ике чиләккә дыңгычлап тутырылган. Кибеттә аңгыра төстәге совет шешәләре генә күземә чалынганга, миңа болар гаҗәп затлы тоелды. Егетләр учка сыярлык шешәләрне суырып чыгарып, тотып-тотып карыйлар.

– Әллә берәрне кесәгә тыгабызмы? – диләр.

– Ярамый! – ди ефрейтор Пилипин. – Соңыннан генерал үзе сыйлаячак безне...

Контейнерларны төяп бетереп, капкачын япкач, генерал Дудаков безне тезеп бастырды да рәхмәт белдерде, берәм-берәм кулларны кысып саубуллашты.

Мәскәүдә һәм Мәскәү астында яшәргә тагын кырык биш ел гомер бирелгән генерал Александр Васильевич Дудаков белән әнә шулай хушлаштык.

Казармага кайтып барганда? егетләр ефрейтор Пилипинны «эт итеп» сүктеләр. «Ну, ничек, сыйладымы?!», «Синең аркада... чуты юк иде бит коньякның!..», «Һәрберебезгә берәрне тыксак та сизми иде бит!..»

Дивизия командиры итеп полковник Жихарёв билгеләнгәч, гарнизон тормышы яңа тәртип кысаларына керә башлады; аның әмере белән кояш чыга, аның әмере белән җил исә кебек тоела иде.

Булачак генерал утыз өч яшьләрдә; төз гәүдә, кырыслыгы килешеп торган чибәр кыяфәт, сыкы төсендәге каракуль папахадан, шинелендә ник бер ялгыш сызык, бөкләнгән эз булсын – бар ягы да килгән, пөхтәлек, затлылык үрнәге... Әмер биргәнче үк, үзенә буйсындыру теләгеи уята торган чын хәрби дәрман аңа тумыштан бирелгән иде.

Аэродромда, очыш вакытларында ничектер, ә менә гарнизон көнкүрешендә аның вакчыллык (педантлык) дәрәҗәсендәге тәртип кертүләре үзен сиздерә башлады. Яшь офицерлар хәрби киемне үзләренчә «бөгеп» китерәләр, хәтта чалбарны клёш итеп (балак очы киңәебрәк тәмамлана), тупыйк башлы ботинка урынына очлы башлы туфли киеп, носкины да ачык төслегә алмаштырып, модага ярашып киенәләр иде. Кайсылары хәтта фуражканың козырёгын кечерәйтеп, гасыр башындагы патша офицерларыныкы сыман итәләр иде.

Полковник Жихарёв чик куйды боларга. Лейтенант, өлкән лейтенант кебек яшь офицерларны туктата да чалбар балагын күтәрттерә. Хәрби стандартка туры килмәгән ботинкасын һәм носкиен алыштырып кияргә боера. Армиянең «сделать и доложить» дигән какшамас бер тәртибе бар; бирелгән эшнең үтәлгәнме, юкмы икәнен соңыннан тикшерергә оныту – гражданкадагы тормышның бәласе түгелме?!

Бер көнне полковник Жихарёв яраннарын ияртеп безнең казармага килеп керде.

Дневальныйның әтәчле тавыш белән ертылып: «Рота, смирно!» дип кычкыруыннан ук гадәттән тыш хәл икәнен аңлап, ятканы-утырганы сикереп торып үрә каттык.

Килә полковник казарма уртасыннан, күз карашы белән кистереп килә; чибәр-усал, пөхтә-ыспай, бөтен гәүдә торышыннан хәрбилекне ярату, буйсындыру ләззәте бөркелеп тора. Инде китәргә дип ишек ягына борыла дигәндә, Володя Дубовойга күзе төште бит моның. Дубовойның, гадәттәгечә, гимнастёрка итәге керләнгән, каешы бил турында, ябык ат муенына эленгән камыт кебек, иркен асылынып тора. Моны күреп, полковник корыч тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Ты что стоишь как бабай?!

Казарма эче дәррәү көлү тавышы белән тулды. Әмма полковникның кырыслыгын безнең көлү генә йомшата алмады.

Шул көннән соң Дубовойга «бабай» кушаматы ябышып калды. Бу сүзнең ни аңлатканын күпләр, әлбәттә, белми иде.

Телем шомара башлагач, мин рус теленә кайбер «төзәтмәләр» керттем.

Танцы мәйданчыгындамы, болаймы, кызларга карата «потаскуха» дигән сүз еш кулланыла иде. Әллә нинди сикәлтәле, авыр сүз. Мин моны «пыкуха» дип, җиңеләйтебрәк әйтүне телгә кертеп җибәрдем. Кабул иттеләр.

– «Как-как» дип, нишләп сез ата каз кебек какылдыйсыз, «кәк-кәк» дип йомшак итеп әйтергә кирәк, – дим. Кабат-кабат әвәләп, «ә» авазын сыгылдырып әйтергә тора-бара күнектеләр бит тәки.

«Сволочь» дигән сүзнең яңгырашы ошый иде миңа. Начар мәгънәне белдерсә дә, мин ул сүзне жәлләп, аяк астыннан күтәреп алдым. Башта өнәмичә йөрделәр дә, тора-бара:

– Эй, сволочь, – дип бер-береңә эндәшү гадәткә кереп, «дустым» дигән мәгънәне алыштырды.

*Пермьдә хезмәт иткәндә, теләгән чакта үз телебездә гәпләшергә, бушанып алырга җай бар, татарлар күп иде. Ә монда... мин – берьялгызым. Туган телем сызып кына күңел юшкынына күмелә бара. Ялгызым калып уйланганда яисә берәр шигырь юлы, адашып, күңелемә килгәндә генә, ана телемдәге сүзләр уйдыгында эзләнә башлыйм. Яфрак астына качкан җиләк кебек, кайбер сүзләр дә әллә үпкәләп инде, әллә ятсынып, хәтер пәрдәсе артына яшеренә.*

*Үз фикеремне мин үз телемдә эчтән, тавышсыз гына белдерәм. Көнкүрештә кирәген җуйган Ана телем хисләремә төренгән тавышсыз эчке тел – ж а н т е л е н ә әверелә бара.*

*Ә рус теле минем өчен көндәлек җан асрау өчен котылгысыз булган яңгыравыклы – т ә н т е л е н ә әверелә бара.*

*Җан телендәге сүзләрнең яңгыраш-тәмен мин әкрен генә җуям шикелле. Никадәр җиңел икән бит үз телеңнән мәхрүм калу. Моңа дистә еллар, гасырлар кирәк түгел икән. Шундый шартларга куелып, ихтыяр көчеңне җуйсаң, эчке иманың да булмаса, туган телеңә хыянәт итүеңне сизми дә каласың. Аннары... Тел сандыгыңда йомылып, сулышсыз калган сүз байлыгы, дәртен җуеп, берәм-берәм күзен йома барачак...*

Район газетасында чыккан шигыремне Фәния хатка салып җибәргән. Поезд Идел күперен чыккан чакта, гаҗәеп су киңлекләрен беренче тапкыр тамаша кылып барганда, әллә каян гына убылып төшкән иде ул шигырь юллары. Язып куярга җай юк иде. Күңелемнән туктаусыз кабатлап, ятлап бетергән идем: «Идел, Идел, күзен кыса кояш нурларыннан, елмая күк сине каршылап, тукта, поезд! Нигә ашкынасың, карый алмый калам яхшылап...»

Сизә идем, рәсем ясау гына канәгатьләндерми башлаган иде. Нидер әйтергә телим, ниндидер уйлар бәргәләнә, ничек шуларны белдерергә, күңел капкаларын нинди көчләр кагып ачмакчы – һич аңламыйм гына бит. Сүз егәре, шигырь җене тынычсызлаган икән лә мине. Ул авыру бер йоккач, котыла алмавымны шул чагында мин белми идем әле. Курка-курка гына редакциягә җибәргән идем – басканнар бит!

Газетаны Матвей Трофимычка күрсәттем. Ул шигырьнең график сурәтенә төксе генә күз төшерде дә көтмәгәндә әйтеп куйды:

– Мин синнән кеше чыгар микән әллә, дигән идем...

Менә, Трофимыч бер атна инде эштә күренми бит әле. Өстәле моңаеп тора. Авырып киткән. Авырый дигәч, без, гадәттә, «салкын тигәндер»гә ышанып, үзебезне юатып куябыз. Бу очракта... хәтәррәк икән шул. Матвей Трофимыч сөйләшеп торган чакта, кинәт кенә учы белән чигә турын кысып, тын кала торган иде. Вакыт-вакыт башы авырткан икән шул. Бәлки, ул авыртуның

сәбәп чыганагы сугыш чорларына барып тоташадыр. Хәрби самолётта укчы-радистның кабинасы койрык төбендә була. Фаҗига-мазар килеп чыкканда, күбрәк укчы-радистлар исән калганнар. Матвей Трофимычларның да, зенит утыннан самолётлары яна-яна төшеп, җиргә килеп бәрелгәч, койрык ягы сынып, илле метрга ыргытыла. Кабина эчендә Трофимыч исән кала. Бәлки, шул чактагы бәрелү аның хәзерге авыруына сәбәпче булгандыр.

Баш миендә кабынган яман шеш, мәкерле тамырларын бөтен тәненә таратып, Матвей Трофимычны бер ай эчендә яндырып бетерде.

Аның җәсәден соңгы юлга озатырга дивизиянең бик күп офицерлары килгән иде.

## Что ты наделал?!

Дивизия буенча «ел йомгаклары» дигән кебегрәк олы киңәшмәгә әзерлек барышы турыдан-туры безгә кагыла. Көне-төне зур-зур плакатлар әзерлибез. Саннар, диаграммалар, хәрби эш нәтиҗәләре язылган мондый плакатлар полклардан да килеп, дивизия штабындагы штурманнар һәм оператив бүлекләрнекен дә кушып бергә җыела.

Мондый «урак өсте» ай буена сузыла. Төнге икедә йә өчләрдә эшне төгәлләп киткәндә, дежурный бүлмәсендәге журналга китү сәгатен-минутын язып калдырасың. Димәк, синең төшкә кадәр йокларга хокукың бар. Беркем дә борчырга тиеш түгел. Ләкин мондый чакта җан түзми, ничек йоклап ятмак кирәк, мин, элеккечә, сәгать тугызда эш урынымда булам. Ә эш убылып кына төшә: берсен бетерүгә, икенчесен сонып кына торалар.

Иртәгә олы киңәшмә башлана дигән көнне Офицерлар йортының зур залына плакатларны сәхнә алдына эләбез. Сәхнә алды иңгә – егерме биш метрлар, биеклеге унбиш метр бардыр. Менә шул ара – идәннән түшәмгә кадәр без ясаган плакатлар белән каплана. Ике кырыйда бомба аса торган лебёдкалар, аларга нечкә тимер чыбыктан үрелгән арканнар тартылган. Шуңа беренче кат плакатлар эленә, аны күтәртеп, икенче кат эленә – шулай бара-бара түшәмгә кадәр менгерелә.

Трибунага пульт куелган: сөйләүчегә ничә минут вакыт калганы таблода янып тора. Указкалар төрле – биш, өч, бер метрлысы бар. Тоткычындагы кнопкага баскач, очында сары лампочка яна торган итеп эшләнгән.

Авырлыгы тоннага җиткән плакатларны элеп бетерүгә, без, солдатлар, залны бушатабыз. Ишекләргә автоматлы сакчылар куела. Хәзер инде монда пропусксыз черки дә борынын тыга алмый.

Иң четереклесе – карта белән эш итү. Секреткадан кирәкле төбәкнең картасын (номерын әйтеп, өлешләп) аласың да (масштаб буенча алар төрле: бер, ике, биш, ун километрлык итеп бүленгәннәре бар) кирәкле зурлыкта ябыштырып чыгасың. Итәкләре өстәл өстеннән салынып торган зур бер карта барлыкка килә.

Исең китәрлек, илдәге төбәкләрнең бөтен елга-инешләре, юллары, өч йорттан гына торган авылларына, сукмакларына чаклы, бөртекләп, картага төшерелгән. Адәм акылы ышанырлык түгел...

Берсендә шулай дивизия самолётлары заданиегә очасы төбәк картасын номерлары буенча ябыштырганнан соң карыйм: безнең төбәкләр ич бу!

Идел-Кама кушылган урыннар, әнә Казан, Чабаксар күренә. Әмма миңа иркенләп карарга мөмкинлек булмады, эшкә тотындык. Кырыйда

офицерлар, подполковник Журавлёв үзе... Четерекле саннар, исәпләүләр, маршрут сызыклары алар күзеннән уза. Язу, картага билгеләр төшерү – минем кулдан.

Картаны уңгарак шудырып, калын пероны тушька манып, яза башладым да... карасам, кул астымда минем авыл... Балтач дип аермачык язылган. Кулым калтырап китте, туктап калдым. Кырыйда күзәтеп торган подполковник Журавлёв, үзенең кыргычлы тавышы белән:

– Что-то у тебя ручка дрожит? – дип яңгыратып салды.

– Там моя деревня, товарищ подполковник, – дим.

– Вот и будем бомбить твою Татарию, – дип, подполковник ирен чите белән елмайды. – Не бойся, это будет всего лишь фотографическое бомбометание.

Картаны иртәнгә эшләп бетерергә кирәк. Журавлёв төнге унда өенә кайтып китте. Комбаров белән Астафьев – ике капитан гына калды. «Операция өстәле»нә иелеп, четерекле нерв җепселләрен ялгап, өчәү мәш киләбез.

Арылды, төнге сәгать икеләр. Астафьев белән Комбаров тәмәке тартырга дип чыгып киттеләр. Алҗыдым дип тормый, шундый чакта да җүләр уй башка килә бит ул. Мин бушаган тушь шешәсен картаның кап уртасына яткырдым. Кап-кара кәгазьне кайчы белән түгәрәкли-түгәрәкли кискәләдем дә шешә астына җәеп куйдым. Читтән караганда ышанмау мөмкин түгел: шешә ауган, кара тушь җәелгән, инде эше бетәргә күп тә калмаган картаның урта бер җирендә – мәхшәр!

Түр тәрәзә янына бастым да тегеләрнең кергәнен көтәм... Менә ишек ачылды... Комбаровның юка чәчле түгәрәк башы күренде. Бер-ике атлавы булды, күзләре зур ачылып, куркынган кыяфәт белән катып калды. Әллә инде теленнән дә язды. Артыннан кереп килгән Астафьевка ымлап кына карта уртасындагы «мәхшәргә» күрсәтә. Гадәттә, тыныч холыклы капитан кычкырып җибәрде:

– Что ты наделал!

Мин боларның шулкадәр тәэсирләнүеннән чыдый алмыйча, сыгылып төшеп, көләргә тотындым.

Шушы җүләрлекнең файдасы тиде бит. Барыбызның да йокы ачылды. Бу моментны кайта-кайта искә төшереп, әгәр чынлап та шундый хәлгә калсак... дип, кичереп карыйбыз.

– Чак инфаркт алмый калдым.

– Иртәгә яңа карта алып, эшне яңадан башлауны күз алдыма китердем дә...

– Әле күпме әр, күпме сүз булачак иде.

– Ну, татарин...

Бу сүзне мин төрле ягымлылыкта ишеткәлим инде. Күрше кабинетта майор Артемьев белән капитан Серёгин эшли. Шулкадәр ипле, тыныч холыклы кешеләр. Мин алар белән күрешергә дип уң кулны сузганда, сул кулны сәлкәү генә күтәреп, честь биргән булам.

– Ну издеваешься, татарин, – дип елмаеп куялар.

Уңдым мин штаб офицерларыннан. Дивизиянең баш штурманы подполковник Мостафин үзе, өченче каттан төшеп, кабинетка кереп хәлеңне белешкәләп чыксын әле. Җитмәсә, ял көненә очучылар ашханәсенә барасы талоннарын керткән.

– Коткар син мине, өйдә хатын пешергән ашны ял көнендә булса да кабып карарга иде бит. Югыйсә, бөтенләй үпкәлиләр, – дип, ул ике талон калдыра.

Ял көнне, иптәшкә Комаровны да алып, киттек очучылар ашханәсенә.

Бинага килеп кергәч үк шаккатып калдык. Һәркайда гөлләр, тәрәзәләрдә затлы пәрдәләр, өстәлләргә ак эскәтер җәелгән.

Өч залга бүленә икән очучылар ашханәсе. Нинди самолётны егәрләвеңә карап, ризыкның тәме, калориясе билгеләнгән. Поршневиклар залы – ике канатлы самолётта очучылар өчен. Калган икесе – реактив самолётта очучыларга – дозвуковойлар һәм сверхзвуковойлар залы. Без, Комаров белән, соңгысына кердек. Башына ак калфак, зәңгәр күлмәге өстеннән ак сарафан кигән стюардесса (без аны шулай атадык) кыз очып кына килеп җитеп, безне өстәл артына утыртты. Ашның гына да җиде-сигез төре бар икән. Кайсын сайларга белми аптырадык.

Ул ризыкларның тәмлелеге! Өстәлдә торган горчица, борыч, әҗикә, тагын әллә нинди шешәләрдәге кызыктыргыч соусларның барысын да татып карыйсы килә.

– Ресторannарың бер кырыйда торсын, – ди Володя. Минем Бөгелмәдәге рестораннан кала, бүтән затлыракны күргәнем булмагач, чагыштыра алмыйм. Бер-бер артлы килеп торган блюдаларның яшелчә-җимешләр белән бай бизәлешенә исем китеп карыйм. Менә нинди дә була икән бит – ашау сәнгате!

Ашханәдән чыккач, гел елмаясы, гел көләсе килә, Володя белән кар атыша-атыша кайтабыз. Тәмле ризык белән бергә күңелләргә кояш керде, кәеф күкнең җиденче катыннан аягын салындырып утыра...

Безнең «ашау бәхете» кичергән мондый көннәр айга ике-өч тапкыр кабатлана башлады. Рәхмәт инде баш штурман Мостафинга һәм аның урынбасары Шаһиморатовка. Хатыннары ял көнендә тәмле өй ризыгыннан өзелдермәсен генә...

## Бүрек

Дисбе кебек, бер җепкә тезелеп, талгын гына эре кар ява. Тополь ботаклары бу тере аклыктан рәхәт кытыкланып, оеп утыра.

Йокыдан туеп, күземне ачуга, тәрәзә уемындагы шушы күренеш мине сәламли.

Яңа елның беренче эш көне.

Киенеп беткәч, искәрәм: бүрегем урынында юк. Бүрек минем башка хыянәт итеп, ташлап киткәнме әллә? Башта үзем генә эзләп карадым. Аннары күрше-тирәмдәге егетләр эзләшергә кереште. Юк кына бит. Өч елга исәпләнгән бүрегем эзен суыткан. Урлаганнар диясе килми. Чөнки казармада угрылык дигән нәрсәнең моңарчы сизелгәне юк иде.

Штабка мин офицерлардан алданрак, тугыз тулганчы килеп утырырга гадәтләнгән идем. Бүген старшинаны көтеп соңга калам инде.

Осипенко килгәч, минем хәбәрдән аптырап калды, йөзендәге кызгылт рәшә урыны-урыны белән тимгелләнеп чыкты.

– Неужели бацилла воровства просачивается и в нашу казарму… – дип үзалдына сөйләнгән кебек әйтеп куйды.

– Сайлап ал, – дип, каптёркадан өч бүрек чыгарып бирде.

Берсеннән-берсе искерәк, «ашы» бетеп, формасын җуйган бүрекләрне киеп карарга да кул күтәрелми, баш чиркана.

Китеп бардым яланбаш кына. И көннең матурлыгы! Чәчне каплап, баш түбәсенә кар өелә бара, өелә бара, гәүдәне төз тотарга тырышып, баш өстенә чүлмәк утырткан кебек атлыйм. Килеп кердем шулай штабка ак папаха киеп, икенче катка күтәрелгәндә эри башлаган карның тамчылары муенны

«пешереп», аркага таба юл алды. Кабинет ишеген ачып җибәрсәм... ушым китә язды. Капитан Астафьев өстәле янына бер төркем офицерлар җыелып баскан, погоннарындагы эре йолдызларны шәйләп, курка калдым. Башына кар бүрек утыртып килеп кергән солдатка болар шаккатып карап каттылар. Ул арада безнең подполковник Журавлёв әчкелтем катыклы тавыш белән кычкырды:

– Бу нинди маскарад?!

– Бүрекне югалттым, – дидем мин юаш кына.

– Кайда? Казармадамы? Старшина Осипенко ни караган?! – дип, ул телефонга тотынды. Офицерлар төркемендә подполковник Мостафин да бар икән. Ул Журавлёвны туктатып калды:

– Кирәкми, чылтыратмагыз. Хәзер мин үземнең бүрекне китертәм, – дип телефон номерын җыеп, хатынына аңлата башлады.

Карасам... Мостафинның иңендә полковник погоннары. Иске елдан Яңа елга атлап чыкканда аңа тагын бер йолдыз өстәгәннәр икән. Югары дәрәҗәдәге офицерларның безнең кабинетка җыелу сәбәбе: катастрофага эләккән самолёт экипажының сөйләшүләрен яздырган «кара ящик»тан гадәти магнитофонга күчерелгәнне тыңламакчылар икән.

Мин туалетка чыгып, башның карын коеп төшереп, сөлге белән сөртенеп кергәч, озак та үтмәде, аскы каттан дежур солдат Мостафинның бүреген кертеп чыкты. Шулай итеп, «сыкылы» каракуль папахага күчкән полковник Мостафинның бүреген, маңгаендагы кокарда эзен тарап, урынына йолдыз беркетеп миңа кияргә насыйп булды. Бу инде солдат кавемендәге бөтен бүрекләргә бүрек иде.

Кайчакларда, кичен кәеф булганда, каптёркадан авиаторлар кия торган әллә ничә замоклы, кесәле, мех якалы куртка алып киям (аңа погон тагылмый), аякта хром итек, бүреккә кокарда тагып куям да, төп капкадан, дежурныйларга честь биреп кенә чыгып китәм «самоволкага»... Яшь офицер яисә сверхсрочник дип калалар бугай. Шәһәр шавына күмелеп, истирәхәт кылып йөрим, минутларның кадерен тоеп, ирекле тормышка манылып алам.

Казармага кайткач инде бүрек маңгаена батып кергән кокарда эзен яңадан тарап, урынына йолдыз беркетеп куям.

***

Ялга кайткач, өйдән ботинкалы тимераякларны алып килгән идем. Ял көне кичен киттем үзебезнең стадиондагы катокка.

Яратам – үткен конькиларның чыкырдап бозга кабуын, бала-чагалар чыр-чуын, кызларның егылганда да ыспайлыгын онытмыйча егылуын, аякларны чалындырмый торган рәхәт музыка яңгырашын, бозда ярылып калган ак эзләр чигелешен яратам.

Монда – аяклар туганлыгы. Бар да бер ритмга көйләнергә тырыша. Янәшәңдә кулга-кул тотышырга кызың булмаса, җил белән култыклашасың.

Сагынганмын икән боз исен.

Каток кайда да бер инде: дәртле музыка, конькиларның сызылып китүе, йә сокланып, йә куркып кычкырып куюлар – болар бар да таныш авазлар букеты, ә бала-чага чыр-чулары шул букетка үрмә гөл булып урала.

Онытылып, шуып барганда аркама кемдер учы белән сугып куйды. Карасам, майор Шаһиморатов елмая, затлы спорт костюмыннан, янәшәсендә чибәр генә ханым бала җитәкләгән. Шаһиморатовның гәүдә торышы спортсмен икәнен сиздереп тора...

Икенче көнне ул безнең кабинетка төргәк күтәреп керде.

– Бу – сиңа бүләк, – ди. Сүтеп карасам... Өр-яңа спорт костюмы. Кичә, катокта минем сәләмәрәк киемгә кыеклап кына күз төшереп алган иде шул...

Рәхмәттән кала нәрсә әйтим инде. Майор Шаһиморатов шундый бүләк бирә алуына үзе дә шат.

– Катокта бөтен кызлар мине сырып алачак хәзер, – дим.

Ул чыгып киткәч, карыйм, төргәк эчендә тагын бер төргәк бар. Теш пастасы сыман калын-юан тюбиклар. Болар – самолётта, ун чакрым биеклектә алтышар сәгать очкан чакта тәмләп кую өчен махсус паёклар икән. Тюбикның берсен кысасың – стакан тулыр-тулмас борщ савылып чыга, бер сынык ипи белән ашап куйсаң (аның тәмлелеге!), җыбылҗык исле ашханәгә барып торасы да юк. Икенче тюбикны кысасың – хуш исле шоколад ишелеп төшә. Өченче тюбикта – какао.

Тора-бара штурман милләттәшләр мине бөтенләй «аздырдылар», өстәлем тартмасында затлы тәгам тыгызлап тутырылган шундый тюбикларга урын җитми башлады.

***

Барановичи шәһәренә тагын бер тапкыр командировкага барырга туры килде. Бу юлы да ЛИ-2 самолётына утырдык. Бу юлы да дивизия командиры үзенең яраннары белән барды. Генерал Дудаковтан аермалы буларак, полковник Жихарёв бөтенләй башка, командарм рухы аның бөтен гәүдә торышыннан бөркелеп тора. Самолёт салонына кереп, түргә үтүгә үк, ул аерып торучы пәрдәне тартып, ябып куярга әмер бирде. Штурвал артына утырмады шикелле. Чөнки бу самолёт аның өчен ишәк җигелгән чытыр арба кебегрәк тоеладыр...

Барановичи аэродромына төшеп утыргач, ишек ачылуга мин кыбырсып, урынымнан тордым да, чыгарга дип бара башладым. Шулчак арттан Жихарёвның корыч тавышы, үткен сөңге булып аркама кадалды:

– Товарищ солдат, вернись!

Мин урыныма кире ничек килеп чүмәшкәнемне дә сизми калдым. Бераздан яраннары белән үтеп киткән Жихарёвның җиле генә тиеп калды. Ул арада ишетәм, нәкъ теге чактагыча, ярсып, оркестр уйнап җибәрде. Мин аны Советлар Союзы Герое буларак, Дудаковны гына шулай каршылыйлардыр дигән идем, дивизия командирын сәламләү ритуалы икән бу...

Барановичида безгә катастрофага эләккән ТУ-22 самолётының хәрабәләрен күрсәттеләр. Өлкән лейтенант Вакарин, дулкынланудан, сулышына төелеп сөйли:

– Күз алдымда булды бит, – ди. – Экипаж командиры белән дус идек. Очыш алдыннан футбол хакында сөйләшеп утырдык. Кузгалганда кабина тәрәзәсеннән кул болгады. Күз алдымда бит... Күтәрелеп киткәч, унбиш секундтан... коточкыч шартлау... күз алдымда бит... төшеп кадалды.

Гадәттә, очучылар катапульта вакытында, креслосы-ние белән, снаряд кебек уналты метр биеклеккә оча. Болар секундлар эчендә, әлбәттә, катапульта ясарга өлгерә алмаганнар. Ә штурман исә кнопкага басып өлгергән, аска очкан, әмма парашюты ачылырга биеклек-ара җитмәгән, җиргә бәрелеп чәпәлгән.

Тимер чыбыклы магнитофон исән килеш табылган. Анда экипаж командирының «Куда задрал нос ё....мать!» дигән кычкыруы гына язылып калган булган.

Штурманның ямьшәйгән креслосы бер кырыйда ята. Самолётның кабыргасы

эчтән ишелеп-ишелеп сузылган меңнәрчә электр чыбыклары белән тулган. Хәйран калмалы, бу кадәр хикмәтле приборларны, бу үткәргеч чыбыкларны җыеп, тоташтырып бетерергә нинди баш, акыл-зиһен җитмәк кирәк.

Туксан тоннадан артык авырлыктагы самолёт җирдән аерылып күтәрелгән чакта, иң хәтәр мизгелләрне үтә. Штурвалны тән сизгерлеге белән генә үзеңә таба тартмасаң, «угол набора высоты» бозылып, самолёт секунд эчендә кисәкләргә таркалырга мөмкин.

Очышын мәңгегә җуйган самолёт хәрабәсен карап йөргәндә әллә нинди уйлар башка килде. Кешедәге ашкыну, тәвәккәллек, үз-үзен аямау, дуамал көчне егәрләргә тырышу һәм... фаҗига. Бу хәрәкәт гел шулай кабатлана тора, азагы да, тукталасы да юк... Шайтани омтылыш...

Миңа үзебездәге ТУ-16 самолётының һәлакәткә дучар ителеп, егылып төшүе хакында материаллар бирделәр. Самолёт җир өстеннән үткән юлның сызымын сызарга кирәк иде. Ни булган, нинди сәбәптән ике турбинасы да ун мең километр биеклектә тынып калган? Моны ачыклау өчен, гадәттә, электр, ягулык һәм башка төрләр буенча махсус белгечләрдән комиссия төзелә.

Самолёт (ярый әле бомбалары булмаган) кинәт сүнеп, электр тогы беткәннән соң, күпме генә тырышып карасалар да, кабаттан худка җибәрә алмаганнар. Бердәнбер юл калган, самолётны акрынлык белән түбәнәйтә бару (планирование)...

Кырга төшеп, зур тизлек белән карлы җирне сөреп барган вакытта кабинага җир укмашкан кар кантары бәреп керә, уң очучының аягын кысып имгәтә. Буынсыз калып, тирбәлеп барган шассилар, җиргә килеп бәрелүгә, канатны тишеп, өскә бәреп чыгалар. Самолёт ике километр буена буразна сызып барганнан соң, олы гына салам эскертенә терәлеп туктап кала.

Өч метрлы ватман кәгазенә менә шул самолёт үткән юлны, кайсы төштә нинди деталь төшеп калганына кадәр бөртекләп схема-рәсем эшләдем. Комиссия әгъзаларына ул катастрофа сәбәпләрен ачыклап, йомгаклау җыелышында күргәзмә әсбап буларак эленде.

## Капитан Комбаров

Бүген эш бик җитди, катлаулы булырга ошый. Хикмәт шунда: дивизиянең реаль картасы бар икән. Ул штаб начальнигы сейфында саклана. Аны биш елга бер дөнья яктысына чыгарып, төзәтмәләр кертеп, яңага күчерергә кирәк, имеш. Картаны эшләгәндә кабинет ишеген эчтән бикләп, хәтта, күрше кабинетлардагы офицерлар да кертелмәскә тиеш.

Сейфка сыярлык итеп бөкләнеп, таслап куелган картаны подполковник Журавлёв алып керде. Нәкъ безгә кирәкле меридиан, параллельләр кергән өр-яңа, чиста карта секреткадан алынып, минем өстәлгә җәеп салынган иде инде. Итәкләре өстәлнең як-ягына салынып торса да, картаны биниһая зур димәс идем...

Таныш шәһәр исемнәре, елгалар... Сугыш!.. дигән хәтәр әмер яңгырауга бу шәһәрләр, күперләр бомба шартлаулары астында калачаклар бит инде.

Карта өстенә иелеп, искесен кырыйга куеп, эшкә керешәбез. Бүлмәдә дүртәү – подполковник Журавлёв, ике капитан – Комбаров һәм Астафьев. Дүртенчебез – мин.

Төш җитәрәк ишек кактылар. Журавлёв үзе барып ачты. Калын портфель

токан полк секретчигы килгән. Автоматлы сакчысы коридорда торып калды. Секретчик алып килгән карталар күрше өстәлләргә җәеп салынды. Аларның реаль карталарыннан да мәгълүмат алу, чагыштыру кирәк икән.

Шулай итеп, бөтен акылны туплап, яңа карта йөзенә яңа мәгънә кертү бара.

Бераздан Журавлёв һәм Астафьевны каядыр чакыртып алдылар. Кабинетта җаваплы булып капитан Комбаров калды. Мин реаль картаның искесен төреп, башка карталар янына куйдым, эшләнә генә башлаган яңасы өстенә кәгазьләр каплап, төшке ашка киттем.

Ике сәгатьтән килсәм... бүлмәдәге офицерларны танымый торам. Капитан Комбаров картаеп киткән шикелле, пешеп чыккан йөзенә күгәрек төс кергән, хәтта, чәчләре дә хәлсезләнеп маңгаена ябышкан. Капитан Астафьев та берни дәшми, ишекле-түрле йөренә. Подполковник Журавлёв та кереп, кырку тавышын күтәреп, ниндидер ымлыклар кычкырып чыгып китте.

Хикмәт шунда: иске реаль карта юкка чыккан. Көпә-көндез. Кабинеттан. Җаваплы булып капитан Комбаров калган иде бит. Ул нишләргә белми, бәргәләнә бичара.

Сизенәләр, полк секретчигын эзлиләр. Дүрт сәгать буена «совершенно секретно» мөһере алган (бер җөмләсе өчен егерме биш елга хөкемгә тартырга мөмкиннәр) реаль картаның язмышын ачыклый алмый тордылар.

Штаб начальнигы Шестопал гадәттән тыш хәл турында дивизия командирына җиткергән. Дүрт сәгатьтән соң, ниһаять, ачыкланды. Капитан Комбаров полк секретчигы портфеленә бүтән карталар белән бергә реаль картаны да салып җибәргән икән...

Автоматлы сак астында янәдән полк секретчигы пәйда булды, реаль картаны тотып, капитан Комбаров, ашыгып штаб начальнигы кабинетына кереп китте.

Бер сәгатьтән приказ әзер иде инде. Капитан Комбаровны өлкән лейтенант дәрәҗәсенә төшереп, егерме дүрт сәгать эчендә бүтән частькә күчерергә, диелгән иде анда.

Капитан Комбаров бүтән күренмәде. Кызганыч, шулкадәр ипле, юаш кеше иде бит ул. Хатыны, мәктәптә укучы улы бар икән. Әмма хәрби кануннар катгый, әгәр дәүләт серенә карата әз генә хилафлык китерәсең икән, берни белән исәпләшенми, тапланасың икән, аклана алмыйсың...

Кинәт үлеп киткән кебек тоелды ул миңа. Мондый тетрәнүдән соң ничекләр сыгылмый калыр да, ничекләр тураер бу кеше, дип уема керә дә сызландыра...

Ә тормыш дәвам итә. Берничә көндә яңа реаль картаны да тәгәлләп чыктык. Эш отыры катлаулана барган саен мине котырта, көч бирә, шуны җиңеп чыгасы килү дәрте яшәвемә мәгънә өсти шикелле...

## Госпиталь

Ярамый шул бәрәңгегә өйрәнгән ашказанын кинәт кенә артык тәмле ризык белән сискәндерү. Сигезенче март тирәләрендә ашханәгә бер дә бармыйча, Офицерлар йорты буфетында да, кабинетта да шоколад капкалап, кофе-какао кебек бүтән меридианнан килгән хуш исле эчемлекләргә генә салынган идем – берничә көннән бәреп чыкты, тупас ризык тансыклаган ашказанымны нык рәнҗеткәнмен ахрысы. «Гастрит в стадии обострения» дигән диагноз куеп, мине шәһәр госпиталенә салдылар.

Баш табиб Маркинзонның хатыны Фрида Григорьевна палатада ятучы

унлап егетне (һәрберебезгә халат, җиңел-кыска балаклы шаровар кигезелгән, хәрби дәрәҗәләрне белерлек түгел) дә бертөрле карый: фонендоскоп куеп күкрәкне, арканы тыңлый, аннары порошоклардан торган өч төрле дару бирә. Кәгазен ачып, шуларны тел өстенә саласың да, су белән юдырып эчкә озатасың. Бераздан рәхәт бер халәт аңны иләсләндерә. Изрәп караватта ятам, түшәмдә әкрен генә люстра әйләнә. Бүтәннәргә күз кырыен төшерәм, алар шуны ук кичерә микән, әмма сорарга кыймыйм.

Көндезге аш вакытында өстәлдәге савытка үрелим дим, ә ул ерагая бара, ерагая. Компотлы стакан күз алдымда юанайды, мин аны бүрәнә тоткан сыман, ике куллап колачларга җыенам. Авыру шулай буладыр инде, дип, бүтәннәр сизмәсә ярар иде дип куркам.

Өч көн буе шундый хәл кичердем. Ниһаять, дүртенче көнне... палатада бик көйсез, гел тавыш чыгара торган, дуамал холыклы грузин егете бар иде, шул Фрида Григорьевна кергәч, тавыш чыгарды бит:

– Сез нинди дару биреп агулыйсыз мине?! Күз алдында бөтен нәрсә әйләнә, туктата алмыйм!

Баксаң, палатадагы бөтен егетләр дә шул халәттә интегә икән. Чөнки барыбызга да бер үк төрле порошоклар бирәләр бит.

Моны белгәч, Фрида Григорьевна каушап калды. Шуннан соң порошокның ике төрен генә бирә башладылар. Боларын гына эчкәч, тәндә бернинди үзгәреш сизелми – күңелсез булып китте. Теге грузин егетенә ачу да килеп куйды. Әйтмәскә иде бит, әйләнсен иде дөньясы, әйләнәсе килгәч... Рәхәт иде лә күзәтеп ятуы...

Госпитальнең бөтен табиблары да яһүд милләтеннән. Медсестралар белән җыештыручылар гына белорускалар. Аларның үзләренчә сузып, кычкырып сөйләшүләре әллә каян яңгырап тора.

1 апрель көнне, хәлне белергә дип, яныма Валя, Рая, Люба һәм Володя Комаров килделәр. Тәм-томнар алып килгәннәр.

Коридорның фикус гөлләре ышыклаган аулак бер урынында, нигъмәтләрне уртага куеп, сыйланып алдык. Баллы нәрсәләрдән курку бетмәгәнлектән, мин печенье генә капкалап утырдым. Китәргә дип кузгалышкач, Володя мине читкәрәк алып китеп, шаккаткыч яңалык әйтте: бүген Оборона министрының приказы булган. Киләсе елдан армия хезмәте ике елга калдырылачак икән. Ә без, өченче елга чыкканнар арасыннан утыз процент солдат демобилизациягә эләгәчәк, имеш.

Мин, бу хәбәргә ышана алмыйча, тынсыз калдым. Беренче апрель, алдау көне, дип, Володяны чыгырыннан чыгардым.

– Приказны үз күзләрем белән күрдем. Менә ипи тотып «ант» итәм дип, – печенье сыныгын күрсәтә. – Их, ике ел ярым гына хезмәт итәчәкбез бит, тиздән – өйгә! – дип, Володя мине кочаклап, дер селкетә. – Гафу ит, авыру икәнеңне онытканмын, – ди.

– Нинди авыру?! Бу хәбәр – үзе бер бальзам, мин җен кебек таза хәзер!

Үзем генә калгач, җан тарыга башлады. Киңлеккә сусап, тәрәзә катына килдем. Бөтен нәрсә мәгънәсен җуйды: дару исләре, палаталар, медсестраларның ак чагылышы, бөресе тулышкан каштан ботакларының тәрәзәгә үрелүе...

Йөрәк ашкына. Миңа сәламәт икәнемне исбатлап, моннан тизрәк чыгарга кирәк. И җүләр, әйтерсең лә казармаңа кайтуың иреккә чыгуга бәрабәр. Мин утыз процентка эләгү өчен кичекмәстән үземне әзерләргә тиешмен!

Ә бит бүгеннән башлап, һәр солдат мин кайтып китәчәкмен дигән ышаныч белән яши башлаячак хәзер...

Утыз процент ... Уннан – өч, йөздән – утыз, меңнән – өч йөз кеше... Мин бу бәхетле санга эләгәчәкменме?

Язмыш атына ышанам, ул үзен тышаулатырга ирек бирмәс...

Ике көннән инде мин штабта, үземнең эш кабинетында идем. Тиз генә Мәскәүгә В.И.Суриков исемендәге сәнгать институтына укырга керү шартлары турында сорап хат яздым. Әгәр язу килсә, армиядән алданрак котылу өчен җирлек булмасмы дип талпыну инде бу...

Язмышны хәл итүдә иң төп кеше – штаб начальнигы – полковник Шестопал. Аның әмереннән тора. Шестопалның кәефен күтәрерлек, исендә калырлык ни дә булса эшли аламмы? Уйланам. Маңгай җыерчыклары – рельслар. Алар өстеннән уй поездлары уза. Дивизиянең елъязма-истәлек альбомына керәсе фотоларны карап чыгам. Шестопал кергән унлап фото бар. Шуларның берсе – пионерлар каршында, кызыл галстук тагып, честь биреп торганы – иң шәбе. Моннан картина эшләп карарга була ич!

Ватман битен стенага беркетеп куям. Фотоны диапроектор аша төшереп, форматын көйлим. Миңа Шестопалның йөз рәвешен генә алып калырга кирәк... Калганы – минем фантазиядән тора...

Алгы планда – честь бирдермичә генә, пионер галстугы тактырмыйча гына... полковникның сурәтен калку итеп бирәм. Артта – самолётлар, һава лачыннары – үзебезнең «ТУ»лар.

Мин бу рәсемне шулкадәр бирелеп, беркемгә күрсәтмичә, төнге сәгать уникеләргә кадәр калып, күңелемне салып, берничә көн буена эшләдем. Башта карандаш белән, аннары тушька күчеп... Чын гравюра, кыр-кырларында ак полоса калдырылган картина бу – шәп килеп чыкты.

Үзем дә сокланып, карап алам да, яшереп куям. Берничә көн шулай кабатланды. Кемнеңдер кулы кагылыр, юк итәрләр сыман шөбһәләнеп, эшкә килүгә, рәсемем шкафта төрелгән килеш урынында торамы, дип тикшереп алам.

Мәскәүдән, Суриков исемендәге сәнгать институтыннан җавап бик тиз килде. Анда керү имтиханнары, кабул итү шартлары тәфсилләп язылган иде (русский язык и литература – сочинение, и устно, история народов СССР). Нәкыш һәм графика факультетына керүчеләргә: нәкыш, рәсем, композиция буенча осталыгын расларга җитмеш сигез сәгать вакыт биреләчәге әйтелгән.

Хатның иң мөһим урыны азагында иде: документлар 1 июньнән кабул ителә, имтиханнар – 11 июльдән диелгән.

Капитан Астафьевка, уңай форсат табып, Шестопалга багышлап ясалган картинаны күрсәттем. Ул, эчкерсез кеше буларак, күңелендәген яшермичә:

– Шәп чыккан бу. Үзенә күрсәтергә кирәк. Җае чыкканда мин аңа әйтермен, – диде.

Мин, аның сүзендә торасына һич тә икеләнмичә, Мәскәүдән килгән язуны чыгардым. Ул игътибар белән укып чыкты да:

– Моны башта Журавлёвка күрсәтик. Алдан аның белән киңәшү зыян булмас, – диде. – Аның алдына Шестопал рәсемен чыгарып салма. Көнләшер...

Подполковник Журавлёв, кыбырсык, җитез холыклы буларак, үз кабинетында гына йомылып утырмый, берәр күрсәтмә бирергә дип безнең кабинетка көненә унар тапкыр бәреп керә. Бер керүендә капитан Астафьев минем хакта сүз кузгатты. Журавлёв тыңлар-тыңламас кына торган кебек булды да:

– Найди себе достойную замену. Иначе – никуда! – дип чыгып китте.

Бу хакта мин үзем дә борчыла идем инде. Володя Комаров кайсыдыр полктан бер егетне тапкан да иде, танышырга һаман җай чыкмый торды.

Беренче елын хезмәт итә торган ул егет Мәскәү өлкәсеннән – Люберцыдан булып чыкты. Виталик исемле. Авызы белән сулавын исәпкә алмаганда, ярыйсы гына кыяфәтле егет күренә. Оператив бүлеккә алып кереп таныштырыр алдыннан мин аңа парикмахерга барып чәчен төзәттерергә, гимнастёркасын юарга, хәзергә парад мундирын киеп килергә куштым.

Башта ул ипле-тыныч кына йөрде. Кулы каләм тота белә. Лозунг пероларын йөртүе дә өметле күренә. Тик бер җитешсезлеге бар: ул тотынган җирдә ак кәгазь йөзендә тап кала. Кара тушь белән эш итә башладымы – уйламаганда пычратып куя инде. Аның һәр хәрәкәте минем йөрәк аша уза, тагын берәр ярамаган нәрсә чыгармасын дип, ут йотып торам. Аның ярты юлда азаплап калдырган сызымнарына эштән соң калып, үзем тотынам.

Күз уңында булсын дип, Виталикны полктан үзебезгә – идарә ротасына күчерттем. «Бүре баласын бүреккә салсаң да, барыбер, урманга карый» дигән кебек, буш вакыт булдымы, үзенең полкына китә дә югала, җитмәсә «салып» кайтып керә. Бусы инде безнең даирәдә күрелмәгән хәл. Хәмер килешми үзенә. Җил тегермәненә охшап китә – куллары, сүз куәсенә ияләм дип, гел бер-берсен куышып, әйләнгәләп, чәбәләнеп тора. Борыны бөтенләй тыңкышланып, һава сулауны бөтенләе белән авызына ышанып тапшыра.

Аптырагач, шулай болагайланып йөргәндә, изүеннән буып алып, мин бу малайны стенага дыңкыдым:

– Тагын бер күрсәм, «салып» кайтканыңны... Башыңны сугып ярам! – дип кычкырдым.

Көннәр үтә тора. Кайту хыялы бөтен аңымны биләгән. Майор Железняк складына төшеп, туган якта рәссам-бизәүче булып эшләячәгемне әйтәм, кайбер кирәк-яракларга күзем кызганын яшермим. Ул, ике дә уйламыйча, миңа илле табак ватман кәгазе, күп итеп тюбиклы буяулар, бик нәзберек кылдан кытайлар эшләгән пумалалар бирә, бик кыйммәтле (50 сумнар тирәсе) әллә ничә данә циркуль, рейсфейдерлар җыелмасы салынган футлярны бүләк итә.

Мин боларны ике посылка итеп өйгә җибәрдем.

Володя белән шәһәр читендәге «кара базар»га барып, чит илдән кергән ак нейлон күлмәк алабыз. Бу инде күрелмәгән затлылык. Мин тагын Бобруйскида танылган оста тарафыннан тегелгән очлы башлы, биек, авыш үкчәле кара туфли сатып алам...

Май ае күбәләк кунса, күбәләкнең яланаяк эзе калырлык самими яфраклары, яшеллеге белән кайнап, Белорус җирен нурга коендыра башлады. Безнең парктагы танцы мәйданчыгына «җан» керде. Ял көне кичен, узган елдагыча, тар капкадан чуар киенгән кызлар бу якка агыла. Ә бу яктан гөмбә кебек бертөрле яшькелт киемле солдатлар килеп, танцы мәйданчыгында укмаша.

Безнең өч берлек – бөтерелмә итәкләре белән бу язга тагын да матураеп килеп кергән кызларыбыз – Валя, Рая, Любалар танцы мәйданчыгында аерым бер игътибарны җәлеп итә.

– Әйдә, Татар ия җирләргә алып китәм сине, – дим Любага.

– Куркам... – ди Люба.

– Сиңа анда кыен булыр шул, – дип, Люба белән килешәм. – Канлы, чи ит ашарга туры килер сиңа. Ук белән җәя тотып, бүре тиресе бөркәнеп йөрерсең. Шалашның менә дигәнен корып куярбыз.

– Безнең әнинең туган җирен мыскыллама, – дип сүзгә кушыла Рая белән Валя.

– Ул бит икенче... Татар белорусы...

– Син чын татар түгелдер... Киноларда күрәбез: алар бит кысык күзле, бөтенләй башка кыяфәттә...

– Кинода бит татар роленда казакъ, кыргыз артистлары уйный.

– Нишләп алай?

– Кысык күзле кеше усал, явыз булып күренә. Ә татар явыз булырга тиеш... Менә минем кебек.

Кызлар көлешәләр. Музыка кулларны кулга тоташтыра. Сулышка – сулыш. Күзгә – күз. Тромбон тавышы йөрәккә бәрә.

Соңгы көннәремме монда? Китеп барырмын микәнни?

Алмагачлар, шашып, чәчәккә коена.

Кал, әйдә, монда кал, кал инде, дип ягымлы белорус язы җиңемнән тарта. Калалмам ахрысы, кичер мине белорус кояшы, болай да инде хәтәр яу-сугышларда күпме татар башын салган бу җирдә. Ә миңа исән-имин кайту бәхете язсын Ходай...

Штабта гадәти эш көне иде. Сирәк була торган хәл: полковник Шестопал кабинетка килеп керде. Басып каршы алдык. Барыбыз белән дә кул биреп, күрешеп чыкты. Капитан Астафьев миңа ым какты. Тиз генә шкафтан теге картинамны алып, өстәлгә җәеп, тыңлаусыз ватман кәгазе бөтерелеп ябылмасын өчен, баш-башларына авыр әйбер куйдым. Капитан Астафьев:

– Иптәш гвардии полковник, күз салыгыз әле, – дип, Шестопалны минем өстәл янына алып килде. Ак кайма уртасында бәрхет кара төстә бик нечкәләп ясалган рәсемгә карап, Шестопал тын калды, ирен читенә елмаю җәелде. Аннары миңа күз төшереп алды, тагын рәсемгә текәлде дә:

– Моны миңа бүләк итәсезме? – диде.

– Сезгә... бер истәлек булсын дип...

Ул арада капитан Астафьев минем рәсемнәрнең газетада еш басылуын, вакытында демобилизация булса, Суриков исемендәге институтка керергә теләвемне, тизрәк әйтеп калыйм дигән кебек, тиз-тиз генә сөйләп бирде. Мин институттан килгән язуны өстәл тартмасыннан алып полковник алдына куйдым. Игътибар белән карап чыкты:

– Анда мәктәпне быел гына бетергәннәрне алмыйлармыни, – дип искәртмә итеп бирелгән юлларны укып чыкты: *(На дневное отделение принимаются лица, имеющие стаж работы не менее двух лет на производстве по специальности или рекомендацию среднего художественного училища).*

Шестопал, сынап карагандай, бер тын сүзсез торды да:

– Алай икән... – дип сәгатенә карап алды. – Рәсем өчен рәхмәт. Мин аны рамга алдыртырмын. Бу миңа армия тормышыннан кадерле истәлек булып сакланыр. Артына кулыгызны куегыз, бәлки сез киләчәктә бөек рәссам булырсыз, – дип, елмаеп кулны кысты. Кул куеп, рәсемне бөтереп тотып, мин Шестопалны кабинетына кадәр озата бардым.

Бәлки бу – минем гомеремдә хәлиткеч көннәрнең берсе булгандыр.

Хәзер инде юлымда бер генә кантар борчып тора. Ул да булса, уйнаштан туган малай – Виталик. Аның һәр хәрәкәте минем йөрәккә кагылып уза. Бу сиңа полк түгел, бу – дивизия штабы, монда югары белемле офицерлар эшли, итәгеңне җыеп йөр, дип тыныч кына әйтеп тә, үгетләп тә, кычкырып та, маңгаена йодрык терәп тә карыйм – юк, аң соралмаган үҗәтлек ягына тиресе калын малайның.

Беркөнне үз полкына барып киләм дип киткән җиреннән сугышып кайткан. Маңгаенда яра эзе. Бу килеш штабка алып барып булмый бит инде, алып киттем моны Офицерлар йортына. Концертмейстердан яра эзенә грим салдырттым.

– Эшлисең килмәсә, мин киткәнче генә түз, аннары үзең карарсың, – дим.

– Полкка кире кайтасым килми, – ди үзе.

Штаб офицерлары каядыр Украинага учениегә китәргә әзерләнә. Ыгы-зыгы, һәр бүлектә ашыгыч эшләр өелде. Офицерларның үзара яшерен генә пышылдашып алуларын, нәрсәнедер белеп тә, әйтергә ярамаганлыгын сизәм, ниндидер астыртын шом канатларын җәя бара. Бу – мине куркыта, шиккә сала. Стенадагы картага карыйм: динозавр нинди этлек эшләргә җыена тагын? Бу шаукымда мин тапталып калмаммы?

Минем язмышка битараф йөргән сыман иде, полковник Журавлёв кабинетына чакырып алды да:

– Иртәгә китәбез. Сез дә без кайтканчы китеп барырсыз шикелле. Мин сездән канәгать калам, – диде, гадәти-кырыс чыраена саран гына елмаю төсмере чыкты. – Хәтерлисездер, декабрь аенда Мәскәүгә, Генеральный штабка җибәрергә дип биш плакат ясаткан идем...

*(Ул плакатларны бик тырышып, әһәмиятле урыннарын төсләр белән бизәп, әллә каян күренеп торырлык итеп, армия кырыслыгына үземчә яңалык кертеп ясаган идем. Плакат астына «Исполнитель гвардии рядовой М.Галеев» дип кую – анысы мәҗбүри иде.)*

– Мәскәүдән чылтыраталар бервакыт, ул гвардии рядовоегыз кайда хәзер, хезмәт итәме әле? – диләр.

– Нигә? – дип сорыйм.

– Плакатлары бик шәп чыккан, әллә соң үзебезгә алдырыйк микән... – диләр. Мин инде сүз башында ук чамалап алган идем. Юк, минәйтәм, ул демобилизацияләнде, дим. Жалко, дип сүзгә нокта куйдылар. Шул чакта сине коткарып калдым, димәкче булам. Югыйсә, бүген-иртәгә кайтып китәсе урынга... Пахал бы до тридцать первого декабря в Генеральном штабе...

Рәхмәт әйтеп подполковник белән саубуллашам. Кичен кабинетта офицерлар да: «Кайтып җитә алмасак...» – дип хушлашалар. Капитан Астафьев иңнән кочып, аркадан чәбәкләп саубуллашты. Болар бар да иртәгә учениегә кузгала. Мин дә тиздән китәм микәнни? Күңел ышанмый.

Ике көннән, 21 майда – приказ, штаб начальнигы Шестопал кул куйган, юл документлары әзер, ике сәгатьтән мин Минск поездына утырырга тиеш. Әйберләр җыелган. Старшина Осипенконы көтәм. Ул бер ай элек миннән кырык биш сум акча алып торган иде. Шуны кайтарырга тиеш. Володя Комаров – янәшәмдә, минем китү шатлыгыннан иләсләнгән акылны дөрес юнәлешкә кертеп йөри.

Килде, ниһаять, старшина. Нигә чырае гел кызыл микән дип уйлый идем, кырыйдан ышкылып узганда искәрдем: бит тиресе бик нәзберек, куе кан тамырларыннан тора икән. Ә поезд китәргә минутлар калып бара. Акылым – өермә. Шул өермә уртасында старшина Осипенконың төче елмаюы унике мәртәбә янып сүнде инде.

– Менә кырык сумыңны кайтарам. Биш сумы... Син үзегезнең якта алма үстермиләр дигән идең. Көзгә хәбәр сал, вагоны белән алып киләчәкбез! – дип ул киң итеп елмаеп куйды.

– Чё ты лыбишься! – дип үзе сыман әйтергә минем чират та бит... Биш тәңкәгә кул селкеп, җылы гына хушлашабыз.

– Йөгер штабка, Шестопал машинасы гына бар анда, сора полковниктан! «Гвардии» дип әйтергә оныта күрмә, онытсаң, тью-тью машина... – дип Комаров миңа юнәлеш бирә.

Мин, тыным-көнем бетеп, Шестопал кабинетының катлы-катлы ишекләрен ачып керәм:

– Товарищ гвардии полковник!

Сәгатемә чиртеп хәлне аңлатып бирәм. Ә ул гадәттән тыш сабыр.

– Әгәр гражданкада авырлыклар килеп чыкса, кире әйләнеп кайт, эш табарбыз, – дип хәерле юл теле. Мин дә:

– Желаю Вам расти до генерала! – дим. Полковникның авызы ерыла.

Шофёры – чөенке борынлы Кистер, һәрвакыттагыча, дәрте ташып торган немец егете. «УАЗ»икны сикертеп диярлек урыныннан кузгата, казармага таба кузгалабыз.

– Почётный круг вокруг казармы! – дип, Кистер бер әйләндереп чыгара. Бу аның яраткан гадәте, штаб каршындагы мәйданга чыгып баскан Шестопал тирәли дә ул почётлы түгәрәк ясап килеп туктарга күнеккән. Ә Шестопалга аның бу гадәте ошый иде.

Әйберләрне Комаров белән машинага салып кузгалабыз. Күрәм, аэродромда эшләүче егетләр волейбол уйныйлар. Тәгәрәп киткән тупларын таптатмыйм, дип Кистер шып туктады, мин тиз генә төшеп, туп артыннан килеп җиткән Михаил Царьков белән кочаклашып хушлашам.

– Привет передай родным краям, земеля. Прощай, увидимся!

Ул арада әллә каян гына минем өстәлгә хуҗа булып каласы Виталик пәйда була. Онытып китеп барасы идем бит, чылбырын ычкындырып, бронза мөһерне кулына сонам. Озата барам, дигән була бит әле. Син минем ничә бөртек чәчемә агарырга заявка бирдең, тинтәгем, хуш!

Кистер безне урындыкларына калын затлы келәм түшәлгән машинасында, күздән утлар күренгәнче талкытып, ике урамны бер итеп, әллә инде йортлар аша да сикертеп, вокзалга китереп бушатты. Поезд китәргә җиде минут бар. Володя белән хат язышырга сүз куешабыз.

– Узган ел шушы перронда нәрсә дигән идең, мине озатырсың дигән идеңме?

– Син беренче булгач, мин – икенче булырга риза, – ди Володя моңсуланып.

Поезд кузгала. Соңгы вагонга кереп, арткы ишек тәрәзәсеннән килеп кул болгыйм. Шпаллар артка таба йөгерә. Күзгә яшь килә. Китмәс борын сагына да башладым түгелме. Рәхмәт сиңа, Белорус җире. Күп нәрсәне аңламаганымны аңларга өйрәттең бугай син мине.

Плацкарт вагонда юлчылар бик аз икән. Дүрт урынга берүзем хуҗа. Шәп булды бу! Тәрәзәне шудырып ачтым. Башны вагоннарны ялап искән дуамал җилгә куйдым. Чәчне йолкый, яңакны чәбәкли, баштагы уйларны җилгәрә... Җилгә уралып, еллар күңелгә бәрә.

«Минме мин?! Ике ел ярым гомер эчендә бер карышка булса да үсә алдыммы мин? Әллә соң ничек киткән булсам, туган якка шул ук хәлдә кайтып бараммы?»

«Нишләп син үзеңә кимсетеп караучыларга иң борынгы, бөек халыкның улы икәнлегеңне кычкырып әйтә алмадың?!

Моннан ничә мең ел элек Баба (Бабай) Аллага табынган Таргитай уллары, өч бертуган патша – Илбаксай, Колаксай, Арпасайлар сак-скиф-сармат илләре төзеп дөньяга исемен яңгыратканнар. Скифлар җиһанда беренче булып ук-җәя, карабаир юргаларда үрә басар өчен өзәңге уйлап тапканнар».

«Япан дала курганнарында алтын-көмештән тиңдәшсез сәнгать җәүһәрләре калдырган сак-скиф-сарматлар турында кемнәр белми?»

«Европаның ничә халкы телендә дастаннар багышланган бөек Атилла оныгы икәнебезне кемнәр белми?»

«Өч җирдә, өч болгар дәүләтен төзегән нәсел атасы – Кубрат ханның оныгы икәнебезне кемнәр белми?»

«Үзеннән соң дүрт улын тулы бер кыйтгада дүрт мәмләкәт төзеп калдырган Чыңгыз хан оныгы икәнебезне кемнәр белми?»

«Евразия киңлекләрендә – күпме елгалар татар исеме белән ага; күпме урман-тайгалар татар исеме белән шаулый; күпме дала-үзәннәр татар исеме белән офыкларга тоташа; күпме тау-кыялар татар исеме белән күккә чөелә!»

«Нигә син боларны бөтен буеңа басып яңгыратмадың?»

«Ничек әйтим! Мин боларны белми идем бит: мине хәтерсез, уйсыз итеп тәрбияләделәр».

«Тарихны белмәгән кешене мыскыллап та, көлеп тә, рәнҗетеп тә була».

«Тарихны белмәгән кеше тамак ялына денен дә, динен дә, телен дә сатачак».

«Үзен дә, телен дә, халкын да яклый алмаган тарихсыз бәндәне бүрек белән бәреп тә йөзтүбән аударып була... Ул – тамырсыз агач кебек, күбәләк җиленнән дә егыла».

«Аклану – мескенлек».

«Бары бер юаныч кала: белмәвеңне белү – белемгә омтылуга беренче адым...»

***

Мәскәү мине битараф кочагын җәеп каршылады. Метрога чумып, җир астыннан «Комсомольская» тукталышына кадәр барып, Казан вокзалына чыктым да, әйберләремне саклау камерасына урнаштыргач, ике кулымны рәхәт селкеп, урамны тутырып агылган кешеләр елгасына кушылдым. Магазиннарга кереп, үземә яңа киемнәр ауларга кирәк. Калдырып киткән иске киемнәрем мине көтә-көтә саргаеп беткәндер инде.

Затлы магазиннарда җансыз курчак кебек салкын күзле сатучы кызлар мин солдатка бик илтифат итмиләр. Сораган әйберне карчыга томшыгы кебек кәкрәеп сузылган озын тырнак очлары белән эләктереп, теләр-теләмәс алдыма куялар. Мин күк төстәге шакмаклы лавсан чалбар алам. Балак очлары кайтарып тегелгән. Иске модага карый инде бу. Шуңа күрә арзанрак та. Шундый ук төстәге эшләпә сайлыйм. Уртасына энҗе бөртеге эләктерелгән кара бант – монысы нейлон күлмәк заказы... Шакмагы үз төсеннән чыккан свитерга күзем төшмәс борын кул сузыла.

Шулай итеп, Сабан туена әзерлек Мәскәүдән башланды.

Казан вокзалына кайтып, икенче катка, хәрбиләр өчен генә эшләп торган ательега керәм. Ике ханым утыра. Стеналарга, бөтен җиргә эреле-ваклы хәрби киемнәр эленгән. Лавсан чалбарны чыгарам.

– Балак очын турайтып, клёш ясап бирегез, зинһар, – дим.

– Биш сум һәм шоколад. Бер сәгатьтән әзер булыр.

Валя дигәненә аңлатып бирәм: балакның үкчә ягы бер сантиметрга озынрак булсын, – дим. Валя дигәне миңа «Ишь ты» дигән кебек сынабрак карап куя.

Хакы белән килешеп, чыгып китәм. Вокзал мәйданчыгында кара погонлы, шактый «йончыган» мундирлы солдат җиңемә кагыла. Тавышы, кыяфәте шундый мескен:

– Мин бөтен акчамны урлаттым. Калугага кайтырга кирәк. Ярдәм ит, зинһар, ялынып сорыйм, – ди. – Менә хәрби билетым, адресны язып ал, кайту белән җибәрәм бурычымны...

– Кирәкми, миңа җибәрәсең бит, минем адресны язып ал, – дип, мин хәрби билетымны чыгарам. Мәскәүдә алдану уенының мондый алымы да бар икәнен уйламыйча, биш тәңкәне чыгарып бирәм. Рус егете түбәнчелек белән, билдән бөгелеп, кат-кат рәхмәт әйтеп китеп бара. (Күзгә карап алдаганнарны кичермим. Ничә дистә ел үткәндер, шул солдат кисәге кайчакларда искә төшә дә... их, егет, мине алдарга ярамый бит, нинди казаларга юлыктың микән, дип аны кызганып куям.)

Бер сәгатьтән керәм ательега, эшләп куйган Валя ханым, киеп карыйм – гаҗәп инде. Лавсан чалбар наят утыра, уң аяктагы капрон оекбашны тишеп, баш бармак йомран кебек башын калкыткан, Валя ханым күргәнче, яшереп өлгерәм.

Яңадан галифе, күн итекләремне киеп, пәрдәле кабинадан чыккач, искәреп алдым: Валя ханым офицер кителенә погон тегеп утыра. Погон кырыеннан атлатылган җепләре күренеп бара.

– Рөхсәт итсәгез... – дип мин аның кулыннан энәне алам, карамый торыгыз, – дип, погонның ярты ягын тегеп чыгам. Бер генә җеп эзе дә күренми. Ябыштырып куйган кебек. Валя шаккатып карый:

– Ничек алай килеп чыкты? Галя, күр әле!

Икесе дә погонны тотып, тартып карыйлар, җеп эзе күренми. Шуннан мин бик гади серен ачам:

– Атлатып текмәскә, энәне чыккан эзенә кертергә кирәк, шул вакытта җеп күренмәячәк...

– Күпме эшлим, моны безгә берәүнең дә әйткәне юк иде әле, рәхмәт сиңа, – ди Валя ханым. – Шоколадың җиткән, акчаң кирәкми. Гражданкада тегүче идең мәллә?

– Мин – ювелир, һәр эштә, – дип, кызлар белән саубуллашам. Чыгып, саклау камерасыннан чемоданымны алам, шунда бер аулакта хәрби киемнәремне салып ташлап, Мәскәүдә алган чалбарны, шакмаклы күлмәкне, юка курткаын, эшләпәне киеп куям. Аякта – очлы башлы туфли. Хәрби киемнәремне таслап төреп, сеткага салып, туалетка кертеп, тәрәзә төбенә куям. Үпкәләмәгез миңа, дим. Яңа чакта мин сезне алып кайтып, ике мәртәбә авылымны күрсәттем. Хәзер инде, искердегез, котылыйк бер-беребездән...

Атлыйм вокзал мәйданыннан, туфлинең биек үкчәләре аякны чөеп-чөеп җибәрә, очып китәрмен кебек. Шулкадәр җиңел, рәхәт, җырлыйсы килә. Минме бу, дип үз-үземне капшап карыйм. Скафандрны салып, бүтән планетага эләккән кебек, ләззәти исерү белән, әрле-бирле йөренәм. Кешеләргә карыйм, уйламыйлар да, киемнәре нинди җиңел икәнен сизмиләр дә сыман...

Кофе эчеп, киләп сарып йөргәннән соң, тагын икенче катка менеп, ательега керәм. Теге ханымнар минем якка күз салыр-салмас кына:

– Что вам, молодой человек. Мы обслуживаем только военных, – диләр. Мин көлеп җибәрәм. Бу нинди җилсу егет керде соң әле, дип, бераз текәлеп карагач кына, танып алалар мине. Чәй өстәле янына түгәрәкләнәбез. Бер-беребезне күптән белгән кебек сөйләшәбез. Алар погон тегү сәнгатенә өйрәткән өчен миңа кабат-кабат рәхмәт әйтәләр.

Сәгать төнге унбердә Чиләбе поезды мине туган як тарафына алып китте.

***

Бер тәүлектән артык юлда талкыткан поезддан соң, иртәнге сәгать җидедә Бөгелмә автобусы мине туган авылым Балтачка керә торган тукталышта төшереп калдырды. Төнлә яңгыр явып узган. Бөдрә рәшәле кырлар парланып ята. Кер кунмаган язгы яфракларда кояш нурлары атына. Әллә нинди рәхәт хозурлык бу! Акылны исертеп баш әйләнә.

Чемоданымны, солдат капчыгын күтәреп бераз җир китүгә, артымда трактор тавышы ишетелде. Карыйм, алдына әллә нинди чытырманлы әйбер таккан зәңгәр «Белорусь» яныма килеп туктады. Кабинадан сикереп төшкән егетне танымыйм, без юк елларда буйга сикергән, ә ул таный, исемем белән эндәшә. Әйберләремне дә, үземне дә кабинага менгерешә.

Ике үр арасында барлыгын сиздерми утырган авылым, тау кашагасына килеп җитүгә, кинәт уч төбендәге кебек ачылып китте. Түбәләр, капкалар, эре чәчәкләре балкып утырган тәрәзәләр – бар да таныш, бар да якын...

Капка төбенә кайтып туктыйбыз.

– Ишегеңне ачмый тор, – дим егеткә. Тын гына күзәтеп торабыз. Игътибар да итмиләр. Әни ишегалдында тавыкларга җим салып йөри, әти баскычта тәмәке тартып утыра. Бераздан соң гына, аптырап, бу трактор нишләп безнең капка төбенә үк килеп туктады соң әле, дипме, кузгалдылар болар. Мин кабинадан сикереп төштем. Әни, гадәттәгечә, сабыр гына килеп, ирләрчә күреште. Әти, каушаудан, тәмәке төтене бөркеп, ютәлләргә тотынды.

– Менә – Белоруссиядән шушындый «Белорусь» тракторы биреп җибәрделәр, – дим, тәме онытылган туган телемдә «тавышлы» сүзләрем мәзәк чыга сыман. Бик тырышып, әйтәсе сүземне сайлап кына сөйләшергә инде. Югыйсә, татарчасын онытып кайткан булып кылана, дип мәзәк чыгаруларын көт тә тор...

– Сабан туена кайтып җитәр әле, дип күңелем сизгән иде аны, – ди әни.

– Минем дә төшкә керде, – ди әти.

Әти капканы ача. Менә ул, капка шыгырдавында – туган нигез пароле...

Кай арада өйгә күрше-тирә җыелып өлгерде. Өч-дүрт өй аша гына яшәүче Рәзинә апа да йөгереп килеп җиткән. Һаман шулай: беренче класс баласы кебек оялчан, бөтен эчкерсезлеге алланып, бит очларына бәреп чыкты:

– Синең белән киткәннәр берәү дә күренми, тагын ялга кайттыңмы әллә? – ди.

– Бетереп кайткан! – ди әни, шатлыгын яшерә алмыйча.

Күрешәләр, шаулашалар, кая солдат киемең, янарал булып кайтканыңны күрергә кердек, диләр.

Бөтерелә өй шатлыгы. Әни савыт-саба чылтырата. Әти елмаеп кына тора әлегә, әзрәк кәгеп алгач кына аның теленә былбыл куна, «Ул-лым» дип, җылы итеп эндәшә башлый.

Күрше-тирә түтиләр бер-берсен бүлдереп тормыйча, барысы берьюлы сөйләшәләр, шул ук вакытта тыңлыйлар да... И, сагынганмын икән мин бу операны!

***

Урау юллар тузанын коеп, еллар тышавын чишеп, бөтен уйларымнан кагынып, бүген менә сиңа таба барам. Башлап әйтергә нинди сүзләр сайлыйм, күңел аланында чәчелеп яткан мең-мең сүз арасыннан иң гадиләре телгә килә:

– Сагынып кайттым, Фәниям!

Соңгы елда атна-ун көнгә бер килеп торган хатларыңда үз күңелеңә тирәнгәрәк яшеренә бара идең сыман. Ераклашумы бу миннән, яраклашумы бүтәнгә?..

Синең тавышың мине, ерактан торып та уята, күз карашың, ерактан торып та назлы эзәрлекли, йөрәк тибешең, ерактан торып та җан тибрәнешенә көйләнә; гомерлеккә шулай янәшәмдә юатучым да, уятучым да – син ул, син, дигән ышану белән яшәдем бит мин. Ә инде гомер сукмагында вакытлы тайпылулар, матурлыкка сокланудан тыела алмаган күңелнең үрсәләнеп алуы гына... Ялгышулар аша синең кадереңне аңлар өчен нәүмиз талпыну гына. Боларны мин сиңа сүзләргә төреп аңлата алмам ахрысы. Тагын менә, чирәмле ишегалдында, эңгер төшеп килгәндә, үзеңне күргәч, әйтеләсе сүз тәлгәшләре боегып калды да, күңел коесына төшеп китте.

– Сагынып кайттым... – дидем дә, – уенчыгы ватылган сабый сыман туктап калдым. Син дә кочакка ташланмадың.

– Тагын ярты елың бар бит әле. Нишләп иртә кайттың?

– Мин дезертир бугай, командир.

Саран гына елмайдың. Күзләреңнең миңа дигән уты чаткыланмый, нидән бу – сагаю салкынлыгы?

Теге вакыттагыча... төшемдә арабызга шуышып кара елан кергәне хәтергә килә. Мин аны таптап, сине кочакларга омтылам. Бөтен тән-рухың киреләнә, кулларың җавап бирми, күзләрең салкын...

– Синнән бизгәнмен икән. Шулкадәр чит син миңа, – дип башыңны читкә борасың.

– Бүтән берәүгә күз салдыңмы әллә?

Җавап хәвефле җептә эленеп тора да, өзелеп төшә:

– Нигә мин?.. Ул беренче булып күз салгандыр бәлки...

Нинди киң тоелган ишегалды тараеп, кысылып килә. Мин, дуамал хис ташкынын тыя алмыйча, капканы бәреп кенә ябып чыгып китәм. Каядыр барырга, бушанырга кирәк. Музыка тавышлары яңгырап торган клуб ягына тартылам. Кайный күңел. Мин шушылай ялгыз калыр өчен еракларадан кайтып төштеммени! Хәзер керәм клубка, авылның иң чибәр кызын урап алам!

Клуб ишеге төбендә егетләр, без югында буйга сикергән яшьләр инде болар... Ярый әле күрешергә дип токарландым беразга, кайнарланып килүемне сүндерә төштеләр болар. Сүзләре колакка керә, мәгънәсе тышта кала, минем аңзиһен кыерсытылып, канаты сынган хәлдә, миңа хәзер юаныч, онытылу кирәк.

Арадан бер егетне читкәрәк алып китеп:

– Авылда иң чибәр кыз кем дип саныйсыз? – дим.

– Гөлсирин, – ди бу.

– Егете бармы?

Көлеп куя:

– Кыргый ул, – ди. – Озата баручылар булды, капкасына бәрелеп, маңгаен канатып кайттылар. Әнә ул, үзе дә килә!

Мин борылып карыйм. Куе чәч толымын баш түбәсенә урап куйган, балериналар кебек озын муенлы, төз гәүдәле кызый кыю гына атлап, сапсары блузкасы, ак юбкасы белән төн караңгылыгын куркытып килә бу. Егетҗиләннәргә күз дә салмыйча клубка кереп китте.

Юк, күңел читлегенә тиз генә ымсындыра торган кош түгел бу! Моңа вакыт кирәк. Әгәр мин дә капкасына бәрелеп чигенсәм, бу егетләр каршында көлкегә калачакмын бит.

Юк, бүген мин бу кыргый кошка якын бара алмыйм. Тапталган мин, сындырылган, читкә тибәрелгән. Клуб ябылмаган килеш өеңә кайтып кит әле, кайчан күрелгәне бар мондый хәлнең...

***

Туганнан туган абыем – Рубис Себер якларыннан, Уренгойдан кайтып төште. Акча сугып, баеп кайткан. Мотоцикл алып җибәргән. «Өйләнергә иде, димләгән кызны Бөгелмәгә барып күреп-танышып кайтабызмы, синең күзең үткен, ошаса, тәвәккәллим», ди.

Киттек Бөгелмәгә турылап. Көн аяз. Мин Мәскәүдән алган яңа киемнәрем белән мотоцикл артында җил бәргәләгәнгә риза булып барам. Машиналар берән-сәрән генә күренә. Рубисның әле мондый көчле мотоцикл иярләгәне юк иде. Велосипед, мопед – шуның ишеләр генә. Юл шәп. Тизлекне арттырырга да була.

Салаязга җитәрәк, асфальт уртасыннан кара төтен бөркеп, масаеп килүче дәү МАЗ машинасы күренде. Болай да тар асфальтны тутырып, караеп килә бу. Сизәм, Рубисның аркасы тирләп чыкты, мотоциклны кырыйгарак алам дигәндә... бәләкәй генә чокырга эләгеп, алгы тәгәрмәч сикереп куйды да, Рубис руль тотрыклыгын тыеп кала алмады, мотоцикл ава язып, туп-туры МАЗ каршысына ыргылды. Әле генә хозурлыгына чумып барган кояшлы күк йөзе, яшел кырлар, минем кичә генә ерак аралардан кайтып төшүем – бар да үкенечкә каламыни, дигән әллә нинди тетрәндергеч бәхилләшү сагышы – бер мизгелгә йомарланып, котылгысыз тизлек белән үлем каршысына суырылып керәчәк бит хәзер! «Их!» – дигән әрнүле ымлык кына юл өстенә чәчрәп калачак!

Ни хикмәт, Рубис авып барган мәлдә рульне каерып өлгердеме, машина торбасыннан бөркелгән эчкелтем сөремле төтен арасыннан чагылып киткән галәмәт зур тәгәрмәч, ышкыла язып, үлем җиле бәреп яннан узып китте. Авып бетә язса да, чытырдап тотынганлыктан, гәүдәләребезне селтәп атмыйча, асфальтны сыдырып барган мотоцикл аска төшеп, уҗымлы кырга чыгып, йомшак җиргә төртелеп тукталды. Бер мәлгә ни үле, ни тере хәлгә калып дөньяны гүя барлыйбыз: күктәге кояш шул укмы, без исәнме? Карыйм, кул аркасы сыдырылган, кан ага, лавсан чалбар балагы умырылып чыккан.

МАЗ машинасы ерак та китми туктаган икән, шофёры йөгереп килә.

– Сез исәнме? – дип икебезне дә күздән кичерде. – Ярый әле, Ходай саклаган... Минем дә баш Себер китә иде, – дип шофёр мотоциклны торгызышты. Сул ягында, аяк баса торган җирләре генә кәкрәйгән. Бүтән зыян юк шикелле.

Сөремле машина китеп барганнан соң да без уҗымлы кырда шактый утырдык әле. Андый чакта гел шулай: фаҗигале истәлекләрне барлап, үзеңнең исән калуыңа юанып аласың...

Аңга килеп беткәч, сәяхәтебезне бүлеп, кире кайтырга булдык.

Авылга төшеп, Фәнияләрнең бәрәңге бакчасы кырыена килеп туктадык. Әнисе – Фәимә апа ары башта, үзе киртә буенда гына бәрәңге матиклый.

Канлы кулны күрсәтәм. Кесәдән кулъяулык чыгарам. Фәния аны erткалап кулны бәйли. Сизеп торам, «яратып» бәйләми. Бернинди җылы сүз, кызгану, ярага кайнар тынын өрү, хәлгә керү сизелми. Ә минем җәлләтәсем, юату сүзләре ишетәсе килә. Юк, миңа карата күңеле бозланган бит моның. Хатын-кыз каршында үзеңнең кирәгең булмауны тоюдан да мескен халәт юк. Бетте болай булгач, бар да бетте.

## КҮТӘРЕРГӘ ЯРАМЫЙ ТӨШЕРЕРГӘ

**Әйе, тереклек судан яралган, адәм баласы якты дөньяга чыкканчы ук тугыз ай буе су эчендә яшәп ала. Су – яшәү чыганагы, су – саулык, су – байлык, су – күңел ачу урыны һ.б.**

**Урта буйлы шәһәрләрнең Алпамша мегаполисларга әверелүе электр энергиясенә кытлыкны һаман саен арттыра бара. Кама Аланындагы АЭС төзелеше мораторий белән туктатылгач, бөтен өмет елга электр станцияләренең куәтен арттыруга кайтып калды. Куйбышев исемендәге сусаклагычның биеклеген 160нчы билгегә күтәрсәк, проблема берхәлгә җиңеләячәк икән үзе... Ләкин чал Идел белән алкын Чулман, бүгенге ярларыннан чыгып, тагын икмәк кырларына җәеләчәк! Икмәк кырлары авылда ла... Ә менә «күтәрергә!» дигән фәрман мәркәзләрдә языла. Чулман–Идел–Казансу–Мишә–Зөя ярларыннан күтәрелсә, су читенә терәлеп салынган меңәрләгән шәхси корылмалар ясалма диңгез төбендә калачак. Ә бит ул ялханәләр «күтәрергә!» дип фәрман чыгаручылар өммәтенең мөлкәте. Кем инде үзен-үзе батырырга әмер бирсен?!**

**Кәнәфидә кырын ятып кына баскыч төбеңнән балык тоту; җилкапканы ачып, кәеф-сафалы дуслар төялгән катерларны каршы алу; йөзә торган мунчаларның ләүкәсендә тибрәнеп ятулар... Болар хакына бөтен шелтәләргә дә түзәргә була.**

**Экология министрлары тырышлыгы белән әзерләнгән катгый законда шәхси һәм сәнәгать корылмалары яр читенә 50 метрга якын килмәскә тиеш диелгән. Тиешен тиеш тә, ләкин бу закон кабул ителгәнгә дистә еллар үтте... Ә берәүнең дә әле сүтәргә тотынганы юк!**

**Бер яһүд агай: дошманның су асты көймәсен өскә чыгарыр өчен диңгезне кайнатырга кирәк, дигән. Диңгезне ничек кайнатыйк соң дип аптыратучыларга ул: мин сезгә шәп идея бирдем, ә аны ничек тормышка ашыру сезнең эш, дигән...**

**Яр буйларын законсыз төзелештән азат итәр өчен нишләргәме? Су саклагыч биеклеген, киресенчә, 160ка төшерергә кирәк. Ул чагында су чите ярдан үзе чигенәчәк. Һәм анда, яңадан, узган гасырдагыча, бала-чагалар су коенып, терлекләр сугарылып, агайлар балык тотып рәхәт чигәчәк. Кыскасы: «Күтәрергә ярамый төшерергә!..»**

**Мин идея әйттем, ә өтерен кая куясын үзегез уйлагыз.**

**Камил КӘРИМОВ**

.

Мотоциклны бер тибүдә кабызабыз, кузгала башлагач, мин Фәниягә ачу белән:

– Сабан туена егетеңне алып кайт, мин дә ялгыз булмам! – дип кычкырдым.

Рубисның мәктәп елларындагы мәхәббәтен «яңартырга» Нурия янына, Чалтаймас авылына төшеп киттек. (Аның булачак балдызы Зимфирә чалбар балагының шакмаклы сурәтләрен җеген җеккә туры китереп, ертыгын шундый оста итеп тегеп бирде, җөй эзләрен берәү дә искәрерлек түгел иде. Мин ул чалбарны тагын ике-өч ел кадерләп кидем әле).

* * *

Клубка чыкканда мин, Фәнияләр өе яныннан узмас өчен, аскы урамнан гына менәм. Бәлки ул үзе күренмәс тә иде, имтиханнарга әзерләнәдер, Мәскәүнең үзенә барып укырга кермәкче бит.

Клубта танцы бара. Музыка ритмына уралып, кызлар-егетләр иркен мәйданчыкка укмашканнар. Бер читтә, киеме, гәүдә тотышы белән горур балкып, Гөлсирин утыра. Туп-туры аңа таба киттем. Мондый  кызны биюгә чакырмыйча ничек түзәсең. Аның чыкмыйм, дип кире кагу мөмкинлеген онытып җибәргәнмен лә... Юк, карышмады, урыныннан торып, озын бармаклы кулын минем учыма тапшырды. Магнитофоннан яңгыраган чит ил музыкасы безне төркем эченә суырып алды. Аның гәүдә-кул хәрәкәтләрендә нindidер нәзакәтлелек бар. Чәчен, «су анасы» модасына ияреп, җилбәгәй туздырмаган, калын үрелгән толымын, баш түбәсе әйләнәли, шундый пөхтә урап куйган, ник бер  тыңлаусыз чәч бөртеге үзен искәртеп торсын.

Гөлсирин миннән бераз кыенсынган да шикелле. Әйтүләренә караганда, мин аны кырыс-усал диебрәк күзаллаган идем. Ә ул әнә, озын керфекләреннән күз алмасына күләгә төшереп кенә сөйләшә.

– Кай арада үсеп җиткәнсең, мин күрми дә калганмын, – дигән булам.

– Сез...

Мин аны бүлдерәм:

– Нинди «сез», мин берүзем генә ич! Авылдашлар булып, гади генә сөйләшик әле.

– Алай әллә ничек...

– «Сез» диюең, якын итә алмам, дигән мәгънәне белдермидер бит?

Гөлсирин, кызарып, ирен чите белән генә елмаеп куйды. Бу елмаю тыйнаклыгында киләчәктә ачыласы нindidер сер канат кагынадыр сыман.

– Мин сезне яхшы хәтерлим...

– Тагын – «сез»...

– Юк, бу юлы «икегезне» димәкче идем. Көпә-көндез, урам уртасыннан барасыз икәү... Фәния апа белән. Син... велосипедта, ул – җәяү. Синең бер кулың рульдә, икенче кулыңны Фәния апаның иңенә куйгансың. Матур итеп, киләсез шулай янәшә...

– Ә син, яланаяклы кызый, койма ярыгыннан күзәтеп тордыңмы?

– Юк, капка төбендә, эскәмиядә утыра идем.

– Шул чакта, үтешли, сиңа борылып карадыммы?

– Юк инде, күрмисең дә...

– Их, белгән булсам соң...

Мин шунда бакчабызга кердем дә, яшеренеп кенә еладым. Нигә мин дә шулай йөри алмыйм, нигә мин һаман бәләкәй микән, дип еладым...

Гөлсириннәрнең өе клубтан әллә ни ерак түгел, сөйләшә-сөйләшә кайтып

киләбез, капкалары турысына җитүгә, бер секундка да тоткарланмыйча, саубуллашам да, үзебезнең тарафка, түбән очка кайтып китәм. Капка төбендә әз генә басып торсам да, бу инде озатып куюга саналачак. Ә болай... кайту юлы бер якка булганга гына...

Тагын күрешкәч, сүзгә-сүз үрелеше шулкадәр табигый ялгана, ул бит үзе дә белмичә минем яралы йөрәкне дәвалый, үзе дә сизмичә, күңел тыны белән мине юата бугай...

Мин дә, үзем дә сизмичә, аңа  ияләшеп барам түгелме?! Әмма, ияләшү сызыгын атлап чыгарга куркам. Юк, аның үз-үзен вәкарьле биеклектә тота белүеннән сагаю гына түгел бу... Куркуның асылында – хисләрне вакытында йөгәнли, нәфесне тыя белү гаделлеге ята. Уятырмын да мин бу кызыйны... аннары ул үкенеч ярында торып калырмы? Чөнки мине барыбер Фәния кыйбласы үзенә тартачак.

Солдат тормышы белән хушлашып, берәмләп-берәмләп кенә яшьтәшләр кайта башлады. Иң беренче Әхсән кайтып төште. Клубка чыккан көнне үк аның күз карашын яктыдан гына киенгән Гөлсирин өтеп алды.

– Ах, чибәр, каһәр! Кай арада җитлеккән бу?! Әтисе председатель иде бит без үсмер чакта. Нигә шул председатель кызларына гына чибәрлекне өеп бирә микән, Ходай, ә?! Бу – минеке, баста!

Күңелем төбендә нindидер бер уй бөресе чатнап китсә дә, мин бер сүз әйтмәдем.

Икенче көнне Әхсәннең йөзе кара коелган иде.

– Кит аннан! Әллә нәрсә бит ул. Кыргый кәҗә! – дип Гөлсиренгә үз бәясен бирде.

Хезмәт срогын бетереп, бездән шактый алда кайтасы Ирек тә, өйрәтелгән эте армиядә үлеп китүе сәбәпле, бездән соңрак кайтып төште әнә. Теге чактагы гайбәте өчен мин аңа бернинди дә үпкә белдермәдем, булган мәкер-низагларны еллар юып алып киткән инде. Әмма нишлисең, шикчел кешегә шик ябышырга гына тора бит ул. Тагын аңа үпкәләргә сәбәп табылды. Ерак җирләрдән кайтып, клубка беренче кат кергән көнне яшел погонлы Ирекнең сусаган карашы Гөлсириндә тукталды.

– Егет кисәге юкмы? Булса да чәйнәп ыргытам! Мондый чибәрлек өчен өзешергә дә була!

– Егете юк аның, – дигәч, Ирек аптырап калды. «Андый-мондый җитешсезлеге беленмидер бит?» – диде. Мин көлеп куйгач, ышанычын йодрыгына кысып:

– Мин аны озата барам! – диде.

Икенче көнне ул кызмача иде. Йөзендә тимгелләнеп, эчке ачуы утрау-утрау булып бәреп чыккан. Мине ул клубның аулаграк урынына алып китеп:

– Миннән көләргә уйладыңмы?! Нәрсә, кулга тотарлык кызлар сиңа гына дигәнмени! – дип, мине тупас кырлы сүзләр белән  керендерә генә. Берни аңламыйча аптырап карап торам. Төшендереп бирде үзе: кичә ул Гөлсиринне озата барган да, шул ук «капкага бәрелеп», кайтып китәргә мәҗбүр булган икән.

– Минем якын иткән егетем бар, – дигән Гөлсирин. Ирек төпченә башлаган.

– Клубта бергә утырдыгыз бит, әйтмәдемени? – дигән Гөлсирин.

Минем күңел рәхәт кытыкланып куйды. Шундый кыргый боланны, күзгә күренмәс җепләр белән бик сак кына үземә якынайта барганмын икән бит. Эчке ау дәртен нәүмиз калдырып, ул җепне өзәргә дә кызганыч, әмма, өзмичә дә булмый иде шул...

## Ярат мине

Иртәгә Сабан туе дигән көнне Азнакайның үзәк урамыннан барганда чаттан каршыма килеп чыкты ул – инде онытыла башлаган «А», «Б», «В» кызларының иң чибәре – Регина үзе!.. Аның тулышып өлгергән чибәрлеге сулышыма капты. Сүз әйтә алмыйча басып торам. Ул, кичә генә аерылышкан кебек, үз итеп, якын итеп елмая. Шомырт кара күзләрендә мут очкыннар биешә.

– Кичә төшкә кергән идең, бүген очрашырга булган икән, – ди.

– Мондый ук чибәр булу – гөнаһ түгелме, дигән Пушкин хәзрәтләре.

– Гөнаһларны үткен үкчә белән таптап барабыз.

– Үзгәргәнсең син.

– Кайсы якка?

– Тагын да чибәрләнү ягына.

– Казанда, медицина училищесында укыдым бит мин.

Юк-барны сөйләшеп барабыз. Биек үкчәләр – чыкы-чыкы, тротуар ташларын сискәндереп бара. Читтәнрәк күз төшереп алам. Нинди чибәрлек! Биек үкчәләр төз аякларны җиргә тигерер-тигермәс кенә алып бара кебек. Аяк очларының алга омтылышында нинди бәйсезлек! Үзе бераз мактанчык, үзе бераз һавалы, шушы кире саналган сыйфатлар үзенә нинди килешеп тора бит, каһәр!

– Иртәгә Балтачка, Сабан туена кайтабызмы? – дим.

– Чынлап чакырасыңмы? – дип, ул кабынып китә. – Минем анда туганнан туган апам яши бит. Кайтабыз.

– Кайтабыз! – дип, кул бирешәбез.

Сабан туе көнендә кояш та икенчерәк яктырта, сандугачлар да армыйча сайрап, төнне көнгә ялгый.

Мәйданга парлашып чыктык. Безне беркем искәрмәс, битараф халык арасында тыныч кына йөрербез дип уйлавым бик беркатлылык булган. Балтач балталы шул ул...

Регинаны култыклап барган җирдән, Фәниянеерактан күреп, утка пешкән кебек кулымны тартып алдым. Гаҗәп, нишләп соң әле ул иптәш кызы белән генә, ягъни, ялгызы гына. Нишләп соң ул йөргән егетен чакырмаган? Бәлки мондадыр, якында гынадыр?

Күпмедер вакыт үткәч, тагын күрәм: Фәния энисе кырыенда... үзе генә. Миңа Регина белән култыклашып, күләгәләребезне бер итеп йөрү оят бит болай... Фәния дә, мин дә аерым-аерым парлы булып мәйданга чыгарбыз дип уйлаган идем ләбаса...

Авылдашлар килеп күрешәләр, җилкәдән кагалар, әмма бөтенесе дә эчкерсез, үтә күренмәле түгел.

Әнә, «Алтынчы Шакир» – Миргазиян абзый килеп күрешә. Янәшәмдәге Регинага күзен кысыбрак, сынап, җентекләп карап тора да, мине читкәрәк алып китеп:

– Авылның иң бай Солтан абзый кызын эләктерде бу ярлы малай дип йөри идем. Ычкындырдыңмы, ачык авыз! – дип иренен бөреп, мыскыллы көлеп куйды.

Кайчандыр тешенә пуля тигән бөкре Миргазиян абзый килеп күрешә, Регинаның да нәфис кулын бирчәйгән кабырчык кебек учына алып, бер мәлгә аңа яшьлек кәүсәрен эчкәндәй, йотлыгып карап тора. Шуннан мине читкәрәк тартып:

– Бик чибәргә өйләнсәң, гомерең тыныч булмас. Сиксән адәм килеп яратам дисә, сиксән беренчегә каршы тора алмый алар... – дип, тәмәкесен кабызып китеп барды.

– Малаҗис, – дип аркадан кага, асты урам Фәүзәт. – Менә мин иллегә кадәр өйләнә алмадым. Мондый кызны ятларга бирә күрмә!

Икебез белән дә килеп күрешкәч, үткен телле Шәмсиямалттәй Регинаның кулыннан тотып:

– Беләбез, үскәнем, Митрәйдә персидәтель кызы икәнеңне дә беләбез. Казанда укып бетереп кайтасы егетеңне көткәнеңне дә беләбез. Бу егетнең дә, – дип ул мине Регинага таба тартыбрак китерә, – бу егетнең дә сөйгәне бар, нигә аларның арасына керәсең?!

Регина аның кулыннан чак ычкынып читкәрәк китә. Бераздан тыны-көне бетеп яныма килә: ике яшь егет килеп, беләген кара яндырып, кысып тотып:

– Үлемеңне эзләп кайттыңмы Балтачка?! Җыештырып куярбыз, апа! – дигәннәр икән. Күрсәт, кая ул егетләр дигәч, мин аларны танып кала алмадым, ди.

Ул арада順 янибызга тракторчы Хәлим абзый белән хатыны Фатыйма апа килеп баса. Хәлим абзыйның басынкы карашы куркулык йөгертелгән кебек, күз кабак-керфекләре туктаусыз лепердәп, ачылып-ябылып тора. Көнчеллеге белән дан тоткан Фатыйма ападан гомере буе гаҗиз ул. Ә Фатыйма апа, ныграк көнләшкән саен чибәрләнә генә бара. Менә ул мине читкәрәк тартты да, мәйданның каршы ягында торган Фәния тарафына ымлап:

– Минем кызлар аның кебек купшы киенә алмады. Шулай да тупырдап үстеләр. Икесен кияүгә бирдем инде. Хәзинәдә тагын да чибәррәге калды... – дип ул уң кашын яшен аткан тизлектә сикертеп куйды.

Ул арада Регинага килеп кемдер тагын янап киткән: «Син, кызый, безнең егетләрнең башын әйләндереп йөрмә! – дигән.

Гыймай Заһиты килеп миңа да хәмер исе бөркеп китте:

– Апаем, муеныңа кара бантик таккач та... эшләпә кидем дигәч тә... Кем булдың ул чаклы?!

«Шәп!» дип аркадан кагулар, яисә бармак янап, сүгеп китүләрнең бетәсе юк иде, ярый әле Рубислар килеп, аулакка, каен төбенә әзерләнгән табынга чакырып киттеләр.

Мәйданнан чыгышлый Фәния ягына борылдым да, карашлар очрашып кисеште шикелле. Күзләрендә аның бу юлы рәнҗү белдергән «Их син!» дигән әрнү сулкылдый иде сыман. Мин, шулкадәр үкенеп, бу көнне кабаттан, икенче төрле итеп башларга иде, дигән өметсез уемнан изелеп мәйданнан чыгып киттем.

Регина ниләр уйлый, аның күңелендә бәйрәм шаукымы – ат чабышлары, көрәшкә чыгып бил алышулар, кашык кабып йөгерүләр – бу шаулы тамаша аерым кешеләрнең аткан ук кебек сүзләре аша кайтаваз-шәүлә булып кына күңеленә кергәндер.

Каеннар арасында мәйдан шавы, үткенлеген җуеп, юашланып калды. Түгәрәк табынга утыргач та Регина әле һаман тынычлана алмый, туктаусыз кагына, гүя плащына кешеләрнең сүзләре сырганак кебек ябышып калган...

Икәү генә каен арасында истирәхәт кылып йөргәндә Регина миңа болай диде:

– Фәния янына барырга дип талпынып карадым да, туктап калдым. Курыктым.

– Аңа нәрсә әйтмәкче идең?

– Әйдә безнең белән, дип. Мин бит барыбер сине аңа калдырып китәм.

– Мин әйбермени, алып, яисә калдырып китәргә?

– Мин бер айдан кияүгә чыгам. Теге апа белеп әйтте, Казаннан егете кайтуын көтә, дип...

– Бер айдан дисең инде...

– Аны бердәнбер син булдырмый кала аласың. Мин көтәм. Бер ай...

Регина, түшемә башын куеп, кочаклап алды:

– Күпме егет артымнан йөрде, җанын ярып бирергә әзер булып. Бер син – битараф. Шуның белән син мине котыртасың да... Ярат мине!..

«Ярат мине, ярат мине!» – дип кабатлады сипкелле каеннар...

***

Сабан туйлар узганнан соң, июль башы кереп килгәндә, Фәнияне Азнакай-Бөгелмә автобусында күреп алдым. Янәшәсенә барып утырдым. Балтачка кадәр берни сөйләшмичә кайттык. Бергә төштек.

Тау өстеннән авыл күренгәч кенә Фәния тукталып, телгә килде:

– Безгә бергә күренергә ярамый, кешеләрдән оят, – диде.

Икенче көнне дә шулай кабатланды.

Өченче көнне мин аның кулыннан тотып, межа ягына, кайчандыр Туйкә мәктәбенә йөри торган юлны каймалаган тугайлыкка таба алып киттем. Кояш сүрәнәеп, Суыр тавы артына төшеп бара, офыкка якынайган саен ашыга, иртән чыгар өчен җирнең каршы ягына барып җитә алмам дип курка ахрысы. Еракта зәңгәр тау кәрваннары дулкын-дулкын булып офык читеннән агып бара. Дөнья матур, дөнья киң. Күңелгә сыгылып иңгән моңсулыкны җиңеп, бөтен каршылыклар ятьмәсен, кылыч белән бер селтәнүдә чабып өзгән кебек, кычкырасы килә. Шул мәлдә «дерт» итеп китәм...

– Бер селтәнүдә...

Фәния әйтәме моны, минем күңел кычкыруын ишетә, тоямы ул әллә?.. Димәк, безне тән, акыл-зиһеннән башка тагын ниндидер өстен бер көч бәйли, димәк безнең йөрәкләр аерым бер дулкында үзара аңлаша: илаһи тартылу көче...

– Нигә без болай булдык соң әле?

– Ни үле, ни тере хәлдә калдым мин Сабан туе көнне. Көтмәгән идем, бөтен халык каршына икенче берәүне алып кайтырсың дип башыма да килмәгән иде.

– Син дә егетең белән чыгасың дип уйладым мин...

– Минем сиңа беркайчан да хыянәт иткәнем булмады.

– Кайтып төшкән көннән бирле мин үз каршымда салкын стена күрәм.

– Бәлки... миндә дә гаеп бардыр... Әмма минем беркайчан да сиңа хыянәт иткәнем булмады. Беркайчан да... Әнә, яңа Ай урагы шаһит.

Кай арада җәйнең юаш төн караңгылыгы иңгән. Күк гөмбәзендә урак Ай, махсус җибәрелгән шаһит кебек, кыйгач карашын безгә төбәгән. Ул тыңлый, ул күрә, ул хөкем чыгара... Бергә калыргамы безгә, гомерлеккә аерылышыргамы?

– Син беркайчан да, бер очракта да үзеңне гаепле саный белмисең. Аллаһ сакласын, кеше үтерсәң дә син шул үтерүнең кешелеккә бик зур яхшылык булачагын исбат итә аласың, шулай бит!

«Шулай бит!» – дип ул тәүге тапкыр миңа күзләрен тутырып карады.

– Мәйданда ялгызыңны гына күргәч, үкендем әлбәттә. Егетең бар, дип, үч итеп кенә бит мин...

– Минем беркемем дә юк. Тик шуны онытма: җиткән кызлы йортның капкасыннан иярле ат өзелмәс диләр. Сүз катканны борып җибәрә белү – һәр кызга бирелмәгән...

Учарланып ялгыз каен үскән тугайлыкта утырабыз. Еракта-еракта утлар җемелди. Яшь бодай кырыннан сирпелеп кенә киткән җил йомшак кына сыйпап уза.

– Армиядә чакта әйтми торыйм әле, дидем. Кайткач, аңлашырбыз, дидем. Үземне синнән коткарасым килгән иде. Сизәм, синең белән авыр булачак миңа.

– Миңа синсез җиңел булачакмы?

– Белмим, нишләп бетәрбез без?..

– Яхшыга гына юра син.

Өшегән кебек калтырап, күкрәгемә сыена. Юеш бите яңагымны пешерә. Икебезнең дә керфекләр авыраеп бер-берсен юата.

– Белә-белә утка керер идеммени, әгәр яратмасам. Яратуым да үкенечкә генә калыр дип куркам...

– Мин чит кызларга карап сокланам, хисләнәм, сөйләшәм, аларны якын итәм икән, бу бит әле ярату, гашыйк булу түгел. Тәмле сулы чишмәнең ләйсән тамчыларын учыма алып татып карау гына... Сиңа булган мәхәббәтнең мәгънәсен ачыграк тояр өчен.

– Сине беркем белән дә бүлешәсем килми. Минем генә яратуым азмыни соң? Нишлим, ничек исбатлыйм, ә?!

– Мәхәббәт богавы уйлап табыйк.

– Их, син!

– Күр әнә, Айны икегә бүләләр. Безне күздә тотып.

Фәния ышанмыйча күккә төбәлә дә, гаҗәпкә кала. Болытлы төн дә түгел, югыйсә. Әллә каян пәйда булган нәзек кенә болыт сузымы урак Айның кап уртасыннан сызылып бара. Гүя кемдер Айны тупас карандаш белән сызып икегә бүлә. Бераздан сызык бетте. Чалкан яткан Ай – күкнең бердәнбер кысык күзе чистарып калды.

– Күрдеңме... Ходай тарафыннан «Бүленмәгез!» дигән киная булды бу.

– Ни генә булмасын, яраттым, яратам, яратачакмын! – дип, Фәния күз яшьләре аша үбә башлады.

Бераздан күрәм: учарланган каен ботаклары арасында Ай кысылып калган, ятьмәгә эләккән алтын балык кебек. Айның бу әсирлектән котыласы килмидер шикелле.

***

Володя Комаровтан хат килде. Ул 1 июньдә кайтып китү бәхетенә ирешкән. Минем урында оператив бүлектә калган малайны эштән куганнар. Сине сагыналар анда, дип шаярткан Володя.

Кайчандыр безне борчуга салган яраткан кызы Евгения хакында Володя болай дип яза:

*...Ждала она меня не так,как нужно, не так, как сама обещала. И вот теперь сам не знаю, что делать. Она чуть ли не на коленях уверяет,что любит меня, что она просто сглупила, что жить без меня не может и т.д. Да и я сам, чего греха таить, люблю ее, по-прежнему и готов ей уже все простить, хотя все в один голос говорят мне, чтобы я сней расстался...*

Хат язышыйк. Мин тиздән Горький шәһәренә яшәргә күчәрмен, ахрысы.

Шунда techинститутка керергә исәп. (Без Володя Комаров белән ярты елдан соң Казанда очраштык). Миннән соң әлегә кайтучылар булмас, ахрысы, – дигән Володя Комаров. Күрәсең, ул инде өлкән дәрәҗәдәге офицерлар арасында кайнаган кеше буларак, алда көтелгән хәтәр вакыйгалар буласын ишетеп белгәндер, мин дә бит нидер сизенгән идем. Ашыгуым да юкка түгел, бер-бер сәбәп чыгар да, тоткарлар дип бик курыккан идем.

*1968 елның 20 августында Чехословакия башкаласына совет гаскәрләре керде. Бу көтелмәгән чара, әлбәттә, безнең еракка оча торган авиациягә бик үк кагылмагандыр да... ләкин барыбер, андый ЧП вакытында хәвефле шаукым бөтен армиягә таралып, хәрбиләрне уяулык сагында тота. Күп солдатларның кайтырга җыенып та ел азагына кадәр тоткарлануы аңлашыла.*

Туган якта күңел утыргач, егетләр белән дә сөйләшеп-киңәшкәч, Суриков исемендәге институтка документларымны җибәрмәскә булдым. Бәләкәйдән сәнгать башлангыч мәктәбе үтмәгәнлектән, анда барып, оятка гына калырмын, үзешчәнлектән чыгып, биеккә сикерә алмам, дип уйладым.

Азнакай посёлогында тагын бер матур бина арткан: мин эшләп киткән СМУ конторасына яңа апартамент өлгерткәннәр. Ике катлы, бакчасы, ихатасы бар. Миңа эшләр өчен иркен клубы, эш бүлмәсе дә каралган.

Мин бу бинага икеләнмичә кердем, мине икеләнмичә элеккеге эшемә алдылар. Иртәгәдән – эшкә. Озакка суза алмыйм. Чөнки минем кесәдә – тынлык, тиен акчалар гына кулга кыенсынып кына тиеп китә.

Ә бүген...

Редакциягә барып, анда эшләүче Ирек Бәдретдинов белән таныштым. Мәктәбебез стенасында шушы Бәдретдинов фамилиясе, матур рам эчендә, өч ел буе эленеп торды бит инде. Укуны алтын медальгә бетергән, имеш...

Танышабыз. Бәлки ул чынлап та медальгә лаектыр. Укуын бетергәч, ул елларда бөтен яшьләр ыргылган КАИга (Казан авиация институты) укырга кергән. Ошатмыйча, ташлап, армиягә китеп барган. Хәзер менә – университетта читтән торып укуын дәвам иттерә икән.

Шыр татар авылында үсеп, чын татар мәктәбен бетереп, русчаны да су урынына эчә. Ике телдән дә, бер-берсенә авыштырып, тәрҗемә итә белә. Бәлки ул чынлап та алтын медальгә лаектыр...

– Азнакайда иң көчле шагыйрь кем?

– Үсепес дип торапыс, – ди Ирек, чуваш акценты белән.

– Бер ел вакыт бир, барыгызны да сытам! – дим.

Ирек рәхәтләнеп көлә:

– Син бит әле шигырьдә күзе ачылмаган көчек шикелле генә, – ди.

Редакциядә көтмәгәндә-уйламаганда Туйкин аганы очратам. Бер дә үзгәрмәгән шикелле. Һаман шулай җитез, хәрәкәтчән.

– Сезнең математик булмасыгыз билгеле иде инде. Укырга керергә исәп бармы? – диде. Китәргә дип кузгалгач, борылып килде дә:

– Бүген сәгать алтыга миңа килеп чыкмассызмы, адресны хәтерлисезме? – диде.

Мин, шатланып, риза булдым.

Кичкырын Азнакайның авыл ягына төштем. Салиха әбигә кереп, хәлен белеп, чәй эчеп чыкканнан соң, Туйкин ага өенә киттем.

Шул ук капка, шул ук коймалар. Чәчәкле аллеядан кереп, ишек кыңгыравына бастым. Ничектер, сизенеп, кинәт борылып карасам, артымда елмаеп басып

тора, йомшак чүәктән, аяк тавышын сизмәгәнмен дә. Кулында әнүч-укроп, яшел суган, сельдерей кебек тәм-томлы үләннәр учмасы.

Өстәлне икебез генә түгәрәкләп, шактый сөйләшеп утырдык. Туйкин ага, кыенсынып кына, хәтта, миннән рөхсәт сорагандай, «ярар микән» дип кенә хәмер шешәсе чыгарып утыртты. Ак аракы – минем дошманым, дип әйтә алмадым, әлбәттә. Чәкештергән рюмканың читен генә «тешләштереп» утырган булдым.

– Шигырьләрең күземә чалынган иде, – диде Туйкин ага.

Гуру, махатма кебек укытучым каршында ниндидер өйрәнчек тәҗрибәләр турында «яздым» дип батыраеп сөйләшү уңайсыз иде миңа. Туйкин ага, гадәтенчә, каты сакал төге сыкыланып, сизелеп торган битен учы белән сыпырып куйды:

– Сүзләрне әйтәм... Кәгазь битенә вак кына булып, тезелеп языла бит инде, ә уйласаң, һәр сүз кырмыска кебек үзеннән зурракны, олы мәгънәне күтәрә ала. Моңа, әлбәттә, чын талантлар гына ирешә. Иҗатта үзеңне табу дигән борынгыдан килгән хикмәт бар. Кызык бит... Энә белән кое казып кына, аның койрыгыннан эләктерә аласың. Икенең берсе – йә табасың, йә – юк! Бусы инде Ходайның ым кагуыннан тора...

Хушлашыр алдыннан, Туйкин ага борынгы сандыгыннан ниндидер төргәк чыгарды.

– Менә мин сиңа ике китап биреп торам. Беркемгә күрсәтәсе булма! Бу минем абыйлардан калган мирас... Утыз җиденче елда, безнең китапларны йөге-йөге белән төяп алып киткәннәр. Анда нинди генә кыйммәтле фолиантлар булмаган... Ә болар... – дип ул киндердән тышланган, кыр-кырлары сүсәреп беткән китапларны кадерләп, сыпырып торды, эчен ачып сак кына актаргалады...

Төп нөсхә түгел, төшереп алынган, тышланган, тегелгән китаплар иде болар. Берсе – Михаил Худяковның Казан ханлыгы тарихы, икенчесе – Хара Даванның «Чыңгыз-хан – бөек полководец» дигән кебегрәк исемдәге китабы...

Туйкин ага боларны ак чүпрәккә, аннары газетага төреп, сеткага салып, кулыма тоттырды.

– Фәлән вакытка кайтарып бир, дип әйтмим. Ашыкмыйча гына сөреп чык. Боларны сынар өчен бирәм: көчең җитмәсә сынасың, көчең җитсә – үзең сындырасың...

Укытучым мине шундый фикерләр ешкынлыгында адаштырып, саулык теләп калды. Мин киләчәк язмышымда акыл-зиһен казанына салырга бәһасез нигъмәтләр бирелгән төенчекне тотып баруымны белмичә дә кайтып киттем.

Нигә бирде микән боларны миңа Туйкин ага, дип аптырыйм. Китапларны ачып-ачып карыйм да... Эченә кереп китә алмыйм... катмарлы, кадими борынгылык... Менә ул – уенчак уй белән бу тормышның өстәге күбеген генә җыярга өйрәтелгән замана баласы кара урман авызында эчкә үтәргә куркып басып тора. Талпынып карый да, тагын чигенә. Кыйбла кайсы тарафта – ул аны белми, чамалый гына...

Искәрмәсәң, искәрми дә торган бер хәл булды. Эре малның кимерелгәннән калган бот сөяген күрше эте Тузикка ташлаган идем. Шушы кадәр мул сөяк күргәч, ул сулышына кабып, тирәсендә әйләнгәләде дә... бераздан күрәм – нәзегрәк урынын табып, авызын каерып ачып капкан, тәмле җелек исеннән күзләре иләсләнеп кысылган, койрыгын дәртләндереп тыкрыкка, аулак урынга атлап китүләрен күрсәң...

Үтеп киткәндә искәрәм, көне буе Тузикның гәүдәсе һаман бер урында, әрекмән арасында кайнаша – каты сөякне җиңәргә дип черәшә бу! Ай-һай, тешең чыдармы, дип карап үтәм.

Икенче көнне шул урынга барып карыйм, шаккаткыч хәл, олы түтәрәм сөяктән баш бармак кадәрле генә иң каты төш-үзәге торып калган. Аннан соң Тузик, җиңүче сыйфатында, ике көн буе бәхетле елмаеп, шатлыгын белдереп, теш арасында ваклап кына өреп куйган сыман, койрыгын байрак итеп чөеп йөрде.

Менә мин дә шул Тузик хәлендә бит. Миңа теш үтмәслек каты, җелеге тыгыз китап бирделәр. Җиңә алмыйм икән, укытучымны әйтмим дә инде... Тузиктан оят!

Эштә мине Бөгелмә төзелеш институтына имтихансыз гына керү исемлегенә яздылар. Автобус белән кичләрен барып-кайтып укыячакбыз икән. Мин моңа башта бик сөендем. Бәләкәйдән үк «инженер» дигән сүз күрсәм йә ишетсәм, күңел кытыкланып ала иде. Сизәм бит, яңа йортларга карагач, эчемнән генә, их, болайрак бизәкләргә, их, икенчерәк төскә буярга иде дип гел үземчә үзгәртергә хыялланып йөри идем. Менә бит, болай булгач, төзүче-инженер дипломы йөгереп кулга керәчәк.

Матди байлык өстендә утырып, әйберләрне әвеш-тәвеш китерерлек маһирлыгым белән, теге... логика дигән бөдрә йонлы тәкәне чыгарып җибәреп, шахматтагы сыман дистәгә якын йөрешне алдан күреп, әллә нинди эшләр майтарып, баеп бетәргә юл ачыла түгелме миңа?!

– Сиңа университетта уку кирәк. Телне, тарихны, әдәбиятны өйрәнү өчен, – ди Ирек Бәдретдинов.

– Анда язучылыкка өйрәтәләрме?

– Юк, беркайда, беркем дә язарга өйрәтә алмый, юнәлеш кенә бирә ала, – ди Ирек.

Мин әле генә инженер булам, дип хозурланган идем, хәзер инде «язу чире» башын калкыта. Кайсын сайларга?

Авылга кайтсам, өйдә кунак бар икән. Ак түти. Аны күрмәгәнемә ун еллар бардыр. Аңа вакыт канаты гел дә кагылмаган кебек. Киресенчә, бермә-бер, аклы-каралы куе чәче аңа шундый килешә, ниндидер Шәрекъ илләреннән килгән акыл иясе рәвешен биреп тора. Ул, әкрен-салмак тавыш белән минем хәлләрне сорашты да, текәлеп, сүзсез генә карап торды. Кап-кара күз тирәнлегенә суырылып кереп барам кебек; тәнем кайнарланып, рәхәт-шомлы дулкын бөтен күзәнәкләремне сыйпап алды сыман.

– Сөбханалла, иншалла, – дип, ул иреннәрен селкетеп, эчтән ниндидер дога укып алды. Аннары миңа якынрак килеп утырырга ым какты да, учымны учына алды.

– Менә ике кулың... Ике кулың кебек үк ике юл чатында торасың икән лә... Берсе – уңга, икенчесе – сулга тарта. Әгәр, икесеннән дә берьюлы китү кодрәте бирелсә, иншалла, ике якта да үзеңне күрсәтә алыр идең. Ә тәкъдир «булдыра аласың», дип ләббәйкә итми, барыбер, сындырып сыный, шулай бит, улым?!

Мин синең киләчәк гомереңне икегә ярып күрәм... Әгәр син сул тарафка юнәлеш тотсаң... сары яфрак кебек акча түшәлгән юлга чыгасың. Акча көшеле сине калын диварлы казна йортына китерә. Гомерең соңына җирдән аерылып, күккә тимер челтәр аша карарга каласың... аңлата алдыммы, улым?!

Ә инде уң якка каерсаң, юлыңа ак кәгазь түшәлгән булыр. Кәгазьне син

намазлык урынына күрерсең. Бу тарафта гадел яшәвеңә бүләк – меңнәрчә куллар күрәм, учны-учка чәбәкләгән куллар урманы. Амин.

Ак түти мендәргә кырынаеп, күзләрен йомып, хәтсез утырды. Аннары, күзен ачты да, бөтен нәрсәне яңадан күргәндәй, серле бер караш ташлап, чәй сорап әнигә дәште:

– Кара булсын, Икълимә, чәеңне җәлләмә, – диде.

***

Туйкин ага биргән китапларны «тешләп» карыйм да, теш үтмичә, кәефем китеп, кире куям. Шактый вакыт шулай азапландым.

Һәм бер көнне, үз-үземне аяусыз камчыларга тотындым: «Син нәрсә, шулкадәр үк надан, тинтәкмени?! Андагы фикерләр, баш җитмәслек итеп, әллә каян, күктән алып язылмаган бит. Тарихи әсәрне аңларлык та акылзиһенең юкмыни?! Ә үзең сүз белән эш итәргә җыенган буласың. Димәк, синең нинди катлаулы язылган фикер каршында да акылың бүәлеп калырга тиеш түгел! Эшләт башыңны, уят акылыңны, җик рухыңны – син моны җиңеп чыга аласың!

Шулай итеп, мин-минлегемне төйгечли-төйгечли, укып чыктым бит әлеге китапларны. Күп нәрсәне аңлап бетермәсәм дә... шаккаттым. Киләчәктә, боларны җеген-җеккә аңлап бетерү өчен тагын шушы темага караган башка китапларны да укырга кирәклеген чамалаган хәлдә, рухи буем бер башка үсеп китте сыман...

Хәзер мин кешеләргә: «Син, үзеңнең кайчандыр дәүләтле халык улы булганыңны беләсеңме соң, нәданым, дип өстәнрәк карый алам. «Эй, ты – потомок Чингиз-хана!» дип кычкырганда, чүгеп калмыйча, башыңны горур тотып, «ә сезнең халыкта бармы соң аның белән тиңләшердәй гаскәр башы?!» дип җавап бирә аласыңмы? Җавап бирә алмыйсың икән, йөрмә буталып, ризыкны тирескә әйләндерү мәхлугы булып...

***

Фәнияне миңа да Бөгелмә вокзалыннан озатырга язган икән. Мәскәүгә китә. Бауман исемендәге Финанс институтында бер ел буена әзерлек курсларында читтән торып укыган, менә хәзер шунда көндезгегә имтиханнар бирергә исәбе.

Икеләнә. Документларымны алып, Казанга гына кайтыйм микән, – ди.

Мин дә Мәскәүдән шикләнәм. Аралар ерагаю да хәвефле...

– Син ничек әйтәсең, шулай була, – дип, ул кулымны авырттырырлык итеп кыса. – Берни дә әйтмәвең әйтү инде, аңладым, – дип вагонның ишек тоткасына үрелә. Үз купесына кереп, тәрәзә янына килә. Йөрәк кысылып куя. Нәкъ теге чактагы кебек... Сигезенче класс кызының Туйкә мәктәбендә зәңгәр рамлы тәрәзәдән карап торуы сыман... Ул самими чордан соң бер гомер үткән кебек...

Түзмичә, проводницаны кагып кына атылып эчкә керим дигәндә, поезд, артына тибелгән кебек, кинәт тартыла, кузгала башлады.

Ах, бу озатулар... Мәңгегә аерылышуның гөнаһсыз чалымы бар шул азга гына саубуллашканда да...

Фәниянең Мәскәүдән язган хаты килеп төште.

– «Бу хатны мин сиңа Казан вокзалыннан яза башлыйм, кайда бетерермен, хәзергә белмим.

Егерменче июль көнне Мәскәүгә барып җитеп, поездан төшкәч, берүзем бер таксига утырып, институтка киттем. Таксистым бик начар кеше булып

чыкты (аның турында кайткач сөйләрмен әле). Кыскасы, мин аңардан көчкә котылдым, анда да әле алдап кына. Юкса, Фәнияң беткән иде инде...

Миңа комендант бер бүлмә бирде. Тышта яңгыр коя. Шулкадәр күңелсез. Утырып бер еладым. Беренче төндә сине төшемдә күрдем. Имеш, сине машина таптаган, үлгәнсең. Мин өегезгә бардым. Кешеләр җыелган. Син берүзең бер бүлмәдә караватта гел тере кеше кебек ятасың. Бераздан күзләреңне ачтың, нидер әйттең. Ни әйткәнеңне хәтерләмим, шуның белән төш өзелде. Төштә исән икәнсең дип бер сөендем, уянгач, төш кенә булган икән дип икенче сөендем.

Кабул итү комиссиясендә документларны алырга дип килгәнемне белгәч, бик ачуландылар, җибәрмәскә телиләр. Мин карышам. Үзең уйла инде, өч елга якын без синең белән аерым булдык, хәзер тагын елга бер-ике генә очрашып, биш ел аерым яшәргәме?! Казанга кайтып укырга керсәм, якын булабыз бит, көнендә кайтып килергә дә була, шулай бит! Аннары син дә укырга Казанга килерсең, дип ышанам.

Белсәң иде, бәгырь, шундый сагынам сине, үткән еллар эчендә болай ук сагынмаганмын кебек.

...Ни булса, шул булыр, ахыры хәерле булсын инде. Мин документларымны алып, Казанга юл тотам. Бу хатымны тәмамлап, шуннан җибәрермен инде...

22.07.67 ел.»

***

Күз ае җиткәч, барып, разведка ясап кайтырга дип Казанга юл тоттым. Фәния аэропортта иртәнге сәгатьләрдә каршы алды мине. Куе кызыл төстәге башлык, джерси пәлтә кигән. Бөтен торышында мин башкала студенты, дигән тыенкы горурлык та бар шикелле. Бу мине көнләштерми, укырга керәсе килү теләген котырта гына.

– Минем институтка барып килик, мин деканатка әйтеп чыгыйм да, – ди Фәния. – Аннары без көне буе – бергә! Син миңа кунакка килгәнсеңдер бит! Ә кунак – кемнең аргамагы әле? – дип ул миңа карата «ишәк» дигән мәгълүм сүзне әйтүдән тайчына.

Финанс институты тау кашында әллә каян күренеп тора икән. Киң баскычлары текә агылып менеп, дүрт колонна итәгенә тоташа. Антик сарайлар мәһабәтлеге бар бу бинада.

Фәнияне мин шул колонналар төбендә көтеп тордым. Студент халкы баскычлардан менә, төшә, керә, чыга. Нинди бәхетлеләр. Мин моңа кадәр кайларда гаип булып йөрдем соң әле, уку храмнарының ишеген какмыйча?!

Фәния чыккач, мин шундый фикер ташладым:

– Әйдә, санап төшәбез, ничә басма булыр икән?

Төшәбез янәшә, үз-үзеңә төбәлгән дикъкать – эчтән дога укыган кебек. Менә соңгы баскыч. Мин – җитмеш сигез чыкты дим, Фәния – җитмеш тугыз, ди. Яңадан астан өскә санап мендек – икебезнең дә сиксән чыкты. Димәк, дөресе шулай. Ни өчен менгән чакта дөрес чыкты? Чөнки менү – максатка омтылу. Андый чакта бөтен егәреңне туплыйсың. Төшү исә – максатыңнан кайтып бару...

Без ул көнне мин укырга керергә исәп тоткан тарих-филология факультетында да булдык. Ул университетның химкорпус дигән якты бинасына «өйдәш» булып урнашкан икән. Коридорыннан сокланып, көнләшеп,

студент халкына кызыгып, бер йөреп чыктым. Фәния бәлки үзләренеке белән чагыштырып карыйдыр.

Кесәне җылытып торырлык итеп, бер елга җитәрлек акча эшләп килергә дә яуларга бу бинаны! Бу – минем чигенүне белми торган максатым! Минем башны уку тарафына бора алуы белән Фәния канәгать...

***

Башкалада икенче көн.

Менә мин үз гомеремдә икенче мәртәбә Казан Кремленә керәм. Теге чактагыдан бер карышка бәлки үсебрәк киләмдер. Мин хәзер ханлыкның аяусыз җимерелү тарихын белергә омтылам. Кая Арча, кая Нугай капкалары; Кырым, Аталык капкасы кая? Мин боларны белмичә көн итәргә тиешме? Татар булып санда саналып яшәргә мөмкин, ә менә чын татар булып аягурә басу – җиңел биреләме бу дөньяда?!

Сөембикә манарасына рөхсәт сорап (анда ниндидер реставраторлар эшли иде), кысан тар баскычлардан күтәреләм. Биектән күп нәрсә күренә, гасырлар пәрдәсе умырылып төшә.

*Күз алдымда моннан биш гасырлар элек башкала өчен барган яу-сугыш мәхшәре. Киселә, асыла, чабыла, таптала яугирләр болыты. Диварлар җимерелә. Йөрәге ярылып атлар җан бирә. Шартлаудан кешеләр генә түгел, хәтта, иңрәп, ханчишмә суы да үрә басып үлә...*

*Шәһәр урамында – шәфәкъ алсулыгы. Кан күлләвекләре уйдык-уйдык җыелып, ахакланып яна...*

*Урамны иңләп, атлар чирүе керә.*

*Иң алда – алмачуар атта патша таҗын киясе бөек кенәз – сәргаскәр.*

*Гаскәриләрнең төмсә йөзендә – җиңү тантанасы.*

*Фанфаралар уйнатып, атлар чирүе керә.*

*Еракта Идел актарыла. Баеп барган кояш йөзенә чәчрәгән кан, утлы кургашка әверелеп, Идел күкрәгенә тама.*

*Башкалага атлар чирүе керә.*

*Тыгыз сафлар алдында – горур падишаһ – һәйкәл булып киләчәккә сикерәсе гаскәр башы.*

*Олы урам чатында – җимерелгән дивар ташына утырган бөкре карчык, бу башкаланың исән калган бердәнбер шаһиты – ак җаны...*

*Дулкын-дулкын булып килгән сафлар бөкре карчык алдында бүәлеп, туктап кала. Урам ташына сибелгән дисбе төймәләре тояк астында шыкырдап уала.*

*Падишаһ карчыкка торырга кушып ымлый. «Сынап карыйк, турая алырмы, бу илнең рухы мәңге шулай бөкре булып калачакмы?»*

*Шул мизгелдә әллә каян, таш арасыннан бит-куллары кара сөремгә баткан күмер күзле малай килеп чыга, карчыкның кулына барып тотына.*

*Моны күргәч, йөзеннән каны качкан җәллад, малайның башын кыеп төшерергә дип, кылычын күтәрә. Шул мәлдә падишаһ, яшен аттырган кебек, кылычын суырып ала да җәлладның кылычлы кулын чабып өзә:*

*– Тимә, яшәсен!*



Ибраһим
Биектаулы

# ЧЫН ДУСЛАРЫМ – СҮЗЛӘР

## Бәйрәмнәр – олуг көннәр

Хак Тәгалә кодрәт-ирке
Галәмнәргә таралган.
Вә Кешелек, вә шайтанлык
Әл-мисакътан* яралган...

Дөнья мәзәге-кызыгы –
Җирдәге ыгы-зыгы.
Биредә туды гамәлләр –
Яхшысы вә бозыгы...

Исте җилләр, акты сулар,
Яңардылар буыннар.
Кешегә Шайтан йоктырды
Яман гадәт-ырымнар...

Мәҗүсилек канат какты:
Үрчеделәр бәйрәмнәр –
Потлар тирә, чыршы тирә
Җырлар, әйлән-бәйләннәр.

Язмышларны күрәзәләп,
Йолдызларга багулар,
«Кыш-бабай»дан бәхет сорап,
Барабаннар кагулар...

Раббысыннан аерылды
Шайтан хисле кешеләр.
Шашынуга иярмәде
Чын мәхлуклар – күселәр...

* Әл-мисакъ – дөнья яралган мизгел.

Ибраһим БИЕКТАУЛЫ (1937) – *шагыйрь, публицист; «Бәйрәм белән!», «Җирдән җиде җиһанга», «Галәм серләре» һ.б. китаплар авторы. Удмуртиянең атказанган журналисты. Ижау шәһәрендә яши.*

Әйләнә Җир...
Күчәре – шым...
Кем аны майлап тора?
365 әйләнеш
    ясала җайлап кына...

Җилдертә Кояш тирәли
    тереклекне Сәйях-Ат[**].
Мыжгый Җирдә ыгы-зыгы,
        ахмакларча сәясәт...

Адәм өчен олуг көннәр –
Рамазандыр, Корбандыр.
Меңләгән гайре бәйрәмнәр
Шайтаннардан калгандыр...

Зыялы зат шөкерана
Бага фани дөньяга,
Исәнлектә, иман эстәп,
Сәҗдә кыла Аллага…

## Төп сөаль

Карт шагыйрьдән нинди эштер:
Торып китә мыштыр-мыштыр,
Актарына кыштыр-кыштыр...

Минме исән? Минме үлгән?
Кылган эштән шайтан көлгән:
Шигырьләр көлдәй чәчелгән...

Мәңгелек дигән бу Кояш
Дүрт милиард елдан сүнәр.
Җирдәге барча мәхлуклар
Кая китәр, кайда түнәр?

Җан иясе, ач күзеңне!
Гафу, гафу, тыныч йокла!
Сөальгә җавап – кыяда.
Менеп җитмәс безнең уклар...

***

Тайпыла критерийләр,
Үтәлми гарантияләр,
Таркала империяләр,
Атыла галактикалар...

Кирәкме, түгелме,
Кичәме, бүгенме –
Тарихны умыра ампутация.

Азмыдыр-күпмедер,
Шаулашып, кул чабып
Үзгәрә репутация.

Коймада ап-ак кар –
Бик нәфис бер челтәр.
Томанда – язмышлар...
Хакыйкать тегелә –
Ак җептән...

[**] Сәйях-Ат – Җир шары.

Адәм аңы эреп ага,
Таркала материя.
Туа шау-мистерия.
Зур мәгънә – үкерүдә...

Җырлана тозсыз җырлар.
Салына җансыз йортлар.

Киләчәк үткәнгә күчә,
Бүгенге – киләчәккә...

Мизгелләрдән мәңгелеккә,
Мыскалдан чиксезлеккә,
Озын сәяхәттән туктап,
Инде куйыйк күп нокта...

## Байлык – китап

Байлык –
Бәндәне аздыра,
Акылыннан яздыра,
Рухын имгәтә, җимерә –
Кешелектән аера.
Ул аннан ансат кына
«Зур маймыл» ясап куя…

Коръән –
Җанга рухи баскыч –
Күккә күтәрелгәндә,
Ул – адәмнең кешелеге –
Яшәгәндә, үлгәндә.

Нәфес корты – алдакчы бай
Китапны кулга алмый…
Илаһи әхлак шәкерте
Олигарх булалмый…

## Гади уйлар

Төкерәм төче сүзләргә,
тантаналы антларга.
Эчкерсезлек – яуган карда
һәм аккан болытларда.

Чәнечке-чытырман-кыя –
юлым булды узылган.
Хак олуг дәресләр алдым
тынлыктан һәм йолдыздан.

Сихерләнәм, әсирләнәм
ерактан килгән җырдан.
Тыныч төндә эреп китәм
Җир-Анам куенында:

«Минлек»кә ирек куймыйча,
агарга да агарга,
соң мизгелдә бу турыда
матур бер җыр язарга...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Айдар
Хәлим

# ХИКӘЯЛӘР

## Чыршы бәйрәмендә

*Көрәштәшем Рафаэль Әбдиев рухына*

I

Безнең балачакта Яңа ел – чыршы бәйрәмнәре дигән нәрсә юк иде.

Татар-мөселман, ачыклап әйткәндә, аңа фарсы календареннан кергән яңа ел – Нәүрүз бәйрәме март азакларына туры килгәнлектән, без яңа елны үзебезнең гамәлдә булган григориан календаре буенча да, дини исәпләнгәнлектән, Нәүрүз бәйрәме итеп тә үткәрмәгәнбез. Ел башлары шулай «башсыз» гына килгән дә киткән, килгән дә киткән. Монда бәлки безнең халыкка хас мөслимин тыйнаклык та, йомыклык та, ярлылык та сәбәпче булгандыр. Мин болай дип милләтемне, нәселемне, авылым халкын йә булмаса үземне гаепләргә теләмим. Хакыйкать буларак кына искә алып китәм.

Беренче тапкыр мин Яңа ел бәйрәмен бары тик 1965 елда, Казан университеты студенты булып алгач, анысын да, шәриктәшләрем тырышлыгы белән генә «билгеләргә мәҗбүр» булдым. Анысы да югыйсә, кеше кыланганны кыланып калыйм, дип түгел, ә беренче гыйнварның минем туган көнемә туры килүенә бәйле иде!

1949-1950 еллар арасындагы Яңа ел булырга тиеш ул. Сугыш әле тәмамланган гына. Күкрәкләргә кунып өлгермәгән йолдызлар күктән җиргә атылган заман. Хәрабәләрдә торымбашлар төтенли, йөрәкләрдә яралар кансырый. Хәрәкәттәге армиядән исән калган аяксызлар, кулсызлар, госпитальләрдән яралылар, концлагерьлардан әсирләр һәм үз илебездәге санаусыз зоналардан тоткыннар кайта тора. Безнең әтиебез беркайчан да кайтмаячак, бу хакта сугыш тәмамланыр алдыннан гына килгән «кара кәгазь» шүрлегебездәге дүәкәмнәтләр савытында ята...

Бер караганда, усал холыклы, кырыс табигатьле, кулы кычыткан саен, еш кына бер сәбәпсез, күбрәк яратудан миңа менгәләп төшкән, икенче караганда,

---

Айдар ХӘЛИМ (1942) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Гомеремнең ун көне», «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

ифрат та йомшак күңелле, туган җанлы, кыскасы, шушы ике сыйфатны бергә тигез итеп берләштергән агам, авылыбыздан өч-дүрт чакрымда яткан Олы Кәркәле җидееллык мәктәбенең бишенче сыйныфы укучысы, караңгы төшеп, йокларга ятар алдыннан гына:

– Иртәгә Яңа ел – Чыршы бәйрәме! Бик теләсәң, барырсың. Иртүк, таң тишегеннән! – дип ярып салмасынмы!

Тукта, нинди Чыршы бәйрәме? Яңа елы нәрсә дә, чыршысы нәрсә?! Безнең якларда чыршы үсми дә әле ул, беләсегез килсә. Күргәнем булмаса да, чыршы нишләптер ямь-яшел агач булып күз алдыма килеп басты.

Абзамнан бу кадәр миһербанлылыкны көтмәгән мин – эрепләр төштем. Барам, бармый диме!.. Таң тишегеннән генә түгел, хет төн уртасыннан – хет хәзер үк!

Мич алдында мәшәләнгән инәкәебез:

– Нигә аны иртәрәк әйтмәдең? – дип битәрләп алды агамны. – Синең шул булыр инде: урманың – колаксыз, басуың – күзсез. Кешегә күренергә аягында юньле чабатасы да юк. Туганыңа чабата тукып бирсәң, бер дә кулың корымас иде!..

Минем бакчама төшкән таш минем файдага иде. Файдаланып калырга кирәк!

– Инәй, өч сум бир! – дип йөгереп бардым мин мич каршына. – Галимулла карттан чабата барып алам...

– Менә хәзер! Тутырып куйганнар ди...

– Булмаса, биш йомырка! Өчне!.. Миңа бабай өч йомыркага да бирәчәк!

– Бирәчәк! Тот. «Төрек Галимулласы» диләр әле аны. Ул нәселдән кышын кар сорап ала алмассың, – дип көяләнде утыз ике яшендә дүрт малай белән тол калган: уникe яшьлек улы кырык алтынчы ел ачлыгында эчәгесе шартлап үлгән, бер ел элек иң өлкәне Ташкент тарафларына бәхет эзләргә чыгып сызган, инде хәзер бәләкәй абзам белән икебезне үстергән инәбез. – Сезнең шул булыр инде. Бир дә бир! Кайчан «Мә!» дия башларсыз икән, Ходаем?

Ул, чәчүргеч очындагы чулпыларын зеңгелдәтеп, ишекне ачты, тыштан өй эченә борхылдатып салкын пар болытлары кертеп, кәҗәнкәгә[1] чыкты һәм минем күзләремә ун булып күренгән биш йомырка алып керде.

– Мә. Башка юк. Бирмәсә, утыныңны ярырга киләм, дип ялын, бәкедән суыңны кертәм, дип буынына төш!..

Йомыркаларны бүрегемә салып, төшеп ватыла күрмәсеннәр өчен колакчыннарын уратып тотып, яланбаш, җәядән атылган уктай тышка атылдым. Өч атлап, ике сикереп, Галимулла бабайның Өязе ярындагы уенчык кебек курасының ишеген шакыдым. Ул авылда иң оста чабатачы. Ул үргән чабаталар чыдам, теземнәре вак, матур, ничектер адымга ырамлы, йөзләре, яшь киленнәр кебек әллә кайлардан елмаеп торалар. Ихата ягындагы бердәнбер тәрәзәчектән өйдә ут әсәрәсе шәйләнми иде. Мин ишекне шакыдым. Салкын һавада ул дөбердәп яңгырады. Күп тә үтми Миңсылу әби, сукрана-сукрана аркылы агачын бушатып, миңа ишек ачты. Чыршыны күрү хакына карт кешеләрне борчу бу мизгелдә миңа, әле быелгы көздә генә беренчегә кергән сабыйга, ике тиен дә тормаган, күрәсең. Чабата дигән хикмәти зариф каршында калганы – вак нәрсә иде. Өй эчендәге юкагач буы белән куерган һавада күптән түгел генә мич кайнарында пешенеп, кәүсәсеннән суерылган курыс әчесе,

[1] Кәҗәнкә – дүрт почмаклы өйнең болдыр ягыннан келәт бурычын үтәгән аран. «Казёнка»дан алынган.

яшь юкә, чалабаш исе тынымны буып куандырды: болай булгач, бабамның тукылган чабатасы әзер булырга тиеш! Мич артыннан, сәкедән ыңгырашкандай авазлар чыгарып, идәнгә төшкән Галимулла карт шәйләнде. Безнең яклар өчен ят, торганы белән ата төрек кебек җете-кара картның карадан-кара сакалы өй эчендәге караңгыдан тагын да караебрак шәйләнеп, миңа якыная, өметем акланасына ышанычымны арттыра барды. Миңсылу әбинең мич кашагасыннан шул арада черт итеп кабызып өлгергән өчле лампасы бабайның ат яңаклары сыман ач битен яктыртып, мөселманча аяланып торган сакалы тәмам сурәтләнгәч, никтер күңелем кителгәндәй булды: бабайга мөкатдәс серемне сөйләп аңлатыр өчен миңа яктылык бөтенләй кирәкми, миңа бары тик караңгылык кына кирәк иде!

– Галимулла бабай! – дидем мин, тыным кысылып. – Иртәгә... иртәгә... таңның тишегеннән... Чыршы бәйрәменә!.. Чабата!..

Сүзем шуның белән тәмамланды. Йөрәк дарс-дорс тибә. Дулкынлануымнан чак егылып китмәдем. Карт бер миңа, бер кулымда төргәктәй төрелгән бүрегемә караш ташлады да, шомырттай кара күзләре, кара сакалы белән йөземә үк капланып:

– Was ist das?[2] – диде.

Мин бабабызның Беренче Бөтендөнья сугышында әсирлеккә төшеп, берничә ел Германиянең Вустрау лагеренда булганлыгын һәм ватанына кайткач, кайчакта, кәефе килгәндә, олысына-кечесенә мәзәк итеп немесчә эндәшкәнен белсәм дә, бу минем өчен шулкадәр дә җаваплы, чабата аркасында гына чыршыны күрә алмый калуым куркынычы янаган мизгелдә немесчә маташтырып, җанымны кыюы көтелмәгән хәл иде.

– Галимулла бабай... – дип үрсәләндем мин, янган утларга төшеп. – Акчабыз булган чак булмады бит әле... Әтәйнең пинсәсе килгәч бирер идек... Минә инәкәем биш йомырка... Җитмәсә, мин сиңа көн саен абзарыңда тиресеңне тазартам! Утыныңны кисәм! Бәкедән суыңны кертәм!..

– Ich liebe dich! Jawohl![3]

Мин ят телне аңламаудан телсез идем. Ичмасам, гарьлегемне күтәрешергә түмәр умарта кебек юан гәүдәсе белән Миңсылу әби дә каядыр юкка чыкты бу шырпы кабыдай кечкенә өйдә. Үземне кая куярга һәм нишләргә белмичә, үкенечтән һәм өстемә ишелеп төшкән кара кайгыдан тиле кебек шаркылдап җибәргәнемне сизми дә калдым. Әмма Галимулла картның һич кенә дә көләргә исәбе юк иде. Өйдәге караңгылык спут каршындагы лампа яктысыннан күпкә көчлерәк булган аралыкта янган күзләре белән миңа чекерәеп текәлгән дә, авыз читләре белән генә елмаеп, бу нишләр икән дигәндәй, агымсулар астындагы кара чуерташ кебек карап тора.

– Галимулла бабай... – дидем мин, тәмам югалып калып. – Миңа ярарлык... яңа чабаталарың бармы соң?! – Аннан ачуын китереп, дөресен әйттерү өчен өстәп тә куйдым. – Миңа гади түгел, миңа шыгырдап торган чабата кирәк!..

– Das ist interessant, kameraden![4]

Ул «Син кем белән эш иткәнеңне белеп сөйләш!» дигәндәй гасаби хәрәкәт белән почмакка таба атлады, идәндә аунап яткан тасма-тасма юкәбашлар, чөшле, калыплар аша җирнең икенче ярымшарына үрелгәндәй үрелеп, шүрлектән күрер күзгә нәкъ минем өчен үрелгән, балавыздай сары, уенчык

[2] Сиңа нәрсә кирәк?
[3] Мин сине яратам! Нәкъ шулай!
[4] Бу бик кызыклы, иптәш!

кебек җыйнак чабата киеме алды, күз алларымда уйнатты. Алардан җәйге юкә урманнарының баллы чәчкә исләре аңкыгандай, нурлар чәчрәп, өй эче яктырып киткәндәй булды. Аннан бабай аларны минем колак түбемә китереп бил уртасыннан сындырды, сәнгать әсәре кебек килешле чабаталар өзелгән аһәң чыгарып ыңгырашты, шыгырдашты, сайрашты, мин шатлыгымнан тәһарәтсез калыр хәлгә җитеп, урынымда сикереп куйдым һәм йөрәгем ярылып китмәсен дип күзләремне йомдым...

– Йә, бала белән бала булма инде, карт тиле! – диде Миңсылу карчык сәке тарафыннан. – Бирсәң, бир дә җибәр!..

– Ир-ат арасына кысылма, әбисе! – дип кычкырды ул аваз килгән тарафка. – Үзебез беләбез, әйеме, улым?

– Әйе, Галимулла бабай! Jawohl!.. – дип эләктереп алдым мин, аның кулларында очар кош кебек талпынган чабаталарга карап. Аннан, гүя кызыктырырга тырышып, бүркем эчендәге йомыркаларга ымладым. – Абзарыңны тазартам! Ишегалдыңны себерәм! Карларыңны көрим, билләһи дип әйтәм!..

Карт чак сизелерлек кенә кеткелдәп, миңа таба борылды, кулларымнан бүрегемне алды, чабаталарны йомыркалар янына салып, бауларын тыгыз итеп бәйләде дә миңа бирде:

– Zum glucklichen Neujahr![5] Нимесләр шулай ди. Бар син, кайт. Йомыркаларыңны инәкәеңә тапшыр. Галимулла карт белән Миңсылу карчыкка йомырка ярамый, эчләре китә, диген. Ул аларны сиңа Яңа ел таңында пешереп ашатсын. – Бабайның авызыннан чыккан татлы сүзләрдән үземә-үзем ышанмыйча күзләрем шар ачыла барды. – Икенче килгәндә син миңа кар көрәргә дип килмә, нимесчә өйрәнергә кил, яме!.. Man muss deutsch bennen, um keinen Krieg fuhren![6]

Килми диме! Миңа бушка чабата бүләк иткән телне өйрәнми диме!.. Сүзләреннән кире кайта күрмәсен дип, тупса аша чыгып ычкынам дигәндә генә, ул сырмам чабуыннан тотып алды. – Тукта. Бик җитди үтенечем бар. Олы Кәркәленең бәйрәм чыршысыннан син миңа берәр ылыс өзеп алып кайтып бирерсең, яме!.. Ылысның сере бар!..

## II

Төне буе йоклый алмадым. Искергән чабаталарымны яңага алыштырыр алдыннан кабатлана иде бу хәл минем белән. Мин яңа чабаталарымны бер киеп, бер салып саташу, таушалып-тузып, мунчалага әйләнгән чыпталарны яңарту минем өчен бәйрәм дә, газап та иде. Бу юлы инде бу гамәл бөтенләй дә мәхшәргә әйләнде. Җитмәсә, боларга тагын бабайның чыршы ылысы дигән борчу өстәлде. Нәрсә була ул ылыс? Мин аны таба алырмын микән? Ылыста нинди сер бар икән?

Шунысын беләм: чыршы бәйрәмендә мин аеруча ыспай күренергә тиешмен. Минем өчен җир йөзендә чабатадан да матуррак аяк киеме юк иде. Гүя ул авылым урманнарындагы юкәләрдән суерылган гади курыс тезмәсе түгел, ә бәлки чәчкәле сурәтләр белән чигелгән хан читекләре иде! Тагын да ныграк кипсен, коргаксысын, күн итек кебек, тагын да кәттәрәк шыгырдасын өчен спут башына куйган чабаталарны мин бая телгә алган төшләремдә кидем дә салдым, кидем дә салдым. Алар миңа энҗеләре чәчелеп торган сафьян каталар

[5] Бәхетле Яңа ел белән!
[6] Киләчәктә сугышмас өчен, нимес телен белергә кирәк!

булып күз алдымда уйнаклыйлар иде. Тез очларыма җиткән ап-ак тулаекларым өстеннән мин аларны ничек кенә кыландырып кими идем! Тора-бара, уянып, бу таң кайчан атар, чабаталарны кияр мизгел кайчан килер икән дип йөзгә кадәр саныйм да, йокыга китмәдем микән дип күземне ачам, саныйм да күземне ачам. Без, абзам, инәй һәм мин бер уртак чүпрәк палас астында йоклыйбыз. Мин, төпчек, уртага йомылганмын. Шулай иткәндә өшетми. Беребезнең тыны белән икенчебезнең арка үзәге җылына. Бер якта ятып, тәннәребез ойый башласа, барыбыз берьюлы икенче якка әйләнеп ятабыз. Болай иткәч, мичкә ягулыкка утын да азрак тотыла. Ята торгач, йокымсырап киткәнмен. Мичтә четер-четер килеп яна башлаган чытыр-чатыр тавышыннан күземне ачсам, мич алдына кунаклаган инәйнең йөзе утның үзеннән дә көчлерәк уйнаклап ялкынлана. Куркып киттем: чыршы бәйрәменә соңга калмаганмынмы?! Сул кулым терсәген сак кына кузгаткандай итәм – урыны буш, инәй чынлап та торган, уң кулым терсәге буш түгел – анда абзам мыш-мыш йоклый. Мин аңа сиздермәскә тырышып, тәңкәле балык кебек, шыпырт кына палас астыннан суырылып чыгам, песи җитезлеге белән спутка сикерәм, инде җылыда шикәр кебек агарган, хуш исләр килеп торган чабаталарымны әләктереп, киенә башлыйм. Бозлы тәрәзәләр әле кап-караңгы. Эресәләр, сулары агар өчен куелган чүпрәкле шешәләргә чүлт-чүлт итеп тамчы тамгалый. Андый-мондый тавыш юк. Димәк, тышта үр куяннарын үрле-кырлы сикертерлек салкын икәнлеген аңлау миңа, балага да, читен түгел...

Вак шакмаклы тастымал бәзеннән тегелгән күлмәгемне, ике кат итеп типчелгән нәзек кара бумази чалбарымны күз ачып йомганчы әләктереп алып, ниһаять, иң көтелгән, иң ләззәтле гамәлемне үтәргә керештем. Аякларыма эчке оекбашларымны, алар өстеннән тулаекларымны тезем очларына кадәр менгезеп кидем, аннан аларны йөзлекләре вак тешле көнбагыш мәмие кебек тезелеп киткән чабаталарым эченә тыктым, киндерәләрен аякны кысмас һәм бушак та итмәс дәрәҗәдә уратып бәйләгәч, тулаекны шаталакларымнан бераз гына югарыдарак катлап, киндерә очларын шуның астына яшереп каплагач, инде хәзер ап-ак шәм кебек тәмам бөтәеп калган тулаекларымны түбәнгә таба сыдырып, гармун күрекләре, күн итек сырлары кебек сыман дулкынлатып сырладым һәм аякларыма басып тыпырдап карадым.

Барысы да кып итеп тора иде!..

Чабаталарым чынлап та җырлый иде!

– Очып китә күрмә! Күнитекле идек, чабаталы булдык! – диде мич алдында кичәдән калган умачны җылытып азапланган инәй. – Җайлап атла, Кәркәле үрләре ай-һай биек!.. Кәҗә майларың чыгасы алда әле!..

Шушы мизгелне генә көткән шикелле, әле һаман йоклап яткан абзам, уянып, янәшәсендә мине дә мырлый дип уйлап, йокылы тавышы белән минем буш урынымны уятырга кереште:

– Тор! Бәйрәмнән каласың килмәсә!..

– Мин әзер!.. – дидем мин, сәке түбәненнән чак кына ишетелерлек итеп.

Кайнар умачны гаптыр-гоптыр җәмхәлләгәннән соң, без абзый белән тыннарны куырып барган салкын төн караңгылыгына чумдык һәм Шәрифҗан күпере каршында, олы юл чатында, күрше авылга йөреп укучы балалар белән җылыдан кубарылып чыгып, чыңрау торналар кебек, шыңгырдый-шыңгырдый еракка барган тезмәсенә килеп кушылдык. Өсләренә безнең кебек бер кат ыштан, юкадан-юка сырма, элпәдәй җиңел баш киеме кигән, суык энәдәй чеметкән сугыш ятимнәре, берсе-берсе белән куыша-куыша, шаярыша, үрләргә

менгәндә-төшкәндә су өсләрендәге чөгермәкләр кебек буталыша, өшисе урында да өшеми, шушы гамәли хәрәкәт белән җылына, күңелен күтәреп, җан азыгы таба иде. Кар шыгырдый, аякларда хәтфә карлар өстеннән йөгергән чабаталар да шыгырдый. Мин шундый сәер күренешкә игътибар итәм: күзгә төртсәң күренмәс караңгы белән авылдашларымның гәүдә каралары ничектер кушылмый, алар үзләренә билгеле бер серле сызык белән аерылалар, сөйкемле сөякләре белән танылып торалар икән. Гүя бу сабыйлар юл буйларындагы көртләргә кара маяк булып кадалганнар да, сугыш яланнарында ятып калган аталарын, туган-тумачаларын каршыларга баралар. Шулар арасында мин дә бар. Чөнки сугыштан кайтмый калып, каршылар кешеләрем минеке дә бар бит. Бар гына диме, күпләр. Сиксән йортлык авылдагы Хәлим нәселеннән уналтау.

«Тырын Түбәсе»ндәге «Бүләк урманы»на да җитеп киләбез икән. Балалар арасында мин үзем укыган Кәркәлетамак башлангыч мәктәбенең башка укучыларын күрмәдем. Бу хәл минем яңа чабата куанычына «Алар бу бәйрәм хакында белми калганнардыр» дигән ялгызлык тойгысы уята иде...

Менә безнең божрага божра бәйләнгән тере чылбырыбыз әле ут та алып өлгермәгән Олы Кәркәле авылына килеп керде. Сулда атлар абзарының каравылчысы өендә мезелдәп яктырган кечтеки тәрәзәсе шәйләнде. Менә сүнәм, менә сүнәм дип калтыранып яна иде ат абзары эчендәге ялгыз соры фонарь. Шушы ялгыз, тирә-яктан караңгылык белән камалган ут әле безне тыштан гына өйкегән суыкны ниндидер дәһшәт белән эчебезгә куып керткәндәй итә иде. Абзар эченнән малкайларның авыр көрсенгән, миһербан сорап пошкырган тавышлары ишетелде. Кая ди печән, саламының оннарына кадәр ялап алынып, авызларын түшәмгә элгән колхоз атлары күз алдыма килде. Минем күп тапкырлар күргәнем булды: салам кибәге борыннарына кергәндә, алар төчкерәләр, күзләре, күл кебек, яшь белән тула һәм туңа. Менә әле дә аларның күзләрендәге туң яшь шушы ялгыз фонарь салкынында чатнагандыр, тояклары тишкәләнеп ярылгандыр, кабыргалары саналып тырпайгандыр. Кайнар тыннарында коры суыктан яратылган бәс аларның тырпаешкан сирәк мыекларын, колак читләрен, борын тишекләрен көмешләгәндер, кашларын, башларын һәм ялларын он кебек ак кар кырпагына тыгып агарткандыр. Атлар, ятим балалардан да ятимрәк атлар, безнең кебек чабышып җылына алмыйлар иде шул. Минем аларның сөяк булып та шакыраеп туңган тоякларына үземнең тулаекларымны кидерәсем, шуны эшли алмавымнан җылыйсым килеп китә.

Җыларлык та шул. Менә бу күпер минем өчен бик моңсу истәлекле ядкяр. Хәтеремдә, моннан өч ел элек, җәй айларында, мин, дүрт яшьлек ятим, сугышта үлгән фронтовик-укытучы улы буларак, биредә оештырылган ач балалар йортында тукланып азапланган, авылымны, инәм һәм туганнарымны сагынып, берничә тапкыр бу «берәнник» вәгъдә итеп, ачы торма да бирмәгән йорттан качып кайтырга ниятләп, берничә тапкыр менә шушы нәгъләт төшкән күпер төбендә хәлдән таеп, егылып, кире кайтарылган идем...

Урамда авылның, безнең кебек кара маяктай серәеп, берәм-сәрәмләп мәктәпкә барган укучылары очраштыргалады. Йокыларын куып, алар күзләрен уыштыра һәм безнең карларны өзеп-өзлегеп атлауларыбызга карап юл бирә. Безнең артыбыздан авылга кергән җылы булып тәрәзәләрдә мез-мез килеп хәлсез утлар кабына. Әйдәп баручылар сулгарак тартты. Яктыра, караңгылык сыегая башлаган икән. Алдыбыздагы янкапка буйлап сузылган тәбәшәк рәшәткәдән безне чакыру каршылады. Әле тәмам юкка чыгып

өлгермәгән караңгылык эченнән «Мин дә мин!» дигәндәй чекерәеп кычкыра иде бу чакыруның эре кызыл хәрефләре. Мондагы «мин»нәр арасында мин үзем дә күпмедер күләмдә «мин» була башлаган идем бит әле, җәмәгать. Әйе, беләсегез килсә, беренче сыйныфның беренче яртысын бер дүртлесез майтарып ыргыткан идем мин. Боларнымы? Боларны абзагыз чәйнәп кенә ыргыта! «Ком-му-нистлар пар-тиясе... җит-тәк-челе-ген-дә... – дип иҗекләдем мин. – Ал-га коммунизм җиң-нүен-нә!»

Капка аша кергәч, тапалган карлы сукмакта безнең чабаталар кинәт кенә шыгырдаудан туктады. Каршыбыздагы озын, бик тә тәбәшәк бинаның кыегы буйлап кычкырган икенче чакыруны да җиңел укыдым мин. «Яшәс-сен без-гә бәх-хетле бал-лач-чак бир-гән юл-баш-чыб-быз Ыс-тал-лин!»

– Бу безнең мәктәп, – диде абзый, горурлангандай итеп, алда утлары яктырган биек бина калкып чыккач. – Чыршы бәйрәме шушында була...

Ниндидер сирәк тойгы белән сизенеп, сизенеп кенә түгел, танып алдым: безнең ач балалар йорты нәкъ менә шушы бинада урнашкан иде ич! Монда минем күңел ташуларым ташкан, саташуларым башымнан ашкан, кайнар яшьләрем тамган иде!

### III

Без ишеккә сыеша алмаган ташкын булып берничә куыклы лампа яктырткан залга килеп кердек. Залны да танып алдым мин. Без монда кашыкларыбыз белән коштабакларыбызны доңгырдата-доңгырдата ашарга таләп итә идек. Урталыкта кечкенә түгәрәк мәйдан калдырып, залны балалар тутырган иде. Бирегә башка авыллардан да йөреп укыйлар икән. Мин йотлыгып яшел чыршыны эзләдем. Биредә бернинди дә чыршы дигән яшел ылыслы галәмәт күренмәде. Абзамнан сак кына:

– Кая соң ул чыршы? – дип сорадым. – Юк бит!..

– Әнә бит! – диде ул, алдыбыздагы, түшәмгә кадәр җиткән сап-сары каенга ымлап. – Шуны да күрмәскә, күзең чыккан мәллә?!.

Әмма мин күзләремә шырпы куеп карасам да, алдымда каенны чыршы итеп күрә алмаудан гаҗиз идем. Иске дәфтәр, китап, гәзит битләреннән ясалган куян, төлке, аю һәм башка җәнлек-җанвар сурәтләре, ясалма «кәнфит-берәнникләр» белән бизәлгән ак, дөресрәге, яфраклары саргаеп, ни сәбәпледер коелып бетмәгән каен чаукасыннан башка бернәрсә дә юк иде биредә. Без салкында алсуланып алмаланган битләребезне дә җылытып өлгермәдек, нәзек кенә муенына кызыл чүпрәк – аны галстук диләр икән! – таккан бер апа чыкты да, барыбызны даһи Ысталин бабабыз исеменнән Яңа ел бәйрәме белән котлады, бәхетле балачагыбыз өчен киләчәктә даһи ышанычын яңа җиңүләр белән аклавыбызны теләде, аннан балаларны, алар белән безнең барыбызны да җитәкләтеп, тыгыз боҗрага тартып кертте һәм без, түгәрәктәге балалар, безнең белән барлык зал хәрәкәткә килеп, каен чаукасы тирәли җырлап әйләнә башладык:

Чыршы, чыршы, без сине
Сагынып көттек ел буе...

Куанычым чиксез иде. Чөнки мин, каен тирәли әйләнеп, аның чынлап та каен түгел, чыршы булуына, алай була алмаган хәлдә, чыршының кайдадыр бер читтәрәк яшеренеп торуына ышана башлаган идем инде. Тагын да шунысы

кызык: мин бу җырның сүзләрен гүя кайчандыр алдан бикләп куйган кебек, яттан белә һәм башкалар кебек, тигез аһәң белән кушылып җырлый идем:

Син тагын да матурырак
Бизәлгәнсең бу юлы...

Апа безне биетте дә биетте. Безнең белән бергә ясалма кәгазь аюлар да, куяннар да, хәтта уенчык кәнфит-манпачилар да биеде. Үзебез ярымач булсак та, ашау, аларны авыз итеп карау уйларыннан бөтенләй арынган идек. Шулай да биредә миннән дә шатлыклырак җан иясе булмагандыр. Мин инде каенның каен икәнлеген тәмам исемнән чыгарып, каенның чыршы була алуына ышанып беткән идем бугай. Кинәт алдыбызда рәт-рәт балалар хасыйл булды. Аларның каршына уң яңагы сабан белән сөреп төшкәндәй тирән ялы, түмәр аягын тез өстеннән аеллы кара каеш белән ныгыткан абзый чыгып, кулындагы нәзек талчыбыгы белән селтәнүе булды, бу төркем кинәт дистәләгән аһәңнәрдән бер тавышлы давылга әйләнеп кубарылды:

Яфраклары яшел ак каенның
Хәтфә җәйгән кебек һәр ягы...

Мондый тотып тыйгысыз күмәк тавышны хор, мондый талчыбыклы абзыйны «дирижир» диләр икән. Ул гүя шушы нәзек кенә чыбыгы белән алдындагы сабыйларны яратып кына суктыра, кыйнап җырлата, тегеләр исә суктырган саен тавышларын үзгәртеп, бер калынайта, бер нечкәртәләр иде:

Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,
Гөрләп тора һәр көн тау ягы...

Кинәт түмәр аяклы абый кесәсеннән кечкенә елтыр нәрсә чыгарды, аны авызына терәде һәм шушы көйнең азагын кабатлап уйнап куйды.

– Галиулла абый. Җыр укытучыбыз. Акампанир итә[7], – диде абзам. – Әле авыз гармунында салдырды. Дәрестә кем яхшы җырлый, шуларга уйнап карарга да рөхсәт итә...

– Аягын германда калдырган, – дип пышылдашты артымда балалар. – Аның каравы, гармун алып кайткан... Авыз гармуны диләр!..

Гармунның үксегән тавышыннан, аңардан да бигрәк уйнап карарга теләвемнән һушым-зиһенем таралган иде. Менә, ичмасам, ничек кенә укыйлар тек укыйлар, нинди генә укытучылардан белем алмыйлар! Мин Олы Кәркәле мәктәбендә укыр өчен Тырын түбәләреннән кайчан менәрмен икән?! Балалар җырлады да җырлады, йөзендәге буразнадай ярасы ничектер тигезләнеп юкка чыккан Галиулла абый исә нимеснең трофей гармунында уйнады да уйнады. Аның кыланышлары үлчәмле, илһамлы, йөзе нурлы, түмәр аягы да үзе кебек тере иде бугай. Минем инде бу куанычтан ачуым килә башлады: балалар нишләп һаман да ниндидер ак каен турында җырлый?! Ул бит инде безнең өчен күптән бүләкләр, уенчыклар элгән Яңа ел чыршысына әйләнде! Әмма бер үк вакытта йөрәгемне исемә төшкән борчу да чәнчеп алды: тукта, чыршы дигәнем бит чынында каен, шулай булгач, аякларыма шушы гармун кебек шыңгырдап торган чабаталарны бүләк иткән Галимулла бабама чыршы энәсен каян табып алып кайтырмын?! Шулай дип сискәнеп өлгермәдем, түгәрәккә

[7] Аккомпаниатор – җырны музыка коралында озата килүче.

күбәләктәй ак күлмәкле, су буедай озын толымлы, кара кыйгач кашлы кыз бала чыгып басты. Аның исеме Мәрьям икән. Кахул кызы ди. Чыны – Мария. Сугыш вакытында әбисе белән эвакутсига[8] килгән дә, әбисе үлгәч, Кәркәледә торып калган. Татарча чатнатып сөйләшә. Чишмәдәй челтерәгән тавышы белән «Эскадрон» дигән халык җырын башкарды. Ду килеп кул чаптылар. Шунда ук Зөмәрә Зәйнетдинова дигән кызкайны чакырдылар. Шушы кызлар белән нибары өч елдан шушы ук мәктәпнең бишенче-җиденче сыйныфларында бергә укырмын, артларындагы партадан толымнарын тарткалап утырырмын дип кем уйлаган?! Зөмәрә мин ишетмәгән-белмәгән Сәгыйть Рәмиев дигән шагыйрьнең «Уку» дигән шигырен шартлатып укып бирмәсенме!

Безне адәм иткән уку,
Адәмне алга илткән уку,
Илтеп күккә җиткән уку,
Уку, уку, уку!
Урысча да уку, уку,
Кытайча да уку, уку,
Кемчә генә дә уку, уку,
Уку, уку, уку!

Шигырьнең гади генә сүзләре мине әллә ниткән сихри дөньяларга алып кереп киткән, мин инде «урысча да, кытайча да, кемчә генә булса да укып-укып», әллә кемнәргә әйләнеп беткән идем. Дөнья үзгәрде дә куйды: минем каты бәгырьле чынбарлыгым теләктәш, йомшак күңелле якты, бәхетле тормышка, аягымдагы чабаталарым чынлап та күн итекләргә, өстемдәге ямаулы бишмәтем затлы тунга, алдымдагы сап-сары каеным ямь-яшел чыршыга, каен ботакларындагы кәгазь кисентеләр чын атлас уенчыкларга әйләнгән иде! Мин авызымны ачып, дүрт тарафны күздән кичердем. Бу дүрт тараф, мине – чын бәйрәмгә әле генә керә башлаган сабыйны, һушына китереп, кузгатышты һәм ишеккә таба чайкалыштырды. Тукта, чыршы бәйрәме дигәннәре бетте дә мәллә?! Шулчак абзам касыгыма төртте:

– Нәрсә каттың? Бәйрәм күп булмый. Чыга башла!..

Арттагы тыгыз агым барыбызны ишеккә таба этәрде. Мин нишләргә дә белмичә, абзамның җиңенә сарылдым:

– Чыршыдан... чыршыдан... Уенчык!.. Бер генә энә өзеп бир!

– Ахмак та икәнсең син, энем! Сары каен чаукасында чыршы энәсен каян аласың?!

Абзамның бу сүзләре мине әкият дөньясыннан чынбарлыкка кайтарды. Минем өчен яшел чыршы булып беткән чауканың мин киредән сагыштан һәм сугыштан көйгән сары каенга әверелүен һич теләми идем.

Без ишекнең тар бугазында буыла-буыла тышка тугарылдык. Монда һава саф, тынны куырып барган салкын иде. Безнең авыл балалары, күрше авыл балалары кебек, бер читкәрәк елышып, үзләре белән алып килгән түтәрәм ипекәй, тәгәрәткән бәрәңге кебек ризыкларын кесәләреннән чыгарып тамак ялгый башладылар. Абзам да үзе белән алып килгән түтәрәмен урталай бүлеп, миңа сонды. Мин аны авыз итәргә дә өлгермәдем, бер соры шинельле, шинеленең күкрәгенә ак салган мал күзе кебек акайган орден беркеткән дәү бәндә, яныма килеп, кулын сузды:

– Миңа да бир!..

[8] «Эвакуация» дигәннән. Сугыш вакытында вакытлыча күченеп килгән халык.

Минем аңа дип сузган ипиле кулымны читкә этәреп, абзам аңа үз сыныгын бирде. Бернәрсәгә аптырамаган башка балалар да ипиләрен өзгәләп, аңа суздылар. Теге бер читкәрәк китеп, комсыз рәвештә учындагы ипи кисәкләрен умыра башлады.

– Вәлиулла абый, – диде абзам. – Математика укытучыбыз. Җирдәге кешеләр арасын йолдызлардан чыгып исәпли. Теге гармунчы Галиулла абый белән игезәкләр. Сугышта бер бомбадан берсе аяксыз, икенчесе һушсыз калган. Контуженнай, диләр. Математиканы су кебек эчә!..

– Су кебек кенәме! Бөтенләй дә алмашынган!.. – дип өстәде бер бик белдекле бала. – Шуңа өйләнми, ди!..

Кинәт ул мине үзенә тартып алды, кысып кочты һәм бар көченә үзеннән этеп җибәрде дә кулларын йодрыклап күкне төя башлады:

– Кабахәт!.. Бәддога!.. Сам знам!..

Әле авызындагы чәйнәмен дә йотарга өлгермәгән Вәлиулла солдат, аңына килгәндәй, кемне каһәрләде, кемгә бәддога укыды, монысы бер Аллаһка гына билгеле иде...

Капкага таба барганда, артыма борылып карадым. Соры шинельле абый итәкләреннән җилләр кузгатып, ырамлы адымнар белән аргы урамга җитеп бара иде.

Башкасын мин хәтерләмим.

Байтак еллар үткәч, мин туксанга җитеп барган Галимулла бабайдан чыршы энәсенең аңа теге чакта ни өчен кирәк булганлыгын сорадым. «Мин Чыршы бәйрәмендә чыршының булмаячагын белеп кенә сине шаярткан идем. Әмма ул миңа түгел, сиңа кирәк иде. Чыршыда кеше гомерен озайта торган мәтлекәп[9] бар, – дигән иде ул. – Әсирлектә без аны мыскалы-мыскалы белән кайнатып эчтек. Исән калдык. Аның немесчә исеме «die Tanneunadel» була. Онытма. Мин сиңа шуны аңлатасы идем. Ярар инде, соң булса да, уң булсын. Аллаһ сиңа чыршы мәтлекәбеннән башка да озын гомер бирсен».

## Койма

Уфадан Чишмәгә барганда, Ирек дигән бик матур авылны үтәсең. Бәби итәкле күлмәк өстеннән алъяпкыч кигән татар килене кебек җыйнак ул. Юл буйлап бер генә урам булып сузылган. Гайрәтле исеменә караганда, үткән гасырның Октябрь түнтәрелешеннән соң, егерменче еллар азагы-утызынчы еллар башында кузгалган «кооператив-күмәк хуҗалыклашу» чорында берәр зур авылдан аерылып чыккан коммунарлар нигезләгән булырга тиеш аны. Авылга кергәндә, сулдан беренче йортның рәшәткәле ихатасын, ягъни коймасын күреп, аның мин сөйләргә җыенган тарихы булуы турында беркем уйлап та бирми, әлбәттә. Тарихның төбендә шул замандагы хакимиятнең җитәкчелек итүдәге «вертикаль-горизонталь» үзенчәлекләре ятуын башына да китерми. Сөйли башлар алдыннан, мин, Чишмә якларына күптән кайтмаган кеше буларак, койманың бүгенге көндә исәнме-түгелме икәнлеген раслый да алмыйм. Бәлки ул череп аугандыр, бәлки, киресенчә, дала кояшында сөяккә әйләнеп җилләрдә зеңләп утырадыр. Хәер, эш бит койманың кайчандыр булуы-булмавында түгел, ә бәлки шушы вакыйганың шушы чорда шушы авылда булуы кызык.

...1981 елның җәе иде бу.

[9] Бу урында витамин, «мятные капли» мәгънәсендә.

Без, ул чакта мин эшләгән Урал-Себер нефть кудыру идарәсе хезмәткәрләре, партия-совет органнарының югарыдан төшерелгән күрсәтмәсе буенча көн саен Уфадан килеп Чишмә районының «Дружба» колхозы үзәге Абдулла авылында терлек өчен яфрак-азык әзерләүдә тир түккән булабыз. Шулай бер көнне, ике-өч яфрак хакына, кая ди ул беләк юанлыгы гына, хәтта ки матчалыкка ярарлык бүрәнәләрне аудара башларга әзерләнеп торганда гына, яныбызга дерелди-дерелди «ЗИС» машинасы килеп туктады. Аннан эчендә кайнаган мәшәкатьләре йөзләреннән кисәк-кисәк ялкын булып коелган партком секретаре төште. Машинасының әрҗәсенә сикереп менде, аннан коргаксулары белән ыңгырашкан чалгыларны ыргыта башлады:

– Җегетләр, ситуатси кискен үзгәрде! Балта-пычкыларыгызны куеп торыгыз! Менә бу чалгыларны эләктерегез дә, җәһәт – олы юлга! – Ул сөйләгәндә ашыга, сүзләрен йота иде. – Санитарный чисткы... Юл буйларын!.. Бер генә чүп әсәре дә калмаска тиеш!..

Әле генә балта-пычкылыдан инде күз йомганчы чалгылы булып өлгергән нефть кудыручылардан берәү:

– Олы юлга ничек чыгабыз соң? – дип сорап куйды. – Ерак кына бит!

– Кая ерак булсын! – диде партком. – Олы юл... култык астында гына бит! Сөйләшә-сөйләшә, киттең-бардың, киттең-бардың...

– Әһә, киттең-бардың ди сиңа!.. Анда барып җиткәнче ыштан төпләрең су булыр, абзый! – диде теге үткерҗан. – Машинагыз белән илтеп куйсагыз ни була?

– Бәй, нигә илтмәскә? – дип килеште партком. – Анысы да була аның. Йә, сикерегез!..

Олы юлга чыгу белән без, бизәкле борчак кебек, тирә-юньгә сибелдек. Чүкелмәгән, чүкелмичә, үлән йөзе күрмичә чормада ятудан калынайган, калтайган, тупасланган, ул гынамы, нә төбе, нә сабы-тоткасы каралмаган, чөйләнәсе чөйләнеп, көйләнәсе көйләнеп бетмәгәнлектән, чалгылар барысы селтәнгән саен хор белән шыгырдый, кайберләре исә, гомерендә чалгы тотмаган «интеллигентлар» кулында туң тимер тавышлары иҗтиһат итеп, атламалары белән сапларыннан чыгып оча башлады.

– Чалгыларыгыз чапмый бит!

– Чапмаса! – диде парторг. – Чапмаса чапмый да куя инде. Миңа печән кирәкми. Миңа марафет кирәк...

Бу кунакларны тагын да кузгатып җибәрде.

– Мондый чалгы белән нинди марафет?

– Өздерми дә!

– Кулларыбыз белән берәмләп сындырмасак кына! – диеште ярдәмгә килгән шәһәр халкы. – Юл буен чабарлык косаркаларыгыз да юкмыни?!

– Дөрес аңлагыз, иптәшләр, – диде тирләп-пешкән парторг. – Косаркасы да, чапкычы да бар аның. Әмма бу очракта эш чапкычта түгел. Эш прынцыпта. Чүп үләне – штучный нәмәстәкәй. Теге заманнардагы кулаклар классы сыман, кешенең күз алдына калкып чыгалар, ысбулычлар... Чыгалар да чәчкә аталар. Әйе, миңа бу ыслучайда печән түгел, марафет кирәк, – дип кабатлады ул. – Юл буйларын чүп үләннәрдән... менә шулай... – Парторг урынында сикеренгәләп үлән чүпләп тә күрсәтте. – ...Менә шулай чеметеп алып... тазартырга кирәк. Бүген чүп үләне аерым исәптә – аларны чалгым чапмый дип кенә ташлап китеп булмый...

Без, партком вәгазеннән рухланган нефтьчеләр, еллар буе нәсел

яңартып котырган чүп үләннәрне чалгылар кистерә алганчы кистерергә, киселмәгәннәрен, каккалый-суккалый сындырырга, иң азгыннарын төбе-тамыры белән йолкырга керештек. Хуҗабызга бу ошады булса кирәк.

– Менә шулай! Була бит!.. – диде ул, урынында тыпырдап. – Аеруча эре, буйга үсеп, күзгә ташлана торган үләннәр исән кала күрмәсен, җәмәгать. Шайтан таягы, кырлы курай, һм... җен арбасы... Кырык эшем кыралай ята. Барып киләсе җирем бар. Мине югалтмагыз, мин – мигом! – дип китеп тә барды.

Ул китеп өлгермәде, безнең янга буяулары коелып беткән, моторы сүндергәннән соң да шактый вакыт туктамыйча эшләп утыра алган «ПАЗ» автобусы килеп туктады. Аннан өстенә ак дача кәчтүн-чалбары, башына шулай ук ак салам эшләпә, аягына изелеп беткән кызыл тәпичкәләр эләктереп алган кеше чыкты.

– Мин райком секретаре Сәхәбетдинов булам, – диде ул һәм, кинәт кенә күчәрдән ычкынган чәкүшкә кебек, урынында дырылдап әйләнде һәм, бернинди ихтыяҗ булмавына карамастан, кеше куркытыр дәрәҗәдәге тел белән урысча сөйли башлады.

– Я ыспыррашиваю, паччаму вы эздись? Ышту важней, сорный трава или забор? Паччаму вы не в деревня Ирек? Вы ызнаете, ыхту к нам едет?

Берни аңламасак та, без аңа чүп үләннәрне чабарга партком секретаре кушканлыгын төшендерергә тырыштык. Бу хәбәр янгын өстенә крәчин сибү белән бер килеп чыкты.

– Вам, тауариши, партком не так сказал. Вчара без аңа, баран-голова, три часа на голова кол тешили, что нам забор министра... важнее, чем юлдагы шайтантаяк. Партком нас так и не пүнәл. Садитесь, тауариши, автавыз, едем мы в деревня Ирек койма строить. Ведь к нам едет сам министр сельхоз Рәсфедератси иптәш Флорентьев!..

Безнең егетләр секретарьне ничек кенә татарчасына борырга тырышсалар да, ул кирегә беткән колхоз үгезе кебек нә алга, нә артка кузгалмыйча нык тора – үзенекен сукалый иде.

Мин таң калдым: Чишмә кадәр атаклы район секретаренең русчасы шулкадәр гарип булуы мөмкин эш түгел иде. Башыма җитеп, тиз генә автобус шофёрыннан бу кешенең нинди вазифа башкаруын белешеп килдем. «Халык контроле активисты Сәхәбетдинов, – диде шофёр. – Нинди секретарь булсын ул, кызыл тәпичкә. Җаваплы эш кушсалар, гел урысча сөйли».

– Флорентьев едет, ә у нас у первага дома деревни Ирек ихата без койма стоит!.. – дип тузынды Сәхәбетдинов. – Какой позор!.. Если он увидит наш колхоз без койма!..

– Чалгыларны нишләтәбез? – дип сорады теге үҗәт егетебез, елар хәлгә җитеп. – Чалгы белән койма төзеп булмый бит!..

Бу сүзләрдән соң «кызыл тәпичкәбез» тынычлана, үз тәлинкәсенә утыра төште.

– Чалгы этто да. Они не нужно. Үзегез белән алсагыз да була, кәнишне. Нәбхәдими струмин для забор, как яго, молоток-келәшчә-шипачлар, кадак, вчәкий гвозди, әбрешүткәләр – барысы да Иректә сезне көтеп саргая!..

Барыбыз да шаркылдап көлеп җибәрдек. «Безне көтеп саргайган әбрешүткәләрдән» көлмичә тыелу мөмкин дә түгел иде шул. Теге һаман да ашыктырды. «Садись, такой событие Чишмә, сам Флорентьев едет, тауариши». Кояштан оялып, чалгыларыбызның йөзен аска бордык та, безгә Уфа кадәр

Уфадан килгәч, ниндидер эш майтарырга кирәктер бит инде дип, автобуска кереп утырдык. Озак та үтми Иреккә дә барып кердек. Автобусыбыз сул тарафтан беренче йортка җитәрәк туктады. Барыбыз да коелдык. Салоннан иң башта Сәхәбетдинов атылып чыкты.

– Ну, нәкәнис! Чалавик есть, фрунт работа есть! Струмин есть. Бистро! Бистро!

Булачак койма йорт биләгән җир буйлап кыска итеп киселгән баганалар, вак рәшәткәлек такта өемнәре, анда-монда ташланган балта, чүкеч, көрәк кебек эш кораллары, кадак әрҗәләре белән чуарланган иде. Ләкин алар дүрт почмаклы бураның дүрт тарафы дүрткә бүленеп өелгән бүрәнәләре белән аралашып, ике арага сыешмагандай, үзара карышып яталар: гүя бүрәнәләр төзеләчәк койманың рәшәткә такталарын якын китерми, эчкә кертми, койма такталары исә бүрәнәләрне эчкә этәрә, тышка чыгармый иде. Гамәлдә шулай булып чыкты да. Гөнаһ шомлыгына каршы, йорт хуҗасы бүген өмә корып, бурасын күтәртә икән. Без, шау-гөр килеп, автобустан төшүгә, өмәчеләр ишегалдыннан чыгып, безгә ябырылдылар.

– Ни эшләргә телисез монда? – диде йорт хуҗасы. – Сезне кем чакырды?

– Райком приказ!.. – дип кәпәренде урысчасы бөтенләй аңлашылмас дәрәҗәгә җитеп шомарган «кызыл тәпичкә». – Немедленно райком указал такой. Заптры районга Ырысыфысыр авыл хуҗалыгы министры иптәш Флорентьев катитсә. Тәк ышту, бүрәнәләрегезне әтсүде немедленно убирайт. Эздись должен быть койма. У меня вчю. Дальше разговор – тюрьма.

– Мин бүрәнәләрне беркая күчермим, – диде ачуыннан нишләргә дә белмәгән хуҗа. – Миңа сезнең коймагыз кирәкми. Йорт-җиремне төзеп бетергәч, мин ул койманы сездән башка да корып куям. Аңлашылдымы, абзый? Яхшы чакта, очты-очты, казлар очты дигәндәй, бередән аяк табаннарыгызны ялтыратыгыз!

– Забор построен вам! Тәки аңламый!

– Миңа койма кирәкми!

– Пәслидни раз упреждаю: эздись должна быть койма!

– Мин дә соңгы тапкыр: кирәкми! – дип кычкырды хуҗа. – Сез минем өмәне туктаттыгыз! Өмәчеләремә койма түгел, пространство нужен!

Бу гүя авыл белән шәһәр арасындагы мәңгелек бәхәснең Мәскәү министры килер алдыннан кузгалып киткән дәвамы иде. Шул бәхәснең иң гүзәл сәхифәсен хәтерләтеп, хуҗаның бүрәнә араларына мүк салып торучы хатыны һәм ике кызы – өчесе дә кызгылттан киенеп алган да, итәкләре белән давыл кузгатып, шәһәрнекеләр алдыннан фырт та фырт үттеләр:

– Бернинди койма кирәкми! Без койманы үзебез төзибез!

Йорт хуҗасы белән халык контроле вәкиле ике әтәч кебек борынга борын килеп бастылар.

– Райком кушты! Безгә райком указаниесе закун!

– Төкерәм мин синең райкомыңа! Сез минем өмәмне өздегез!

– Әле син шулаймы? – диде урысча сүз байлыгы такырайган иптәшебез, кинәт кенә татарчасын исенә төшереп. – Әле син райкомга тел тидерәсеңме?! Мин сине йорт төзетү түгел, авылдан кудырам. Кулак токымы!.. – Сәхәбетдинов сәгать сиртмәсе кебек оясыннан ычкынып чыкты һәм өстә яткан бүрәнәнең башына барып тотынды. – Уфалар, нәрсә карап каттыгыз? Күтәреш! Бүрәнәләрне – ихата эченә!

Райкомнар белән бәйләнүдән коты чыккан «уфалардан» кайберәүләр,

уңын-сулын аңышып тормастан, бүрәнәләрне ихатага ташый да башладылар. «Чишмәләр» ягы да аптырап калмады, коймага дигән кирәк-ярак, корал-корамаларны чыгарып атырга тотынды:

– Чукынып китегез!

– Без сезне чакырып китермәдек!..

Төркемнәрнең берсе, пыр тузып, ихатага бүрәнә, икенчесе койма материалларын ихатадан тышка чыгарып аткарган чакта, үткәндә-сүткәндә бер-берсенә кагылып китеп, кул сугышына илтә торган этеш-төртеш китте. Бу төртеш нәрсә белән тәмамланган булыр иде, әгәр ихатага шул минутта каерылып төшкән бер ишеген доңгыр-доңгыр өстерәп, һава чыгарган ике тәгәрмәч тимере белән җирне сөреп, «Жигули» килеп кермәсә һәм аның кабинасыннан авызлары шатлыктан колакларына җиткән иркәй, хатынкай һәм ике ир балакай килеп чыкмаса! Хатын белән балалар, шунда ук бүрәнә астына мүк салудан туктап торган кызлар белән кочаклашып, күрешә башладылар.

– Гаяз абзый! – дип кычкырды руль артыннан чыккан ир йорт хуҗасына. – Ав-вар-рия!.. Ходай коткарды! «КамАЗ» астыннан диярлек исән чыктык, абзыкаем! Балалар исән, хатын исән, үзем исән!..

Һәм ул аю гәүдәле Гаяз абзыйсын курчак урынына кочаклап күтәрде, урынында әйләндерде, аннан төшерде, аннан тагын әйләндерде:

– Күрәм, синдә өмә! Йорт күтәрәсең, әйеме? Мине, бертуганыңны, чакырып та тормагансың, ә? Ярар, үпкәләмим. Хәерле сәгатьтә!

Бер өмәдән көтмәгәндә икегә әйләнгән өмә өмәчеләре авызларын ачып калганнар иде. Эш туктаган, сәгать йөрми иде.

– Сез нәрсә балталары суга төшкән кеше кебек каттыгыз! Менә мин сезгә берьюлы дүрт өмәче алып килдем, – дип, дәртле аваз салды кунак. – Әйдәгез, эшкә башлыйбыз. Өмә дәвам итә!..

Бу сүзләрдән соң өмәчеләрнең ике төркеменә дә ничектер оят булып китте. Безнең барыбызны да гарьлек биләп алды. Яшисе килеп китте. Сәгать йөри башлады. Ходай Тәгаләнең бүләккә биргән нинди матур көнендә алар шушы бәрәкәтне ямьсезләп яталар икән ләбаса. Өмәчеләр башта акрын гына кузгалыштылар, шуннан сиздерми генә станнары белән хәрәкәткә килделәр. Җирдә тырым-тырагай яткан балта-пычкы, чүкечләр, бергәлек тоеп, кулларга сикерде. Аннан барысы бер камытка җигелеп һәм илегеп эшли дә башладылар. Аларны, бу берсен-берсе бөтенләй дә белмичә дошманлашып өлгергән кешеләрне, шулай килештерү өчен йорт хуҗасы Гаязның моннан егерме чакрымда яшәгән энекәше Әгъзәм гаиләсенең Чишмәгә барганда авариягә эләгүе кирәк булганмы?!

Кызыл тәпичкәле халык контроле активистының без исемен дә хәтерләп өлгермәдек. Чөнки беренче бөек адымны ясаган кешеләр еш кына исемсез кала. Биредә дә шулай булып чыкты. Ул койрыгы шиңгән бөркет кыяфәте белән йорт хуҗасы Гаяз янына килде һәм, күзләрен челт-челт йомып:

– Ярар, булганы булган, – диде. – Булмаганы булмый торсын. Йорт белән бергә сиңа койма да кирәк бит инде, туган. Синең өмәчеләрең бураңны күтәрсен, минем өмәчеләрем авыл кырыендагы йортыңны коймалы итсен, ә? Министр килә бит, пон-нимаешь!.. Райком да исән, без дә тук!..

Гаяз елмаеп җибәрде.

– Әллә кайчан шулай диләр аны, – диде. – Тауга менүе кыен, аның каравы төшүе ансат. Өмә уртак булачак. Эше дә, кичке ашы да...

Без койманы дүрт сәгать дигәндә өлгерттек. Кешеләрне кешеләрдән аерырга

тиешле койма кешеләрне берләштерүче койма булып чыкты. Бүрәнәләрне күтәрергә икенче аркан да табылды. Тегеләргә ярдәм итеп, бураны бергәләп күтәреп бетердек. Кичен җырлаша-җырлаша мәҗлес кордык.

Өмәбезнең бу өлешендә «халык контроле» юк иде инде.

## Штабтан шалтыратмадылармы?

УЙМАК ХИКӘЯ

Бүген без Таллы Чишмә авылында Валериан абзыйны җирләдек. Үзе һәм ата-анасы сау-сәламәт чагында туган авылын, ата-анасын кайтып күрергә форсат тапмаган кардәшемнең үлеме – минем үз гомеремдә күргән иң үкенечле үлем булгандыр, мөгаен.

Без аны туганнары, авылдашлары, аңа иң якын булып, гомер биргән ата-анасы янәшәсенә күмдек.

Гамәлдә исә без аның җәсәден татар-мөселман зиратына кертмәскә тиеш идек. Халык исә аны, ыһ та итмичә, шәригать кануннарын бозып булса да, авыл мулласы тарафыннан ясин чыгарып, мөселманлыгыбызның башка барлык күңел һидаятьләрен, кадер-хөрмәтләрен күрсәтеп җирләде. Ул безнең өчен, ни дисәң дә, Чеховның Ванька Жуковы кебек, «шәһәрдән авылга бабайга» кайтып җирләнергә тиешле, шуңа «хокукы булган» авылдашыбыз иде...

Бар милләткә, аеруча яшьләребезгә гыйбрәт булган бу язмыш сәхифәсе, аларны бакча башларындагы карачкы кебек куркытып торырга тиеш. Ул нәкъ менә шушы тетрәткеч гыйбрәте белән онытылмаска тиеш тә инде.

Мин аны күреп белми идем. Бу тарихны соңгы сигез ел буена үз пинсәсенә тәрбияләп, керен юып, ашатып-эчертеп, җир куенына тапшырган бертуган сеңлесе София сөйләде. 1935 елда туган, нибары дүрт сыйныф күләмендә генә белеме булган Валериан абзый хәрби хезмәтен тутырганнан соң, ялланып, армиядә өстәмә хезмәткә кала. Андыйларны бездә ул заманнарда «макаронник» диләр иде. Спагетти гына түгел. Юанрагыннан тотын. Хәзер «контрактник» кына диләр.

Яхшы хезмәт итә ул. Әйтегез, кайсы татар начар хезмәт иткән? Башта СССР, аннан Рәсәй Федерациясе дигән сәер ил армиясендә рекорд куеп, бу макаронник кардәшебез, аз да түгел, күп тә түгел, кырык биш ел буе әрме сабанын сөйри. Хәрби плац аның өчен тукмачлык камыр тактасына әверелә. Аны армия казаны, казарма каптеркасы тирәсеннән трактор белән дә тартып чыгара алмагач, ахыр чиктә көч-хәл белән, бик зурлап озатуга ирешәләр. Аңардан котылган көн барлык армия масштабындагы бәйрәмгә тиңләшә яза. Мондый вазифадагы татарга хас саклык, пошаманлык һәм тырышлык күрсәтеп, иртән искән җилгә дә үрә катып, кырык биш еллык хезмәт чорында күкрәген елтыр значоклар белән тутырган бу чын мәгънәсендәге салдафон – старшина Валериан Мулаянов (әлбәттә, фамилиясе бер генә «л» белән, чөнки ике «л» белән яздырган хәлдә «мулла» килеп чыга!) кырык биш ел эчендә үзенең алдына тезелгән меңләгән «юеш борын»нан буыннарындагы сеңерләрне скрипка кылларыдай зеңләтеп, менә дигән «ватан сакчысы»н җитештерә; кырык биш ел эчендә старшина кулыннан сүгенү катыш кимендә кырык биш тонна кер вә исле сабын, кырык биш тонна эчке күлмәк-ыштан, кырык биш тонна тастымал, кырык биш тонна матрас һәм башка цейхгауз маллары үтә.

Ул, әлбәттә, үзен «дастуйный» күргән һәр «ваянный татар» кебек ак чәчле маржа – Маринага өйләнә. Аңардан Антон, Святослав, Елена атлы балалар табып үстерә. Әмма гомере гарнизоннан гарнизонга исраф ителеп, маржасы кайтмагач, балалары да папаларының туган авылы – Таллы Чишмәгә кайтмас була, үзе исә, яшь чагындарак кайткалаган булса да, соңгы егерме елда, бигрәк тә ата-анасы да үлеп киткәч, тынычланып алып, бөтенләй дә кайтмас була. Шунысы шаккатыра: култык төбендәге Курскида яшәп яткан старшинабыз хәтта ата-анасын да җирләргә «кайта алмый».

Ләкин Аллаһы Тәгалә аны туган авылы, онытылып беткән туганнары, ата-анасы белән көтмәгәндә һәм менә ничек очраштыра. Ул, әлеге дә баягы, Бәди әби таягы дигәндәй, тагын да шул көтмәгәндә җан шаукымы белән сырхап, алмашына башлый. Шизофрениянең агрессив булмаган, әмма медицинада «җиңел» дип бәяләнсә дә, тормышта бигүк җиңел булмаган формасы белән чирли милләттәшебез. Сырхавы, көчәйгәннән-көчәя барып, түземнәре беткәнгәме, әллә якыннарының аны тәрбияләргә теләмәүләреннәнме, хатыны белән балалары авыл хакимиятенә һәм исән калган бердәнбер сеңлесе Сафияга «Карый алмыйбыз, килеп алыгыз!» дигән аяктан егарлык хатлар, телеграммалар яудыралар. Кем барып алсын аны? Конверт сатып алырга акчасы булмаган авыл хакимиятеме? Әллә үзе җитмештән узып азапланган пенсионер Сафия әбиме? Аннан, шулай юл читенә чыгарып аударырлык нинди яман чир белән чирләгән соң аларның кемгәдер ир, кемнәргәдер ата булырга яраган авылдашлары?! Аннан, нигә барып алырга? Аның бит гаиләсе – дуп-дубрый хатыны, аның пенсиясенә трико-джинсы киеп, «мероприятиеләрдән» кайтып кермәгән балалары бар, алар... исән-саулар?!

Таңнардан бер таңнарда Сафия апа кулына җылы комган тотып, кече йомышы белән шул таңга ишек ачса, ата-инәләреннән калган таш тупсасында кулына төенчек тоткан Валериан абзыкае утыра. Чак-чак егылыплар китмәде. «Әйдүк, кара чәйнүк!» Әмма болай шаяртып тора диме, маржа калҗасы булса да, үз абзаң – кабул ит! Әле генә китереп киткәннәр, күрәсең. Тере гәүдәсеннән җылы бөркелә!.. Ахры, чирдән дә, чире белән бер уңайдан апасын күрүдән дә күзе тонган Валериан әллә ни аптырамастан: «Сынку... с дочерью... – диде сеңлесенең өзгәләнеп сораштыруларына биргән җавабында. – Со штаба... не звонили?»

Монысы нинди штаб тагын? Баксаң, аның чире дә шул «штаб» дигән нәмәрсәдән чыккан икән. Төенчегендәге маржасы язган сәлам хаты да, поликлиникада тутырыла торган «Сырхау тарихы» да шул «штаб»ка бәйле иде. Тамагына яхшы ашый-эчә торган, бер караганда, алсу йөзле, таза йөрешле абзыйсы авылдашлары һәм Сафияның үзе белән татарча сөйләшми, үзен чит-ят тота, һәр нәрсәгә шикләнеп карый, монысы ярый, монысына чыдарга була, иң авыры, читене, кыены шунда ки: тәүлекнең теләсә нинди вакытында өйдән чыгып китә, теләсә кая бара, зиратларга кадәр керә дә, үзенә очраган һәр кабер ташы, һәр куак, һәр түңгәләк, һәр җан иясе, һәр кешедән «Штабтан шалтыратмадылармы?» дип сорашып арый, хәлдән тая, өенә кайтып, сеңлесенә тагын да шул «Штабтан шалтыратмадылармы?» дигән соравын бирә дә урынына ава. Йокысы туйганчы гырлап йоклый да яңадан «штаб эзләргә» чыгып китә. Бу иң авыр чирләрдән дә авыр, аеруча кеше кайгысын кайгы итми торган халык күтәрә алмастай чир икән ул. Һәм бу сәер чир «армия агрессиясе», тагын да фәннирәк итеп әйткәндә, «милитарен психоз» дип атала икән. Алты ел буе коткарырга тырышты Сафия абыйсын

бу штаб агрессиясеннән. Кунак урынына тәрбияләде үзен. Аллаһ ризалыгы өчен. Буяткан чәчле җиңгәсеннән пинсәсен дә соратып азапланмады. Кайда гына, диде, «безнеке ни прапал». Тегеләр үзләре дә юлламады хәрби пенсия аттестатын, тазалыгын-саулыгын сорашып та азапланмадылар. Берсенең ире, өчесенең этиләре гүя таш кебек су төбенә чумды да югалды. Ә менә Сафия өчен абыйсы су асларына болай тиз генә чуммады. Ул аны үз җитәгендә алты ел буе табибларга йөртте. Өшкертте. Үлән сулары эчертте. Әмма абзасы дөнья кызырып «штабны» эзләүдән туктамады. Шулай бер тапкыр, таралган колхозның җимерек базлары тирәсендә эзләнгәндә, тирәнгә очып төшеп, бик каты имгәнде һәм урын өстенә ятты.

Сафия аны ике ел буе кулыннан ашатты-эчертте. Сеңлесе – татарча, абзасы – ватык-җимерек урыс телендә сөйләште. Әмма тел каршылыгы туганлыкка каршы тора алмады. Барыбер дә аңлаштылар. Сафия абзыйсын энҗе бөртеге кебек таза, астын-өстен, кием-салымын кәтрә дә керсез тотты. Рәхмәт төшкере. Бу чулпыларының тавышы яулык асларыннан – үрелгән чәчләреннән зеңгелдәп ишетелгән гади татар кызының Нобель премиясенә лаек батырлыгы түгелмени?

Менә миңа шушы җеназада катнашырга насыйп итте. Без Валериан абзыйны, әйткәнемчә, ата-анасы янәшәсенә куйдык. Муллабыз да, әйткәнемчә, җеназа йолаларын җиренә җиткереп башкарды. Каберенә куелган тактада фамилиясе ике «л» белән «Валериан Сәмигулла улы Муллаянов» дип язылган иде.

Зират капкасыннан чыкканда, безне ачы хатын-кыз четрәңе каршылады.

– Где мой папуля?! – дип өзгәләнә иде кырык яшьләр чамасындагы чәче-башы тузгыган хатынкай. – Я хочу видеть моего папочку!..

Ул аның төпчеге – моңа кадәр атасының туган авылын күрмәгән Еленасы иде.

Атасының җеназасына аны беркем чакырмаган иде.

Каны чакырган иде бу баланы.

Аңарда кан кычкырган иде.

Валериан абзый фаҗигасе буялган чәчләргә өйләнгән татар кешесе, бу очракта урыс армиясендәге татар әрмисе, татар әфисәре, татар макароннигы кичергән ничәнче фаҗига булды икән?

Меңенче?

Йөз меңенче?

Миллиончы?

Кайчан бетәр?

Бетәрме?

## Өязе

НӘСЕР

Өязем!

Язым!

Назым!

Үзәгем үзәкләреннән өзелеп төшкән тальян моңым! Бәгърем бәгырьләреннән сызылып чыккан курай моңым! Ай нурыннан каелган якты юлым, бавырымнан савылган кайнар каным! Мин синдә язлар саен торналарымны һәм кыр

казларымны каршыладым, күзләр саен озатып калдым. Басуларыңда җир сөрдем, иген иктем. Болыннарыңда мал көттем, киерелеп печәннәр чаптым. Урманнарыңда түмәр умартага дип юан агачлар аудардым. Тау сәндерәләреңдә тәгәрәтә-тәгәрәтә кыярлар, кавын-карбызлар үстердем. Мин синең текә ярларыңда ат уйнаттым. Кызлар сөйдем. Кайчандыр, моннан утыз-кырык ел элек:

Өязекәй! Илкәй! Нечкә билкәй!
Бөгәлләрең көләч бөгелә.
Дулкыннарың минем йөрәгемнең
Алтын алмасыннан түгелә, –

дип язган идем. Хак икән. Түгелде. Түгеләчәк. Түгелсен иде. Амин!..

Әйе, сине, синең яр буйларында яшәгән халыкларны яратмау мөмкин түгел.

Көньяк Уралның мәгърур күкрәгеннән бәреп чыгып, үлемсез җырларыңны җырлый-җырлый, чуваш Өязебашыннан дистәләгән татар авыллары аша Аюлы Кул, Мендәрле Кул, Салкын Чишмә, Кәркәле, Тукмак, Җилдәр кебек дистәләгән атаклы чишмәләр белән кодрәтләнеп, бәрәкәтле тупрагыңны моңга сугара-сугара агасың-агасың да якты дулкыннарыңны Азнай, Исламгол кебек башкорт авыллары арасында шундый ук шагыйранә Дим елгасына китереп коясың.

Синең дулкыннарыңда мәчет манараларыңның Ярымайлары чайкала.

Җир шары чиксез, анда матурлыклар бихисап. Әмма мондагыдай көмеш сулар, көмеш тамчылы таллар, меңьяшәр өянкеләр беркайда да юк. Мондагыдай итеп, уң тарафтан татар «Әлифба»сыдай ак, якты ташлары белән суга ишелеп төшкән тау тезмәләре, яфракларына, чәчкә күзләүләренә сары бал яккан болынлык-урманнар, сул тарафтан, мондагыдай итеп, елга ярларына шуышып төшеп ялганган киң күкрәкле басулар-иңкүлекләр, кап уртада – алтмыш-җитмеш чакрымнарга сузылган үзән-әрәмәлекләрдә ак күбек булып кайнаган баланлык-шомыртлыклар, гөлчәчкәләр арасыннан гына аккан мондый алкыннар башка беркайда да юк. Әнә, бөдрә таллар сыман дулкын-дулкын килеп, вак мал үлән чемчи, кояш нурларында ала-кола төсләрдә елкылдап сыер көтүләре үлән кертләтә, тулы янбашларын уйната-уйната, елкы табырлары сутлы үлән утлый... Биредә чут та чут килеп сандугачлар сайрый, кыз-кыркын туй мәҗлесләренә колмак, җиләк-җимеш хәстәрли, малай-шалай, җегет-җилән, тән-иман ныгытып, текә ярлардан түбәнгә, дулкыннарга сикерә, балыклар исә, шушы ярларда гомер кичергән шигъри таллык-болынлыкларны, горур халыкларны, аларның балаларын – ил өчен утка керүдән дә курыкмаган батыр җегетләрне, гүзәл кызларны күреп калырга тырышкандай, гөп тә гөп су өсләрендә сикерешә...

Өязем, торналарым һәм кыр казларымның назлы төяге – Өязем!..

Мондый матурлык адәм баласына илаһи зурлык өләшә, ул гүя ашамый торып та илаһи туклык кичерә. Биредә олпат өянкеләр йон эрләп утырган йөзьяшәр Ак Әбиләргә, билләреннән корт күче сарган Ак Бабайларга охшаган. Гүя бу көмеш өянкеләр, каба төбендә утырган апалар сымак, күктәге ак болытларны йон көнҗәләсе итеп кәүсәләренә бәйләгәннәр дә нәсел җебе эрлиләр. Тарих тукымасын тукыйлар. Гүя бу өянкеләр, нәкъ шул умартачы бабайлар кебек, челтәрле битлек киеп алганнар да, бал кортларының көмеш өермәсе эчендә умарта карыйлар...

Күп тә үтми, бу өянкеләр әле генә мунчадан чыккан, аклы-кызгылт иген

бөртегенә охшап, сука артында җир сөргән агайлар, сабан артыннан сөтле пар күтәрелгән кара туфракка итәкләреннән тук орлыклар сипкән яшел камзуллы җиңгәчиләрне хәтерләтә башлый. Алар вакытсыз картаймый, вакытсыз үлми. Әрләш-талаш, үзара гауга-низагның ни икәнлеген дә белми гомер кичкән бу затлар Аллаһның имин хозурында йөз яшьтән дә озаграк яшиләр...

Кем дә кем җиде төс белән балкынган Өязе таңнарын күрмәгән, шул чын сөю газабын татымагандыр кебек. Кем дә кем Өязе шәфәкъләредәй кичке-таң шәфәкъләрне күрмәгән, шул чын югалтулар фаҗигасен кичермәгәндер кебек. Кем Өязе буйларында булмаган, шул җир йөзендәге иң эчкерсез, иң тырыш, иң шаян-наян, иң моңлы, иң шагыйранә халыкны күрмәгәндер кебек. Шуңа күрә, Өязе-Дим үзәннәрен«Шагыйрьләр үзәнлеге» дип атыйлар. Халыкның акылын, моңын-талантын, әдәп-сызатын, холкын-фигылен, димәк, шигъри-мәдәни җегәрен, ул эчкән суның сыйфаты билгели, диләр. Өязе суларында үзебезнең татар Менделеев абзабыз ачкан элементлар системасындагы барлык асыл матдә-мәгъдәннәр дә бар. Җидегән, Кәркәлетамак, Качаган, Ишле, Баязит, Җилдәр, Шатман, Сатый һәм башка татар авылларының чишмәләреннән көч-куәт алган Өязе алкыннарындагы алтыннан халыкка камил акыл, ак көмештән хиссият-шигърият, терекөмештән тере шаянлык иңгән. Андагы җиз аһәңнәрдән кара көнчелек китеп, алар урынына матурлык яратылган, очсыз бакырлыктан бахырлык китеп, аның урынына батырлык килгән. Бу сулар картайган саен яшәртә, җан газапларын йомшарта белә. Шушы сыйфатлар татарны халык итеп саклаган һәм бүген дә саклый. Сакласын иде, амин!..

Кайларда гына булсам да, нинди генә җирләр күрсәм дә, нинди генә сулар эчсәм дә, синдәгедәй матур җирләрне күрмәдем, синдәгедәй тәмле суларны эчмәдем, Өязем!.. Синең көмеш бугазыңнан дастаннар агылган. Телеңнән алтынга тиң җыр-шигырь өзелеп төшкән. Синдәге иман кан тамырлары булып улларыңның һәм кызларыңның уч төпләренә бүрткән. Синең ярларыңдагы катламнарда борынгы һун, сармат, кыпчак, болгар-татар бабаларыбызның авыр, әмма каһармани тарихлары, бабаларыбыз балаларының бүгенге сынаулы әхвәлләре сурәтләнгән. Шуңа күрә дә синдә Канзәфәр би, Әкри батырлар, җырчы Акмуллалар үсеп чыккан һәм чыга тора. Әнә, көнбатыштан һәм көнчыгыштан килгән тышкы һәм эчке дошманнардан сине яклау өчен тау араларыңнан рәт-рәт булып улларыңның гаскәри урманы агыла, Өязем!.. Әнә, ерак офыкларга аккан үзәннәрең буйлап сине саклау өчен, бер-берсенә аркага-арка ишелеп, өянкеләреңнең горур явы килә, Өязем!.. Әнә, улларыңның яраларын бәйләү өчен, үзәннәреңнең бер очыннан икенче очына, ак халатлы ашыгыч ярдәм туташлары кебек, ак күбектә кайнап, Ак Баланнарың, Ак Шомыртларың йөгерә, Өязем!..

Баш очымда тракторларың гөрләсен, атларың кешнәсен, сыерларың мөгрәсен, кәҗә-сарыкларың бәэлдәсен иде!

Үләсе килми! Яшисе килә! Яшисем килә, минем Өязем!..

Иген башагыңның бишек-биләвендә яткан һәр бөртегең – синең, минем, аның сабые ул, Өязем!..

Юк, без үлемсез! Нишләп без үләргә тиеш? Без үлемсезләр кавеменнән ул, Өязем!..



Рәсимә
Гарифуллина

# МИНЕМ КҮҢЕЛЕМДӘ ЯҢА ЯЗ

## Язмышлар язылган

Язмышны берәү дә сайламый,
Авырмы-җиңелме – язылган.
Гомерләр юлында өлешкә
Алтыны, көмеше табылган.

Гомерне бизмәннәр үлчәми –
Һәркемнең вакыты билгеле.
Туасы сәгате сугылган,
Тәкъдирдә буласы билгеле.

Язмышлар язылган сәгатьтә
Гомернең бөресе ачыла.
Без кочак җәябез бәхеткә,
Ул килә, елмаеп каршыга.

Яшь чакта, көч-куәт барында,
Хыяллар канаты талпына.
Җиһанны кочарга әзербез
Алдагы максатлар хакына.

Бу тормыш юлында сикәлтә,
Киртәләр сагалый җитәрлек.
Бер йөрәк кичергән барсын да,
Барласаң – исләрең китәрлек.

Гомерләр йомгагын сүткәндә,
Күкләрне айкарлык көч булган.
Янымда акыллы сердәшем –
Канатлар пар булган, нык булган.

...Язмышны берәү дә сайламый,
Авырмы-җиңелме – язылган.

---

Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА – *шагыйрә; «Минем куллар – синең кулда», «Йолдызлар юл күрсәтер», «Зәңгәр дуга» һ.б. китаплар авторы.Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Балык Бистәсендә яши.*

## Сорау-җавап

– Күңелдән дә тирән,
Күңелдән дә сизгер
Ниләр бар?

– Барсын да аңлаучы,
Сереңне тыңлаучы
Якыннар.

– Кылычтан да үткен,
Шикәрдән дә татлы
Ниләр бар?

– Кылычтан да үткен,
Шикәрдән дә татлы
Телләр бар.

– Бик авыр булса да,
Кемнәр ул зарланмый
Түзгәннәр?

– Кояштан да нурлы,
Сабырның сабыры –
Әнкәйләр.

– Яхшысын-яманын
Кичереп яшәүче
Кемнәр бар?

– Хәтерләр калса да,
Сабырлар сынса да,
Кичерә белүче
Туганнар.

## Хатын-кыз

Тормышта ни генә эшләмәс,
Алиһә – хатын-кыз дигәнең.
Күз сирпеп карар да сихерләп
Каратыр үзенә сөйгәнен.

Барсын да булдыра, кыю зат,
Хәйләкәр – хатын-кыз дигәнең.
Кирәксә елый да, көлә дә...
Барыбер эшли үз дигәнен.

Тәвәккәл дә үзе, зирәк тә,
Сабыр да хатын-кыз дигәнең.
Эчендә гарасат булса да,
Белдерми янганын-көйгәнен.

Утларга керер ул, кирәксә,
Фидакарь – хатын-кыз дигәнең.
Серенең зерлеге – йөрәктә,
Яшерер, сиздермәс белгәнен.

Яратса, ихластан яратыр,
Тугры зат – хатын-кыз дигәнең.
Юлбарыс шикелле ташланыр,
Кирәксә якларга сөйгәнен.

## Чагыштыру

Кыш аеның карлы-бураннары
Ятып елый көртләр сыртына.
Ни сорыйдыр җирдән, ни көтәдер,
Зәһәреннән йөрәк йолкына.

Китмәс өчен тартышадыр бу кыш,
Язга бил бирмәскә телидер.
«Килүләр бар җиргә, китүләр бар»,
Бу кыйтганы, бәлки, белмидер.

Февраль бураннары тукталыр да,
Кояш көлер, якты яз килер.
Кышын өйгән көртләр елга булып,
Күз яшьләре кебек түгелер.

Гөрли-гөрли гөрләвекләр агар,
Тыпыр-тыпыр тамар тамчылар.

Җиңел сулап калыр урамнар,
Җылы тунын салыр юлчылар.

Әй, үзгәрер җиһан, дөнья буйлап
Былбыл җыры китәр моң булып.
Бик яшисе килә бу тормышта
Гел янәшә, сиңа тиң булып,
Син яраткан матур җыр булып.

Мәңгелеккә китеп югалдың да,
Сагынудан җаным йолкына.
Җилләр түгел, минем йөрәк елый,
Ятып елый көртләр сыртына.

## Кабыну

Ничә язлар үтте, ничә җәйләр,
Юк идең бит, ничек табылдың?
Яшьлектәге кебек канат үсте,
Яшь чактагы кебек кабындым.

Ике битем яна, очам гына,
Әйтерсең лә аккош күкләрдә.
Бәхетме бу? Әмма мондый бәхет
Үлеп терелү күк күпләргә.

Мин яңадан: «Яратам», – дим сиңа.
«Яратам», – дип дәшә кайтаваз.
Табигатьтә генә кайтса да яз,
Минем күңелемдә яңа яз.

Тән күзәнәкләрем яшәгән күк
Хисләрем дә исән икән лә.
Алар бары бер карашны гына,
Синең назны гына көткәннәр.

Бер очкын да җитә тергезергә.
Кузлап торган учак кабына.
Сөюең чын булса йөрәгеңдә,
Яшәр өчен көчең табыла.

Шушы көчкә буйсынасы килә,
Терәк итеп синең иңнәрне.
И мәхәббәт, назлы иркәң белән
Уяттың син тагын кемнәрне?

Ничә генә язлар, җәйләр үтсен,
Күңел югалтканын эзли гел.
Көйрәп торган учак төсле йөрәк,
Бер очкын да җитә, шуны бел!



Галимҗан
Гыйльманов

# ХИКӘЯЛӘР

### Замана баласы

Ул кыз автобуска килеп керүгә, бөтен халык калкынып куйды. Урыннарыннан торып, үрелеп караучылар да табылды.

Болытлы көндә күк йөзендә пәйда булган кояш кебек иде ул. Ә кояш, мәгълүм булганча, яктыртып, җылытып кына калмыйча, күзләрне дә чагылдыра, миләрне, каннарны да кыздырып җибәрә.

Бу юлы да шулай булды.

Кояшлы көннән балкып килеп кергән кыз ягына, сокланулы карашлар белән бергә, ямьсез, мәнсез сүзләр очты. Автобус салонын тутырып утырган әби халкы, тел чарларга җай чыгуына куанып, замана баласына ябырылды:

– Кара инде моны, ә, тәмам чишенеп беткән бит! Адәм мәсхәрәсе!

– Ботын-ботка чалып торуын әйт син... Тьфу, анасы тапмагандыр, Иблис төкергәндер моны!..

– Кара-кара! Изүен ничек ачкан... Оятсыз! Ирләрне бозып йөрүчеләр шулар инде, ахирәткәем. Әнә, ныклап карап кал, синең Әүхәдиеңне дә шулар юлдан яздыргандыр әле...

– Дөмеккере! Ничек карап тора бит, юньсез!..

– Әйтмә дә генә... Бозылулары җитте яшьләрнең... Йә, болардан нинди игелек күрмәк кирәк?! Игелек кылу түгел, чәчләрен дә тарап үрә белмиләр бит алар...

Кыз бу сүзләрне ишетмәмешкә сабышты. Әбиләр шау-шуы бераз басыла төшкәч кенә, салон түренә борылып, йөз-битләрен җыерды да:

– Ыр-р-р! – дип, үртәп куйды.

Бигрәкләр дә кыска иде шул кызыйның итәкләре! Бигрәкләр дә ачык иде шул аның күкрәк-шәрәфләре! Бигрәкләр дә чибәр, мәхәббәтле иде шул ул! Ачык, якты йөзенең, җилбәгәй чәчләренең, кыйгач кашларының, аяз күк төсендәге күзләренең, чиядәй тулышкан иреннәренең, бит очындагы «мәхәббәт

---

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ (1957) – *прозаик, шагыйрь, әдәбият белгече; «Тозлы яңгыр», «Албастылар», «Оча торган кешеләр», «Тәкъдиргә юл», тагын ике дистәдән артык китап авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. А.Алиш һәм Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

чокырлары»ның автобус салонындагы тиргешле, каргышлы дөнья белән бернинди уртаклыгы да юк иде...

Әйе, күңел сискәнерлек, йөрәк җилкенерлек дәрәҗәдә яшь, ымсындыргыч иде бу кызый. Күпләрдән аермалы буларак, мин аны яратып каршы алдым, яратып озатып калдым... Чөнки мин бу кызны яхшы белә идем.

Ул ике ел инде ялгыз бер әбине карый. Төгәл генә әйтә алмыйм – әбисеме ул аның, берәр туганымы, әллә аңа бөтенләй чит-ят кешеме? Көн саен, кайткан уңайга, кибетләрдән ризык җыеп кереп, шул түшәк иясен бөртекләп карап, астын-өстен алыштырып, тамагын туйдырып, юындырып-киендереп чыга.

Беләм, килбәтсез генә төенчеген күтәреп, бүген дә шул авыру әбекәй янына чыгып китте ул. Күпме пычрак, әшәке сүз ягылып калды аның яшь, саф һәм мәхәббәтле җанына! Күпме нахак рәнҗеш һәм әрнеш белән китте ул гомеренең ахырын яшәп ятучы, үз янына кергән һәр игелекле җанны изге бер фәрештәгә тиңләп көтүче Хода бәндәсе янына.

Бу кыска итәкле, күзләрне чагылдырырлык ачык түшле кызның изге юлда йөрүе хакында тагын белүче булгандырмы, юкмы, төгәл генә әйтә алмыйм. Булгандыр да, чөнки бу хәлне якын-тирәдә күпләр белә иде. Ләкин алар да, мин дә кызны яклап бер сүз эндәшмәдек. Шуның белән үзебезгә гомерлек борчу һәм авырлык алдык.

Без ничек тә түздек. Кеше күңеле түзем бит ул. Ә менә Кояш ничек түзде икән бу гамьсезлеккә? Бу нахак рәнҗешкә ничек түзде икән? Әнә бит ул һаман елмая, көлә, гүя дөньяда бер генә борчу да, бер генә рәнҗеш тә калмаган кебек...

### Әдәбият һәм хастаханә

Мин ул якташымны вокзал ишеге төбендә очраттым.

– Слушай, парин, мин синең китабыңны укып чыктым. Ну язып та карыйсың мәгәр... Албасты карчыкларың белән чистый хыялый иттең, понимаешь!.. Шәп-шәп... Күп нәрсәгә башкача карый башладым... Согласен, серләр күп әле безнең дөньяда...

Авыл кешеләре юл чатында очрашмый кайда очрашсын инде?! Икенчесендә дә шул ук вокзал буенда каршыма килеп басты:

– Слушай, парин, бик кызык иттем бит әле дөньясын... Беләсеңме нәрсә эшләдем? Ни за что белмисең! Гомеремдә беренче мәртәбә хәйләләштем. Ату һич вакыт юк, понимаешь!.. Әле менә бу китабыңны сатып алдым да, вакыт табалмыйча, бер атна кулда әвәләп йөргәч, таныш врачыма әйттем: »Әйдә, авырыйм әле берәр атна, менә шушы китапны укып бетергәнче генә...» – дидем. Кая барсын, койка бүлеп бирде. Ашамый-эчми, йокламый-нитми, тын да алмыйча бер атна буе укыдым. Ну, парин, язып та карыйсың түлке... Ышанырга да, ышанмаска да белгән юк... Ә син беләсеңме нинди татлы бу тойгы – ышаныргамы, ышанмаскамы?..

Өченче күргәндә мин аны бөтенләй танымадым. Тәмам бетәшкән, ябыгып, кечерәеп калган...

– Нәрсә булды? – дип сорыйм.

Дәшми. Мышнап тик тора. Танымаган булып кылана хәтта.

Кабатлап сорыйм:

– Ни булды? Ник дәшмисең? – дим.

– Кит моннан!.. Тукта, парин, синме бу?

– Мин бу, мин. Танымыйсыңмы әллә?
– Таныйм да, танымыйм да.
– Ничек инде алай?
– Мин, парин, үземне дә танымыйм хәзер... Тәмам хыялыйланып беттем бугай... Точно! Тиле мин хәзер...
Ах-ух килеп, якташым үзенең тарихын сөйләргә кереште.
– Шул синең сихерле китапларың аркасында инде. Хыялый әсәрләреңне укып җиңеләя яздым бит мин, понимаешь... Әйтеп тә ышанмассың, бервакыт йокым качты, аннары, дивана бәндә кебек, үземне белештермичә, өйдән чыгып китә башладым. Урманнарда, кырларда кунып калган чаклар да булды. Хатын шикләнә башлады. Нәрсә генә эшләмәдем. Эчүне ташлап карадым. Булышмады. Эчеп тә карадым. Глухо! Бөтенләй ычкына яздым. Аракы шаукымыннан да хәтәррәк булып чыкты бу сихер дигәннәре... Менә әле больницага барышым... Ятып дәваланып карарга исәп... Ничек уйлыйсың – булышыр микән?
Шактый киткәч, кабат әйләнеп килгән. Хәлсез, боек йөзендә шул арада якты-нурлы чалымнар пәйда булган. Үзе кыенсынып кына сораган була:
– Тагын берәр язган әйбереӊ юкмы, парин? Булса, больницага китереп кит әле...

## Көмеш аеллы бүрек вакыйгасы

Ул көнне мин каядыр ашыга идем. Әйбәт җиргәдер. Чөнки иң затлы бүрегемне киеп чыккан идем. Яңа өелгән купшы кибән кебек күпереп торган ул бүрегемне мин ел буе акча җыеп алдым. Бер хикмәте дә бар: бауларын бер-берсенә эләктереп кую өчен аңа кечкенә көмеш аел тагылган иде...
Барам шулай көяз генә атлап. «Бүрегемне күрәләрме?» – дип як-ягыма каранып барам. Юк, мин бара торган аллеяда ник бер җан әсәре күренсен! Әле караңгы да төшеп җитмәгән югыйсә, кая качып беткәндер бу халык?!
Ә! Суык! Шуңадыр. Минем генә шәп бүрегем булгач та... Мин генә ул... Бүрек якаларын төшереп, көмеш аелны чыкылдатып эләктереп куям да... җилдерәм генә!
Туктале! Җилдерми генә тор... Артымнан куып җиткән ул бәндә кисәген ничек кенә күрми калдым соң әле? Мин исемә-акылыма килгәнче, бу бәндә башымдагы затлы бүрекне йолкып-тартып алды да кирегә йөгерде...
Алай тиз генә алмый торсын әле! Бу бүрек өчен тиккә генә ел буе акча җыйдыммыни мин?! Шулай тиз генә колак кагар өчен көмеш аеллысын сайладыммыни?! Ишь ты! Тоттырырмын мин сиңа!
Ачуым чыгып та бетте, бүрек бурының артыннан куып та киттем, атылып килеп, җилкәсенә барып таябыштым... Шулай бер-беребезгә ябышкан килеш кар өстенә тәгәрәдек. Әүмәкләшеп тәгәрәп йөрибез кышкы бакча буйлап: башлар ялангач, киемнәр тузган, чәчләр карга укмашып каткан...
Беренче булып мин айныдым. Айнуым булды, арабызда кысылып, бәргәләнеп йөргән бүрекне эләктереп тә алдым. Кулга бүрек кергәч, теге бәндәдән ычкынып, трамвай тукталышы калган якты урам ягына йөгерерлек көч табу кыен булмады... Ничек барып җитеп, йөгереп барган көйгә, ачык ишектән трамвай эченә ничек атылып керүем истә дә калмаган. Шул гына хәтердә: берзаман трамвайдагы халык миңа әйләнеп-әйләнеп, үрелеп-үрелеп

карый башламасынмы... Кемдер, хәлемә кергәндәй, ихлас көлемсерәп куя, кемдер, шикләнеп, читкә тайпыла...

Бу сәерлекнең сәбәбен кайткач кына ачыкладым: ул көнне мин ике бүрек алып кайтканмын икән бит! Үземнеке арткы якта эленеп тора, көмеш аелы нык булган, күрәсең, ә каракның минеке кебек үк затлы бүреге кәперәеп башымда утыра! Күземә күренәме дип, кат-кат тотып карадым – нәкъ минеке кебек, хәтта аелы да саф көмештән эшләнгән!

## Хат кыйссасы

Бүген беркемнән дә хат көтми идем. Шулай да, компьютерым артына утырып, электрон почтаны карап алырга булдым. Гадәткә кергән эш кенә иде бу...

Һәм менә Ходайның рәхмәте – миңа кемнәндер хат килгән! Ачам, укыйм: «Мин Сезнең иҗатыгызны күптән күзәтеп киләм. Үзегез белән дә еш очрашам. Кемлегемне белергә тырышмагыз. Барыбер белә алмаячаксыз. Мин Сезнең белән танышу өчен язмыйм. Киңәш сорап язам. Сез бит күңел язучысы, җан белгече, кеше күңеленең иң нечкә җирләренә дә кагыла беләсез, геройларыгыз исә үз бәхетләрен тоеп, һич югы аңа омтылып яши... Күп очракта алар үз бәхетләрен табалар, үз теләкләренә ирешәләр дә...

Минем дә бик бәхетле буласым килә. Тормышның чын бәхетенә ирешәсем килә. Ләкин сез, бу хатын бәхеттән бөтенләй мәхрүм калган икән, дип уйламагыз. Һич алай түгел! Мин – беренче мәхәббәт шатлыгын да, бала бәхетен дә тулысынча татыган кеше. Ләкин тормыш бәхете бөтенләй башка икән ул. Яшәү яменнән, яшәү гаменнән тәм табып, һәр яңа көн өчен сөенеп яшәү икән ул... Мин андый бәхетне дә беләм... Беләм кебек... Әмма шул бәхетемне югалта баруымны тоям... Бүген минем аяк астында җир убыла, баш өстендә кояш тоныклана...

Сәбәбен сорыйсың инде («син» дип яза башлавыма ачуланма, минем болай сөйләшергә хокукым бар, гомер буе аралашып яшибез ләса!). Сәбәбе бик баналь – ирем яратмый башлады...»

Бик серле хат булып чыкты бу. Тирән уйларга салды ул мине. Уйланмаслык та түгел иде шул: Кеше язмышын хәл итә торган хәлләр хакында яза минем «иске-яңа» (кем соң ул?) танышым. Әлләни аптырамас та идем, иң гаҗәбе – минем өйдә дә шул ук хәл... Аптырап беттем: кайчандыр сөеп-яраткан күңелем хатынымны ятсына башлады, соңгы вакытта хәләлем үзе дә миңа «ах» итеп тормый... Яшьрәк чакта ай-һай тәмле телле, нечкә күңелле иде ул минем. Бер матур сүз әйтеп җибәрсә, минем түбәм күккә тия иде, җаныма ныклык, йөрәгемә ышаныч, тәнемә егәрлек иңә иде... Соңгы вакытта җанга май булып ята торган матур сүзләрен әйтми башлады хатыным. Ул әйтмәгәч, мин дә аның каршында бик егылып китмим...

Нәкъ шул турыда яздым хат авторына – минем алда үз язмышын ачып салырга батырчылык иткән хатынкайга башкача җавап язарга мөмкин дә түгел иде...

«Син тормышыңның сәбәбен ireңнән эзләмә. Иң элек үз күңелеңне җилгә кагып кара. Исеңә төшер: ничек каршылыйсың син аны? Ничек озатасың? Әйтмәсәң дә беләм: эштән кайтканда каш җыерып каршы аласың, эшкә киткәндә эчке бүлмәдә дус хатының белән телефоннан гәп сатып каласың...

Шулаймы? Шулай-шулай, белеп торам. Нидер булган синең күңелеңә. Тормыш ваклыклары басып киткән аны, гайрәтне чигәрерлек бертөслелек ялкыткан, җитмәсә, дус хатыннарың да үзләренең ялгыз, әмма мәхәббәт тарихларына бай тормышлары белән кызыктырып торалар... Менә әйт әле: кайчан соңгы мәртәбә иреңә: «Матурым», – дип эндәштең? Кайчан аны юктан гына да мактап алдың, үсендереп куйдың?»

Җавап озак килми торды. Рәнҗеттем ахры, калган өметен дә сүндердем, дип уйладым. Аннары бу сәер тарихка бөтенләй кул селтәдем. Юкка да ышанып китәсең, белмәгән-күрмәгән кеше сүзен күңелеңә якын аласың, дип, үз-үземне битәрләп бетердем... Бераздан тәмам оныттым мин бу сәер хат хакында. Ник дисәң, үз тормышымда бөтен булган борчуларны оныттырырлык хәлләр башланып китте...

Беркөнне эштән кайтып керсәм, хатыным нурлы елмаеп ишекне ачты да, яшьлегебездәге кебек, назлы куллары белән муеныма сарылды. Баштарак каушап калсам да, бик тиз аңыма килеп, аны күтәреп үк алдым, җиңел, җыйнак гәүдәсен кочагыма кыстым...

«Ай, син нинди көчле! – диде ул. – Баһадирым минем!» Аннары яшьлек дәртен исенә төшерә башлаган тәнемә сарылды...

Кинәт кенә барысы да үз урынына кайтты. Без тагын матур гына торып киттек. Элеккеге тиле мәхәббәт инде булмаса да, күңелләребездә кабат уянган җылы, изге хисләрне «өф» итеп кенә тотып, саклап-кадерләп яши башладык...

Мин теге сәер хат хакында оныткан идем инде. Бердәнбер көнне почтама тагын бер хат килеп керде. Мин аны шундук танып алдым: «Теге танышымнан бит бу!»

«Рәхмәт Сиңа барысы өчен дә! – дип, күптәнге танышына мөрәҗәгать иткән кебек язган ул бу хатын. – Син миңа матур киңәш бирдең. Мин нәкъ шулай эшләдем. Чыннан да син хаклы булып чыктың. Беләсеңме, мин бит кайчандыр күңелемдә бөреләнә башлап та, чәчәк атканчы сүрелгән бәхетемне кабат яңарттым. Мин бүген шундый бәхетле! Ирем дә бәхетле – мин моны сизеп, тоеп торам. Рәхмәт Сиңа! Инде соңгы үтенечемне дә кире какма, зинһар! Синең белән күрешәсем килә. Күзләреңә карап, ихлас рәхмәтемне белдерәсем килә! Бүген кич «Бәхетле» кафесына килә алмассыңмы? Син мине шундук танып алачаксың, борчылма... Көтәм».

Мин риза булдым. Рәхмәт ишетәсе килүдән түгел. Киресенчә, бу серле танышыма үземнең дә рәхмәт әйтәсем килде. Аның белән хат язышканнан соң әйбәтләнеп китте минем тормышым! Үземнең дә шатлыгым күңелдән ташып-түгелеп тора. Шул шатлыгым белән уртаклашыр өчен хатынымны да үзем белән алырга булдым. Тик бу көнне аның каядыр барасы бар икән. Хәләлем, йомшак, мәхәббәтле куллары белән муеныма сарылып, битем очыннан үбеп, очып диярлек чыгып киткәч, бераз ямансулап тордым да өебездән ерак түгел генә урнашкан «Бәхетле» кафесына юнәлдем. Юл уңаеннан чәчәк кибетенә кереп, күпереп торган ак чәчәк бәйләме алдым. Хатыным нәкъ шундый чәчәкләрне ярата бит. Ул яраткач, бу чәчәкләрне башкалар да яратадыр кебек тоелды миңа. Татлы чәчәк исенә исереп, ничек барып җитүемне сизми дә калдым. Бераз ис-акылымны җыеп, фикерләремне туплап торганнан соң, ымсындырып чакырган кебек, үзе ачылып-ябылып торган хикмәтле ишеккә кереп чумдым...

Хат иясен мин бик тиз танып алдым. Иң түрдә урнашкан өстәл артында, кочагымда сыяр-сыймас булып күпереп торган чәчәкләр кебек үк күркәм

гөлбәйләм тотып, иксез-чиксез бәхете елмаюлы карашларында, тән хәрәкәтләрендә, җан сулышында, бөтен язмышында чагылган хәләл хатыным утыра иде...

## Әбием хикәясе

Сугыш башлануга, авылыбызга читтән бер гаилә кайтып төште. Гаилә башлыгы – сугышка ярамаган Чулак Сафый дигән бер Украина татары. Хатыны исә холкы беләнме, безнеңчә аңламагангамы, аз сүзле, салмак кына йөрүчән украинка иде. Үзләре белән берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала ияртканнәр.

Ташландык бер өйгә урнашып яши башладылар болар. Сафый бик тә уңган кеше булып чыкты – хәленнән килгән, көче җиткән барлык эшне дә эшләде – фермада мал карады, көтү көтте, ашлык сукты. Өенә кайтса да – йокларга гына. Яисә үзләре үстереп җибәргән яшелчә бакчасында казынырга.

Килүләренә бер-ике ай үтмәгәндер, тирә-юньдә Сафыйлар хакында белмәгән кеше юк иде инде. Бик саран кешеләр иде алар. Ике ел яшәп, ике ел буе байлык җыйдылар. Эш көненә тигән ашлыкларын да сатып җибәргәннәр дип сөйләде хәтта халык. Бар булган киемнәрен, өй җиһазларын да талчукка илтеп бетерделәр. Бакчаларында күкрәп уңган кыяр-помидорларны да авыз итмәделәр бугай алар. Һаман-һаман базарга чыгардылар...

Сафыйның сөяккә калган балаларын кызганып, авыл кешеләре, очраган саен, аларга берәр кыерчык икмәк биргәлиләр иде. Колхоз, мәктәп җитәкчеләре Сафыйны берничә тапкыр идарәгә дә чакыртып сөйләшкәннәр, ди...

Бердәнбер көнне Сафый авырып китте. Ферма юлында хәлсезләнеп егылып яткан килеш тапканнар. Әмма ул икенче көнне үк тагын эшкә чыкты.

Инде бөтенләй эшкә ярамый башлагач, Сафый чүпрәк-чапрак, тимер-томыр, сөяк, көл җыю эшенә тотынды. Шулай ул ике ел буе акча туплады.

Баштарак сугыш дөрләгән яклардан кайткан бу гаиләне авыл халкы ачык йөз белән каршы алса да, соңыннан алардан бизде. Кешеләрне Сафыйның комсызлыгы, саранлыгы читләштереп бетерде. Сафый берара юкка чыгып торгач, «әллә бу хатынын, балаларын ташлап, акчасы-ние белән читкә качтымы» диючеләр дә булды. Кабат авылда пәйда булган Сафыйны кешеләр таный да алмадылар: беренче тапкыр ул елмаеп йөри башлады.

Сугыш бетәргә аз гына калгач, Сафый дөнья куйды. «Ач яшәде, үзен-үзе һәлак итте», – дип сөйләнде халык. Бер-ике авыл картыннан башка аның каберенә баручы да булмаган, диләр. Сафыйның хатыны да күп тормады – балаларын ияртеп үз туган якларына кайтып китте.

Инде сугыш тәмамлангач, авылга каяндыр пөхтә киенгән хәрби кеше килеп төште. Танкист. Күкрәге орден-медаль белән тулы бу кеше Сафыйны эзли иде. Халык сагаеп калды. Шулай да, кунакны зиратка алып барырга булдылар.

Кич зур җыелыш җыелды. Хәрби кеше сөйләячәген ишетеп, бөтен авыл халкы клубка кереп тулды. Кемне генә комсыз Сафыйның язмышы кызыксындырмагандыр ул чакта. Бар халыкны гаҗәпләндереп, теге кеше сүзен Сафыйга рәхмәт әйтүдән башлады. Баксаң, комсызлыгы белән дан алган Сафый, акча туплап, берүзе бер танк сатып алган да фронтка җибәргән

икән. Дөресрәге, әлеге капитанның үз кулына тапшырган. Ике ел буе бу танк дошманнарны кырган, Берлинга кадәр барып җиткән…

Хәрби кеше сөйләде дә сөйләде. Ә зал үкседе дә үкседе. Шулай төнге уникегә кадәр…

Ул көнне авылда төне буе ут янып чыкты. Җеназада яткан Сафыйның ябык чыраенда беленер-беленмәс булып калган елмаю искә төшеп, һәркемнең күңелен сыкрата, елата иде.

## Шәехзадә Бабич хатирәсе

Язгы ташулар вакыты җитсә, Күәш елгасы ниндидер бер ыргый җанварга охшап кала. Бу җанвар тәннәргә суык йөгерерлек итеп үкереп ала да тирән ухылдап куя… Бераз тынып торганнан соң, тагын үкерә, тагын ухылдый…

Астурамның бөтен халкы Бабичлар йорты янына, Хәсәнәйләр очына җыелган. Моннан Күәш әйбәтрәк күренә. Кечерәк өй зурлыгындагы аклызәңгәрле бозларның бер-берсенә бәрелеп, таралып төшүен, шундый ук мәһабәт бозларның бер минутка гына тынычлап торган су тигезлеген ватып-җимереп калкып чыгуын, күккә ашарга теләп тә, егәрләре бетеп, шапылдап суга килеп төшүен карап тору кызык та, шомлы да иде.

Күәштәге манзарага мөкиббән киткән халык Бабичлар ягыннан йөгереп чыккан кечкенә малайны шәйләми дә калды. Бакча капкасыннан тәгәрәп диярлек килеп чыккан бу «ак төенчек» койма белән елга арасындагы ун-унбиш адымны очып кына узды да ярга якынлашкан бер боз кисәгенә сикереп тә менде.

Шуны гына көтеп торган кебек, Күәш елгасының төбенә сузылып яткан «җанвар» ә дигәнче бу бозны үз куенына элеп алды һәм бөтерә-бөтерә эчкә алып кереп китте. Ап-ак күлмәк-ыштаннан, озын кунычлы ак оекбаштан торган ак төенчек бозлар янәшәсендә бөтенләй күренмәс булды.

Бер тында «аһ!» дип куйган халык исенә килгәндә, олы, мәһабәт гәүдәле Мөхәммәтзакир хәзрәт капкадан атылып килеп чыккан иде инде… Шунда кешеләр тагын бердәй булып:

– Мәхдүм!.. – диештеләр һәм тагын зәһәр үкереп яткан афәт дәрьясына текәлделәр… Барысы да ап-ачык иде: «җанвар» үз куенына беренче мәхәллә имамының кече улын – урамның күрке булып үсеп килүче Шәехзадә мәхдүмне йолып алган иде…

Бер төркем яшьләрне, багур-колгалар тоттырып, түбәнгә йөгерттеләр – Шәехзадә менгән боз ярга таба килмәсме? Кая чаклы барыр ул? Каргавыл борылмасын борылгач, Агыйделгә дә ерак калмый бит. Агыйделгә кадәр китсә?.. Йа Хода! Коткара күр бу гөнаһсыз җанны!

Кемдер агачның башына ук менеп киткән. Аның ара-тирә:

– Әнә ул, әнә!.. Әнә-нә-нә-нә!.. Әнә тагын! – дигәне генә ишетелеп кала. Бу сүзләр астагыларның күңеленә җылылык, өмет биреп торалар, мәхдүмнең исән-имин булуын белдерәләр.

Кинәт бер сәер хәл булып алды. Әллә нинди зәхмәтле тавышлар белән үкереп яткан «җанвар» кинәт туктап-тынып калды. Әллә чираттагы ухылдау алдындагы тынлык шулай озак булып тоелды, әллә картларның догалары күк катына барып иреште – кеше зиһене моны аңларлык түгел иде.

Агач башында утырган шәкерт малайның тавышы да ишетелмәс булды. Елга өстендәге гаҗәеп күренештән ул да тораташ булып каткан иде, ахры.

Ә Күәштәге хәлләр, чыннан да, бик серле иде. Шәехзадә утырган боз, башка бозларны читкә этә-этә, кинәт ярга таба килә башлады. Кайбер бозлар, хәтта, «ак төенчек»ле боз якынлашу белән, үзләре үк читкә йөзеп китәләр кебек иде.

Шәехзадә утырган боз күзгә күренеп ярга якынлашты. Менә дилбегә буе ара калды, аннары колга җитәрлек булды, бераздан шыгырдый-шыгырдый ярның үзле балчыгына ышкылып йөзә башлады. Шунда боз өстендә калтыранып туңып утырган Шәехзадә дә хәрәкәткә килде һәм мәче җитезлеге белән ярга сикерде, аннары мышнап килеп җиткән Гыйльман абыйсының куенына менеп тә утырды…

Хәсәнәй яры буенда калган халык аларга каршы кузгалды. Алда йөгерәатлый Мөхәммәтзакир хәзрәт бара иде.

Мәхдүм этисен шунда ук күреп алды. Җиргә төшерүне сорап тыпырчына башлады. Гыйльман түзмәде, малайны инде шактый корып өлгергән җиргә бастырды. Малай этисенә таба йөгерде. Әмма килеп җитәргә берничә адым калгач, шып туктады, сынап-текәлеп хәзрәткә карап тора башлады. Бигрәк тә аның чәчләренә аптырады малай. Хәзрәтнең ике як чигә чәче, акшарга буялган кебек, ап-ак иде…

Мөхәммәтзакир хәзрәт тә туктады. Аның йөзенә дә гаҗәпләнү галәмәте чыкты. Чөнки ул, малаеның күзләренә карау белән, калтыранып китте: ниндидер илаһи бер тылсым белән, элекке чем-коңгырт күзләр күк төсенә кергән иде. Ул моны шунда ук изге фалга юрады һәм, малаен кулларына алып, күккә күтәрде…

## Лифтта

*12 сәгать 18 минут*

Урамга чыгып, җилләнеп кенә керәм дигән идем. Язылып беткән романыма нокта куя алмыйча интегеп утырдым-утырдым да, каләмемне өстәлгә атып, урамга чыгып киттем. Ләкин чыгып җитә алмадым. Лифтта ябылып калдым. Өченче катта гына торам югыйсә... Юк бит, утырып төшәргә кирәк!

Минем белән бергә тагын дүрт кеше ябылып калды. Бишенче каттан Майсәрә исемле хатын. Җиденче катта яшәүче Исмәгыйль абзый. Сигезенче каттан Нәкыя апа һәм унынчы каттан Адилә исемле кыз.

Башта рәхәтләнеп көлештек. Аннары, кычкырып, кешеләр чакырырга тотындык. Бераздан ишекне дөбердәтә башладык. Алай да беркем килмәгәч, тибенергә керештек. Белеп торабыз: тиз генә чыгып булмаячак моннан. Ял көне бит. Йорттагыларның күбесе дачаларына таралганнар, лифтёр хатын төшке ашына кайтып киткән...

Иң элек Майсәрә телгә килде – алтынчы сыйныфта укучы малаен сүгә башлады:

– Дөмектерәм! Үтерәм шул малайны! Ул булмаса, шушы хәлгә калыр идеммени мин?! «Икеле» алып кайткан бит, юньсез! Укытучысы: «Чиреккә «өчле» чыгарам», – дип шылтыратмаса, аягымны да атламас идем. Моннан исән чыга алсам, үтерәм, дөмектерәм шул чукынчык малайны!

Майсәрәне Нәкыя апа җөпләп алды:

– Ә минеке кичә лаякыл исереп кайткан. Төне буе уфылдап, ухылдап

чыкты... Бүген баш төзәтергә аракы сорый. Шул мөртәтнең ах-ух килеп ятуын ишетмәс өчен генә чыгып киткән идем... Котылыйм гына әле шушы төрмәдән!.. Кайтыйм гына!.. Күрсәтермен менә йөз граммны!

Исмәгыйль абзый да ачуын чак-чак тыеп торган икән:

– Хатыны хатын кебек түгел! Йә әйтегез, кемнең ире кибеткә сөткә йөри? Юк андый ир! Эшен дә эшлисең, әйберен дә табасың, өстәвенә кибеткә дә чабасың... Моннан соң аягымны да атламыйм! Үзе йөрсен! Җитте!.. Белеп торам: өйдә сөенеп утырадыр әле, күз алдымнан олакты, дип... Ну чыгыйм гына әле!..

Иң ахырдан Адилә сүз алды. Аның еламсырак тавышы болай да нечкәргән күңелләрне тәмам җебетеп җибәрде.

– Әнием... Әнием мине куып чыгарды. Өч сәгатьтән дә иртәрәк кермә, диде. Янына Дамир абый килде, шуңа шулай ди ул... Не-на-ви-жу!

Тагын ярдәмгә чакыра башладык. Кемдер лифт стенасын төяргә, дөбердәтергә кереште, кемдер сикеренә, тибенә башлады, кемдер йөзен яшереп кенә күзләрен сөрткәләде...

*13 сәгать 42 минут*

Берникадәр тын калып, моңсуланып утырганнан соң, Майсәрә борчулы тавыш белән сөйләнеп китте:

– Нишләп кенә йөри икән балакаем? Тамагы ачып беткәндер инде мескенкәемнең... Соңгы вакытларда ябыгып та китте. Ябыгыр да шул. Әнисе көннәр буе эштә йөри. Ял көнендә... менә... лифтта бикләнеп утыра... Башсыз түгел бит ул. Хәзер эләктереп алырга тора. Бераз күз-колак булу гына җитми. И Ходаем, кичерә күр мине, әйбәт ана да була алмадым шул балама... Зинһар саклап йөрт җанкисәгемне, тәүфыйклы, иманлы ит. Нишләрмен мин ансыз? Ә ул минсез нишләр?.. Их! Исән-имин чыксам, бер тиргәмәс идем үзен, иркәләп-назлап кына йөртер идем. Бала җаны назга ныграк килә бит ул... Моннан соң дәресен дә карап торыр идем, мәктәбенә барып, укытучысыннан да сорашып-белешеп йөрер идем... Йа Рабби, чыгар безне моннан, газиз балам хакына булса да чыгар!

Нәкыя апаның тавышы да бу юлы йомшак-ягымлы гына:

– Минеке дә ул чаклы юньсез түгел түгелен... Куллары алтын, йөрәге ялкын дигәндәй. Эчүен дә бик сирәк эчә. Бик кирәк булганда гына каба. Кичә дә дачабызга бура сөйләшеп кайткан... Ярата ул мине. Минем өчен бөтенесен эшләргә дә әзер. Бу юлы да эчүен эчкән, ә өч бөртек чәчәк кыстырырга онытмаган... Югыйсә чәчәк бирешергә бала-чага түгел бит инде без... Их, моннан чыга алсам, билләһи дип әйтәм, өф итеп кенә тотар идем дә үзен... Чыгып кына... булмас... шул...

Исмәгыйль абзыйны да танырлык түгел. Аның шундый мөлаем һәм самими чагын мин беренче күрәм әле.

– Моннан соң ипи-сөтне иртән иртүк алып кереп куям. Болай вакытлы-вакытсыз йөрү килешми. Хатын-кызның өйдәге эше дә җитәрлек бит аның... Барысына да ничек өлгерсен ул?! Бу юлы исән-сау калсам, ничек яшәргә икәнен белер идем инде... Чөкердәшеп кенә гомер сөрер идек апаң белән...

Адилә исемле кыз, киресенчә, олыларча, акыллы һәм мәгънәле сүзләр сөйләнде:

– Мин дә әниемне аңламыйм. Гомере буе үзе генә яши бит ул. Минем белән булса да, һаман ялгыз... Беркеме юк бит аның, ә минем әтием юк... Дамир абый

да беренче генә килә әле. Әниемә ул бик ошый. Дамир абый да аны ошата. Мин моны беләм, сизәм... Мин аларга бәхет кенә телим. Алар бәхетле булса, мин дә бәхетле булам бит... Моннан соң әниемне бер дә, бер дә ачуландырмас идем!.. Тизрәк ачсыннар гына...

*14 сәгать 58 минут*

Ниһаять, лифт ишеген ачтылар. Безне кысан, тынчу, караңгы төрмәдән азат иттеләр. Хәбәр итеп өлгергәннәр: ишек төбендә һәркемне үзенең кадерле, газиз кешесе каршы алды.

Майсәрә шундук малаена барып ябышты. Ябышып кына калмады, аны тозлап-борычлап тирги башлады:

– Нишлисең син, малай актыгы?! Нишләтәсең син анаңны? Үлсен, дөмексен, дисеңме? Бирермен мин сиңа «икеле»не! Нәрсә җитми сиңа? У-у, кибәкбаш, өйгә генә керик әле, күрсәтермен мин сиңа ничек укырга кирәклеген!

Нәкыя апа да, лифттан атлап чыгу белән, бер читтәрәк басынкы, юаш кыяфәттә басып торучы иренә карап кычкырды:

– Ну алкаш, сөенденме инде? Бөтен ачуыңны чыгардыңмы? Сөен! Икенче мәртәбә, хәлеңә керәм дип, урамга торып йөгермәячәкмен! Хет үл шунда! Бүтән тереләй кабергә керәсем юк! Колагыңа киртләп куй, исерек бүкән!

Исмәгыйль абзый өтәләнеп көтеп торган хатынын бөтенләй күрмәгәнгә салышты. Әмма шунда да теш арасыннан гына хәләл җефетенә берничә ачы сүз әйтеп өлгерде:

– Мәңге сөт капмаслык иттең син мине! Сөтең-иең белән чукынып китмисең шунда, ыһ та итмим...

Адилә дә елап-шешенеп беткән әнисенә үчле һәм рәнҗешле иде:

– Или – ул, или – мин!.. Бүтән килеп йөрмәсен, әйт үзенә! Миңа кирәкми ул. Мин ансыз да яши алам... Без... яши алабыз...

Ә миңа нәрсә? Олы, шыксыз авызын ыржайтып карап торган лифт төбендә ялгызым басып калдым. Гыйбрәт, әлбәттә. Аның каравы, романны төгәлләргә җай табылды. Шунда ук, өемә кереп, тәмамланмаган әсәремнең соңгы җөмләсен язып куйдым: «Иман үзгәрә, холык үзгәрми, диләр. Дөрес икән».

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



*Татарстан Язучылар берлегендә бер төркем язучылар. Сулдан уңга: Мирсәй Әмир, Рафаил Төхфәтуллин, Николай Нефёдов, Гамил Афзал, Гөлшат Зәйнашева, Зәки Нури, Нәби Дәүли. 1979 ел.*



*Габдулла Шамуков (Габдулла Рухулла улы Шамуков. 1909-1981). Олуг артист, язучы һәм тәрҗемәче.*



*Татарстан Язучылар берлегендә. Утырганнар: Хәсән Туфан, Ләбибә Ихсанова; басып торалар: Ренат Харис, Равил Фәйзуллин. 1972 ел.*



*Ватан сугышында катнашкан шагыйрьләр. Сулдан уңга: Сибгат Хәким, Мәхмүт Хөсәен, Әнвәр Давыдов. Үткән гасырның 50нче еллары.*




*Тарих галиме, сәясәтче Индус Таһиров һәм тарихи романнар авторы Нурихан Фәттах. 1998 ел.*



*КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Фикърәт Табиев, РСФСРның Язучылар идарәсе рәисе, шагыйрь Сергей Михалков. 1979 ел.*

# «ПРИСТАНЬНАР ЯРГА ЯТЫП КАЛА...»



Сибгатуллин! Юк, заманында Тукай язган «шәм сынлы», фырт Сибгатуллин түгел бу, бүтән – шагыйрь Сибгатуллин, Кадыйр Сибгатуллин! Быелның февралендә аңа 75 яшь тулган булыр иде. Тулган булыр иде шул... Ә ул 1994 елны дөньяда 52 яшен тутырып безнең арадан китеп тә барды. Аны якын белгәннәр дә сирәкләнеп бара инде... Белгәннәрнең дә күбрәге аның Чаллыдагы яшәү чорын хәтерли булыр. Кадыйрның башлангыч иҗат елларын беркадәр белгән, беренче шигырьләренең матбугатта чыгу шатлыкларына шаһит булган: менә хәзер – күп гомер узгач, шул елларны татлы сагыш белән искә алып утырырлык чордашлары, иҗатташлары ничә генә данә калды икән? Менә шул сирәкләрнең берсе булам инде мин!

Кадыйр белән якташ, райондаш мин. Хәтта яшьтәшләр диярлек (аерма 1 генә ел). Төрле мәктәпләрдә (мин – Котлы Бөкәш, ул – Олы Солтан) укысак та, бер үк сыйныфларда белем алабыз (беренче танышканда 9 нчы сыйныфта укый идек). Икебез дә шигырьләр язабыз. Хәл-әхвәлләр, киләчәк планнарыбыз турында бер-беребезгә хатлар да сырлаштыргалыйбыз. Ә төп аралашу (үзенчә иҗади ярыш!) район газетасы битләре аша бара. Газетаның бер санында аның шигырьләре басыла, икенчесендә минеке, дигәндәй. Рәхәт! Шатлык! Кулдан ручка белән язган сүзләрең әллә ничә мең данә булып басма хәрефләр белән чыксын әле! Хыяллар котыра! Безгә бит әле нибары уналты, унҗиде генә яшь! Өстәвенә, район үзәгенә килеп очрашып торабыз. Безне район газеты (ул вакытта «Октябрь юлы», хәзер «Авыл офыклары») хезмәткәрләре, яңа гына югары белем алган егетләр, соңрак танылган журналистлар булачак Хәмзә Зарипов, Рәшит Гариповлар машинкада бастырылган үсендерү хатлары җибәреп, әдәбият түгәрәге утырышларына чакырып торалар! Барабыз! Теләп, сөенеп барабыз! Районыбызның төрле почмакларыннан кайчак велосипедта, кайчак (очраса) юлаучы машинада, кайчак җәйдаклап та... Ниндидер 20-25 чакрым нәрсә ул бездәй егетләр өчен! (Бу хакта журналыбызның 2015 елның 5 нче санында, «Ак җилкән» сәхифәсендә Хәмзә Зариповның бер язмасы кыскартылган вариантта басылып та чыкты. Ул аны 1978 елны ук язган булган.) Чын мәгънәсендә бәхетле чаклар! «Үзең язган китабыңны тотып, Кайтсаң иде Туган авылыңа!» дигән юллар шул елларда туган да инде.

Әнә шулай, дәртле хыяллар белән үрелгән, бергә булып, бергә дәвам итәргә дип сүз куешкан уйлар, барыр юллар 1960 елның җәендә көтмәгәндә аерылды да куйды. Икебез дә 10 классны тәмамлап, аттестатлар алып, Казан университетының тарих-филология факультетына, аның да татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керер өчен документларыбызны тапшырдык. Имтиханнар бирү башланды. Ни кызганыч, Кадыйр рус теленнән инша язганда имтиханнан үтә алмады... Шулай итеп, татар әдәбиятына, аның теленә хезмәт итәргә омтылган егетнең хыялын, максатын җимереп, әлеге дә баягы «великий и могучий» аркылы төште. Парадокс, әмма факт. Меңләгән, меңләгән имгәтелгән язмышларның, шәхси фаҗигаләрнең бер генә нәни мисалы бу! Ул елны конкурс дигәннәре дә бик зур иде шул. Ялгышмасам, бер урынга уннан артык абитуриент. Ходай рәхмәте белән мин имтиханнарны уңышлы биреп, студент булып киттем, ә Минкадыйр дустым, юл читендәрәк дигәндәй, билгесезлектә утырып

калды. «Атадан бала яшь кала. Атадан бала яшь калса да, бик зур эшләр башкара» дигән халык сүзләрен башына китергәндерме ул чакта? Төгәл кем белсен инде? Шулай да, китергәндер дип уйлыйм. Үз яшеннән байтакка олырак иде инде ул. Яшьли ятим калып, хуҗалыктагы күп нәрсәне үзбаш хәл итеп, «лаеш шулпасын» күп чөмергән, чын мәгънәсендәге, чыныккан «сугыш чоры баласы» иде ул! («Бишекләрдән үзебез төшеп җиктек туарылып калган атларны».) Югалып калмады егет, әлбәттә, тырышты, үз юлын табарга омтылды. Техучилище, армия хезмәте, «Оргсинтез заводы» төзелешләре, кичке факультетта укулар... Әмма бу юл, мәктәп елларында хыялланган олы юл ук түгел иде инде...

Кадыйрга тумыштан ук зур шигъри талант орлыгы салынган булган. Ул – укып-өйрәнүдән бигрәк, гади авыл халкы тормышы төбеннән, халык сөйләме, авыз иҗаты үзәгеннән күтәрелгән табигый шагыйрь. Дөрес, һәркемнең таланты табигатьтән килә. Әмма һәр биләмәнең, һәр тугайның үз кошы, үз моңы... Миңа калса, Кадыйр Сибгатуллин «сугыш чоры баласы»ның җан авазын яңа буыннарга бик тә төгәл һәм дөрес итеп, халыкчан итеп җиткерә алган шагыйрьләрнең берсе. Әлбәттә, бу мохиттә Кадыйр ялгыз түгел. Аваздаш ишләрен аннан элгәргерәкләр арасыннан да, яшьрәк даирәдән дә табып була. Әйтик, Әхмәт Рәшитов, Зиннур Насыйбуллин, Айдар Хәлим, Рәшит Әхмәтҗанов... Ә язу манерасы, сөйләм стиле ягыннан мин аны Рим Идиатуллин, Нияз Акмаллар янәшәсендәрәк күрәм. Ихлас аваз, кырыс интонация, ятышлы ритм...

Әгәр, әдәбият гыйлемендәге һәм көндәлек тәнкыйтьтәге 70-80нче еллар татар поэзиясенә багышланган мәкаләләргә, гомумкүзәтүләргә, аерым хезмәтләргә күз салсак, бер нәрсәгә игътибар итәсең: шул заманның иң яхшы шагыйрьләре рәтендә гадәттә өч исем телгә алына: Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин, Кадыйр Сибгатуллин... Бу саналуда, бер караганда, бернинди гаҗәпләнерлек нәрсә юк. Лаек исемнәр. Хикмәт бүтәндә: бер төбәктә, бер чорда өч җитди шагыйрьнең дәррәү диярлек пәйда булуында! Моңарчы кабатланмаган уникаль күренеш! Кайдадыр, кайчандыр мондый хәл кабатланырмы? Әйтү кыен...

Әйткәнемчә, шагыйрь шактый сикәлтәле тормыш юлы кичерде. Яшәлгән 52 яшь бер караганда байтак күренсә дә, аның күпме генә өлеше чын иҗатка бирелде икән? Күпме гомер дөнья куута, кирәк өчен яшәүгә, көнкүрешне, гаилә тормышларын җайга салырга сарыф ителгән! Өстәвенә, шагыйрьнең характер-холкы да шактый ук каршылыклы иде. Минемчә, яшүсмер чагында ук аның җанында ир-ат холкы формалашты, һәм ул күпме генә яшәсә дә, әнә шул яшьли формалашкан принципларыннан китмәде яки китәргә, үзгәрергә теләмәде. Башбирмәс горурлык, туры яки үзсүзлелек, үсмерләрчә максимализм, кискенлек-кызулык һәм... беркадәр чарасызлык, ялгызлык...

*Орлык булып йөктә барасың да,*
*ялгыш кына төшеп каласың да,*
*интегәсең чиста башың белән*
*дегет сөртеп көпчәк арасында.*
.................................................
*Каныга бит мәрхәмәтсез язмыш,*
*бер башакта ничә арба сагыш!*
*Серкәләнеп уйный шул ук арыш,*
*дегет сөртеп тора шул ук арыш...*

Мондый юллар тиктомалдан гына туа алмас. Тукаебыз да «Шат яратса да Җиһанга, ят яраткан Раббысы» дип язып калдырган бит... Тик шулай да Кадыйр Сибгатуллин – үзенчә бәхетле язмышлы шагыйрь. Иң мөһиме – яңа буыннарда Шагыйрь җанын аңлаучылар бар. Аның кайбер шигъри юлларын халыкныкы санап яттан сөйләп йөргән кешеләрне дә беләм мин. Чын шигырь шундый булырга тиеш тә! Аның кемнәрнеңдер, нинди катлам кешесе булуга карамастан, күңелләренә юл ярырлык кодрәте булырга тиеш! Ә Кадыйр иҗатыннан сискәндерә, тетрәндерә һәм сокландыра торган юлларны

байтак табып була. Димәк, андый шигырьләр мәктәп дәреслекләрендә дә урын алырга хаклы. Моны аңлаучылар хәзер күбәя бара шикелле. Соңгы елларда шагыйрь һәм галим Факил Сафин, Фәния Хамматова, Роза Хәмидуллина, Вазыйх Фатыйхов һәм тагын кайбер фидакяр милләттәшләребезнең тырышлыгы белән Кадыйр Сибгатуллинның татар һәм рус телләрендә үз шигырьләре, һәм шулай ук аның иҗаты турында хезмәтләр чыкты. Сөенәбез!

Кадыйр Сибгатуллин – үзебезнең Татарстан егете. Монда туды, яшәде, иҗат итте. Яшәгән урыннары – Балык Бистәсе (Балыклы Чүкәй, Кече Укмас, Яншык авылларын кертеп) – Казан – Чаллы каласы. Әмма гомере буе сагынган, рухы канат каккан һәм... бакыйлыкка күчкән җире – туган ягы – Балык Бистәсе булды. Шагыйрьнең күп кенә шигырьләрен укыганда күз алдыма Кама буе, пристаньнар, баржа-саллар, керәшәле ярлар, томан сарган офыклар җанлана... Шагыйрьнең йөрәгендә гомер буе Кама-Чулман дулкыннары тибрәнде кебек. Икенче бер яктан шагыйребезнең шигъри юллары искә төшә:

*Беләсең,*
*бик тигез салмадык эзне дә...*
*Без дә бит бу Җирнең баласы...*
*Еллар сагыныр безне дә!..*

Бу кыска гына язмамны моннан 35 еллар элек Кадыйр Сибгатуллинга багышланган бераз озынрак килеп чыккан шигырь белән тәмамламакчы булам. Язылу тарихы үзенчә гыйбрәтле. 1983 елның февраль аенда Чаллыда һәм Түбән Камада минем иҗат кичәләрем булып узды. Кичәләр зур залларда гөрләп үтә. Күңел күтәренке. Һәм беркөн... миңа якташым, яшьлек дустым Кадыйрны Чаллы хастаханәсендә үлем хәлендә ята, дип хәбәр җиткерделәр. Йөгердем больницага. Хәле чыннан да бик начар, инде берничә көн реанимациядә ята икән. Ялынып-ялварып дигәндәй, зур танышлар ярдәме белән генә янына керергә рөхсәт алдым. Залсыман ярым караңгы зур бүлмәдә ята Шагыйрь. Читтәрәк тагын бүтән ятаклар һәм аларда да ак җәймәләргә уралган җан ияләре бар иде. Янына килеп бастым. Таныды да шикелле, керфекләрен кагып куйгандай итте... Сөйләшеп булмый. Ярамый да... Алып килгән кызыл чәчкәләрне уң кулы тирәсенәрәк куйдым. 5-6 минутлап карап торабыз бер-беребезгә шулай... Авыр. Андый чакта озак басып торып та булмый. Бераздан миңа «чыгарга!» дигән ым кактылар. Дөресен әйтим, мин ул чакта Шагыйрь белән мәңгегә саубуллаштым дип чыгып киттем. Һәм... Ходайның чиксез рәхмәте: шул көннәрдән соң Шагыйрь терелеп, аякка басып тагын 11 ел яшәде! Иҗат итте! Бу шигырь әлеге вакыйгадан соң ике еллап вакыт үткәч язылды. Шулай да, язманың «эчке сулышы»нда әлеге «саубуллашу» хисе дә чагыла шикелле.

*23-25 гыйнвар, 2017 ел*

## Тордым басып Кама ярында

*Пристаньнар ярга ятып кала,*
*елый-елый китә пароход.*
Кадыйр Сибгатуллин

Бик ямансу булды быел кайткач
Балык Бистәсенең ярында.
Яланаяк басып тордым гүя
боз каплаган учак урынында...

Күңелнең бер якты аланына
төште кебек кырау-күләгә.
Пристанебызны алганнар бит,
без калалар «яулап» йөргәндә!

Яшьлек яры ятимләнеп калган,
бушап калган тирә-әйләнә.
Дебаркадер урынында хәзер
күбекләнеп дулкын тирбәлә...

Мәкәрҗә күк шаулы булган җир тын.
Казлар гына йөри чемченеп...
Бистәбезнең бу тарихи җирен
искә алдым авыр көрсенеп.

Кавышу-аерылулар үзәге иде!
Кая халык? Атлар? Әрҗәләр?
Кая балык, дегет, сыра исе?
Тозлы кыяр саткан марҗалар?..

Шушы төшкә ничә буыннардан
кемнәр генә аяк басмаган!
Нинди генә язмыш үтмәгәндер
пароходка салган басмадан!

...Пароходлар хәзер читләп үтә,
сәлам бирми безнең ярларга.
Ярдан атылып, керәшәләр генә
каршы чыгып оча аларга...

Һай замана! Әле кайчанмы соң
басып торып шушы ярларда,
шигырьләребезне укый идек,
Туган якны теләп данларга.
Җилләр генә безне тыңласа да,
бәхетлеләр идек дөньяда!

Хыялландык, яндык шушы ярда!
Кама безне аңлыйдыр иде.
Пароходның гудок бирүләре
безнең өчен үзе җыр иде!

Пристань ул – булган җанлы тарих,
бер бизәге безнең якларның.
Инде ул да кайтмаска дип киткән,
кайтмаган күк яшьлек чакларың.

Киткән чакта телгә килгәндер ул:
«Сау булыгыз! Сәфәр – затонга!»
Бу тормышта һәркемгә дә язган
соңгы тапкыр нидер озатырга...

...Басып торам элекке урында.
Офыкларда сагыш пәрдәсе.
Күзем йомсам күрәм: яшьлектәге
пароходларымның шәүләсен!

Яшьлекне җил офыкларга куган.
Керсә, бары – төштә ул еллар...
Кайсы затоннарда муртаялар
«Засулич»лар, «Вера Фигнер»лар?*

Дөнья – фани. Ярлар гына түгел,
үзебез дә шактый үзгәрдек!
Нуры азрак хәзер күзләрнең,
чынлыгы ким әйткән сүзләрнең...

Тик шулай да кылганыбыз – ихлас!
Азмы-күпме бар ул – эшебез.
Халык күңеленә җырлар уеп,
яшәргә дип килгән кеше без!

Хакыйкатькә тирән кергән саен,
кеше күп чак кала шул ялгыз...
Кама өстендәге күкрәүләр
әйтә кебек: «Югалтышмагыз!
Югалтышмагыз!
Югалтышмагыз!..»

Бик ямансу булды бу юл кайткач
яр буенда басып торулар!
Күңел өзгәләнеп теләгән иде
шул сәгатьтә бергә булырга...

...Бу хисләрне берәүгә дә әйтми
йөртә алыр идем эчемдә.
Шулай да бер ачылыйм дидем
әҗәлләрне кичкән кешегә.

*22 гыйнвар, 1985 ел*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре*

* Пароход исемнәре.

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА РЕАЛИЗМ: РӘФКАТЬ КӘРАМИ ПРОЗАСЫ

## РӘФКАТЬ КӘРАМИГӘ 75 ЯШЬ

XX гасырның урталарында татар әдәбияты социалистик реализм чикләүләрен үтеп чыгу мөмкинлекләре таба, классик реализм һәм романтизм, модернизм сыйфатларын кабат әдәбиятка кайтара. Әлеге үзгәрешләр әдәби әсәрләрнең һәм эчтәлек, һәм форма җәһәтендә чагылыш таба. Хәтта иҗатлары белән реализмга йөз тоткан, кискен идея-эстетик яңарыш-борылыш юлын түгел, бәлки дәвамлы традицияләрне үстерү юлын сайлаган язучылар иҗатына да чор шаукымы йогынты ясый.

Шундыйлар арасында 1960 еллар ахырында татар әдәбиятына килеп, бүгенге көнгә кадәр реалистик язу рәвешенә тугры калган Рәфкать Кәрами – Кәрамиев Рәфкать Кәраметдин улы да бар.

1960 еллар – илне индустриальләштерү хәрәкәтенең колач җәйгән вакыты, хезмәт романтикасы әдәби барышның да үзәгенә куелган заман. Удар төзелешләрдә эшләүче сәләтле яшьләрнең каләм тибрәтүе совет әдәбиятында «производство романы» дигән жанр төрен китереп чыгара. Социалистик реализмның шушы чордагы үзәк жанр төренә әйләнеп, ул илдәге данлыклы төзелешләр, алардагы тормыш хакында сөйли. Авторлары да – башлыча, мәктәпне тәмамлагач ук шул төзелешләргә эшкә киткән, читтән торып югары белем алган яшьләр. Рәфкать Кәрами дә – шуларның берсе, аның әсәрләре татар әдәбиятында, гомумән совет әдәбиятында барган процессларга аваздаш иҗат итеЛә. Бу урында Г.Ахуновның «Хәзинә» (1963), «Хуҗалар» (1968), «Хыялый Хәйрүш егетләре» (1965), Ш.Бикчуринның «Каты токым» (1973), А.Гыйләҗевның «Зәй энҗеләре» (1965), Р.Төхфәтуллинның «Агымсу» (1968), Э.Касыймовның «Томан аша» (1968), «Һаваларда тургай» (1973) роман-повестьларын искә төшереп, телгә алып китү урынлы булыр. Нефть чыгаруны, яңа шәһәрләр, заводлар төзү барышын тормыш материалы итеп сайлаган мондый әсәрләрдә төп конфликтны хезмәткә караш хасил итә. Идеологик яктан, тормышны үзгәртеп төзүдә партиянең роле ассызыкланса да, социалистик реализм таләпләренең бераз йомшаруы әсәрләрдә автор фикер-карашларының, позициясенең әхлакый мотивлаштырылган булуында күренә. Әхлакый мотивлаштыру исә хезмәткә, матди байлыкларга мөнәсәбәттә, шәхси кешелеклелек сыйфатларында аермачык, акка-карага аерып шәрехләнә.

Язучының беренче әсәре – «Дүрт кешелек каюта» (1967) повесте турыдан-туры хезмәт темасына багышланмаган. Автор геройларын теплоходта Идел буйлап сәяхәт иткәндә очраштыра. Каютага урнашып, беренче танышу вакытында ук геройлар хезмәт урыны ягыннан аерып куела. «Хәят апа каучук заводында аппаратчы булып эшләгән, менә ун ел инде пенсиядә икән, бу сәяхәткә ул, ял итүдән бигрәк, ире сугышта һәлак булган урыннарны, изге Сталинград җирләрен күрү өчен бара икән.

Ә Луиза кием тегү ательесында эшли.

Клара да үзенең балалар йортында үсүен, хәзер заводта эшләвен әйтте»[1]. Алга таба төп геройларның тагын берсе – Җәүдәт исемле егетнең дә «эшләп укый торган» яшьләрдән булуы ачыклана. Тырыш, акыллы, хезмәт сөючән, спортсмен егет образы беркадәр идеаллаштырылып, социалистик реализм таләпләренә туры китереп иҗат ителгән. Аның каютадашлары да – хезмәттә дә, спортта да алдынгы булганнары өчен шушы сәяхәткә юллама белән бүләкләнгән егетләр.

[1] Кәрами Р. Мәхәббәт бураннары: Повестьлар. – Казан: Рухият, 2004. – Б.10.

Повестьта каршылык Кларага бәйле килеп туа һәм асылда эшләп яшәү (советча яшәү рәвеше) белән урлап (яки үзең өчен генә) яшәү рәвеше арасында булып чыга. Ятим үскән кыз караклар бандасына эләгә, ләкин алар белән араны өзәргә көч таба. Теплоходта йөзгәндә әлеге каракларның берсе «Граф» Кларaны таный, үзләре белән алып китәргә тели. Әмма Җәүдәт һәм башка егетләр кызны аралап калалар. Кыска гына вакытта хасил булган һәм чишелгән әлеге каршылык мәхәббәт сызыгында кабатлана. Бер якта – эшләп яшәү юлын сайлаган Клара, икенче якта – үзе өчен генә яшәүче Луиза арасыннан Җәүдәт Кларaны сайлый. Авторның әхлакый мотивлаштырылган фикере вакыйгалар барышында ныгытыла.

Сайланган тормыш материалы үзгә булса да, Р.Кәраминең икенче повесте – «Кичке уйлар» (1968) шундый ук каршылыкка корылган. Язучы бу очракта авыл яшьләре тормышын сурәтли. Шакир, шахтада эшләүче егет, авылына кайтып, яшь кыз Галиягә өйләнә. Дүрт балалары туа. Әмма акча артыннан куып, Шакир ярату хисен дә, хатынын кадерләүне дә оныта. Өй сала, һәм иң зур теләге – «Волга» машинасы сатып алу аның барлык тормышын биләп ала. Шакир теләгенә ирешә, әмма хатынын югалта. Шул вакытта ул үзенә машина түгел, бәлки өйләнешкәндә хыялланган матур тигез тормыш кирәген аңлый. Шулай язучы укучысына матди байлык артыннан кууның мәхәббәтне дә, кешеләр арасындагы җылы мөнәсәбәтләрне дә юкка чыгаруын күрсәтә. Әлеге фикер повестьтагы уңай герой амплуасында бирелгән Фалих образы мисалында ныгытыла.

«Капитан Хәкимов» (1972) повестенда тормыш материалы башка өлкәдән сайланса да, яшьләр, аларның гаилә кору, хезмәт итү тарихы укучыга үрнәк рәвешендә сурәтләнә. Вакыйгалар барышында хәрби хезмәттәге Самат Мисбахович Хәкимов, аның өйләнүе, хатыны Гөлсемнең дә үзенә тиң хезмәт сөючән булуы, балалары туу, илнең ерак чикләрендә хезмәт иткәндә очраган кыенлыклар, аларны җиңеп чыгу укучы күз алдыннан бер-бер артлы уза бара. Үз хезмәтенең чын патриотлары, ил өчен яшәүчеләр тормышын аерып алып, автор аларны әхлакый идеал пьедесталына куя.

Повестьларның өчесенә дә хас уртак уңай сыйфатлардан, язучының тормыш детальләрен белеп, аңлап, матур тел белән, укучының күз алдына килеп басарлык сурәтләү осталыгын күрсәтергә кирәк. Язучы тормышны, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, ситуацияләрне тирәнтен белеп, үз күңеле аша уздырып яза. Әйтик, Шакирның, күбрәк акча эшләргә теләп, төзүчеләр бригадасыннан хәйлә белән каравыл торырга эшкә күчүе, бүре килгән төнне Галиянең каравылга чыгуы, яки Гөлсемнең сөт кабул итү пунктында әшнәлеккә каршы көрәшүе кебек эпизодлар тормышчан, ышандырырлык итеп тасвирланган. Төп геройлар янәшәсендә шундый ук матур омтылышлар белән, башкалар тормышын бизәп яшәүче геройлар ярдәмче рольләргә куела. Әдәби эшләнеш ягыннан яңалыгы белән шаккатырмасалар да, әсәрләр укыла.

Үзәк кимчелек буларак, хикәяләүнең шактый көпшәк баруы күзгә ташлана, моның сәбәбе исә шушы чор социалистик реализм юнәлешендә язылган әсәрләргә хас конфликтсызлык сыйфатына барып тоташа. Укучы игътибарын «тотып торырлык» сюжет хасил итүче, әсәрне башыннан ахырына кадәр бер тарихка җыярлык каршылык табылмау әсәрләрне таркауландыра. Совет идеологиясе исә яңа социалистик җәмгыятьтә мондый кискен каршылыкларның инде калмаганлыгы турында сөйләп тора. Нәтиҗәдә 1960-1970 еллар совет әдәбиятында әлеге тенденция әдәби барышны тоткарлаучы төп сәбәпләрдән берсенә әверелә. «Конфликтсызлык» теориясе, «лакланган» чынбарлыкны сурәтләүче әсәрләр мәсьәләсе әдәби тәнкыйтьнең көнүзәгенә куела. Р.Кәраминең социалистик реализм юнәлешендә иҗат ителгән повестьлары турында да шуны әйтергә мөмкин. Аерым бер күренешләр шулкадәр җентекле, гаҗәпләндерерлек сурәтләнә һәм сокландыра, әмма ул төгәлләнүгә, хикәяләү башка сукмакка борыла. Төп геройларның бары тик уңай яктан гына сурәтләнүе, тискәре геройларга мөнәсәбәтнең алдан ук мотивлаштырыла башлавы бүген инде, әдәбият нык үзгәргән бер чорда, аеруча күзгә ташлана. Без алдарак билгеләп үткән уңай сыйфатлардан, автор фикеренең әхлакый нигезле булуын, язучының тормыш ситуацияләрен яхшы белеп иҗат итүен тагын бер кат искәртсәк тә, болар гына әсәрләрнең иҗат юнәлешен үзгәртә алмый.

Һәр иҗатчы бу торгынлыктан чыгу юлын үзенчә эзли. Р.Кәраминең соңрак язылган

«Сагышлы кояш» (1979), «Йөрәгемне ут алган» (1981), «Мәхәббәт бураннары» (1985) кебек повестьларында киңәйтеп тәкъдим ителгән мәхәббәт маҗаралары күпмедер күләмдә укучы игътибарын җәлеп итү һәм “тотып тору» вазифасын башкара да. Бәхетсез мәхәббәт тарихлары үкенеч ноктасында төгәлләнә, язучы моның сәбәбен кешеләрдәге төрлелектә таба. Моңа бәйле, язучы Б.Камалов аны язучылар арасында «мәхәббәт профессоры»[2] дип тә атый. Әйтик, «Сагышлы кояш»та ул бер-берсенә тиң булмаган Сәлим белән Фирдиянең очрашу, гаилә кору, аерылышу тарихы төсен ала, «Йөрәгемне ут алган» повестенда буйдак Флүр Сәхбиевичның, Гөлмирәгә гашыйк булып та, аңа өйләнергә көче җитмичә, югалткач кире кайтарырга омтылышы шулай ук тискәре ноктада төгәлләнә.

Моннан тыш, Р.Кәрами иҗатына хас, аның әсәрләрен интеллектуальлеккә юнәлткән тагын бер сыйфатны аерып күрсәтергә кирәк: ул әсәрләрнең тарихи, мәдәни-тарихи мәгълүматлар белән урынлы һәм отышлы баетыла баруы. Үзе тарихчы белгечлеге алган язучы күп белә, укучысын да җае чыккан саен дөнья тарихына, рәсем яки музыка сәнгатенә, аерым шәхесләр биографиясенә, географик урыннарга нисбәтле кызыклы мәгълүматлар белән таныштыра. Мондый урыннар һич тә ят ямаулык түгел, алар әсәр тукымасына бик табигый урнашып, укучы игътибарын җыйнап торалар.

Билгеләп үтелгән сыйфатлар Р.Кәраминең олы жанрда иҗат ителгән әсәрләрендә дә саклана. Социалистик реализм таләпләренә туры китереп язылган «Очар кошлар белән янәшә» (1977-1982) романы[3] совет чорындагы яңа тормыш төзү, илне индустриальләштерү романтикасын шактый тулы күз алдына китереп бастырырлык итеп уйланылган. Аның төп геройлары (чыннан да, күплек санда әйтү дөресрәк булыр) – Казанда химкомбинат төзүче яшьләр! Алар арасында хикәяләү җебен сузган үзәктәге герой Гөлүс – Алабугада мәктәп тәмамлап, «Метеор» белән шушы зур төзелешкә килгән егет, роман ахырында бригадир, социалистик ярышка йомгак ясарга баручы оста төзүче. Романның башында һәм ахырында Гөлүс белән «Метеор»да очрашу аның тормышын, әкиятләрдәгечә, бер цикл итеп йомгаклап куя. Гөлүснең илкүләм билгеле зур төзелешләргә үз өлешен кертү хакындагы хыялын тормышка ашыруы романдагы төп тарих кебек тәкъдим ителә. Ягъни романдагы иҗтимагый төп сюжет сызыгын яшь кешенең тормышта үз урынын табу тарихы хасил итә. Асылда, мондый композиция халык авыз иҗатыннан килә торган традицион сюжет калыбын хәтерләтә.

Башка геройлар тормышында да шундый ук төгәлләнгәнлек күзәтелә. Миләүшә, Зиннәт, Виктор, Әзһәм, Галя, Дуся һ.б. яшьләр – һәрберсе үз язмышы, үз проблемалары белән укучы күз алдына килеп басалар да, бердәм хезмәт коллективы эчендә шул проблемаларны чишәрлек көчле кешеләргә әйләнәләр. Романның исеме дә яңа төзелешләр романтикасының яшьләргә канат куюына ишарә ясый. Дөрес, әсәрнең үз эчендә автор, Семагин исеменнән, бу фразаны уйната: «...без – төзүчеләр, без – очар кошлар янәшәсендә биектә эшлибез. Ләкин безнең тәнебез генә түгел, рухыбыз да югары булырга, биек булырга тиеш. Аннан без ташлар гына тезмибез, без меңләгән кешеләрнең, бигрәк тә яшьләрнең күңеленә яхшылык та тезәбез, хезмәт дигән олы төшенчәне иңдерәбез. Без тимер-бетон колонналар гына күтәрмибез, без яшьләрне аякларында нык басып торырлык итеп, югарыга күтәрәбез, яшәргә өйрәтәбез» [4] дигән сүзләр әйттерә. Шуның белән әсәрнең язылу максаты да тагын бер кат искәртелә! Хезмәткә, аның кешеләрне камилләштерү көченә сокланып иҗат ителгән бу әсәр хезмәтнең тормышны гына түгел, аңа мөнәсәбәтне дә үзгәртүен билгели. Әсәрнең мәгънәви асылы әхлакый яссылыкка юнәлтелә: төзелешләр, хезмәт романтикасының кешене рухи үстерү-камилләштерүе, аны шәхес буларак ныгытуы ассызыклана. «Кеше һәм эш – бер үк нәрсә. Эш юк икән, кеше дә юк, кеше булмаса – эш тә юк»[5] дигән сүзләр дә роман эчендә кешелеклелекнең мөһимлеген ассызыклау белән үрелеп бара.

Шулай итеп, совет чорында әдәбиятка килгән, прозаның роман, повесть, хикәя жанрларында иҗат иткән Р.Кәрами иҗаты мисалында без татар әдәбиятының реализм юнәлешендәге канатының социалистик реализм чикләүләреннән арыну

[2] Камалов Б. Мәхәббәттә имтихан // Татарстан хәбәрләре. – 1993. – 26 май.
[3] Кәрами Р. Очар кошлар белән янәшә: роман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. – 375 б
[4] Шунда ук. – Б.312.
[5] Шунда ук. – Б.302.

юлларын эзләве, әхлакый проблематиканы, мәхәббәт тарихларын, тарихи-мәдәни мәгълүматларны тирәнрәк файдаланып, классик реализмга кайтырга омтылуын күрәбез. Социалистик реализмга хас, аның асылын билгели торган сыйфатлар исә хикәя жанрында бөтенләй сизелми: бу, әлбәттә, кече жанрның эчке хасиятләренә бәйле күренеш. Башка милләтләр әдәбиятларындагы кебек үк, социалистик реализм юнәлеше роман яки повесть жанрларына зур таләпләр куя. Бу юнәлешне сайлаган прозаикларның хикәяләре исә классик реализм традицияләрен тергезеп язылган кебек тоела. Р.Кәраминең хикәяләрендә дә бу шулай. Әйтик, беренче әсәрләреннән булган «Кара малай» (1966) хикәясендә чын җир кешесе, эш кешесе Әнәснең, авылда хаксыз мөнәсәбәттән күңеле кайтып, шәһәргә килүе, әмма җирсүгә, туган җирдә иген үстерү теләгенә буйсынып, кабат авылга кайтып китүе сурәтләнгән кечкенә генә текстта, туган җирнең кадере проблемасы шушы яссылыкта чишелеш таба. Хезмәт («Горурлык», 1967; «Юаш», 1967; «Шофёр хатыны», 1968; «Якты елмаю», 1972; «Гөрләвекләр ага челтерәп», 1971 һ.б.), мәхәббәт һәм шәхси кичерешләр («Җепшек кар ява», 1967; «Кайтмады», 1968; «Бер очрашу», 1973; «Хуш, ак каен!», 1975; «Өзелгән чәчәк», 1980, һ.б.), тормыш сынауларын кичеп чыгу («Яшәү мәгънәсе», 1971; «Кәккүк тавышы», 1974; «Өч монолог», 1978; «Ир баласы», 1984; «Авылдаш», 1995 һ.б.) күренешләрен тормыш материалы итеп алган хикәяләрдә дә һәрвакыт әхлакый бәя, яхшылыкның – яхшылык, явызлыкның – явызлык булып әйләнеп кайтуы, намуслы яшәү үзәккә куела. «Юаш» Хәлимнең намуссыз авылдашының төзелештән материал урлавына каршы төшәргә көче җитүен күрсәткәндә дә, композитор Касыйм аганың дан-дәрәҗәләрдән түгел, яңа көй тудыра алудан («Якты елмаю») яки Сәмига түтинең кызы хезмәтен хөрмәтләүдән («Гөрләвекләр ага челтерәп») кичергән бәхетле мизгелләрен тасвирлаганда да, Нәгыймнең төзәтелмәгән ялгышлары («Кәккүк тавышы») яисә Зөфәрнең мәхәббәтенә хыянәте («Хуш, ак каен!») өчен үкенечен сурәтләгәндә дә, язучы кешенең теләсә нинди ситуацияләрдә дә кешелекле булып калуы мөһимлеген ассызыклый. Әмма реализмга тугрылык хикәяләрнең публицистикага тартымлыгын китереп чыгара. Шул ук вакытта, Р.Кәрами иҗатының бу чорда асылы белән социалистик реализм сукмагында калуын да искәртергә кирәк.

Үзгәртеп корулар Р.Кәрами иҗатына тематик үзгәреш алып килә. Язучы якын тарихка, шәхес культы фаҗигасенә мөрәҗәгать итә. «Репрессия елларында хаксызга рәнҗетелгән гөнаһсыз җаннар истәлегенә багышлыйм. Автор»[6] дип эпиграф куелган «Каргышлы этаплар» (1989) романы 1980 еллар ахыры татар әдәбиятында шушы теманы күтәргән бер төркем әсәрләргә үз тавышы белән килеп кушыла. Басылып чыгуга, романның шушы темага кагылган башка әсәрләрдән шактый аерылып торуы[7] күрсәтелә. 1999 елда «Каргышлы этаплар» романы Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаек дип табыла.

Әсәр 1937 елның декабре вакыйгалары белән башлана. өч яшьлек малайлары белән бәхетле тормыш иткән, тагын бер бала көткән яшь ир һәм хатын – Мотаһир белән Мөсәмирә гаиләсенә ил кайгысы килеп кагыла: ирне кулга алалар, ун елга хөкем итеп, лагерьга җибәрәләр. Язучы вакыт-вакыт натуралистик төгәллек белән шушы герое кичкән җәфаларны сурәтли. Кайчак геройлар исеменнән сөйләү, психологизм отышлы кулланыла, әмма бу алым даими күзәтелми. Психологизмның тагын бер үтемле алымы – Мөсәмирәнең ире кулга алыныр алдыннан күргән куркыныч төше, төшендә үзләре бозавын чит көтүгә илтеп кушуы Мотаһирның тоткынлык тарихын колачлап ала: ул иреккә чыкканнан соң да искә төшерелә.

Роман «лагерь прозасы» дип исем алган әсәрләргә хас күп сыйфатларны үзенә туплаган. Иректәге тормыш – тоткынлык, ирекле кешеләр – сак органнары хезмәткәрләре, җитәкчеләр кискен каршы куела. Әдәби сурәтләү документаль өстәлмәләр белән баетып барыла һәм әсәрдә чагылыш тапкан аерым кеше тарихы – ил тарихы, шәхес культы этаплары белән кушыла, бербөтен хасил итә.

Шул ук вакытта Кәрами әсәренә хас кайбер үзенчәлекләрне дә күрсәтеп үтәргә

---

[6] Кәрамиев Р.К. Каргышлы этаплар: Роман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1995. – Б.3.

[7] Гәрәева С. Каргышлы язмышлар кабатланмасын // Мәдәни җомга. – 1995. – 5 апрель; Вәли М. Каргышлы еллар: бер китап басылып чыгу уңаеннан уйлану // Казан утлары. – 1996. – №8. – Б.168-174; Сверигин Р. Мотаһирның каргышлы язмышы // Ватаным Татарстан. – 1996. – 9 август.

кирәк. «Лагерь прозасы» төшенчәсе әдәбиятта совет тоталитар режимының җинаятьчел асылын фаш итү, социалистик мифны җимерү (демифологизация) вазифасын иң үтемле башкарган әсәрләрне берләштерә. Мондый әсәрләрдә сәяси гаепләп кулга алынган кешеләрнең гаепсез булуын күрсәтү ил сәясәтенең ялгышын тагын бер кат ассызыклау өчен файдаланыла. Р.Кәрами бу сыйфатны тагын да көчәйтү юлын сайлый. Аның тоткынлыкка эләккән герое хәтта фамилиясе дә башка булган кеше «урынына» кулга алына. Баллы Күл авылына Мотаһир Нәбиуллин дигән кеше артыннан килгән милиционерлар, аны өендә туры китерә алмыйча кайтып килгәндә, Түгәрәк Күл авылына җылынып чыгарга керәләр. Шунда йорт хуҗасы, электән үк Мотаһир Фарукшинга теш кайрап йөргән Тавис Тарханов белән мондый сөйләшү була:

«– Алай икән, – диде Тавис Тарханов, янә уйга талып. – Әгәр нитсәк... Бездә дә бер кеше бар... Тужы Мотаһир атлы. Фамилиясе Фарукшин йөри йөрүен, ә бабасы – Нәбиулла...

– Алай ярамас бит.

– Нигә ярамасын икән, – диде Тавис Тарханов, боларның икеләнә калуларын күреп. – Кеше урынына кеше булгач... Рәхмәт кенә әйтерләр...

– Һы, – дип тамак кырып куйды таза милиционер. – Ниндирәк кеше соң ул?

– Эт! – диде Тавис Тарханов, идәнгә төкереп. – Ревкомиссия председателе. Алыгыз да китегез. Әллә кайчан олактырырга кирәк ие.

– Да-а...

– Әйе. Тәмамысы җелеккә төште. Күптән озатасы нәрсә.

– Шәп бит бу, – диде милиционер, иптәшенә карап. – Тик безнең кулда аңа санкция юк бит.

– Аптырамагыз, аның да бабасы Нәбиулла. Исеме дә туры килә. Ә безнең аңа дигән бөтен кәгазьләр әзер. Иртәгә районга илтәсеием»[8].

Бу сөйләшү, шулай итеп, Мотаһир Фарукшинның кулга алынуына, аннары Мотаһир Нәбиуллин буларак «каргышлы этаплар» узуына сәбәп була. Автор исә кулга алынган кешенең гаепсезлеген алдан ук «икеләтә» укучыга җиткереп куя.

Бер үк вакытта бу әдәби факт әсәрдә тагын бер мөһим вазифа башкара: шәхес культы фаҗигаләре өчен ил җитәкчелегенең, тоталитар системаның җаваплы булуы белән янәшә, намуссыз, үзләренең шәхси тормышын гына кайгыртып яшәгән, астыртын, кара эчле кешеләр дә гаепле икәнлекне күрсәтә. Шушы фикер авыл кешеләре – Тавис Тарханов, Әблиев кебекләрнең үз-үзен тотышы мисалларында әсәр буенча өзелмичә алып барыла. Хәтта срогын тутырып, Архангельск якларыннан авылга кайткач та, кешеләрнең, элеккеге хезмәттәшләренең, җитәкчеләрнең Мотаһирга мөнәсәбәте, бәяләнмичә генә, җәмгыятьтә кешелеклелек, хәлгә керү, мәрхәмәтлелек сыйфатларының җуела баруын күрсәтүгә хезмәт итә. Роман ахырында Мотаһирның, өйдәге туйны калдырып, Тавис Тархановка ярдәм итәргә баруы, аны үлемнән коткаруы бу мотивны йомгаклап куя. Гәрчә әлеге күренеш әсәрнең гомуми тукымасында артык тоела – Мотаһирның азат ителүе һәм аклануы, үзен кемнәр гаепләп кул куйганын белүе ноктасында роман үзәгендәге тарих тәгалләнә, эпилог ролен үти торган вакыйгалар романның төп структурасын көпшәкләндерә.

Шәхес культы тегермәненә эләккән герой итеп гадәти авыл кешесе, үз эшен намус белән башкара торган ир-егет, медицина хезмәткәре сайлану ул килеп эләккән ситуацияне, кулга алу – сорау алулар – Алабуга төрмәсе – аның хакындагы хәбәрне яшерүләр – хөкем итү – этаплар – лагерь тормышы кебек үзгәрә баручы күренешләрне бербөтен абсурд тормыш образына җыярга ярдәм итә. Гади татар кешесе 1917 елдан соң төзелгән абсурд, кешелексез, бернинди логикага да буйсынмый торган системага каршы куела. Бу системаның шул гади эш кешесен сындыру, җимерү, юк итүгә юнәлтелгән булуы хакындагы фикер әсәрнең башыннан ахырына кадәр, сиздермичә генә, укучыны «озата» бара. Бигрәк тә лагерьдагы хәлләрне җентекләп тасвирлау, кешене һәр мизгелдә үлем сагалап торуны, ачлыкны, кешеләрнең явызлануын күрсәткән күренешләр әһәмиятле вазифа башкара. Автор позициясе тәгәл белдерелмәсә дә, әлеге капма-каршы куеп сурәтләү рәвеше укучының фикеренә тәэсир ясау чарасына әйләнә. Шулай итеп, текстта бу хәлләргә кем гаепле дигән сорау куела, аңа җавап та

[8] Кәрамиев Р.К. Каргышлы этаплар: Роман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1995. – Б.20.

бирелә. Күпмедер күләмдә, әсәр ахырында автор Мотаһирның уйлары рәвешендә бу хәлләрне үкенеч ноктасыннан тагын бер кат гомумиләштереп уза. Әмма укучыга үз фикерен булдыру мөмкинлеге калдырылган.

Әдәби тәнкыйть романның аерым үзенчәлекле сыйфатларына игътибар итә. Мәсәлән, Р.Сверигин аны болай бәяли: «Беренчедән, Р.Кәрами үз башыннан кичергәннәргә таянмый, ә киң гомумиләштерү мөмкинлекләрен эшкә җигә һәм романның гаять зур ышандыру көченә ирешә: әсәр бер тын, бер сулыш белән дигәндәй укыла. Икенчедән, автор әсәренең үзәгенә иң ачы язмышка юлыккан герой тормышын куймый. Мотаһирның тоткынлыкка эләгүе гайре табигый һәм аянычлы булса да, алга таба аңа барысы да гел кире генә килеп тормый, язмыш елмайган очраклар да күренгәли (...) Шулай да, минем аңлавымча, бу романның кыйммәте – шәхес культы дәһшәтләренең тулы картинасын ачып бирергә тырышуда түгел, ә кешенең һәрвакытта, һәр заманда да ирекле зат, бәхеткә лаеклы зат икәнлеген раслауда»[9]. Чыннан да, шушы сыйфатлар әсәрнең язучы иҗатында аерым урын тотуына ишарә ясый.

Әсәрнең иҗат юнәлешен билгеләгәндә, аның социалистик реализм сукмагыннан киткәнлеген, әмма классик реализм традицияләрен яңартуга да туры килмәвен әйтергә кирәк. Бер яктан, әсәрдә тергезелгән абсурд, ирексез тормышка каршы куелган герой, аның табигый, мәрхәмәтлелек һәм әхлаклылык хас булган образы дөнья сурәтен гармониягә (хаосны космоска) китерерлек итеп уйланылган. Димәк, текст реализм юлында кала, әмма аның төп постулатлары белән бәхәскә керә. Без анда постреализмның төп сыйфатларын табабыз: чынбарлыкны кеше язмышына йогынты ясый торган төрле хәл-әхвәлләр тупланмасы итеп карау; тәртипсез, абсурд тормыш ситуацияләрендә кешене иң мөһим кыйммәт итеп күтәрү шундыйлардан[10]. Безнең фикеребезчә, мондый кискен үзгәрешләргә язучыны тема этәрә.

Әмма аннан соң иҗат ителгән романнарында Р.Кәрами классик реализмга әйләнеп кайта, бу очракта яңартылган реализм (неореализм) төшенчәсен кулланырга мөмкин. «Олы юл да сикәлтәле», «Сөеп туймас чакларым», «Кая чабасың, гомер юртагы?» трилогиясе шундыйлардан.

Шулай итеп, илле елдан артык татар әдәбиятына хезмәт иткән, әдәби барышны күләмле әсәрләр белән баеткан Рәфкать Кәрами иҗаты турында сөйләгәндә, бу иҗатның милли мәдәниятебездә реализм иҗат юнәлеше белән турыдан-туры бәйләнештә икәнен искәртергә кирәк. Язучының иҗади фикерләве XX йөзнең икенче яртысы иҗтимагый-мәдәни тормышында барган үзгәрешләр белән тәңгәл (алардан алда яки арттa калу буларак бәяләнә алмый), һәм әдәби барышта үз урыннарын тапкан башка реалист язучылар: Ә.Гаффар, А.Расих, Э.Касыймов һ.б. иҗатына күпмедер аваздаш. Социалистик реализм сукмагыннан башланып та, аның чикләүләрен үтеп чыгу мөмкинлекләрен эзләү Р.Кәрами әсәрләрендә әхлакый мотивлаштыруның беренче планга чыгуына, мәхәббәт маҗараларының, тарихи-мәдәни мәгълүматларның сюжет таләп иткәннән артыграк күләмдә тәкъдим ителүенә сәбәп була. Шулар ярдәмендә һәм үзенең татарча матур, табигый теле, сурәтләү осталыгы белән язучы әсәрләрнең тәэсир көчен арттыру юллары таба.

Соңрак, XX гасыр ахырында, шәхес культы темасы аша постреализмга килеп, прозаик классик реализм сукмагына әйләнеп кайта. Үзгәртеп корулардан соңгы чор позициясеннән, демократик үзгәрешләр алып килгән мәгълүмати иркенлектән торып совет чорына, шул вакыттагы гади кешеләр, яшьләр тормышына, бигрәк тә эш-гамәлләр, хыял-өметләр, идея-ышанулар, әхлакый принциплар күзлегеннән чыгып бәя бирү омтылышы ясый. Бу омтылыш совет чорындагы «лакланган» бәяләрдән дә, шул ук вакытта заманча яңа әдәбият тудырган сурәттән дә аермалы булып чыга.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*филология фәннәре докторы*

[9] Сверигин Р. Мотаһирның каргышлы язмышы // Ватаным Татарстан. – 1996. – 9 август.
[10] Лейдерман Н.Л. Гипотеза о постреализме // Лейдерман Н.Л., Липовецкий М.Н. Современная русская литература: 1950-1990-е годы. В 2-х томах. Т.2: 1968-1990. – М.: Издательский центр «Академия», 2006. – С.587.

# ТАРИХ – САБАК, ТАРИХ – ГЫЙБРӘТ



Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры, академик, халкыбызның тарихын өйрәнүгә зур көч куйган күренекле галим **Рафаэль Сибгат улы Хәкимов** бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Шул уңайдан журнал укучыларыбызга аның белән әңгәмә тәкъдим итәбез.

***– Рафаэль Сибгатович, Сез җитәкләгән институт ике дистә ел эчендә халкыбызга егерме гасырлык тарихын кайтарып бирде. 7 томлык татар тарихын туплап чыгару – үзе үк тарихи вакыйга. Тарих ул сабакланыр, гыйбрәтләнер өчен дигән гыйбарә бар. Тарихчы, фәлсәфәче, сәясәтче буларак, халкыбызның шушы олы тарихы Сезгә нинди сабаклар алырга, нинди гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирде?***

– Беренчедән, без татарларга һәм Татарстанга төрле уйдырмаларга түгел, ә документларга таянып эшләнгән чын тарихны кайтардык. Әлеге эштә дөньяның иң танылган 200дән артык галиме катнашты. Безне үз тарихыбызны үзебез яздык дип гаепләү мөмкин түгел. Бу хезмәтне кире кагу бик авыр.

Икенчедән, КПСС ҮКның 1944 елгы карары нигезендә, өйрәнү катгый тыелган Алтын Урда чоры тарихы, Миркасыйм Госманов тырышлыгы белән шактый тулы һәм җентекле рәвештә яктыртылды.

Өченчедән, «болгарчылык» һәм «татарчылык» тарафдарлары арасында бернинди дә каршылык юк. Болгар дәүләте татар тарихында әһәмиятле чорларның бары тик берсе генә. Болгарлар үзләре – һуннарның көнбатыш тармагы гына, ә көнчыгыш тармагын, әлбәттә, татарлар тәшкил итә. Көнбатыш һәм көнчыгыш тармаклар берләшкәннән соң, Алтын Урда барлыкка килгән. Болгарларның Батый хан һөҗүменә каһарманнарча каршы торуы төрки кабиләләр арасында даими рәвештә булып торган үзара чуалышлар кысаларында каралырга тиеш. Бу – этник түгел, ә сәяси мәсьәлә. Шуңа күрә «болгарчылык» белән «татарчылык» тарафдарлары арасында үзара килешмәслек катгый каршылыкларга һичбер нигез юк. Бер уңайдан шуны да әйтергә кирәк: Болгардагы мәчетләр, хан сарае, төрбәләр – болар барысы да Алтын Урда шәһәре калдыклары, алар Бату хан башкаласы ыгу белән бәйле. Батуга кадәр ул башкалага охшамаган бер авыл була, һәм анда җимерерлек нәрсәләр булмый.

**– Һәр яшәлгән көн тарихка күчә. «Кичәге», «бүгенге» көннәр дип тарихчылар хәтта тулы гасырларны да атыйлар. Бу гыйбарә фәнни яктан караганда да шулаймы? Әйтик, Казан ханлыгы, Алтын Урда чорларын «кичәге көн» дип кенә бүгенгегә якынайтып әйтүләр – бу чынлыкта фәнни чыганаклар күп булуданмы? Тарих институты галимнәре тарафыннан халкыбыз тарихындагы кайсы ак тапларны юа алдык дип бәялисез?**

– Бу сорауны ике өлешкә аерып карарга кирәк. Беренчесе. Татар халкы, нигездә, Алтын Урда чорында формалаша. Элеккеге чорлардан безгә нилэрдер калган, ләкин Урда күп нәрсәне тамырдан үзгәрткән. Әмма татарларның XIX-XX гасыр

реформаларында җәдитчеләрнең роле зур. Бу чорда татарларның менталитетында, яңа тормыш төзүгә әзерлегендә кискен үзгәрешләр була.

Икенчесе. Җиде томлык («История татар с древнейших времён») татар тарихының ни дәрәҗәдә киң, бай (масштаблы) булуын күрсәтә. Татарлар һәрвакыт дәүләтчелеккә ия халык булган, күпсанлы дәүләтләр төзегән. Алар җимерүчеләр түгел, киресенчә, төзүчеләр. Бату хан үзе генә дә гомерендә 110нан артык шәһәргә нигез салган.

Өченчесе. Чынбарлыкта «татар игосы» вертикаль хакимияттән гыйбарәт булган: (1) кенәзләр хан указы (ярлыгы) нигезендә билгеләнгән; (2) 10 процент күләмендә халыктан салым (ясак) җыелган. Дин әһелләре салымнан азат ителгән; (3) ир-атлар хәрби хезмәткә тартылган. Барлык башка нәрсәләрдә кенәзлекләр автоном булган. Татарлар үз динен һәм мәдәниятен башкаларга көчләп такмаганнар. Монда берниндиdә гайре табигый нәрсә юк. «Монгол-татар игосы» дигән төшенчә рус елъязмаларында күзгә чалынмый. Ул 1817 елда Христиан Крузеның «Атлас и таблицы для обозрения истории всех европейских земель и государств от первого их народонаселения до наших времён» дигән язмасында беренче тапкыр искә алына. XIX гасыр урталарында әлеге хезмәт рус теленә тәрҗемә ителә һәм Петербургта бастырып чыгарыла. Шуннан бирле «татар игосы» темасына мөрәҗәгать итмәгән бер генә тарихчылар буыны да юктыр, мөгаен. Бу ак таплар сәясәт нәтиҗәсендә килеп чыкканнар. Тарих, фән аларның нигезсез икәнен күрсәтте, исбатлады.

***– Тарих институтының өйрәнү-тикшеренүләренең географиясе киңәйгәннән-киңәя. Бу Сезнең күбрәк «Алтын Урдачы» булуыгыздан киләме, әллә өйрәнү-тикшеренүләр нәтиҗәсендә ул киңлекләр үзләреннән-үзләре киңәяме? Ишеткәнебезчә, Сез менә ничә еллар инде Алтай Республикасы, Болгария илләре белән тыгыз хезмәттәшлек итәсез. Ул хезмәттәшлекнең нинди перспективаларын күрәсез?***

– Алтай белән эшләү табигый, чөнки безнең төп тамырларыбыз шунда. Һуннар берләшмәсе, Төрки каганлык нәкъ менә шунда барлыкка килгән. Безнең ата-бабаларыбыз Алтайда металл эретә башлаганнар, металлдан башка корал да, моннан соңгы яулап алулар да булмас иде. Бабаларыбыз төрки рун язуын уйлап тапканнар. Һуннар Дунай ярларына кадәр барып җиткәннәр, шуңа күрә Болгария дә безгә кызыклы. Татар тарихын Татар бугазыннан алып Дунайга хәтле булган гаять зур аралыкны колачлаган хәлдә генә аңларга мөмкин.

***– Әйдәгез әле бүгенге көн вазгыятенә кайтыйк. Быел бөтен дөньяны тетрәндергән Октябрь революциясенә 100 ел тула. Һәр түнтәрелеш тарихка кан белән язылган. Тарих 100 ел элек булган вакыйгаларга кайчан хак хөкемен чыгарыр? Әллә чыгардымы инде? Ул хөкем карары белән академик Хәкимов килешәме?***

– Тарихны «ошый-ошамый» күзлегеннән бәяләргә һич ярамый. Ул ничек бар, шундый. Революциянең кайсын гына алма, барысы да канга буялган – аның табигате шулай. Робеспьер диктатурасына карамастан, Француз революциясенең Франциягә генә түгел, ә бәлки бар Европа тарихына да йогынтысы зур була.

Рус революциясе дөньяны үзгәртте. Әлбәттә, Октябрь революциясе барышында илне Урта гасырдан алып чыгуга тәвәккәл адым ясарга мөмкинлек бар иде. Әмма Гражданнар сугышыннан соңгы вакыйгалар аны котылгысыз тарихи чоңгылга ташлады. Төп гаеп, әлбәттә, Сталинда. Әгәр Ленин озаграк яшәгән булса, ил, мөгаен, Швеция кебек, социал-демократик юлдан китәр иде. Черчилльнең шундый сүзләре бар: «Россиянең беренче фаҗигасе – Ленинның дөньяга килүе; икенчесе – аның үлеме».

***– 100 ел элек булган вакыйгаларның бүгенге глобаль дөньяга йогынтысы әле дә бармы? Нинди ул бүгенге дөнья?***

– Социализм йогынтысында капиталистик дөнья үзгәрде, ул үзе җибәргән хаталарны истә тотып, социаль проблемалар белән шөгыльләнә башлады. Россия исә, ни кызганыч, үзенең үткәненнән гыйбрәт алмады.

***– Федерализм турында Сезнең фикерләрегез журнал укучыларыбыз өчен бик тә кызыклы булыр. Бүген еш кына Россияне федерализм тарафдарлары саклап калды дигән бәяләмәне ишетергә туры килә. Федерализм ник СССРны саклап кала алмады соң? Инде киләчәгебезне фәкать федератив дәүләт төзелеше генә тотрыклы итәрме? Милли мәсьәләләр һаман саен киеренкелек ала барганда, федерализмның үзен алда ни көтә? Милли республикаларның үзәк белән вәкаләтләр бүлешүе – бу федерализмның бер төреме? Киләчәктә андый килешүләрнең дәвамы көтеләме?***

– Федерализм СССРны коткарып кала алмады, чөнки Союз чын федераль дәүләт түгел иде. Союз Килешүе яхшы булды, әмма аны төзүне Горбачёв озакка сузды. Шулай итеп, ил Союзны сүз баткагында батырды.

Илебезнең киләчәгенә килгәндә, инануымча, федерализмга альтернатива юк. Моңа ике сәбәп бар. Беренчесе – этник төрлелек. Икенчесе – бердәм үзәктән торып кына идарә итеп бетереп булмаслык дәрәҗәдә зур территория. Мәгълүм ки, барлык алга киткән илләр федератив. Әгәр Россия дә алга киткән илләр дәрәҗәсенә җитәргә уйлый икән, төбәкләрне көчәйтү турында кайгыртырга тиеш. Көчле төбәкләр – көчле Россия. Көчсез төбәкләр – көчсез Россия. Сайлау мөмкинлеге зур түгел.

Вәкаләтләрне тапшыру килешүләр нигезендә яисә үзәк хакимият карары буенча булырга мөмкин. Ничек кенә булса да, вәкаләтләрне аларны яхшырак башкара алучыларга тапшырырга кирәк. Үзәккә әллә ни күп вәкаләтләр кирәк түгел, әгәр дә ул инде коррупциягә кереп батмаган булса, аңа стратегик функцияләр мөһимрәк: илнең иминлеген саклау (оборона), финанс системасы, тышкы сәясәт, бюджетны өстенлекле юнәлешләргә карап бүлү, дәүләт аппаратын тоту. Калганын рәхәтләнеп төбәкләргә һәм муниципаль берәмлекләргә бирергә мөмкин.

***– Милли мәсьәләләр Советлар хакимлек иткәндә болай киеренке түгел иде, диючеләр бар... Ул вакытта да киеренкелек булган шул. Әтиегез, халык шагыйре Сибгат ага Хәким, шәһәр мәктәпләрендә очрашуларда булып кайткач, укучыларның милли әдәбиятны бик сай белүләренә тирән борчылуын белдерә торган булган. Ул чакта шәһәрләрдә милли мәктәпләр, гомумән, бармак белән санарлык кына калган иде, һәм бу проблема милли мәгариф проблемасы буларак түгел, ә шәһәр белән авыл арасындагы проблема, ягъни сәяси-милли проблема буларак түгел, ә социаль проблема булып каралган, күрәсең... Сәясәтче, Дәүләт Советы депутаты буларак, милли мәсьәләләрне, бигрәк тә милли мәгарифебезне үстерү өчен кичекмәстән нинди чаралар күрү кирәк дип исәплисез?***

– Мәгариф ул, гомумән, милли булырга тиеш. Мәсьәлә аралашу чарасы буларак каралган телдә генә түгел, ә телдә сакланып калган гореф-гадәтләрне, йолаларны, рухи кыйммәтләрне югалтмауда. Мәсәлән, мин балачактан «тәртип», «чаманы бел», «дәрәҗәне төшермә» кебек сүзләрне ишетеп үстем. Башкача әйткәндә, мин үземә тапшырылган эшне җиренә җиткереп, төгәл башкарырга, бар нәрсәдә чама хисен белергә һәм бер читтән икенче читкә ташланмаска, милли абруйны сакларга тиеш. Мин боларны иң мөһим, дөньякүләм кыйммәтләр дияр идем.

***– Союз түгел, җәмгыять тә түгел,***
***Курыкмаган диген ничек, әй,***
***Хакыйкатьне әйтеп бирү өчен,***
***Бер Толстой җиткән, бер Тукай.***

***Сибгат аганың атаклы «Кырыгынчы бүлмә» поэмасындагы бу юлларга бәйләп, шундый сорау бирәсе килә: милләтебезнең бүгенге шартларда да алгарышын тәэмин итү өчен ничә Тукай, ничә Толстой кирәк икән безгә? Иҗат союзлары, милли җәмәгать оешмалары, милли зыялыларыбыз, әдипләребез нинди уй-гамәлләрдә булырга тиеш бүген? Милли матбугатыбыз, радио-телевидение, интернет челтәре ни дәрәҗәдә җәлеп ителгән бу максатка?***

– Халык белән бергә яшәргә, аның ихтыяҗларын, теләкләрен белергә кирәк. Башка критерийлар юк. Мин күп кенә илләрдә булдым, һәр халыкның үз тарихы, үз яшәү

рәвеше бар. Үз мохитеңә чит илдән бер нәрсәне дә күчереп куеп булмый. Башкаларны белергә, өйрәнергә, алга киткән милләтләрдән үрнәк алырга кирәк, ләкин Татарстанда ничек, ни рәвешле яшәргә кирәклекне берәү дә әйтә алмас. Минем Әти һәр җәй авылга кайта торган иде. Ул гомере буе, хәтта язган темасы сугыш һәм Ленин белән бәйле булганда да, һәрвакыт шушы бер авыл турында гына язды. Синең кечкенә генә дөньяң бар кешегә дә кызыклы, чөнки без барыбыз да үзебезнең шул кечкенә тормышыбыз белән яшибез, дия иде ул.

***– Кешелек тарихына ике төрле караштан бәя биреп була: беренчесе – ул тоташтан сугышлар, басып алу-буйсындыру тарихы – бу тарихны, әлбәттә, «җиңүчеләр» яза; икенчесе – кешелекнең рухи, мәдәни үсеше тарихы... Ни кызганыч, бүгенге дөнья тагын да сугыш афәтенә тарыды. Канлы сугыш, салкын сугыш атамалары еш кабатлана бүген...***

***Курск дугасының иттарткычында үлем белән күзгә-күз очрашкан Сибгат ага татар әдипләре арасында иң актив пассифист иде бит. Ни кызганыч, бүгенге телевидение экраннарда сугышның романтик төсмерләрен күбрәк куллана түгелме? Чын патриотизммы бу? Каләм ияләре, әдипләргә ни әйтер идегез?***

– Патриотизмга дошман кирәк, югыйсә ул үзен дәлилли алмый. Патриотизм идеология була алмый, чөнки ул дәүләтнең, икътисади сәясәтнең, әхлакның нинди булырга тиешлеге турында сөйләми. Тыныч заманда патриотизм ул – ни эшләргә белми аптырашта калу кебек.

***– Әдәби журнал мөхәррире буларак, дөнья әдәбияты, милли әдәбиятыбыз, сәнгатебезнең бүгенге хәл-әхвәлләре турындагы фикерләрегезне дә беләсебез килә... Без кайда идек тә, әле кая барабыз? Язучы Рафаэль Хәкимовның каләме кальбендәниләр бар?***

– Бер сүз белән әйткәндә, татарлык. Соңгы китабым «Каково быть татарином?» дип атала. Бу бик җитди китап түгел, ләкин ул чынбарлык, безнең һәм күршеләребезнең тормышыннан алынган вакыйгаларны сурәтләүдән гыйбарәт.

***– Мәгълүм булганча, быел безнең милли әдәбиятыбызның алтын көшеле булган «Казан утлары» журналының да нәшер ителә башлавына 95 ел тула. Сезгә журналыбыз белән даими хезмәттәшлектә булганыгыз өчен, бүгенге әңгәмәгез өчен зур рәхмәтләребезне әйтеп, үзегезнең дә шушы көннәрдә гомер бәйрәмегез – 70 яшь тулуны бөтен әдәбият сөючеләргә җиткерәбез. Сезгә, гаиләгезгә иминлек, бәхет-шатлыклар телибез!***

– Рәхмәт. Мин «Совет әдәбияты» журналының яңа саны чыгуын нинди түземсезлек белән көтүебезне әле дә хәтерлим. Сугыштан соңгы чорда редакциядә Кави Нәҗми, Габдрахман Әпсәләмов һәм Сибгат Хәким эшләде. Атна буе журнал материалларын тикшереп, бары тик шуннан соң гына үзебезнең иҗат эшенә керешә идек, дип сөйли иде әти.

Журналның һәр саны үзе бер вакыйга иде. Хәзер дә шулай... Әдәбиятыбызга, гомумән, халкыбызга хезмәт итүдә уңышлар телим Сезгә!

*Әңгәмәдәш* – **Илфак ИБРАҺИМОВ.**

# «ЗУР ТӘРӘЗӘ БАР ДИП АҢЛА ДӨНЬЯГА КҮКРӘКТӘ СИН»

«Шагыйрьләрнең шигъри җанын эстәп, / Самум җилләр улый үзәннәрдә», – дип язган иде кайчандыр «Мең кат үлеп, мең кат терелерлек» шигырендә Җәүдәт Дәрзаман, үзеннән алда киткән чын талантларның язмышы турында фикер йөртеп һәм, әлбәттә, Тукайны да күзаллап. Барыбызны да уйландырырлык, бик гыйбрәтле һәм чын шагыйрь йөрәгеннән генә чыга торган сүзләр. Инде әдәби һәм фәнни җәмәгатьчелек уздырган чараларда күренмәсә дә, яңадан-яңа әсәрләре белән безне сөендермәсә дә, Җәүдәт абыйның һаман да әдәбият, бигрәк тә шигърият, аның да кечкенәләргә атап иҗат ителгән кыйсме өчен җан атуына шикләнмим. Иҗтимагый тормышның шактый болгавыр вакытларында – 1988-1994 елларда хезмәттәшләре тарафыннан «Ялкын»га баш мөхәррир сыйфатында сайланып куелганнан соң, журналны балалар рухына якынайту, укылышлы һәм эчтәлекле итү юлында зур көч куйган Җәүдәт Харис улы Дәрзамановны һәрвакыт олы ихтирам хисләре белән искә төшерәм.

Танылган балалар шагыйре, прозаик, журналист Җәүдәт абый Дәрзаманның иҗатка үзеннән алда килүчеләр белән исәпләшүенә, алар мирасыннан этәрелеп китеп еш язуына гаҗәпләнмим. Ул – сүз сәнгатебез белән яхшы таныш һәм аның уңышлы алым-чараларын тотып алган, үзенеке дә иткән, шуның аркасында мирасханәбезне бездән соң да укылырлык әсәрләр белән баеткан иҗатчыларның берсе.

Традицион кысаларга өстенлек биргән Ж.Дәрзаман иҗатының Тукайныкы белән бәхәскә алынмаслык тыгыз бәйләнеше бар. Дөрес, аның шигъриятта тукайчы булуы бар кеше өчен дә кычкырып тормый, ягъни шагыйрьгә багышланган күпсанлы әсәрләрдә чагылыш тапмый. Моны эчке сиземләү белән тоярга һәм фәнни белемеңә таянып кына аңлатырга була. Шул ук вакытта Җәүдәт Дәрзаманның өлкәннәргә адресланган кайбер әсәрләренең Тукай иҗаты белән элемтәсен интертекстлар ярдәмендә дә исбатларга мөмкин. Әйтик, ул кайвакыт әсәрләренә эпиграф сыйфатында Тукайдан алынган юлларны куя, әмма алардан этәрелеп китеп, иҗади кумирыныкыннан аермалы темаларга килеп чыга яисә бөтенләй башка интонацияләрдә, эмоциональлектә иҗат итә. Мәсәлән, аның «Диктор Данил Ибраһимовка» дип исемләнгән юмористик шигырен Тукайның «Шүрәле»се мотивлаштыра. Моны «Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл, Кырлай диләр» эпиграфы һәм: *«Гәрчә озак тормасаң да, / Син анда туган идең, / Җир тырмалап тормый гына, / Шәһәргә «шуган» идең»*, – рәвешендәге Тукайдан трансформацияләнгән строфалары ачык күрсәтеп тора.

Җәүдәт Дәрзаман иҗатының Тукайныкы белән бәйләнешләре төрле планда бара. Әйтик, «Ап-ак карлар ява» поэмасында лирик мин Тукай, Такташ кебек танылган шәхесләрне, татар тарихында булып узган эш-хәлләрне искә төшерә, алар арасында янәшәлекләр уздыра. Әсәрнең Тукайга мөнәсәбәтле өлешендә ул кышкы матур көндә урамда барганда бер теләнче картны күрә, һәм аның күңелен: *«Гасыр түгел, бары еллар санап, / Тукай язган ул карт кайткан кабат»*, дигән уйлар борчый башлый. Моның белән шагыйрь, тарих алга барса да, шул ук проблемалар кешеләрне сагалый дип әйтергә тели, Тукай иҗатының искермәвен, һәр чорда актуаль калуын күрсәтә. Икенче яктан, шагыйрь рухи остазы тудырган образларның күңел түрендә яшәвен, тормышта әледән-әле хатирәләрен җанландырырлык сәбәпләр тууын сөйли. Чыннан да, аның күкрәгендә, Тукай әйткәнчә, дөньяга зур тәрәзә бар.

Ж.Дәрзаман мирасханәсендәге кайбер мөһим чәчмә әсәрләрне дә Тукай язганнар мотивлаштыра. Әйтик, каләм иясенең тормыш-яшәеш турында физик-физиологик хәл-халәткә бәйле уйланулары рәвешендәге «Ник кирәсез төшләремә?» эссесена фәлсәфи-лирик ачкыч рәвешендә Г.Тукайдан *«Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул!»* юллары сайланган. «Драматургия классигы Г.Камалга» адресланган

«Тормыш – сәхнә» әсәрендә исә, яңа заманда барган үзгәрешләрне тасвирлаганда, Җ.Дәрзаман шулай ук аларның да элекке чорларга, Тукай, Исхакый, Җәлилләр заманына аваздашлыгын әйтә:

*«Тарих төпкеленнән Тукай калка,*
*Күз салыйм дип печзән базарына.*
*А!*
*Никадәр охшаш заман килгән,*
*Ни кадәрле азык язарына.*
*Тормыш – сәхнә.*
*Килгән заманалар,*
*Бер ишарә гүя үткәннәргә».*

Аталган поэмада Җ.Дәрзаман иҗтимагый-сәяси проблемаларны, аларның бигрәк тә милләтләр яшәешенә кагылганнарын Тукайча кыю күтәреп чыга. Язучы татарның үзенә генә бәйле, бигрәк тә аның җитәкче төркемнәренең гаделлегеннән, рухларының сафлык дәрәҗәсеннән торган мәсьәләләр хакында да сөйли. Төрле бүләкләр, шул исәптән Дәүләт премияләре бирү-алуга мөнәсәбәтле ул болай дип яза: *«Тормыш – сәхнә. Яшәү – комедия. / Тамашачы бары көлә генә. / Тәкъдим булса, бүген Тукай үзе / Узмас иде Тукай бүләгенә»*.

Китерелгән цитата, һичшиксез, Тукайча көлү үрнәге булып тора. Ул – адресатлы, үткен яңгырашлы, шул ук вакытта асмәгънәле һәм гаять тә актуальлеккә ия.

Җ.Дәрзаман – Тукай кебек киңкарашлы, төрле жанр һәм формаларда һәм төрле яшьтәге укучыларга атап иркен язган, заман белән бергә атлаган каләм иясе. Шулай да әдәбият сөючеләр аны, алда да сиздереп алганча, балалар шагыйре буларак яхшырак белә. Җәүдәт абыйның Тукай алымнарын нык саклаган, остазы сайлаган юлдан үскән шигъри өлкәсе дә – нәкъ менә балалар әдәбияты. Ул, «Айбулат», «Карурман кунаклары» әкият-поэмалары белән, шулай ук Тукай заманында балаларның яшь үзенчәлекләрен искә алып язылган, дәреслекләргә кертелгән һәм инде заманча рухлы, шәкли камилләшеп беткән, киңкатламга аңлаешлы, шул ук вакытта өлкәннәр өчен дә кызыклы булган эпик поэзиябезне тагын да үстерде, баетты.

Югарыда телгә алынган әсәрләргә фольклорчылык Тукай аша да, Тукай сайлаган традицияләрне дәвам итү рәвешендә дә үтеп керә. «Карурман кунаклары» дигән атаманы укуга, чын татар баласы күңеленә Г.Тукайның “Кәҗә белән сарык», «Шүрәле» тасвирланган серле карурман, аның әкияти каһарманнары киләдер дип беләм. Әлбәттә, башкалар язган сюжетларны кабатламаска тырышып иҗат иткән Җ.Дәрзаманда инде икенчерәк каһарманнар һәм аларның саннары да бик күп. Шул ук вакытта геройлар арасыннан Тукайныкыларга охшашракларны, һичшиксез, табарга мөмкин. Әйтик, «Карурман кунаклары»нда без тормыш тәҗрибәсе, акыллылыгы, хәйләкәрлеге аркасында урман хайваннарыннан аерылып торган һәм Бүрене акылга утырткан Кәҗә белән очрашабыз.

Җ.Дәрзаман, заманнан калышмыйча иҗат итүче булса да, тормышта булмастайны язган, планетаара, галәмара сугышларны, әллә нинди куркыныч җан ияләрен тасвирлаган каләм әһелләре юлыннан китми – милли әкият каһарманнары галереясы үсәргә тиешлекне, улларыбыз һәм кызларыбыз, оныкларыбыз һәм оныкаларыбыз, беренче чиратта, үз рухи-мәдәни байлыгыбызда тәрбияләнергә тиешлекне аңлап эш итә. Аның иҗаты, Тукайның балалар өчен язылган әсәрләре кебек, табигатькә, башка төрле җан ияләренә, Туган җиргә, шул җирнең игелекле затларына мәхәббәт тудыруны күздә тота.

Җәүдәт Дәрзаманның балалар шигърияте, Тукайныкы кебек, ачык аңлаешлы, төзек калыплы, тормышның төрле якларын иңли һәм баланы тирәлек-табигатькә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә, ел фасылларына, көндәлек эш-хәлләргә бәйле мәгълүмат белән баета. Шулай итеп, ул аны киләчәк тормышка, олылар дөньясына керергә хәзерли. Җәүдәт абый язган әсәрләрдә җиңелчә юмор, киная алымнары еш кулланыла, әмма алар барыннан да бигрәк якты төсләр, хисләр, шатлык авазлары кебек күңелгә сеңә.

**Рифә РАХМАН**

## Кереш сүз

*Әле күптән түгел генә Казан университетының Сирәк кульязма китаплар бүлегендә XIX гасыр татар шагыйре Әхмәтҗан Тубылиның (1825-189?)[1] 701-т номеры белән тагын бер кызыклы кульязмасы табылды. Аның кем тарафыннан, кайда табылуы билгеле түгел. Ә.Тубыли аны Тубыл (Тобольск) шәһәрендә сөргендә вакытта язган. 1-11 битләрендә көйләп укыла торган, әхлакый характердагы кыска гына хикәяләр урын алган. 11-49 битләрне шактый зур күләмле «Мәшһүр вә мөтәгәррриф улан Фәрһад гашыйк илә мәгъшук Ширин хикәясе» тәшкил итә. Ә.Тубыли кульязманың беренче битендә үк Фәрһад һәм Ширин турындагы әсәрен кайчан тәмамлаганын әйтеп китә: «Тарих миляди 1879 санә бөрҗи-җәүзәнең[2] 13нче йәүмендә тәмам улынды».*

*Татарлар арасында Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә, Йосыф-Зөләйха, Сәйфелмөлек-Бәдыйгелҗәмал турындагы мәхәббәт әсәрләре киң таралган. Ләкин Фәрһад һәм Ширин мәхәббәте турындагы тарих фольклорда һәм әдәби әсәрләрдә бик сирәк очрый. Моның сәбәбе, бәлки, шунда ки: Низами, Нәваи, Әмир Хөсрәү Дәһләви, Җами кебек Шәрекънең бөек классиклары әсәрләрендә Фәрһад белән Ширин мәҗүси диндәге кешеләр булып күрсәтеләләр һәм бу ике гашыйкның мәхәббәте күбрәк дөньяви планда сурәтләнә. Эчтәлеге буенча һәм композицион яктан Ә.Тубыли әсәре, Низами, Нәваи поэмаларыннан аермалы буларак, Фәрһад һәм Ширин турындагы төрки легендаларга якын тора.*

*Татар әдәбиятында бары тик ике генә шагыйрь бу сюжетка мөрәҗәгать итә: Алтын Урда чоры әдибе Котб (XIV г.) һәм XIX гасыр шагыйре Әхмәтҗан Тубыли. Котбның «Хөсрәү-Ширин хикәяте» текстын җентекле һәм җитди рәвештә Х.Й.Миңнегулов һәм Р.Г.Әхмәтьянов тикшереп чыктылар. Р.Г.Әхмәтьянов аны хәзерге татар әдәби теленә күчерде[3] . Әхмәтҗан Тубылиның Фәрһад белән Ширин турындагы хикәясенә килгәндә исә, шуны әйтергә мөмкин: ул төрки-татар әдәбиятларында киң таралыш тапкан катнаш проза белән шигъри (бәйтләр белән; алар текстта курсив белән бирелде) рәвештә язылган. Ихтимал, әсәрнең фольклористик варианты булгандыр. Тик анда әдәби интерпретацияләр шактый гына күп урын алып тора. Шуңа күрә аны татар авторының оригиналь әсәре дип атап була. Кызганыч ки, кульязманың соңгы битләре сакланып калмау сәбәпле, бу гүзәл әсәрнең азагы юк. Шулай да «Мәшһүр вә мөтәгәррриф улан Фәрһад гашыйк илә мәгъшук Ширин хикәясе»нең сакланып калган өлеше 76 кульязма сәхифәдән гыйбарәт. Текст кыскартылган вариантта бирелә.*

# МӘШҺҮР ВӘ УКЫМЫШЛЫ БУЛГАН ФӘРҺАД БЕЛӘН МӘГЪШУКАСЫ ШИРИН ХИКӘЯСЕ

Равилар түбәндәге риваять һәм шундый хикәят итәләр ки, Гаҗәм икълимында һәм Хөрәсән өлкәсендә бер зур шәһәр бар иде. Һавасы әйбәт урында урнашкан булып, тирә-ягын баг-бакчалар, гөлбакчалар биләп, һәр бакчада бер зур гына инеш бар иде. Һәм шәһәрдән дүрт якка ераграк киткәндә киң сәхрә, анда куаклыклар, сөнбелләр, миләүшәләр, ләләләр үсә иде. Һәм ул сәхрәнең уртасыннан зур елга шаулап ага иде.

Ул шәһәр халкы барчасы күңел ачу, кәеф-сафа илә мавыга иде. Өстәвенә шәһәрнең ире булсын, хатын-кызы булсын бик матурлар иде. Берәрсенең йөзенә баксаң, матур бөдрә чәчләре күңленә уралып әсир итәр иде. Һәм ул илнең патшасы хатын кеше иде,

[1] Аның турында кара: Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли // Казан утлары. – 1997. – №1. – Б.147-154; Ахметзянов М.И. Новые археографические материалы и их значение в исследованиях по истории татарской литературы // Дис. ... докт. филол. наук. – Казань, 1998. – С.285.

[2] Бөрҗи-җәүзә – төрки календаре буенча зодиакаль ай исеме. Май-июнь аена туры килә.

[3] Котб. Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман). – Казан: Мәгариф, 2003. – 363 б.

һәм ул илдә шундый кагыйдә бар иде: патша үлеп, аның углы калмаса, кызын тәхеткә утыртып, патша итәләр иде. Һәм менә бер заман патша булып Мәһмәнәбану[4] исемле хатын тора иде. Аның берничә акыллы вәзире бар иде. Һәрберсе гакыл вә гамәл иясе иде. Һәм ошбу падишаһның дәүләт башында торган елларында бар тирәдәге дәүләтләр тыныч иминлектә иде. Тик тирәдәге хәтта күп гаскәрле булган шаһлар да, Мәһмәнәбанудан хәвефләнеп, ел саен һәдия-бүләкләр бирәләр иде.

Мәһмәнәбануның кыз карендәше бар иде. Исеме Ширин булып, Зөләйхага тиң матур иде. Йөзе-күзе ачык, керфекләре – ук, кашлары – җәя. Һәм бу ир-атның күңелен багларлык заман афәте нибары ундүрт яшендә, Дәүләт көлаһы[5] башында иде. Шунлыктан мәзкүр шәһәрдә бик атаклы иде. «*Адәм заманыннан бирле килмәгән синдәй бер гүзәл, / Исемең – Ширин, сүзең – ширин, син инде шундый бер гүзәл»*, – диерләр иде.

Мәһмәнәбану Ширин өчен матур күшек[6] һәм күркәм касер[7] төзетмәкче булды. Чөнки Мәһмәнәбану Ширинне шулкадәр ярата иде ки, ансыз бер минут торалмас иде. Мәһмәнәбануның бер оста төзүчесе бар иде. Һөнәрдә гаять үсешкән, һәртөрле сәнгатьне үзләштергән иде. Һәндәсә[8] гыйльмендә җиде дәрәҗәсе[9] бар иде. Һәм аңарда берничә шәкерт өйрәнә иде. Алары да һәндәсә гыйльмендә маһир иделәр. Бәс, Мәһмәнәбану ул төзүчене чакырып әйтте: «И төзүче, Ширин өчен бер күшек ясатырга телим, ләкин ул шундый булсын, дөньяның дүрт өлешендә дә тиңе булмасын иде», – диде. Төзүче, җир үбеп: «Шаһ фәрманыңа, мин әзер», – диде.

Мәһмәнәбану аңа бәясе бөтен өлкәдән алынган салым акчасы кадәр торган кием бүләк итте. Төзүче шатланып, шаһинә ягыннан чыгу белән, һәндәсә гыйльмен кулланып, һәркөн таңнан алып йолдызлар кабынганчы кадәр эшләде. Мәһмәнәбану ул касерне җиде кат күккә охшатып, җиде кат күкнең һәрберсенә тиеш итеп эшләргә кушты. Әүвәлге касер тулган ай[10] шикелле ак төстә булса, диван әһле шул төстәге киемнәр кисен. Падишаһның аңа килгәндә кигәне дә ак була. Икенче касернең исеме Меркурийга нисбәтле, төсе зәңгәрсу, шуның өчен анда намаз укырга зәңгәрсу киенәләр. Өченче касернең аты Зөһрәдер. Төсе ал һәм һәммә диван әһеле ал кияләр. Дүртенче касер ай төсендә сарыдыр, диван әһеле сарыдан киенәләр. Бишенче касер Миррих-Марс, кызыл төстә һәм диван әһеле вә шаһ үзе кызылдан киенә. Алтынчы касер Юпитерчә, төсе яшел, диван әһле яшелдән киенә. Җиденче касер Сатурнча булырга тиеш, төсе карасу, диван әһле кара киенәчәк.

Шуннан соң төзүче оста шул күрсәтмәләр буенча касерләрне төзеп бетерде. Хәзер бизәкләргә кирәк иде. Ул шәһәрдә бер оста бизәкче бар иде. Бәһзад нәккаш диерләр иде. Төзүче-архитектор ул Бәһзадны чакырып, [касерләр янындагы] күшекне буяу-бизәүне аңа тапшырды.

Әлеге нәккашның бер углы бар иде, атына Фәрһад диерләр иде. Ул да әтисе кебек һөнәрче иде. *«Әле тик унбиш яшендә, дәүләт таҗы башында. / Гыйззәт һәм шәрәф кафтаны[11] өстендә, кулы һаман эшендә»*. Кашы, керфеге кара, муены ак, күз бәбәкләре кара, үзе гаять якты төстә, яңаклары гөл, күзләре хыялый шикелле. Тәне камфара һәм, гомумән, тулган ай кебек иде ки, аны бер күргән кеше җаны белән мәфтүн булыр, тартылыр иде.

Ничектер бер көнен болар аталы-угыллы ул күшекне бизәгәндә, иркә кыз Ширин эшне карарга дип, аның белән бергә Мәһмәнәбану да йөрергә чыгып, икәүдән-икәү бакчага килделәр. Күшек тирәли карап йөргәндә, Шириннең күзләре нәккашның углы Фәрһадка төште. Һәм Ширин, шул сәгатьтә җаны-тәне, эче-тышы белән гашыйк булып, үз-үзен көчкә кулга алып, баш төзүчегә: «Болар нинди бизәүчеләр?» – диде. Төзүчеләр башлыгы: «Болар, солтаным, ике нәккаш, әтисе һәм углы, әтисе Бәһзад,

[4] Мәһмәнәбану – борынгы легендар Иран патшабикәсе Семирамида. Мәһмәнәбану – аның прототибы.
[5] Көлаһ – гадәттә, дәүләт кешеләре һәм кызлар кия торган ялбырколаклы киң бүрек.
[6] Күшек – җәйге зиннәтле сәрайчык.
[7] Касер – зур булмаган хәрби ныгытма.
[8] Һәндәсә – геометрия; бу очракта – инженерлык.
[9] Дәрәҗә – осталык дәрәҗәләре мөселман илләрендә элек тә булган.
[10] Семирамида борынгы Бабил-Вавилон патшабикәсе Саммурамат (Шаммурамат) белән ярыша кебек. Алар да җиде төстәге касерләр корганнар. «Семирамида баглары» борынгы антик заманнарда дөньяның «җиде гаҗәеп корылмасы»ның берсе булган.
[11] Кафтан – төрки-татар сүзе (каты «к» белән әйтелә). Тексттан күренгәнчә, «кафтан» татарча «каптал»; һөнәрчеләрнең киеме булган.

углына Фәрһад диләр», – диде. Шулай итеп, Ширин боларны бик яратты, Фәрһад та бер карауда Ширингә шундый мәхәббәт баглады, әйтеп-сыйфатлап бетермәле түгел.

Мәһмәнәбану белән Ширин сәрайдан чыгып, күңел ачулар һәм уенлы-чынлы сөйләшүләр белән мәшгуль булдылар. Әмма Шириннең дәртенә гыйшык уты кабынып, сабыры-карары калмыйча, бер сылтау белән кулына гаҗәеп алтынсу лимон алып, бергәй кеше-фәлән булмаганда Фәрһад эшләгән төшкә барып, нәзакәт белән үзен күрсәтте. Һәм Фәрһад [кем йөри икән дип] әйләнеп караса, Ширин алтын лимонны аның нәкъ күкрәгенә тондырды да, Фәрһад лимонны тотып, үзенә атканны күргәч, тиз генә бер якка тайпылды. Һәм Фәрһадның да гашыйк икәнен аңлап, артык мавыкмыйча сәрайга кайтты, һәм Фәрһад та ахшамгача көчкә эшләп, төнен күзләренә йокы кермичә, иртән иртүк торып, атасыннан өч сәгать элек эшкә тотынды. Равилар әйткәнчә, бу тарафтан Шириннең гыйшкы ялкынланып яна башлады. Тагын кулына алтын лимон алып, сак-сак кына килеп, гөлләр арасыннан ай кебек күренеп, тагын Фәрһадка лимон ыргытты. Фәрһад шундук әйләнеп карады һәм Ширинне күрү белән кулындагы фөршаты[12] төшеп китте – ул һуштан язды. Шуннан Ширин сәрайга кайтты. Фәрһад бераз ятып, аһ-ваһлар белән, һушына килеп, кичен өйгә кайтып бераз ял иткәч, төн уртасыннан торып, ахшамда ук эш урынына килде. Ике көн узды. Шириннең сабыры-тәкате калмады. Галәмдә беркем булмаган кебек вакытта бакчага килде. Һәм бичара Фәрһад тагын да элекке тиешле даирәсеннән чыгып, биһуш булып егылды. Ширин бу хәлне күрде дә, форсатны ганимәт белеп, тиз генә килеп, Фәрһадның яңакларын берничә тапкыр үбеп, түбәндәге бәйтне язып, дивана Фәрһадның баш очына куеп калдырды. Бәйт: *«Белмәм, мәләкме син яки фәрештә, аклым алдың, әфәндем, бер күрештә. / Мин бит дәрт хәлләрен һич тә белмәгән идем һичбер гәз. / Мәхәббәт бер бәла шәйдер, грифтар булмаган белмәс»*.

Шуннан соң Ширин сәрайга кайтып китте. Шунда Фәрһад һушына килеп, ул кәгазьне табып укыды. Тагын аһ итеп һушыннан язды. Соңыннан акылына килеп, алтынлы рам һәм буяулар илә Шириннең рәсемен ясады.

Кич-иртән ул тасвирга багып-карап, күңелен юатыр иде. Ләкин кичә-көндез күзләреннән яшь урынына кан агар иде[13]. Әмма бу тарафта Ширин дә саргаеп сулды. Менә бервакыт төн чагында гөлстанына сәрай паркына барып күшеккә каршы утырып, бу бәйтне сөйләде: *«Ширин әфәнде бер ширингә[14] төште: аһ итеп күңеле Ширингә төште. / Күзләребез шундук язмышка баглап, Фәрһад белән Ширин бу көнгә төште»*. Фәрһад капка янында эшләр икән. Бу былбыл авазларын ишетеп, күңеле бер үлеп, бер терелеп, сабыры-тәкате калмыйча, шунда тагын бер тапкыр аһ итеп, бу бәйтне әйтте: *«Күзләрем шикәр, имеш, кем дисәң, Ширин, имеш. / Мин аны шикәр дисәм, чыннан да, ширин, имеш»*, – дигәчтен, Шириннең сабыры-тәкате калмыйча, шундук йөгереп килеп, болар бер-берсенә сарылып, гүя ки лаякыл исерек булдылар. Бераздан үз-үзләрен кулга алып, бераз шатлыча сөйләшеп, шуннан соң Ширин сәрайга китте. Фәрһад бичара, тагын ялгыз калып, бу бәйтне укып әңләнде[15] : *«Минем күңелем дәртеннән, һәр кала багып әңләнер. / Әңләнмичә мөмкин түгел, бу хәлгә багып әйләнер»*.

Шулай итеп, ул көн ахшам булып, төзүчеләр башлыгы кул астындагыларга ялга рөхсәт бирде. Ширин белән Мәһмәнәбану килеп күшекне карадылар. Бик канәгать булдылар вә тагын кечерәк күшек ясатырга карар кылдылар. Мәһмәнә, төзүче башлыкны чакырып: «Афәрин осталыгыңа, әмма бу күшекнең каршысында тагы кечерәк бер күшек булуын телим һәм аның монысыннан бераз матуррак нәкышле булуын эстәр», – диде. Төзүче башлык «фәрман – солтаннан» дип, киләсе иртәдә эшкә керешеп, берничә көн эчендә тагын бер күшекне төзеп куйды.

Бу көннәрдә Шириннең дайәсе[16] аның белән Фәрһад арасында мөгамәләрне күзәтеп тора иде. Һәм күңеленнән «бер нәккаш углы белән бер патша кызы арасында нинди мөнәсәбәт булырга мөмкин» дип, гыйшык уты барлыгын башына да китермәде. Ә тегеләр исә кичә-көндез гыйшык утында яндылар. Ул арада, кыскача әйткәндә, күшек тәмам булды. Нәккашлар да китеп бардылар... Мәһмәнәбану белән Ширин күшекне бер тамаша кылдылар да сәрайга киттеләр.

[12] Фөршат – буяу пумаласы.

[13] «Күздән яшь урынына кан агу», әлбәттә, төп-төгәл мәгънәдә түгел, фольклорда да «төрелгән» фразеологизм гына (күп тапкыр очрый).

[14] Ширин – төп мәгънәсендә «шикәрле су».

[15] Әңләнде – моңланып җырлады.

[16] Дайә – мөселманнарда балаларны балигъ булганчы карап-багып йөрүче хатын.

Көннәрдән бер көн Мәһмәнәбану, сарае тирәсендә гизгәндә, бер тирән чокырны ябып-бикләп торган зур бер таш күрде. Ул зур ташны заманында Сөләйман пәйгамбәр диюләре китереп куйганнар иде. Моның тирәсендә йөргәләгән җарияләр «әллә бу бер кое микән» дип, килеп колак тоттылар. Аста су агып ятканлыгын Мәһмәнәбануга хәбәр иттеләр. Мәһмәнәбану әмере буенча хезмәткәрләре килеп, ул ташны тырыша-тырыша бераз кузгатып, бер бакыр чиләк илә бераз су чыгардылар. Тик берәве дә ул суны эчәргә җөрьәт итмәде. Үлемгә хөкем ителгән бер кешене төрмәдән китереп, ул суны эчерделәр, берни булмады. Шуннан барысы да эчтеләр. Шикәр ширбәтенә охшаш эчемлек татыдылар. Ширин әйтте: «Бу су безнең касеребезгә булса иде. Бер хәвез ясатыр идек». Мәһмәнәбану осталар чакырып каратты, чара таба алмадылар. Чөнки касер белән теге ташландык кое арасында зур тау бар иде. Мәһмәнәбану әмер итте: кем дә кем шул суны килтерер исә, ни теләсә, шуны бирәм, дип. Беркем дә батырчылык итмәде, чөнки «мөмкин түгел» диярләр иде. Тик Фәрһад кына, бу хәбәрне ишетү белән: «Мин суны күчерә алам», – диде. Мәһмәнәбану: «Әгәр син бу эшне булдыра алсаң, ни теләгең булса да, үтәрмен», – диде. Фәрһад әйтте: «И, шаһым! Минем синнән теләгәнем – капу агалыгыдыр[17]», – диде. Мәһмәнәбану: «Мин сине сәрайга эшкә алам, тәхеткә утыртам», – диде. Фәрһад: «Минем карашымда капу агалыгы синең тәхетеңнән дә биегрәктер», – диде. [Бу сүзләр] Мәһмәнәбануга ошап, шундук әмернамә булып, [сәрай хезмәткәрләренә] «эшкә ни кирәк булса, бирәсез», дип фәрман итте.

Равилар әйтер ки, бу тарафта Ширин-назның хәле көннән-көн пәришан-кайгылы булып, гыйшкы ялкынланып, ниһаять, Мәһмәнәбанудан Фәрһадны барып күрергә рөхсәт сорады. Мәһмәнәбану рөхсәт итте. Ширин сәрайдагы күпсанлы кызлар вә җарияләр белән йөреп, җирле-мәхәлли мүрәдкә[18], арба-көймә остасына барып, бер мәгәлдәк[19] алып, юлга карар итте.

Ә бу тарафта Фәрһад бичара күрде ки, Ширин килә. Шундук кулындагы киркәсен куеп, сәламләүгә урыныннан торды. Мәрхәбәләшкәч, Ширин сазын чиртеп, былбыл сайраган кебек бу бәйтне әйтте: *«Мине җәфага салган җәя кашым каршымдадыр, / Вә сөеп, бәндә итеп елаткычым каршымдадыр»*. Һәм кулындагы сазын Фәрһадка сузды. Карыйк, Фәрһад ничек җаваплар: *«Бәндәсен җәфага салган, Йари-гарым[20] килде янә, гүзәлем. / Язгы гөлләр кеби миңа, гүзәлем, һәрвакыт дөнья шатлыгы янә, гүзәлем. / Ләгылем[21], күңел уем, рәхимле бул, бул ягымлы Фәрһадыңа, гүзәлем. / Минем имкян юк хәзер үк, сөймәгә, гүзәл шаһым. / Бар ки күкләрнең казасы, валлаһи, шуңа аһым»*, – дип, сазын Ширингә бирде. Ширин дә тагы күрик ниләр сөйләде: *«Ашкарә[22] булмас иде дәрт, бер кыенлык булмаса, / Кемсәләр белмәс иде, аһ, бер кырын[23] як булмаса»*, – дип, болар бер-берләренә сарылып, ниһаять, серебезне берәрсе күрә калмасын дип, бәрәләп-куркынып тизрәк аерылдылар да, Ширин ялт-йолт сараена килде. Шуннан соң Ширин һәр өч көн саен Мәһмәнәбанудан изен[24] алып, тамаша итим дип Фәрһадны күрергә килер иде.

Равилар әйткәнчә, Фәрһад инде бер риваятьтә – кырык көндә, бер риваятьтә бер елда Ширин гыйшыгында теге суны агызды. Су хәвезгә килгәч, бихисап корбаннар киселде – бәйрәм ителде. Мәһмәнәбану Фәрһадны баштанаяк кеш тиресеннән тегелгән киемнәргә төреп киендерергә теләде. Ләкин Фәрһад моңа бөтенләй игътибар итмәде. Фәрһадны мунчага җибәреп, бер букчайга затлы кием-салым күндерде һәм, ул мунчадан чыккач, шул киемнәргә киендерделәр. Шуннан Фәрһад Мәһмәнәбану каршысына килеп, җир үпте. Мәһмәнәбану әмер итеп, бер хуш исле үлән түшәделәр, Фәрһадка бер хезмәткәр һәм бер кол тәгаен иттеләр. Әмма Фәрһад: «Мин үзем хезмәткәрмен, миңа хезмәткәр кирәкми», – диде. Ләкин Мәһмәнәбану ашчылар башлыгына, әмер итеп: «Көн саен өч суфра[25] миңа китергән шикелле тәгамне аңарга бирәсез», – диде.

[Мәһмәнәбануның Фәрһадны үзенә ир итеп, патша ясарга тырышулары нәтиҗәсез кала. Шуннан соң Мәһмәнәбану Фәрһадны төрмәгә утырта. Фәрһад төрмәдә утырганда, музыкаль аләтләрдә уйный, җырлый һәм шигырьләр яза. Аның шигырьләре бөтен

[17] Капу агалыгы – капка сакчыларының башлыгы.
[18] Мүрәд – арба төре.
[19] Мәгәлдәк – ябулы карета.
[20] Йари-гар – Әбүбәкер сәхәбәнең кушаматы, гомумиләштерелеп, «тугры дус» мәгънәсендә дә кулланылган.
[21] Ләгыль – асылташ.
[22] Ашкарә – Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән билге.
[23] Кырын – тискәре.
[24] Изен – рөхсәт бирү.
[25] Суфра – өлеш.

илгә тарала. Бервакыт Мәһмәнәбануның төшендә Фәрһадны азат итәргә кушыла һәм Мәһмәнәбану аны төрмәдән чыгарта. Фәрһад шәһәрдән тауларга китә, анда берүзе, төрле кыргый хайваннар белән дус булып яши һәм Ширинне сагынып вә үз кайгысын белдереп җырлар чыгара. Бермәл хайваннары белән калага килеп, Ширин яшәгән сәрай алдына тукталып, музыка чалып-җырлап, Ширин белән аралаша. Ләкин Ширин сәрайда бикләнгән хәлдә, беркая да чыгалмый. Фәрһад тагын таулар арасына китә.

Бермәл ул таулар арасына Мәһмәнәбануга күрше дәүләт патшасы Хөрмүз яуга килә. Хөрмүз һәм аның аучылары төркеме бер тукталышта гаҗәп музыка һәм җыр авазларын ишетәләр. Эзләп барып карасалар – ерткыч хайваннар урталыгында үзе дә ерткычсыман булып беткән Фәрһад утыра. Хөрмүз аның белән сөйләшә, хәлен белә. Фәрһад бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Бу сүзләрне ишетеп, Хөрмүз Фәрһадны сөйгән яры Ширин белән кавыштырырга вәгъдә бирә].

Вә Хөрмүз шаһ Фәрһадка әйтте: «Егетем, шул кулыңдагы сазны беркадәр чал, минем өчен һәм дустың Ширин өчен. Һәм сукбайлык хәлләреңнән беркадәр шигырь сөйлә», – диде. Фәрһад та сазны кулына алып, карыйк, ни сөйләде: *«Мин гашыйк, ялгыз вә хәйран кылды айрылу, камәтем ким кылды, күзем яшь, коң[26], айрылу. / Айрылу чире кыйлгандыр күңелемне харап, мондый кайгы күрмәдем күргәнче мең моң айрылу. / Язмышым елау икәндер, дидем, и шаһе-җиһан, И ашинам[27] , дәртең белән кайгы сондың (соңыннан) айрылу. / Кемне күрсәм дә хәлемә рәхим әйлә, дим дә мин, юк сине күргән берәү, кайчан беләр соң айрылу? / Аһ, нигә алдырдым кулдан, шундый назлы яр иде, әй, гаҗәп, кемләр күрә ярны, булгач язмышың айрылу. / Фәрһадыңа йөз чөерде, дөнде бу чәрке-заман, язмышым мал-мөлкемә гамьнәр өстәде бигөман. / Гадәтем булды шуннан соң миңа аһ илә фиган[28], өсти гамьне вакыт үтү, җәй вә кышын айрылу»*, – дип, тагын зар-зар елады. Болар хәйран калдылар. Шаһ әйтте: «Минем күңелем өчен тагын бер җыр җырла. Мин ант итәмен ки, Мәһмәнәбану минем таҗ вә тәхтемне тартып алалса да, мин вәгъдәмнән чигенмәм – Ширинне сиңа алып бирермен», – диде. Фәрһад бу сүзләрдән рухланып, тагын шундый бер бәйт әйтте: *«Айрылу кайгысын итәем мин кабаттан, шулчаклы миңа ярымны күпсенде фәләк. / Галәм багында бардыр бер гөл-чәчәк аткан, куймады шуңа мине, гүяки күп күрде фәләк. / Аерды ярым Ширинне миннән ул тиз үк, тиз таптым, тиз югалттым аны тик бер үбеп. / Бу тауларда ялгызын ялыктым гел йөреп, миңа бер сөйкемле сөяkне[29] күп күрде фәләк. / Гаҗәпме белдерсәм һаман да мин аһ-зарны, яндыргач бу вөҗүдемне кайгыру нары. / Адаштыргач мине монда кайгы моңнары, миңа кайдан бер кисәкне шулай күп күрде фәләк»*, – дип, аһ итеп, сазын кулыннан төшерде. Хөрмүз шаһ моның хәленә хәйран калып торды һәм әйтте: «Сиңа бер тәкъдимем бар, һа Фәрһад. Синең белән сәрайга китик. Бер хат язып Мәһмәнәбануны күндерик. Әмма сиңа бу кыяфәттә йөрергә ярамас, киендереп бөтәйтик. Шуннан Ширинне таләп итәрбез».

Фәрһад разый булып, сәрайга килделәр. Фәрһадны мунчага китереп, пакь юындырып, чиста киемнәр киендереп, шаһ диванханәсенә китерделәр. Хөрмүз шаһ аның бу кыяфәтен күреп «афәрин!» диде.

Шунда ул Мәһмәнәбануга бер намә язып, капучылар җитәкчесенә – диздарга тапшырып, адресатка бирдерде. Фәрһад исә шаһ хезмәтендә калды, Кәтхода-диздар, Мәһмәнәбануның сараена килеп, намәне-хатны вәзиргә бирде. Вәзир исә Мәһмәнәбануга, Мәһмәнәбану исә Диван әфәндесенә[30] бирде. Ул хатны өнләп, кычкырып укыды. Намәдә болай язылган иде: «Мин ки, Хөрмүз шаһ, ярдәмчем Фәрһад агага[31] карендәшеңнең кызы Ширинне кәләш итеп, тиешлечә җиһазландырып миңа күндерәсең. Әгәр «юк», дисәгез, минем көчемә таулар да тагу[32] булмас! Сугыш ачып, кул[33] куәтем илә алырмын, соңыннан «белдем» яисә «белмәдем», димәссең», – диелгән.

[Ләкин Мәһмәнәбану риза булмый. Моннан соң аның батырлары белән Хөрмүз шаһ батырлары арасында бергә-бер көрәшләрне бәян итүгә күп урын бирелә. Көрәшләрдә

[26] Коң, куң – эрен.
[27] Ашина – якын дус, интим дус, әшнә.
[28] Фиган – ачы зарланулар.
[29] Сөйкемле сөяк – бу урында: сөйгән яр.
[30] Диван әфәндесе – «диван» сүзе текстта – Дәүләт Советы; Диван әфәндесе – Дәүләт Советы Рәисе. Ул дәүләтара хатларны кычкырып укыган.
[31] Фәрһад монда беркемгә дә ага түгел, «ага» бу урында «рәсми дәүләт кешесе» мәгънәсендә.
[32] Тагу, таңгу – киртә, комачау.
[33] Кул – гаскәр; колонна.

Фәрһад та актив катнаша. Мәһмәнәбану үз тарафына бер-бер артлы ике җадучыны[34] китереп карый. Ләкин Хөрмүз шаһ тарафдарлары ул җадучыларның әмәлләрен җиңәләр һәм үзләрен дә юк итәләр.

Шул вакыйгалар эченә актив фигурант булып Хөрмүз шаһның углы Хөсрәү килеп керә. Җадучыларның кәсәфәте арасында, диелә, Хөсрәү Ширингә гашыйк була. Шулай итеп, әсәрне Фәрһад-Ширин-Хөсрәү өчпочмагы җанландырып җибәрә. Мәһмәнәбануны берничек тә Ширинне туйлап бирергә күндереп булмагач, Хөрмүз шаһ бөтен гаскәре белән һөҗүмгә күчә, һәм Мәһмәнәбану гаскәре тар-мар ителә, ул үзе көчкә исән кала (әсәрнең калган өлешендә аның турында сүз дә бетә).

Инде гашыйклар арасында барча кыенлыклар артта калды дигәндә, Хөсрәү Ширин өчен көрәш башлый. Аңа ярдәмгә (әсәрдә исемсез) бер дайәсе һәм яһүди Бәхтигян – Хөрмүз шаһның вәзире килә. Ширин белән Фәрһад инде кавышабыз, никях укытабыз дигәндә, Фәрһадны янә канал казуга җибәрәләр. Эшеңне бетергәч өйләнерсең, диләр. Хөсрәү Фәрһадны шунда үтермәкче була].

Беркөн Хөрмүз шаһ диванга килеп күрде ки, Хөсрәү юк. Соңыннан сорады: «Углым ни өчен диваныма килмәде?» Әйттеләр ки: «Кәефе булмаганга килмәде». Шуннан соң Хөрмүз биш хәким-табибны китереп әйтте: «Бар, шаһзадә янына бар, аның сәламәтлеәхвале ничек икән?» Хәким килеп күрде ки, гыйшык галәмәтләре бар, хасталык түгел. Һәм моны этисенә әйтте. Падишаһ углының дайәсен чакырып китереп әйтте: «Барып шаһзадәдән сөальәйлә – кемгә гашыйк, ул синнән яшермәс», – диде. Дайә шундук белдерде: «Шаһзадә Ширингә гашыйктыр», – диде. Хөрмүз шаһ вәзире булган яһүди Бәхтигянны чакырып әйтте: «Мондый хәлгә чара нидер?» – диде. Бәхтигян әйтте: «Миңа өч көн мөһләт[35] бирегез, аның чарасын табыйм», – диде. Падишаһ: «Бик әйбәт», – диде.

Бәхтигян ханәсенә килеп, бер шәйтани фикергә килде. Шуннан соң шаһка килеп әйтте: «Шаһым, фәлән тауның итәгендә бер сулык бар, су буылып тора, шул суны агызып бу тарафка китерсәң, Ширинне сиңа никяхлап-туйлап бирермен», – диде. Һәм Хөрмүз шаһ та бу фикерне хуп күреп, Фәрһадка тәклиф итте: «Ишеткәнемчә, Мәһмәнәбануның хәвезенә су китергәнсең», – диде. Фәрһад бичара гыйшыклык утында иде. Тик нишләсен? Моны ишетеп ай итте. Башын түбән салып: «Фәләк! Ае[36] аңарга кара кебек күренде... Фәрһадның елап әйткәне: *«И фәләк, нишлисең, ничек котылыйм кулыңнан мин, и кара бәхетем, нинди караңгы көннәргә салдың син?»* Моңа өстәп әйтте: «И шаһым, баш өстендә җаным корбан булсын. Ярым юлында шундый кыенлыклар икән, монда Хак Тәгаләнең бер хикмәте бардыр, киркәмне[37] китерегез».

Күрсәтелгәнчә, Фәрһад өч йөз батманлы киркәсен алып, текә кыяларны кырыпватып, түбәнтен юл ачмага булды. Равиләр әйтер ки, Хөрмүз шаһ Ширингә бер җария тәгаенләде. Ул җария Ширинне бик яратты һәм ислам диненә мөшаррәф булды, Ширинннән гайре илә якынлашмады. Ширин дә ул җарияне үзенә ахирәт итте. Ул вакытвакыт Фәрһадка сәлат[38] җиткереп, сәлам китерер иде. Атын Гөлбайаз диерләр иде.

Көннәрдән бер көн Ширин сердәше булган җариягә: «Фәрһадка миннән сәлам әйлә һәм бер кәррә йөзен күреп кил. Һәм мин дә сиңа багып, күңелем ачылыр иде», – диде. Гөлбайаз тауларга юнәлде һәм Фәрһадны күреп килде. Кырык көнләп тагын тау кискәч, эше бетмәячәген әйтте. Ширин аһ итеп елый башлады. Гөлбайаз, Ширинне юатып: «Кайгырма, ахыр чиктә Фәрһад синеке була», – диде. Шуннан бер-берсенең махсус серләре турында сөйләштеләр.

Бер көн Хөрмүз шаһ вәзиргә һәм Хөсрәү шаһзадәгә: «Бүген Фәрһадның хәлен белеп килик», – диде. Болар өчәүләшеп чыгып киттеләр. Күрделәр ки, Фәрһад янында бихисап арыслан вә капланнар әйләнгәләп йөриләр. Фәрһад шаһның килгәнлеген күргәч, киркәсен болгап, ул җанварларны читкәрәк куалап җибәрде. Болар читкә китеп тыныч кына утырдылар. Бу өчәү дә Фәрһадның эшен күреп, хәйран булдылар. Ташка бәргән саен таш тузан булыр иде. Диюләр дә эшли алмаганча эшли иде. Шаһ һәм вәзир таң калдылар. Тагы сәрайга кайтып киттеләр. Шуннан соң Гөлбайаз җария дә хуҗа туташына әйтте: «Бер көнен без дә барып Фәрһадның тау ярганын күрсәк

[34] Җаду – сихерче, күз бууычы, күрәзәче.
[35] Мөһләт – вакыт.
[36] Ае – язмышы.
[37] Киркә – китмән.
[38] Сәлат – бу урында: изге теләк, дога.

иде», – диде. Һәм кичен барып, шаһтан рөхсәт алдылар. Иртән бүтән җарияләргә дә әйтте: «Сезләргә дә шаһтан рөхсәт алдым, әйдәгез, Фәрһадны күреп килик», – диде. Ширин: «Менә мин дә барыйм», – дип өзгәләнде.

Кичә вә көндез аһ итеп аны уйлый иде. Хөрмүз шаһ та Фәрһадның янына барып, Фәрһад өчен тагы йөрәге янып, нык ачынды. Тиз арада Ширинне Фәрһадка никяхландыру уена килеп, сәрайга кайтты. Солтанга[39] әйтте: «И, минем банди-җиһаным[40], минем моннан Фәрһадка тыныч багарлык түземлегем калмады, сабыр-тәкатем бетте», – дигән кебек шактый сөйләште. Соңра читтән генә Ширингә: «Шаһың сиңа рөхсәт бирсен, тагын бер барып, Фәрһад белән күрешсен, моннан соң аңа ни булыр, ни булмас, дөнья хәледер», – диде. Һәм Ширин вә Гөлбайаз тагын бер кич җарияләр белән тауга бардылар. Ширин Фәрһадны күреп, аның бу хәлләргә грифтар булганлыгыннан күп елады. Фәрһад Ширинне тагын күреп, ошбу бәйтләрне сөйләде: *«Йөрәген көйдермә Фәрһадның, Ширинем – йөрәгемә дәрде-дәруным. / Гөлләргә көлмәк (?) ярашыр, ди, былбыла гөлләр ярашыр, ди»,* – дип, бер-берсенә моңлы карашып елаштылар. Инде Фәрһад та тагын сазын кулына алып, бер тапкыр «аһ» дип, җаны-күңеленнән алып, бу бәйтне әйтте: *«Күзем кәбаб булды гыйшкың утында, пәрванәмен, ләкин янып та тормам»*, – дип, сазын Ширингә бирде. Ширин, сазны алып, ошбу бәйтне әйтте: *«Күңелсезләнмә хәзер, әйтмә аһны – гашыйкларга аерылу килә инде. / Кил, тыңла сүзем, гүзәлләрнең шаһы, елаганнар бер көнен көлә инде. / Тулган ай кебек әйләнмә-дуланма, вә каршымда мескен булып кыланма. / Мине сөймәс диеп төрле уйланма, сөяргләр сөеп карар, белмисеңме»*, – дип, Фәрһадның кискән ташларын караштыра башлады. Күрде ки, эше күп калмаган икән. Бәс, тагын Хак Тәгаләгә сине миннән, мине синнән аермасын, дип җырлап кабатлады: *«Теләгем бу минем, и Изге Мәүләм, аермасын мине синнән, сине миннән»*, – дип, үзе дә Фәрһадның йөзенә багып, аһу күзләреннән[41] энҗе данәләре кебек яшьләре агып чыкты, Фәрһадның йөрәген даглады. Фәрһад шундук Ширингә: «Елама, җөкәреңне-йөрәгеңне яндырма. Инде нибары дүрт-биш көнлеге эш калды», – дип, ошбу бәйтне әйтте: *«Китәр кальбеңдәге сары, шатлык аятләре килде, / Ирештек – туйга аз калды, сафа аятьләре килде»*, – дигәч, Ширин бер сүз әйтте: «Минем тугрылыклы гашыйгым, Фәрһадым, минем күңлемдәге телемдә, монда килгәндә атымның тоягы каерылды, әйбәт галәмәт түгелдер. Әмма, әй Раббем, хәерлегә булсын», – дигәч, Фәрһад та бер аһ итеп, түбәндәге бәйтне сөйләде: *«Бу дөньяда морадыңа ирешү ятлардан тора, безнең дә бу эшебез, язмыш Алладан тора»,* – дигәч, болар бер-берсе белән хушлашып, Гөлбайаз белән Ширин тагы сәрайга килделәр. Ширин кабат төшендә күрде ки, Фәрһады каршына бер ерткыч хәйван килеп, һөҗүм итеп, атылып Фәрһадның өстенә менде, үзен яклый алмыйча калды. Ширин уянып, кайгыга төште. Гөлбайазга сөйләгәч, ул: «Хәерлегә була, әфәндем[42] ». Әмма Ширин әйтте: «И җаным Гөлбайаз, Фәрһадны барып күр, иртәгә иртән кайтып җит». Ләкин соңра, кешегә ышанмыйча, төн уртасында үзе барып, Фәрһадны сау-сәламәт, йоклаган хәлдә күреп, Хакка күп мактаулар, данлаулар әйтеп, шөкерләр итеп кайтты. Ләкин халык арасында сүз чыкты ки, Ширин килеп йөри икән, дип. Һәм Фәрһад төннәрен уянып, куышында йокысыз ята торган булды. Ниһаять, Ширин назамин (назлы) көндез килеп, Фәрһадны күргәч: «Әлхәмдүлилләһ ки, сине сау-сәламәт күрдем», – дип, төнге вакыйганы сөйләп бирде. Һәм Фәрһад барысын да хәерлегә юрады. Ширин бәйт әйтте: *«Әлхәмдүлилләһ, төнлә сау-сәламәт таптым сине, җан бәдәндә икән, Мәүләм аермасын синнән мине»*, – диде. Фәрһад, Ширин үзенең куркыныч төшен сөйләгәч, бераз күңеле төшсә дә, белдермичә хәерлегә юрады һәм бәйт әйтте: *«Эчкәнмен икән көлкеле бу ярым мәҗлесендә мин...»*

*Кереш сүз авторы һәм текстны*
*бүгенге имляга күчерүче –*
*филология фәннәре кандидаты*
**Алсу ХАСАВНЕХ.**

[39] «Солтан» дип еш кына патша хатынына яисә кызына әйткәннәр.
[40] Банди-җиһан – бу дөнья белән бәйләнгән әйбер-күренешләр.
[41] Аһу (тау кәҗәсе) күзләре – аһуларның күзләре Шәрекътә традиция буенча иң матур күз мисалы санала.
[42] Элек заманда хатын-кызларга да «әфәндем» дип мөрәҗәгать иткәннәр.

# ЯШӘҮ ҖЫРЫ



Моң дигәнең сайрар кошның күңеленә кайлардан иңә икән?.. Җәй көне бакчабыздагы алмагачка нәни бер кош килеп кунды. Кунды да, дөньяның бар мәшәкатен, гамен читкә куеп торыгыз дигәндәй, әй тотынды сайрарга! Чүп утау да, су сибү дә онытылды – тирә-якта могҗизага тиң сихри моң гына хакимлек итә иде. Уч төбенә сыенырлык кошчыкның бәгыренә бу кадәр моң каян килгән, ничекләр сыйган? Ул шулкадәр өздереп сайрый, тыңлаган саен, аңа кушылып, күңелнең кырык кылы тетрәнеп куя, тән чемердәп китә: гаҗәеп төгәллек, гаҗәеп ритмика һәм... тормышка мәдхия! Әйе, әйе, кошның җыры – яшәү турында иде. Ул минутта, аның телен аңлагандай, башымны кыйгайтып, авыз эченнән генә җырга кушылганымны хәтерлим: «ак болыт – син матур, лә-лә-лә, ак кояш – син көләч, лә-лә-лә, күңелләр ак булсын, сагышлар онытылсын...» Кошчык минем балаларча шаяртуымны ишетми, җанында шулкадәр пакьлек, шулкадәр сафлык, чисталык, самимилек; ул, әйтерсең, әле генә читлектән очып чыккан да яшәүнең һәм ирекнең никадәр татлы икәне турында бар җиһанга җиткерергә ашыга...

Көйязарларның да җан түренә былбыл оя корадыр, күрәсең. Йә булмаса, кошлар җырын тыңлаган мәлдә, һәр аваз нотага әверелеп, күңел дәфтәренә языла барадыр... Бармаклары күз иярмәс тизлек белән баян телләреннән йөгереп үткәндә, аның йөзенә беркадәр гаҗәпсенү тарала: янәсе, көй язу бит ул... көй язу... Үзеннән-үзе килә дә чыга инде... Менә шулай, чикләвек ваткандагыдай, гап-гади һәм бик җиңел. Композитор Инсаф Хәбибуллинны якыннан белгәннәр аның үзенең дә гадилегенә, ихласлыгына, тыйнаклыгына күнегеп беткәннәр. Тормышны ничек бар – шулай кабул итү һәм ярату. Минемчә, бу ир-егетнең яшәү фәлсәфәсе әнә шул хакыйкатькә сыенган. «Беренче җырымны мин Әфганда яздым», – диюеннән шундый нәтиҗә ясавыма үзе ачуланмас, шәт. Үлем белән күзгә-күз очрашканнар өчен яшәү мәгънәсе капчык-капчык алтын-көмеш белән түгел, һәр туган таңга сөенеп күз ачу, күкрәк тутырып сулыш алу белән үлчәнә. Тәүге җырның – көе дә, сүзләре дә Инсафныкы булган җырның «Мин сине яратам» дип аталуында әнә шундый хикмәт күрмисезме? Олысына да, кечесенә дә таныш гап-гади сүзләр: мин сине яратам, яратам, яратам, мин сине барыбер үземә каратам... Юк, кара кашлы, кара күзле чибәркәйне күз алдына китерүдән генә туган аһәң түгелдер бу. Кабул каласы янында, Әфган таулары арасында, гомернең һәр мизгеле кыл өстендә асылынып торганда, ипләп кенә гитара чиртеп утырганда, әле мыек кына сызылып килгән ять-яшь егетләрнең тормышны ярату турында сөрән салуларыдыр...

«Сандугач керде күңелгә», «Бер егет гармун сайлый», «Чит ил дидем», «Күңелем тулса, кереп елыйм каеннар арасына» – Салават башкаруында үзәкләрне өзгән «Йөрәк җыры», «Сибелде сәйләннәрем», «Чәчәкләрне өзмәгез», «Безнең этиләр», «Бар да кала»... Бу исемлекне дәвам итсәм, җитмештән артык җырны санап чыгарга тиеш

булыр идем. Алар барысы да халык арасында таралып, үз булып киткән, барысы да күпләргә яхшы таныш. Тик шунысы кызганыч: җырларның авторы хәзер сәхнәдә дә, радио-телевидениедә дә бик сирәк очракта тамашачыга тәкъдим ителә, чын хуҗалар булган шагыйрь һәм композитор ни өчендер артык кашык шикелле читкә тибәрелеп килә. Бүген татар эстрадасындагы байтак җырчыларның репертуарында Инсаф Хәбибуллин көй язган җырлар урын били. Табигатьнең үзеннән күчкән, җан җылысы белән сугарылган ул моңнар...

Инсафның туган авылы Ирмәш – Актанышның табигате белән күзләрне камаштырырлык, үзе дә, исеме дә җырга тиң Агыйделе, таулары, чишмәләре белән таң калдырырлык гүзәл бер почмагы икән.

*– Һе, Ирмәшне белмәскә инде... Иң матур табигать шунда бит. Безнең капкадан чыгуга, тауга менеп китеш. Кыш буе шуннан кайтып керү юк иде, чана тартып, гел тауда уйнау. Җаен Иске Иделдә су керәбез. Авыл бәләкәй булса да, без үскәндә анда бала-чага күп булды. Күршеләрдә унике бала иде! Без өч бала булганбыз, олы апам Сәмәрә исән-сау, хәзер дә авылда яши. Уртанчы апа Римма мин туар алдыннан биш яшендә үлеп киткән.* – Инсаф балачак хатирәләрен искә төшергән арада, мин дә, кечкенә генә буйлы, орчык кебек бөтерчек малайга ияреп, шул елларга кайтып киләм.

...Җәйрәп яткан Әргәнеш болынлыклары, шунда йөргән атлар, сыерлар – алар Инсафның бабасының байлыгы. Әтисе Әхнәф абый ягыннан бабайлары – әнә шундый булдыклы, эшчән, җыр-моңга, гармунга мөкиббән затлар. Талкыган, замананың кырыс җилләре аларның дөньясын да пыран-заран китергән: кичә җир хуҗасы булып, киң атлап йөргән гаярь затларны землянкага куып төшергән... Әнисе Сәхия апаның нәселен дә урап узмаган ул зилзилә: байда сатучы булып эшләгән Нурмөхәммәтне (Сәхия апаның әтисен үз итеп Нурым дип кенә йөртәләр) Себер далаларына илтеп ташлаган. Сөргенлектә шагыйрь Хәсән Туфан белән бергә булуын гына язмышның кечкенә бер «бүләге» дисәк инде... Нурмөхәммәт агай икесенең гел аралашып яшәвен, паёкларны бергә бүлешеп ашавын еш искә төшерә торган булган. Сөргеннән кайткач та, әлеге дуслык өзелмәгән – Уфа якларына юлы төшә калса, шагыйрь Актанышка сугылмыйча китмәгән, дусты Нурмөхәммәтнең сөргенлектә үткән ун елын хезмәт стажына кертү артыннан да ул йөргән. Хәсән Туфан Себердә көтү көтсә, Нурмөхәммәт агай бүрек теккән. Ул һөнәрен үзе белән авылга да алып кайткан, тиз арада Актанышның атаклы бүрекчесенә әверелгән.

Балалык һәм яшьлек чорында нәсел тамырлары турында да, илдәге сәяси вакыйгалар турында да артык уйланмыйсың шул. Колакка чалынганнарны бүген килеп искә төшергәндә аһ итеп куярлык: тамырлар белән бергә тарихи чынбарлык үзе дә бакыйлыкка күчә бара...

*– Минем әти сүзгә бик оста, җор телле кеше иде, хәтере дә нык әйбәт булды. Вакыйгаларны көне-сәгате белән әйтеп сөйли торган иде. Балык тотарга ярата иде, ау үргәндә булышырга мине дә үзе белән ала. Әтинең «коптилкасы» да бар иде, авылда бер! Өйдә балыктан да өзелгән юк, кешедән дә... Ну минем балыкка бер дә уш китми. Бабайның – без аны әткәй дип йөрттек – хромкасы, саратский гармуны бар – шуны шыгырдату ошый. Үзалдыма уйнап тик утырам... Шуннан әти кая, ничек басасын күрсәтеп, «Карабай» көен өйрәткән иде.*

Инсафның тәүге остазы, менә шул рәвешле, әтисе булса, аз сүзле, тыйнак Сәхия апа улын Актаныштагы музыка мәктәбенә – баян классына илтеп биргәч, малай биш ел буе танылган музыкант Мирзанур Фәрухшин сыйныфында укый. Шул вакытта ук күңелдә үзенән-үзе бөреләнеп килгән көйләр, әле самими генә хәлдә булса да, җанны көйрәтә башлый; үзе баяннан әз генә калку булган Инсаф аларны укытучысына да уйнап күрсәткәли. Һади Такташның шигъри юлларын бераз гына үзгәртсәк: «кем уйлаган шушы шаярулар анда кәсеп булып калыр дип»... Музыкага һәвәслеге белән аерылып торган малай мәктәп концертларының берсендә дә катнашмый калмый; имтиханнарны да иң яхшы тапшыручылар исемлегендә була; урта белем алгач, җиде юл чатында да аптырап басып тормый – 1984 елда туп-туры Казанга, сәнгать институтының оркестр бүлегенә юл тота. Сабакташлары арасында Әлфис Кыямов, Рафик Таҗетдинов, хор

бүлегендә укыган Зәйнәп Фәрхетдинова, Зөфәр Билалов кебек, еллар узгач, исемнәре халыкка танылачак студентлар да була.

Студент дигәннән, уку елларында теләсә кайсы чор шәкертләрен, аеруча егетләрне берләштерүче бер нәрсә бар. Әйдәгез, без аны халыкчан итеп, «шабашка» дип кенә атыйк әле... Стипендияне тартып-сузып күпмегә җиткерәсең, әле анысының бөтенләй эләкмәве дә ихтимал бит: кемдер вагон бушата, кемдер ипи заводында эшләп ала, кемдер студотряд белән төзелешкә чыгып китә... Инсаф та беренче курста ук «Төзүчеләр» мәдәният сараенда, режиссёр Камил Саттаров җитәкләгән халык театрында эшли башлый, баянда да уйный, спектакльгә көйләр иҗат итә. Тик максаты – иш янына куш булыр дип акча эшләү түгел, ә үзен сынап карау. Хыялый күңелне һаман каядыр әйдәкләгән тарту көченә буйсынып, иҗатка килү.

Бу урында иҗат турындагы сүзебез беразга тукталып торыр. Арада – армия еллары. Сагынып сөйләр көннәре дә, мизгеле елларга тиң булып, үзәкне өзгән, онытырга, онытырга, ничек тә искә төшермәскә теләгән чоры да бар аның. Көндәлек битен актаргандай, укырга яраган урыннарына гына күз салсак... Украинаның Могилёв-Подольский шәһәрендә, «учебка»да үткән айлары башкаларныкыннан әллә ни аерылмыйдыр. Хәер, алай дисәң, армиягә алынган һәр солдатка киногa төшү бәхете тәтиме?! Барысы хакында да тәртибе белән сөйлик. Инсаф хезмәт иткән 3 нче рота үзенең күрсәткечләре белән беренче урынга чыга. Нәкъ шул мәлдә шәһәргә «Киевфильм» студиясе килеп, сугыш турында кино төшерү белән мәшгуль икән, исәпләре – солдатларны да артист итеп уйнату. Алдынгы булгач, бүләк йөзеннән әлеге мөмкинлек 3 нче ротага бирелә, алар... немецлар булып уйнарга тиеш.

*– Кино дигәннәрен шәһәрдән ун чакрымлап читтә, яланда төшерәселәр икән, анда танклар да, йөк машиналары да тезелеп тора. Безнең янга тартма-тартма немец киемнәре, каскалар, кирза итекләр, автоматлар китереп куйдылар. Шуларны киеп, автомат тотып, танклар артыннан йөгерергә тиеш инде без... Без чапканда, режиссёр ярдәмчесе кемгә нишләргә, ничә адым атлагач егылырга кушып, команда биреп тора. Мин артык озак йөгермәдем, өч-дүрт патрон «аттым» да кәкрәеп аудым... Әллә ничә дубль ясый-ясый «нимес»ләрне төшереп бетергәч, каршы окоптагы совет гаскәрләрен төшерергә тотындылар. Аларны «холостой» снаряд белән шартлаталар, безгә исә, чынга охшасын өчен, көрәктер, тактадыр ише нәрсә белән балчык өемен тузгытып, һавага чөеп торырга кушалар... Шулай ике атналап артист булып йөрдек. Беркөнне эш беткәч, шәһәргә кайтырга җыендык – көн суытып җибәргән, ә безгә йөк машинасында, ачык кузов өстендә кайтасы. Кызганганнардыр инде, киеп уйнаган киемнәр белән кайтарып җибәрделәр. Башта – немец каскасы, өстә – немец формасы... Бертөркем солдатлар шулай тезелеп утырдык, юлдан үткән машина шофёрлары, күзләрен шакмак итеп, борыла да карый, борыла да карый. Борылмассың, машина тулы нимес кайтып килсен әле...*

Инсафның җор тел белән сөйләгән хикәяте иң кызык урында өзелде: баксаң, ул әлеге фильмның алдагы язмышы белән бөтенләй кызыксынмаган икән! Эшләнеп беткәнме, экраннарга чыкканмы – «белмим, чыкмагандыр ул... Киноның исеме «И никто на свете» дип аталачак, менә хәзер Германиягә барып төшереп бетерәбез дигәннәр иде дә, ай-һай, аннан соң болганчык еллар китте бит...» – дигәннән артык җавап яңгырамады. Шулай диюе, мактанырга теләмичә, мыек астыннан елмаеп, колагыма токмач элүе генә булды микән... Чөнки Интернет битләрендә әлеге фильм чыннан да бар, анда немец солдатлары танкка ышыкланып йөгерә, совет гаскәрләренең окоплары өстендә ком бураны уйный...

Уен һәм чынбарлык арасы әллә ни ерак түгел икән. «Учебка»дан соң Әфганстанга, ут эченә барып керергә мәҗбүр егетләр күңелендә нинди буран уйнаганын үзләре генә беләдер. Бу тема – аларның күбесе өчен «табу». Авызларыннан артык сүз алырмын димә. Сафка тезеп бастырып, офицерлар: «Син Әфганстанга барырга ризамы?» – дип сораганда, «Юк!» дип җавап кайтарырга оят, хурлык кебек... Әфган – иң беренче чиратта әниләрнең йөрәк ярасы ул. Бер генә ана да үз баласын сугыш өчен дип үстерми... Ничек әйтергә, газиз кешеңә – әнкәеңә җәһәннәм уты эченә кереп китүеңне җайлап кына, йомшартып кына ничек әйтергә, нинди сүзләр, нинди җөмләләр табарга?



*Инсаф үзенең шәкертләре белән*

Җөмлә кирәкми. Бер, бары тик бер сүз – «Әфганстанда» дип хәбәр итүең җитә, әнкәң дә сиңа кушылып шул ук ялкыннарда яна... Әнә, янәшәдәге егетләрнең берсе хатка: «Мин Монголиядә», дип язып маташа – конверттагы кыр почтасы номерына карап, чит илдә икәнен барыбер чамалаячаклар... «Әни авыру минем, Әфганда дисәм, шунда ук үләчәк», – мәктәп бусагасыннан гына атлап, чып-чын сугышка килеп эләккән егет-малайның иртә җитлеккән фәлсәфәсе бу.

Әйтергәме, юкмы дип байтак икеләнгәннән соң, Инсаф үзенең кайдалыгын якыннарына яшермичә язып сала. Соңыннан, исән-сау әйләнеп кайткач, күршеләрнең: «Әнкәң коймаларга сарылып елый иде», дигән сүзләрен ишетеп, үзенең дә күңеле тулган мәлләре аз булмагандыр...

Таулар илендә яралган «Мин сине яратам» дигән җырны әнә шуңа күрә тормышка мәдхия дип бәяләдем дә инде... (Бу җыр бүген «Зөләйлә» төркеме башкаруында өр-яңа сулыш алды.) Яшәү кадерен аңлаудан, ак белән караны беркадәр аерырга өйрәнүдән туган җырдыр ул. Шулай булмаса, армиядән соң кабат институт бусагасына әйләнеп кайткач, укытучысына әйткән сүзләрендә катгый хакыйкать яңгырамас иде.

*– Беркөнне коридордан барам, каршыма тарих укытучысы килә. Без аның белән аралаша идек, дус идек. Хәл-әхвәлләрне белеште дә, Әфганстанда хезмәт итеп кайтуымны ишеткәч: «Ничек соң, интернациональ бурычыңны яхшы үтәдеңме?» – дип сорап куйды. Мин әйтәм, нинди интернациональ бурыч булсын анда, басып алу сугышы бит ул, дим. Әй шунда укытучының йөзен күрсәң! Күзләре түгәрәкләнде, бите агарды-күгәрде, бармагын авызына куеп: «Тссс! Болай дип сөйли күрмә! Кеше ишетә күрмәсен!» – ди бу, бөтенләй коты очты.*

Сүз белән әйтеп бетереп булмаганны моң аша җиткерергә була. Якты, дәртле көйләр кешедә яшәү шатлыгы уятсын, моң белән сугарылганнары күз яше аша күңелне чистартсын. Тик бер генә шарт – тыңлаучыга очсыз, мәгънәсез, зәвыксыз нәрсә тәкъдим ителмәсен! Хәер, нинди зыялы остазлардан белем ал да кулыңдагы гармун телләренә зәвыксыз көй килеп сарылсын, имеш... Тукай премиясе лауреаты, танылган композитор Бату Мулюков, шулай ук Тукай бүләге иясе, дирижёр Хәсби Фазлуллин, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әнвәр Әминев... Нинди мөгаллимнәр, гаҗәеп зыялы, затлы шәхесләр!

Студент кына булса да, Инсаф Хәбибуллинның да талантын, баян телләрендә җитез йөгерешкән бармакларын күреп алганнардыр. Шулай булмаса, өченче курста укыганда ук аны якташы, Табанлыкүл егете, филармониядә эшләп, халык арасында танылып өлгергән Хәнәви Шәйдуллин үз төркеменә баянчы итеп чакырыр иде микән? Монда да әле матди якны уйлау юк: һаман да шул үзен иҗатта сынап карау теләге! Булдыра аламы, ошаталармы? Ошаталар! Бер сәхнәдә эшләгән баянчы Фәрит Хатипов та мактау сүзләре әйтеп күңелен канатландыра. Инсафның кулына әллә каян гына Мәхмүт Хөсәеннең «Күрше кызы» дигән шигыре эләгеп, илһам килгән мизгелдә шуңа көй дә язып куя, ул җырны Х.Шәйдуллин тиз арада өйрәнеп, радиога да яздырып кайта. Тулай торактагы кызлардан Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрен алып торган Инсафта янә иҗат дәрте: шул китапны шаярган кебек кенә актарган арада «Сандугач керде

күңелгә» дигән юлларга шаярган кебек кенә көй дә килеп куна. Дөрес, үзе бер дә егылып төшми: артык гади тоеламы шунда... Тик, ни хикмәт, күп тә үтми, әлеге җыр бөтен тулай торакның хитына әверелә, аның янына «Бер егет гармун сайлый» дигәне өстәлә, тагын, тагын... Бераздан бу җырлар Наил Шәймәрданов чыгарган кассетада да урын ала, Салават, Зәйнәп репертуарына да керә.

Үз иҗаты хакында Инсаф, тыйнакланып, бик гади һәм җиңел генә итеп сөйләп ала. Әйтерсең, шигырьләрнең мәгънәләләрен генә сайлау да, аларга тәңгәл килерлек көй язу да, Актаныш музыка мәктәбендә егерме алты ел мөгаллимлек итү дә, элегрәк, фонограммалар булмаганда, икешәр сәгать буе баян күтәреп, сәхнәдә басып торулар да, партитура язу да, халык уен коралларыннан ансамбль төзү дә шулай җиңел генә, җайлы гына, үзеннән-үзе генә эшләнә торган хезмәтләр... Ә бит җиңеллекне эзләсә, институт тәмамлагач, башкалада төпләнеп калыр иде, йә булмаса, соңрак, башка шәһәрдә эш урыны тәкъдим итеп чакыргач, шунда юл тотар иде. Ни дисәң дә, олы казанда кайнавы уңайлырак... Юк, филармониядә эшләгән җиреннән, инде үзенең талантын, исемен күрсәтеп өлгергәч, Актанышка дәшеп кайтаруларына каршы килми, туган ягына юл тота. Мәдәният йортында җигелеп тартырдай кеше кирәк, музыка мәктәбендә укытырга, бөтен чараларны оештырырга, вокаль ансамбльләргә ноталар язарга, кыскасы, районның сәнгать дөньясында кайнарга...

*– Ул чакта районда мәдәният бүлеге мөдире булып эшләгән Казбек Каюмович Әдһәмов, министрлыкка шалтыратып, минем хакта: «Ул бит бездән направление алып киткән егет, үзебезгә кайтсын», – дигәч, кайтырга туры килде инде. Хәнәви Шәйдуллин белән соңгы тапкыр Яркәйдә концерт куйдык та, шуннан кайтышлый, 8 мартта ул мине Актанышта калдырып китте. Әй әйбәт кеше иде! Ул беркайчан бер кеше турында гайбәт сөйләмәде. Балачактан авырлыкны җитәрлек күргән, ятим үскән: кесәсендә бер уч ашлык табып, теге елларда әнисен ун елга төрмәгә утырткан булганнар. «Басуда, буразна арасында йоклаган чакларым күп иде», – дигәне истә әле Хәнәви абыйның...*

Сүз җебе Инсафның үз уңышлары ягына түгел, әнә шулай башка игелекле затлар тарафына борыла да китә. Ә бит, алда әйтелгән сүземне кабатлап, аның 26 ел буе баян классында укытуын, районның мәдәни тормышында таяну ноктасы булып торуын гына ассызыкласам да, никадәр сабырлык, никадәр тырышлык һәм тынгысызлык таләп ителгәнен төбенә тоз коеп сурәтләп бирә алмам. Бүгенге көндә Инсаф Хәбибуллин «Агыйдел» Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе итеп билгеләнгән, хорны да ул алып бара. Аның элекке данын югалтмыйча, дәрәҗәсен тагын да күтәрергә, артистларның профессиональ осталыгын тагын да арттырырга, репертуарны тамашачы «татар җыры менә нинди була ул!» дип нәтиҗә чыгарырлык итеп яңартып торырга кирәк. Ансамбль хакында сөйләгәндә, «Агыйдел»нең Инсаф өчен үз баласыдай якын һәм кадерле икәнен аңлау кыен түгел. Артистларның таланты, хакимиятнең аларга игътибары, гаиләләләргә чират белән фатир бирелү, элекке мәдәният йортының күз явын алырлык итеп яңартылуы һәм бинаның тулысынча ансамбль карамагына тапшырылуы, яңа биюләр, җырлар хакында күзләре янып, очкынлана-очкынлана сөйли, ә менә үзенә бирелгән грамоталар, Мактау кәгазьләренең кайчан, ни өчен икәнен дә «белмәмешкә салыша»: Ф.Туишев исемендәге гармунчылар конкурсында беренче урын яулаганын да, «Тургай» балалар җыр конкурсында җиңеп кайтканын да, 1996 елда «Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исемгә ия булуын да теленнән тартып кына төшерерсең... Ә бит бүген әрсезләр заманы: ике-өч көй язып – әле аларның да чын композиторлар көеннән кисәк-кисәк урланган булуы бик ихтимал – «мин композитор, сүзен дә үзем язам, үзем чыгып җырлыйм» дип күкрәк чөеп йөрүчеләр җитәрлек. Тагын да яманрагы – тамашачы үз каршында тамак ертып кычкырган, үрле-кырлы сикергән шундый бушбугазларга мөкиббән, аларның исемнәрен белә, концертына йөри, котыра-котыра кул чаба. Быел җәй ачык һавада барган бәйрәмдә бер җырчы егетнең очсызлы шаяртуларына һәм: «Әйдәгез, апашкалар, кушылып җырлыйбыз!» диюенә дәртләнеп биегән апа-әбиләрне күреп, шулкадәр гарьләнгәнемне онытмыйм. Сәхнә түреннән торып үзләрен мыскыл иткәнгә сөенәләр, сәнгать дигәннең оятсыз мәзәкләргә кайтып калуына

шашынып кул чабалар. Шуңа күрә чын талантларның артык тыйнак булып читтә калуына сокланырга да белмәссең, бераз чеметеп алырга да...

Инсаф Хәбибуллин көй язган җырларны беркадәр барлап чыккач, мин аның шигырь сүзләренә таләпчәнлеген искәрдем. С.Хәким («Белсәң иде»), Р.Вәлиева («Әниемә»), М.Мирза («Без туфрактан яралганбыз»), Л.Лерон («Әтисез үскән бала»), Р.Миңнуллин («Китмәссең син җанымнан»), Ш.Җиһангирова («Бер адымда гына»)... кебек шагыйрьләрнең иҗатына мөрәҗәгать итү үзе генә дә зәвык һәм таләпчәнлек хакында сөйли. Соңгы елларда Ф.Дәүләтбаев, Р.Сәлахиев кебек якташ шагыйрьләребез белән тыгыз элемтәдә булуы да күзгә чалына; арада эстрада җырлары да, романслар да бар. Минемчә, матур көй тусын өчен күңелнең дә матурлыгы, яктылыкка омтылуы, иң мөһиме – якыннарыңның сиңа теләктәш булуы кирәктер ул. Билгеле мәсәлдәгечә, тормыш дилбегәсен берең бер якка, икенчең башка якка тарткаласа, бер урында таптанудан ерак китәлмәссең... Бу җәһәттән Инсафның җаны тыныч, чөнки хатыны Зөһрә дә, уллары Искәндәр белән Йосыф та, үзе кебек үк, сәнгатькә гашыйк җаннар. Шулай булмый ни! Актанышка эшкә кайткач, әле мәктәп укучысы булган, «Агыйдел»дә биеп йөргән Зөһрә тышкы матурлыгы белән генә түгел, җан җылысы белән дә үзенә бәйләп өлгерә бит. Өч ел очрашып йөргәннән соң корган гаиләләре ышанычка, мәхәббәткә нигезләнгән. Алабуга культура-агарту училищесын, читтән торып пединститут тәмамлаган Зөһрә ханым бүген Актанышның 1 нче мәктәбендә психолог булып эшли, рәсем дәресләре, бию түгәрәге дә алып бара. Олы уллары Искәндәр – кайчандыр әтисе укыган музыка мәктәбендә укып, саксофонда уйнау серләренә өйрәнгән, рок-музыкага гашыйк, бәрмә уен коралларын буйсындырырга ярата. Төзелеш институтының архитектура бүлегендә, хәзер бишенче курста укучы егет Америкадан, Канададан килгән рок-группалар белән дә чыгыш ясаган, яшьләр арасында популяр булган «Алканат» төркемендә дә уйнаган. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр дигәннәре хак инде: булдыклы егет рок-музыка өчен көй иҗат итәргә дә өлгергән. Йосыф исә әлегә җиденче сыйныфта белем ала, ул да музыка мәктәбенә йөри, саксофонда уйный, шахмат түгәрәгенә дә җитешә. Казанга ярышка барып, икенче урын алып кайткан, 2 нче разрядлы шахматчы исемен дә иярләгән. Үзе теләп гитарада уйнарга өйрәнгән.

*– Кара инде, балаларым белән мактанып ташладым түгелме?.. Ә менә минем әни гомергә тыйнак булды, беркайчан «улым моны язган, болай эшләгән» дип кешегә сөйләп йөрмәде. Әнигә 91 яшь, бүген авылда, Сәмәрә апа янында яши. Әти генә бик иртә, 73 яшендә үк китеп барды...*

Инсаф үзе быел илле яшьлеген каршылый. 5 февральдә, тирә-якның әле сафлыкка, аклыкка күмелгән мәлендә туган ул. Шуңа күрә дөньяга ирештерер сүзе дә аклык турында.

Алмагачка кунган сандугачның җыры да яшәү матурлыгы турында дигән идем бит. Сайрар кошның мәдхиясе – ак кояшка, бөдрә болытларга, дөньяның фанилыгын искәртеп искән таң җиленә, агымсуларга, гомумән, тормышның үзенә. Аңа дан-дәрәҗәләр дә, купшы-төче сүзләр дә мөһим түгел. Көен тыңласыннар, отып алсыннар да башкалар да шушы җырга кушылсыннар. Яшәү җырына. Бары шул гына...

**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА**



Ибраһим
Гази

# ЮГАЛГАН МӘРЗЫЯ

ФРОНТ ДӘФТӘРЕННӘН

Ян, күңел, сызлан, күңел!

Ноябрь башларында Украинада җан биздергеч ямьсез көннәр була. Шалама болытлар, салына-салына, агач башларына хәтле төшеп, җирдәге ләчкелдек томан белән тоташалар да, вак иләктән иләгән кебек, тәүлекләр буе сибәләп торалар. Кая гына басма, анда су чыпырдый, кая барып ышыкланма, аннан җилкәгә су тама. Киемнәргә генә түгел, бәгырьгә хәтле яңгыр суы сеңәдер кебек. Ә кояш... мәңге күренмәскә сүз биргән кебек, атналар буенча күк йөзенә чыгып карамый. Кешеләрнең чырайлары караңгылана, тиктомалга бәйләнешәсе, әрләшәселәре килә. Матур вакытлар җиткәнче, кояш чыгып дөньяны нурга күмгәнче, минем үземнең, мәсәлән, бөтенләй үлеп торасыларым килә башлый. Мондый көннәрдә ялгыз башың юл йөрергә язмасын! Ә менә мин нәкъ шундый көннәрнең берсендә юлда идем.

Иртәдән бирле яңгыр астында килә-килә, чыланмаган бер генә җирем дә калмады. Фуражкамның кырыйларыннан тамчы тама, шинелемнән кайнар пар күтәрелә, аякларыма пычрак өелгән. Адым саен диярлек туктыйм да итегемә ябышкан пычракны атып торып җибәрәм, аннары тагын әкрен генә адымлыйм. Инде бик арыдым. Утырып ял итәсем килә, тик уч төбе хәтле генә дә коры җир юк.

Авыл күренде. Картаны чыгарып карадым. Самодурово булырга тиеш. Бу авылдан соң да миңа әле утыз километр барырга кирәк. Юк, бүген җитү турында уйларга да ярамый. Шушы авылда гына кунармын, ахры.

Аякларымны көчкә өстерәп, урам авызына килеп кердем. Дөресрәге, элек урам булып та, хәзер кара күмерләр генә өелеп калган җиргә... Юк, бу снаряд йә бомба төшеп янмаган. Немецлар йә үч итеп, йә чигенгәндә шулай яндырып киткәннәрдер. Чигенгәндә алар гел шулай итәләр. Бер авылның сыер көтүен пулемётлар белән кырып киткәннәр иде; без барып кергәндә, сыерлар кырда күбенеп ята иде. Аннары аларның тагы мондый яман гадәтләре дә бар: чигенер алдыннан, махсус отряд тәрәзәләргә автоматтан сиптереп йөри. Билгеле инде, алар моны тәрәзә пыяласына кунган чебенне үтерү өчен эшләми, ә чигенү ачуыннан, ичмаса, хатын-кызларны, бала-чагаларны күбрәк кырып китик дип эшлиләр. Күрәсең, бу авылда тәрәзәләргә ату белән генә канәгатьләнмичә, урамы-урамы белән яндырып киткәннәрдер. Монда кереп кунарга түгел, яңгырдан ышыкланырга да урын юк.

Элек урам булган җирдән әкрен генә барам. Як-ягымда сөремле кара мичләр басып кала. Авылны урталай ярып узган коры елга каршына килеп җитәм дә туктыйм. Теге якта йортлар исән, берничә морҗадан төтен дә чыга. Коры

елганың төбеннән чишмә бәрә булса кирәк, бер кыз көянтә-чиләк белән су алып кайтып килә. Мин аңардан: «Теге якка туры юл бармы?» – дип сорыйм. Ул бер сукмак күрсәтә. Сукмак, коры елга төбеннән узып, үргә таба күтәрелә, бакчалар аркылы үтеп, урамга барып чыга булса кирәк.

Кеше бакчаларыннан йөрергә яратмасам да, туры юл шул дигәч, киң чокыр төбенә, мондагыча әйтсәк, балка төбенә тая-тая төшеп китәм. Аннары очларында гына яшел яфраклар эләгеп торган вак агачлар арасыннан үргә таба менә башлыйм. Яңгыр һаман сибәли. Агачларга ябыша-ябыша менәм.

Туктап ял иткән чагымда, ниндидер көзге чәчәкләр арасында язулы таш күрәм. Якынрак барып карыйм. Кабер ташы. «Кайсы бичарасы ята икән инде монда?» дип уйлыйм. Украина җиренең азатлыгы өчен башын салган берәр сугышчымы? Әллә фашистлар кулыннан кичкән гөнаһсыз берәр совет кешесеме? Әллә берәр чудак үзе исән чакта йөргән, утырган тау битенә күмүләрен сорап, дуслары, иптәшләре аның соңгы үтенечен җиренә җиткергәннәрме?

Ташның битен каплап торган чәчәкләрне кулым белән аралап, язуга иеләм. Бу нинди могҗиза? Гарәп хәрефләре белән татарча: «Сөекле кызыбыз Мәрзыяга...» дип башланып киткән язу! Мең тугыз йөз кырык өченче елда Украина илендә татарча язылган кабер ташы! Донбасстагы шахталарда, заводларда татарларның күп булуын белә идем. Ләкин бу бит Донбасс түгел, Көньяк Украина, монда шахта да юк, заводлар да юк.

Сугыш, сугыш! Кайларга гына адаштырмыйсың син безнең сөякләребезне! Кем булган икән соң бу кыз? Ни өчен аны бирегә текә яр битенә күмәсе иткәннәр? Нинди язмыш аны Көньяк Украина туфрагына китереп ташлаган?

«Хәер, – дидем мин үз-үземә, – моның бер дә искитәрлек җире юк. Сугыш бөтен халыкны бутап бетерде. Менә син үзең, Идел буенда туып Идел тауларында үскән бер татар, шушы сугыш аркасында кайларда гына булмадың, нинди генә җирләрдә йөрмәдең. Әгәр сиңа сугыш кырында үлеп калырга язган булса, иптәшләрең, бәлки, сине дә берәр юл чатында күмеп, кабер ташыңа исемеңне язып китәрләр... Күрәсең, сугыш давылы чәчеп ташлаган татарларның берсе шушында вакытлыча төпләнгән булгандыр да, кызлары Мәрзыя үлеп калгандыр. Алайса, нигә соң аны зиратка илтеп күммәгәннәр, ә бирегә, яр битенә китереп җирләгәннәр? Рус каберлегенә күмәргә теләмәгән өченме?»

Кемнән дә булса сорашып беләсем килде. Таштан күзләремне алып, тирә-ягыма каранам. Бер кеше дә күренми. Аруымны да онытып, тиз-тиз сукмак буйлап менеп киттем.

Башына капчык бөркәнгән, кулына чыбык тоткан яланаяклы бер хатын бакчадан чыга да сукмак буйлап минем каршыма төшә башлый. Мин аны туктатам. «Бу кабергә нинди кеше күмелгән?» – дип сорыйм. Ул минем соравыма каршы: «Берәү дә күмелмәгән», – дип кырыс кына җавап бирә дә чылтыр-чылтыр узып китә.

Ничек инде берәү дә? Ташта аермачык язылган бит! Мин аптырабрак калам.

Сукмак мине түтәл бакчасына алып менә. Башлары кисеп алынган айбагыр таяклары, кәбестә күчәннәре арасыннан бара-бара, бер ишегалдына килеп чыгам. Ян тәрәзәләре белән салкын гына карап торган йорт кәмәшендә җан әсәре барлыгы сизелми. Гүя хуҗалары аны ташлап чыгып киткәннәр дә, шуңа кәефе кырылып, ул яңгыр астында күңелсез генә боегып утыра кебек. Башка вакыт булса, мин мондый караңгы чырайлы йортның бусагасын да атламас идем, ләкин Мәрзыя каберенә бик якын торганга, мин, кыз хакында болар ни дә булса әйтә алмасларммы дип уйлап, кереп чыгарга карар итәм.

Ишектәге язуны күреп, кинәт туктап калам. Украин телендә күмер белән «Марфа өйдә юк» дип язылган. Яхшылабрак карасам, стеналарның да төрле җирләрендә шундый ук язуны күрәм. Сәерсенәм. Берәр им-том булса кирәк дип уйлыйм. Өйгә чир кермәсен дип, шулай язып куюларны ишеткәнем бар иде. Ничектер күңелем тартмый башлый. Берәрсе чыкмый да ичмаса. Әллә чынлап ташландык йортмы бу югыйсә? Өйалды ишеген әкрен генә төртәм. Ишек шыгырдап ачылып китә. Идәндә өсте капланган сулы чиләкләр тора. Бер почмакта сыра чүлмәге-сыра чүлмәге сары кабаклар тезелгән. Шик юк, бу йорт ташландык түгел.

Өй ишеген ачып, бусаганы атлыйм да беркавымга басып торам. Бер кеше юк. Инде чыгып китмәкче булам, шул вакыт зәгыйфь кенә тавыш ишетелә. Миңа ул идән астыннан ишетелә кебек. Бик сәерсенәм, тагын тыңлыйм. Юк, тавыш кабатланмый. Ул да булмый, ыңгырашу ишетелә һәм шуның артыннан ук әлеге зәгыйфь тавыш татарча (саф татарча!) «Миргали, синме?» дип сорый.

Күзләрем ияләшеп җитмәгәнгә, абайламый торам, имеш. Түрдәге караватта кемдер кыймылдый, тавыш та шул яктан ишетелә икән. «Миргали, ник алай иртә кайттың?» дигән тавыш кабатлануга, мин тиз генә шунда таба атлыйм. Йа Хода! Беләкләре сөяккә генә калган бер карчыкмы, хатынмы дип әйтим, караваттан миңа шомлы күзләре белән карап ята. Ахры, ул, үз өендә кинәт кенә ят кеше күргәч, бик курыккандыр, мин дә, аның мендәрдәге сап-сары йөзен, шомлы күзләрен күреп алгач, әллә нишләп киттем. Ул миңа карый, мин – аңа, икебез дә сүз башлый алмый. Шуннан кисәк кенә мин:

– Мәрзыя сезнең кызыгыз түгелме? – дип сорап куям.

Көтмәгәндә татарча дәшкәнгә, төшемме бу, өнемме дип бугай, караваттагы җан иясе күзләрен миңа тери дә ката да кала. Мин тизрәк тагын сүз кушарга ашыгам:

– Ник дәшмисез? Мин кешегә тимим.

Карчык кыймылдап куя. Күзләрендәге шомлану бетә. Ул үзенең мине танымавын әйтә, кем булуымны сорый. Күрәсең, ул әле минем бичура түгеллегемә ышанып бетми булса кирәк. Мин үземнең нинди кеше икәнлегемне әйткәч, карчыкның кипкән куллары миңа таба сузыла, күзләренә ике тамчы яшь чәчрәп чыга.

– Якынрак кил, ичмасам, күрмим ич, – ди ул миңа. Берничә ай инде бизгәк чире белән газаплана икән, соңгы көннәрдә тавык күзе килеп өстәлгән, кичкырын күрми башлый икән.

– Тәрәзәдәге шәлне алып ташласана, – ди ул, сөяк кулы белән ишарәләп.

Мин барып шәлне алып атам. Өй эченә тонык кына яктылык саркый.

– И улым... – дип, ул миңа бик озак карап тора. – Үзебезнең татарны күрмәгәнгә бишбылтыр. Картым Миргали монда бердәнбер татар...

Минем кебек узып баручы бер солдат, шушыны эчсәң сихәтләнерсең дип, сары сәдәп төсле дару биреп калдырган икән дә, хәзер ул да беткән, әрем эчеп кенә бер дә файда күрә алмый икән.

– Марфагыз кем була соң сезнең? – дип сорыйм мин.

– Марфабызмы? Мин булам инде ул Марфа, – ди карчык.

Исеме Мәрфуга икән, хохол хатыннары Марфа дип йөриләр икән. Күршеләре бик яхшы кешеләр икән: кайсы сөтен кертә, кайсы җимеш суы биреп чыга. Рәхмәт яусын үзләренә. «Марфа өйдә юк» дип яздыручылар да күрше хохол хатыннары, имеш. Янәсе, чир өйдән чыгып торган арада шулай дип язып ишеккә элсәң, чир инде кайтып керә алмый икән. Карты Миргали татарча гына язмакчы булган да, хатыннар, хохол чире татарчаны аңламас дип, украинча язып биргәннәр. Ләкин бу бизгәк өянәге, күрәсең, язуга да карамый торгандыр. Һаман сәламәтләнә алмый икән.

Карчык минем Мәрзыя турындагы соравымны җавапсыз калдырды. Мин хәзер инде Мәрзыя тәгаен аларның кызлары йә кардәшләре дип уйлый башлыйм. Карчыкның хәле авыр булганга, кайтарып сорарга базмыйм, ә сорыйсым бик килә. Бу йортка шуның өчен генә кердем дә бит. Мәрзыя алар кызы булып, мин карчыкның төзәлеп җитмәгән ярасына орынсам, аңа бик кыен булачак. Мин һаман бизгәк турында сөйләшәм, карты хакында сорашам, ә кыз турында авыз ачарга куркам.

Берәр китап күрсәм, битләрен актарып карамыйча түзә алмый торган гадәтем бар. Киштәдәге китапларга барып ябыштым. Юк, карт белән карчык укый торган китаплар түгел болар. Моны укыган кеше яшь булган. Бу, мөгаен, Мәрзыя китапларыдыр. Минем шулай дип ышанасым килә. Берсен алам, берсен куям. Боларны Мәрзыя тоткан дип уйлыйм, китаплары исән, ә үзе инде юк, ул инде кара җир куенында ята. Фашистлар кавеме илебезгә сугыш белән килеп кермәгән булса, ул әле, бәлкем, бүген исән-сау булыр иде. Бәлкем түгел, әлбәттә, исән булыр иде. Аның үлемендә, мөгаен, немецлар гаепледер. Башка кем яшь кешенең гомерен киссен? Тик алар гына безнең илебезгә үлем, газап һәм күз яше алып килделәр. Тик алар гына безнең кызларыбызны, егетләребезне хайван урынына куып алып китеп, Германиядә муеннарына коллык камыты кидерттеләр. Алар гына, безнең хатын-кызларыбызның чәч толымнарын кисеп, үзләренә йомшак түшәк ясадылар. Алар гына, безнең кешеләребезнең тиреләрен салдырып, үзләренең дамаларына ридикюльләр тектеләр, лампаларына карындыклар тарттылар. Бу дөньяда бер гомер түгел, биш гомер яшәсәм дә, мин аларның бу «эшләрен» онытачак түгел!

Карчык белән сөйләшә-сөйләшә, һаман китап битләрен актарам, карандаш белән сызылган урыннарга күз йөгертәм, эзләнәм, нәрсә дә булса табармын, Мәрзыя укыганмы, әллә бүтән берәүме икәнен тәгаен белермен кебек тоела. Чү, нииндидер кәгазь! Дәфтәр битеннән ертып алынып, карандаш белән генә язылган: «Әткәем, әнкәем, кичерегез мине, артык чыдар хәлем калмады. Кызыгыз». Беренче сүзләрне укуга, эсселе-суыклы булып китәм. «Кызыгыз» дип кенә кул куйган булса да, моның Мәрзыя булуында шигем юк. Ул, бичара, үзен-үзе үтерде микәнни? Мин карчыкка күтәрелеп карыйм. Безнең күзләребез очраша. Карчык көрсенә, уфылдый, мышкылдый башлый. Карчык елый. Мин башымны түбән иям.

...Ул бүленә-бүленә, күз яшьләрен йота-йота сөйләде. Кайвакыт кинәт туктап кала иде дә бик озак вакыт бер сүз дәшә алмыйча ята иде. Мин куркып китә идем. Аннары ул янә телгә килә, янә сөйли башлый иде. Шулай туктап хәл җыя-җыя, ул бер сәгатьләп сөйләгәндер. Тавышы бик зәгыйфь булганга, мин, берәр сүзен ишетми калудан куркып, бик зур игътибар белән тыңлап утырдым.

...Бик матур, бик җитез кыз була аларның Мәрзыялары. Бөтен тирә-күрше сокланып туя алмый үзенә. «Кызыгыздан уңдыгыз, бәхете түгәрәк булсын» диләр. Ана белән ата куанып бетә алмый, үзләрен бик бәхетле саныйлар. Кызны укыталар. Яхшы киендерәләр. Иртә белән җилфердәп мәктәпкә чыгып киткәндә, кызның артыннан сокланып карап калалар. Мәрфуга түти кызны үзенә охшата, яшь чагымда мин дә аның шикелле идем, ди. Карт исә миңа охшаган дип бара. Матурлыгы синеке булса, уңганлыгы минеке, ди. Яшь чагымда мин фәлән идем, төгән идем, дип сөйли башлый. Алар шулай кызларының матур сыйфатларын үзара бүлешәләр.

Сугыш булмаган булса, язмыш аларның гаиләсен монда китереп ташламас иде. Әнкәсе дә бүген, бизгәк ялкынында көеп, болай кибеп ятмас иде. Без дә, гадәтләнгән хезмәтебезне ташлап, кулыбызга үлем коралы алмас һәм бүген монда

йөрмәс идек. Ләкин сугыш... сугыш безнең тормышыбызның астын өскә китереп ташлады. Сугыш безнең шәһәрләребезгә, авылларыбызга кеше канына сусаган фашистларны алып килде. Совет кешесен кешегә дә санамаган, ә үзләрен әллә кемгә куйган немец фашистлары безнең өйләребезнең ишекләрен каерып ачтылар да хуҗаларча рөхсәтсез-нисез туп-туры түргә уздылар. Сандыкларыбызда, гардеробларыбызда казыну гына җитмәде, алар җаныбыздан да кадерлерәк күргән намусыбызга тукынмакчы булдылар. Яшьләребезне матур яшьлектән, сабыйларыбызны рәхәт балалыктан мәхрүм иттеләр. Фашист аждаһасының аягы баскан җирләрдә балаларга карасам, күңелем өзелә. Көлмәсләр, шаярмаслар. Сабый килеш картайганнар. Бичараларның сабыйлыгын фашистлар урлады. Мең ләгънәт аларга шуның өчен!

Сугыш кабынып алдыннан, Миргали абзый М-ль шәһәрендә тимер юлда эшли. Сугыш, Мәрзыялар гаиләсен куып килә-килә, шушы Самодурово авылында артларыннан килеп җитә. Баштарак әле берәү дә немецлар монда озак эләгеп тора алыр дип уйламый, менә-менә яңадан үзебезнекеләр килеп җитәр, фрицларны пыранлатып куып алып китәр дигән өмет белән яши. Авылның кызлары, егетләре, Кызыл Армия борылып килгәнче дип, урманга кача. Безнең Мәрзыя да алар белән китә. Әмма фронт бик тиз ерагая, туп тавышлары да ишетелми башлый. Кызларның күбесе урманнан кире авылга кайтырга мәҗбүр була. Немец солдатларының күзенә чалынмаска дип, Мәрзыя, битен корымга буяп, иске киемнәргә киенеп, пәри төсенә кереп йөри. Бүтән кызлар да шулай итәләр. Үз илеңдә урамга чыгарга курык, матурлыгыңны күрсәтергә шикләнү, кач, пос, таракан кебек, ярыкка кысылып яшә... Шул ук кояш, шул ук ай, шул ук йолдызлар, шул ук кешеләр, бер төрле дә үзгәреш юк сыман, ләкин урамда немец солдатлары, авыз гармуны уйнап, «Дойчланд үбер аллес»ны акырып йөриләр. Алар сине теләсә авыл артындагы чокырга илтеп атып үтерә ала, теләсә этләрдән талата ала, теләсә намусыңны таптый ала. Кичәге кояш, кичәге йолдызлар астында бүген син ирексез, бүген син кол. Бүген синең җиреңә дә, үзеңә дә килмешәкләр хуҗа. Күңел моның белән һичничек килешә алмый, урамга йөгереп чыгасы, бугазларына ябышасы килә... Әмма автомат көпшәсеннән өстеңә үлем сикерергә торганны күрәсең дә, тешләреңне кысып, артка чигенәсең...

Беркөнне ялт итеп торган матур машинага төялеп, авылга немец офицерлары килеп төшә. Озакламый халык арасына коточкыч хәбәр тарала: имеш, барлык матур кызларны, комиссия куеп, М-льдә ачылачак «начар йорт»ка алып китәчәкләр икән. Авылны кайгы сөреме баса. Матур кызлары булган ата-аналар кызларын тизрәк берәр яры олактырырга тырышалар. Әмма юл чатларына инде автоматлы солдатлар куелган була, хатын-кызларны авылдан чыгармыйлар, карчыкларга хәтле битләрен төкерек белән ышкып карап кына уздыралар.

Мәрзыя бит бу авыл кызы булмый, тик аны да комиссиягә дәштерәләр. Әле кайчан гына үзенең матурлыгына куанып бетә алмаган кыз бала бүген инде матур булып тууы өчен хәсрәткә төшә. Фашистлар килгәч, матурлык кирәксез, зарарлы, алай гына да түгел, хурлыклы бернәрсәгә әйләнеп кала. Мәрзыя төн буе йоклый алмый, ә иртә белән, әнкәсе өйдән чыккан арада, өстенә күкерт кислотасы сибә. Кызның куллары, аяклары пешә, ә бите, Мәрзыяның бүгенге дошманы – матурлыгы – исән кала... (Китап эченнән табылган язуны Мәрзыя үзенә кислота сибәр алдыннан язган була.)

Шифаханәдән чыккач, яңадан авылга кайтып күренмәскә кирәк булган, ләкин кая барсын? Ул тагын әти-әнисе янына кайтып керә. Бераз ябыккан, агарган, әмма матурлыгы, немецлар килгәннән бирле бәлагә әйләнгән

матурлыгы, бераз да сулмаган була. Картлар кызларының исән-сау үз аягы белән кайтып керүенә чиксез куаналар. Тик күңелләренең бер кырые белән, иртәрәк кайтты, дип пошыналар, чөнки кызларны әле һаман җыялар икән, «тегендә» матур кызлар һаман җитми икән.

Мәрзыя кеше күзенә бөтенләй күренмәскә тырышып яши. Мөмкин булса, ул хәзер ташка, агачка әйләнер иде, вакытлыча үлеп торыр иде. Әмма ни аяныч! Адәм килеш яшәргә кирәк.

Авыл кара урман түгел, кызның кайту хәбәре немецларга барып ирешә. Күңел ачу йорты өчен кызлар җыючы отряд Миргали абзый өенә килеп керә. Мәрзыя тәрәзәдән сикереп төшә, качмакчы була, аны түтәл бакчасында куып тоталар. Кыз тегеләрнең кулларын тешли, битләрен тырнап бетерә, аның кул-аягын бәйләп өлгерәләр, машинага салып, үзләре белән алып китәләр. Артларыннан йөгереп чыккан Мәрфуга түти, һушыннан язып, урамда егылып кала. Карты Миргали үзенең карчыгын күтәреп өйгә кертеп сала. Бер төндә хатынының чәчләре танымаслык булып агара.

Карт белән карчык ут йотып хәбәр көткәндә, өйләренә беркөнне ике иякле, ал яңаклы фельдфебель килеп керә. Ул Миргали агайдан ниндидер язуга кул куйдырырга тырыша. Янәсе, аның кызы хәзер Германия гаскәренә хезмәт итә, ата-анасына ай саен фәлән хәтле акча килеп торачак, менә шушы контрактка кул куй. Миргали абзагыз, кул куярга минем сезгә кызымны сатканым юк, сез аны талап алдыгыз, ди дә, бүреген киеп, өйдән чыгып китә. Баядан бирле елап басып торган Мәрфуга түти немецтан кызы Мәрзыя хакында сорашмакчы була, фельдфебель аны аңламый, кесәсеннән акча чыгарып: «Сатлык йомыркагыз юкмы?» – дип сорый.

Көннәр үтә. Бүтән кызлардан хәбәр килгәләп тора, Мәрзыядан юк. Беркөнне, караңгы иңәр алдыннан, Мәрзыя үзе кайтып керә. (Караңгыланганчы авылга керергә оялып, урманда йөреп торган икән.) Элекке матур Мәрзыядан инде күләгә генә калган була. Ул хәзер көннәр буе, башын тезләренә куеп, бер урында утыра. Әнкәсе берәр сүз катса, җавап кайтару бик газаплы эш булган кебек, кашларын җыера, чыраен сыта, ләкин авызын ачып бер сүз дә әйтми.

Кайтуына биш көн тулды дигәндә, Мәрзыя бераз җанлана, аз-маз сөйләшкәли дә башлый. Бер тапкыр ул «тегеннән» киеп кайткан затлы күлмәген утка салып яндыра да үзенең өйдә калган ак күлмәген киеп куя. Мәрфуга түти аның көзге каршында боргаланганын да күргәләп кала. Ананың күңеле сөенә. Кызыбыз әкренләп аелына кайта дип уйлый.

Бер тапкыр Мәрзыяның, күлмәк өстенә күлмәк, күлмәк өстенә күлмәк киеп, көзге каршына барып басканын күргәч, әнкәсе:

– Кызым, ник алай кат-кат киеп куйдың? – дип сорый.

Кыз сәер генә елмая, әнисенең соравын җавапсыз калдыра. Аннары ул каядыр чыгып китә. Аны кич белән әлеге коры елга битендә тезләрен кочып утырган җиреннән табып алып кайталар. Икенче көнне дә аны шуннан табалар.

Бервакыт әтисе аның көрәк күтәреп бакча ягына киткәнен күреп кала. Бераздан шул якка барса, кызы Мәрзыя яр битенә чокыр казыган да шул чокырга кереп утырган.

– Кызым, нишләп чокырда утырасың? Чык, әйдә кайтыйк, – дигәч, Мәрзыя, әтисен танымаган кебек, күзләрен тутырып, гаҗәпләнеп карап-карап тора да, калтыранып, кинәт чокыр төбенә сеңә. Аптырап киткән Миргали кызын тартып чыгармакчы, алып кайтмакчы була. Мәрзыя үрсәләнеп кычкыра, еларга тотына: «Сез мине биреп җибәрәсез, куркам, кайтмыйм!» – ди.

Миргалинең өендә бик озакка ачы хәсрәт урнаша. Тоташ кайгылы көннәр

эчендә тик бер генә шатлыклы көн булып ала: кызлар җыючы отрядның биш кешесен коры елга төбеннән үле килеш табалар. Авылның хәсрәте өчен, кемнәрдер шулай үчне кайтара. Әмма бу куаныч та озакка бармый. СС отряды килеп, ярты авылны кара күмер итеп китә. Мәрзыя, ашарга да, хәтта кунарга да кайтмыйча, чокырда утыра башлый. Ата белән ана нишләргә белмиләр, кызны өйдән чыгармаска, бикләп асрарга уйлыйлар. Ләкин Мәрзыя йә качып, йә алдап чыгып китә. Атасы чокырны күмеп тә карый, Мәрзыя барып яңадан казый. Инде ахырда килешәләр: берни эшләп булмый, утыра бирсен, диләр, ач үлем белән үлмәсен дип, ашарына илтеп-илтеп бирәләр.

Бәла өстенә бәла килеп кенә тора. Мәрзыя күршеләрнең кече кызлары Наденьканы үзе белән чокырга алып йөри башлый. Алып бара да көннең-көн буе җибәрми. Наденьканы уенга чыгара алмыйлар. Мәрзыя, сагалап торып, үз янына алып китә. Күршеләре, зарланып, Миргали абзый янына керәләр. Ул бичара нишләсен! Үз баласын бәйләп куярга кулы бармый. Тик шулай да өйдән чыгармаска вәгъдә бирә. Ләкин Мәрзыя беренче көнне үк, тәрәзәне ватып, чыгып кача, Наденьканы, уйнап йөргән җиреннән тотып, чокырга алып китә. Күршеләр керәләр, барып әйтәбез, дип куркыта башлыйлар. Бүтән бер чара да калмагач, атасы Мәрзыяны бау белән стенага бәйләп куя.

Бу урынны сөйләгәндә, карчыкның кинәт тавышы бетте, ияге калтырый башлады.

Мескен Мәрзыя ябыгып сөяккә генә кала, өсте-башы тетелеп төшә. Әнкәсе яхшы күлмәк кидерергә теләсә, Мәрзыя кими: «Укырга киткәндә киярмен, торсын», – ди (ул медицина институтына җыенган булган икән), көчләп кидерсәләр, шундук салып атып, искесен киеп куя.

– Үз балама үзем әҗәл теләгән чакларым күп булды, – ди бичара карчык.

Күз көеге булып шулай йөри торгач, беркөнне Мәрзыя юкка чыга. Китаплар тотып, кичкырын авыл урамыннан барганын күреп калучылар булган. «Кая барасың, Мәрзыя?» – дип сораганнар. «Мәскәүгә укырга киттем, әтигә әйтмәгез», – дигән. Билгеле инде, аның сүзен берәү дә чынга алмаган. Артыннан кызганып карап калганнар.

Карчык сөйли-сөйли тәмам арыды, тавышы сына, әйткән сүзләре авызыннан абынып-сөртенеп чыга башлады. Ниһаять, ул бөтенләй тынды.

– Эзләп карагансыздыр бит? – дип сорадым мин, бик озак көткәннән соң.

– И, эзләмәгән кая инде! Атасының бармаган җире калмады. Юк, суга аккан шикелле югалды.

– Ә кабер? – дидем мин, баягы кебек бик озак көткәннән соң.

– Кабергә берәү дә күмелмәгән... Мәрзыя чокыры дип йөртәләр... Атасы шунда таш та куйды.

Яңгыр суыннан тәрәзә пыялалары елый. Өй эче караңгы, йодрыкларымны тез башыма кадап, мин хәрәкәтсез утырам. Карчыкның сулыш алганы да ишетелми: вакыт-вакыт уфылдап куймаса, аны үлгән дип уйларга мөмкин булыр иде, ул тәмам кипкән, саргайган. Күпме шулай утырганмын, менә карчык янә телгә килде:

– Күрше хатыны әйтә, мин аны төнлә чокыр янында күргәнем бар, ди. Белмим. Чокырга кайткач, нишләп өйгә кайтмас икән... Әтисе сагалап та карады, юк, очрата алмый. Үлгәндер инде, мескенем... Ул гомердән бирле...

Мин карчыкны тынычландырырлык бер сүз әйтә алмыйм. Тешләремне кысып, тәрәзә пыяласыннан агып төшә торган яңгыр суына карап утырам. Күңелем сызлый, күңелем әрни...

95

# ТАТАР МӘДӘНИЯТЕНЕҢ КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН

## 1919 ел

**1 январь.** «Эш» газетасында Вәли Шәфигуллинның «Советлар Россиясендә татар матбугаты вә әдәбияты» дигән мәкаләсе басылды.

**15 январь.** Астрахань татар театры Гогольнең «Өйләнү» пьесасын сәхнәгә куйды. Спектакльнең режиссёры – Зәйни Солтанов.

**7 февраль.** Татар драма артистлары труппасы Гафур Коләхмәтовның «Кара һәм кызыл» драмасын сәхнәгә куйды.

**9 февраль.** Казан Журналистлар союзы «Красные зори» исемле әдәби һәм сәяси журнал чыгара башлады.

**21 февраль.** Казанда Мөселман матбугат комиссиясе төзелде. Председателе – Рәүф Алмаев.

**21 февраль.** Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр» пьесасы буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды. Режиссёры – К.Тинчурин.

**28 февраль.** Шамил Усманов Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә эшли башлады. 10, 11 һәм 12 март. «Эш» газетасында Г.Ибраһимовның «Иҗтимагый революция һәм татар зыялылары» исемле зур мәкаләсе басылды.

**10 март.** Сәнгать хезмәткәрләрен оештыру максаты белән Казанда артистларның, музыкантларның һәм һәвәскәрләрнең гомуми җыелышы уздырылды. Җыелышта, шәһәрдәге сәнгать эшчеләрен барлау һәм киләчәккә бурычлар билгеләү өчен, вакытлы комиссия төзелде.

**18 март.** Журналистлар союзы янында мөселман секциясе төзү максаты белән, «Эш» газетасы редакциясендә татар язучылары, шагыйрьләре, тәрҗемәчеләре һәм журналистларының гомуми җыелышы булды.

**24 март.** Беренче Идел буе татар укчылары бригадасы төзелә башлады. Бригаданың комиссары – Шамил Усманов.

**4 апрель.** Танылган трагик Мохтар Мутин бенефисына Нариман Наримановның «Надир шаһ» трагедиясе куелды.

**16 апрель.** Укучы яшьләрнең «Берек» оешмасы Габдулла Тукайны искә алу кичәсе оештырды.

*«Эш» газетасы, 13 апрель.*

**18 апрель.** Драматург һәм шагыйрь, большевистик «Көн» газетасының (Сембер) редакторы Фәтхи Бурнаш Коммунистлар партиясе сафына керде.

**24 апрель.** Коммунистлар партиясе мөселман секцияләренең, Казан өлкә бюросы «Интернационал»ның иң яхшы тәрҗемәсенә конкурс игълан итте. Конкурста беренче урынны С.Сүнчәләй алды.

**23 май.** Зур театрда «Галиябану» драмасының премьерасы булды. Хәлил ролендә С.Айдаров, Галиябану булып Г.Болгарская уйнады.

**30 майга кадәр.** «Мәгариф» һәм «Бертуган Кәримовлар» исемле шәхси типографияләр конфискацияләнде.

**10 июнь.** «Эш» газетасында М.Максудның «Изге көрәшкә» дигән нәсере басылып чыкты.

**Июньнең беренче яртысы.** Татар һәм башкорт халыкларының уртак шагыйре Шәехзадә Бабич ак фетнәчеләр тарафыннан җәзалап үтерелде.

*«Кызыл Армия» газетасы, 16 июнь.*

**16 июньгә кадәр.** Самарада (хәзерге Куйбышев) «Таң» исемле театр труппасы оештырылды.

*«Яңа көч» газетасы, 16 июнь.*

**25 июнь.** «Эш» газетасында түбәндәге игълан басылды:

«Татарлар арасында театр вә музыка эшенең куелуы һәм аның киләчәктә өмет ителгән барышы хакында 26 июньдә кич 7дә булачак киңәш мәҗлесенә Казанда булган оешмаларның һәркайсыннан 1-2шәр вәкил чакырыла. Шулай ук татар театры һәм аның барышы хакында үз фикерен әйтәчәк һәрбер кеше килергә тиеш. Мәҗлес Тукай урамында «Эш» конторасының идарәханәсендә булачак».

**25 июнь.** Танылган революционер, коммунист Камил Якуб фетнәчеләр тарафыннан үтерелде.

**Июнь – сентябрь.** Г.Ибраһимов, махсус задание буенча, дошман тылында йөрде. Соңыннан ул, бу сәяхәт-командировкасының хисабы төсендә, «Дошманнар арасында дүрт ай» исемле очерк язды. Очерк «Кызыл юл» газетасының 7 сентябрь, «Эш» газетасының 15 сентябрь, «Кызыл Армия» газетасының 16 сентябрь саннарында басылды.

**6 август.** Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге, Казан өлкәсе һәм шәһәренең бер төркем интеллигенциясе, руханилары һәм мөгаллимнәре өчен, аңлашу мәҗлесе үткәрде. И.Казаков, С.Сәетгалиев, Р.Рәхмәтуллин җыелышка килүчеләргә (30 кеше) Совет властеның асылы, тоткан политикасы турында аңлаттылар.

*«Эш» газетасы, 8 һәм 14 август*

**8 август.** Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге карамагындагы татар драма артистлары труппасы Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» исемле комедиясен сәхнәгә куйды. Спектакльнең режиссёры К.Тинчурин.

**19 августка кадәр.** Зөя өязендә дәүләт театр труппасы төзелде.

*«Эш» газетасы, 19 август.*

**19 август.** «Кызыл юл» газетасында «Матәм маршы»ның татарча тәрҗемәсе басылды.

**24 август.** Казан югары сәнгать мәктәбендә күргәзмә ачылды. Ул өч бүлектән (рәссамчылык, скульптура һәм монументаль-декоратив сәнгать) тора.

**7-14 сентябрь.** Казанда һәм губернада китап атналыгы үткәрелде.

Китап атналыгының максатлары: 1. китап җыю; 2. халыкка китапның мәдәни ролен аңлату һәм 3. китапханә эшләре белән халыкны таныштыру.

14 сентябрьдә Казанда 20000 гә якын китап җыелды.

*«Эш» газетасы, 11 һәм 17 сентябрь.*

**21 һәм 29 сентябрь.** «Кызыл Армия» һәм «Эш» газеталарында түбәндәге мөрәҗәгать басылды:

«Урыннардагы партия оешмаларына һәм язучылар дикъкатенә!

Октябрь революциясенә 2 ел тулу мөнәсәбәте белән, Казандагы мөселман журналистлары һәм язучылар катнашы белән түбәндәге темаларны эченә алган зур бер җыентык чыгарылачак:

1. Революция корбаннары (кыскача тәрҗемәи хәлләре, революция дәверендәге хезмәтләре, мөмкин булса рәсемнәре);

2. Революция тарихы (Февральгә кадәр, Февраль – Октябрь арасы, Октябрьдан соң);

3. Учредительное собрание;

4. Гражданнар сугышы (төрле дәверләре);

5. Мөселманнар арасында милли хәрәкәт (съездлар дәвере, Милли шуралар, Хәрби шура, Милләт мәҗлесе вә башка дәверләр);

6. Мөселманнар арасында, сәяси агым (эшчеләр оешмалары, социалистлар комитетлары, большевиклар партиясе комитетлары, сул эсерлар, конференция, съезд, комиссариатлар вә башкалар)...

Материаллар «Эш» яки «Кызыл Армия» идарәсенә җибәрелергә тиеш». Сентябрь. Стәрлетамакта Башкортстан Ревкомы органы «Башкортстан хәбәрләре» газетасы чыга башлады. Ул 1922 елда Уфага күчте һәм РКП(б)ның Башкортстан өлкә комитеты органына әверелде. 1924 елда «Башкортстан хәбәрләре» нигезендә 2 газета чыга

башлый: башкортча «Башкортстан» һәм татарча «Яңа авыл» (хәзерге көндә бу газеталар «Совет Башкортстаны» һәм «Кызыл таң» исемнәре астында чыга).

**Сентябрь.** «Кызыл йолдыз» газетасының 65 санында Муса Җәлилнең «Бәхет» исемле беренче шигыре басылды.

**Октябрь башы.** Казанда шәрык консерваториясе ачылды.

**18 октябрь.** Ф.Бурнаш рус совет шагыйре Д.Бедныйның «Ачлык-патша» исемле поэмасын тәрҗемә итте.

**5 ноябрь.** «Эш» газетасында түбәндәге игълан басылды:

«Ноябрь урталарында Төркстанга китәчәк «Шәрык поезды»нда чыгарылачак газета идарәсенә казакъча (кыргызча), сартча, фарсыча яхшы белә торган һәм шул телләргә русчадан тәрҗемә итә ала торган язучылар кирәк. Шулай ук югарыда күрсәтелгән телләрдә яхшы сөйли белә торган хатиблар һәм лекторлар кирәк...»

**7 ноябрь.** Октябрь революциясенең 2 еллык бәйрәме хөрмәтенә Пороховой бистәдә Шамил Усмановның «Беренче адым» исемле 3 пәрдәле пьесасы куелды.

**27 ноябрь.** «Эш» газетасы игълан итте:

«Казан губернасы Мәгариф бүлегенең мәктәптән тыш мәгариф эшләрен карау бүлекчәсе тарафыннан, сәхнә эшчеләре җитештерү максаты белән, «Драматический студия» ачыла. Шул студиягә керергә мөселманнардан русча яхшы аңларлык, сәхнә эшенә мәхәббәтле 4 һәвәскәр кирәк... Студиянең башлануы декабрь башында».

*«Кызыл Армия» газетасы, 22 декабрь.*

**«Казан утлары». 1967 ел, №8**

---

*Хикәя яза аласызмы?*

# ҖИҢҮЧЕЛӘР АРТА!

Ошбу еллык бәйгеләребезнең 2016 елгысына да йомгак ясалды менә. Сыйфат яхшыра бара, шуңа күрә җиңүчеләр дә алдан билгеләнгән урыннарга сыймады, аларны арттырасы булды.

Беренче урынны «Үкенү газабы» дигән хикәясе белән (№3) Казандагы 96нчы гимназия укытучысы **Лилия Нуриева** алды. Ул яңарак кына Мәскәүдә «Жизнь замечательных людей» сериясендә чыккан «Минтимер Шаймиев» дигән китап белән бүләкләнә (авторлары Игорь Цыбульский һәм Нурсөя Шәйдуллина).

Икенче урынны, шөкер, ике түгел, өч итәргә туры килде. «Көмеш бүләк» ияләре: Сарман районының Җәлил бистәсеннән **Әнисә Минһаҗева** («Сыңар алка», №3), Чирмешән районындагы Лашман мәктәбенең 11нче сыйныф укучысы **Айгөл Саматова** («Серле ярдәм яки кайтарылмаган бурыч», №6) һәм Башкортстандагы Эстәрлебаш районының Турмай авылыннан **Хисаметдин Исмәгыйлев** («Тәңрем ташламасын», №8). Алар Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабы белән бүләкләнә.

Өченче урын ияләре исә бишәү булды! Бу – Казандагы 4нче гимназиянең 7нче сыйныф укучысы **Рәис Әхмәтов** («Камәрия әби хатирәсе», №2), шул ук гимназиянең 6нчы сыйныф укучысы **Миләүшә Фәйзуллина** («Оныткамын бит!», №2), 96нчы гимназия укытучысы **Гүзәлия Тарханова** («Сер», №3), Тукай районының Күзкәй авылыннан **Флёра Мәрданова** («Ай кызы», №3) һәм Арча районының Яңа Кырлай авылыннан **Гөлшат Дәүләтбаева** («Соң иде инде», №7). Алар «Яңа базар» дигән китап белән бүләкләнә. «Казан утлары» 2011-2012 елларда үткәргән, «Печән базары» дигән сатирик әсәрләр конкурсына килгән әсәрләрдән төзелгән китап бу.

Киләсе саннан 2017 ел бәйгесе хикәяләре басыла башлый. Алар ноябрь азагына кереп бетәргә тиеш. Башламнар 1нче санда бирелде.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Республикабыз җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде. 16 гыйнвар көнне Татарстанның халык шагыйре (2016), публицист, тәрҗемәче, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия (2007), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (2011) лауреаты **Лена Галимҗан кызы Шакирҗанованың** (Лена Шагыйрьҗанның) 72 нче яшендә йөрәге тибүдән туктады.

Лена Шагыйрьҗан 1945 елның 4 июнендә Татарстан Республикасының Актаныш районы Пучы авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Лена туганнан соң күп тә үтми, аларның гаиләсе Әтнә районына күчеп китә. Аның балачагы һәм мәктәп еллары шушы районның Күлле Киме һәм Түбән Көек авылларында уза. 1962 елда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә.

1967 елда институтны тәмамлап, Казан шәһәренең 80 нче татар урта мәктәбендә укытучы булып эшли.

1968-1973 елларда Л.Шагыйрьҗан – Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә җырчы-артистка хезмәтендә. 1974-1987 елларда – Татарстан дәүләт радиокомитетында тәрҗемәче-журналист.

Л.Шагыйрьҗан – 1987 елдан СССР (Татарстанның) Язучылар берлеге әгъзасы.

Мәктәптә һәм институтта укыган елларда ук каләм тибрәтә башлый. 1977 елда аның шигырьләре «Кызлар җыры» исемле күмәк җыентыкка урнаштырыла. Л.Шагыйрьҗанның татар шигърияте мәйданында зур казаныш булып саналырлык «Ышанам йөрәгемә», «Иман әлифбасы», «Шигырьләр, поэма», «Боҗра вә Хөҗрә» шигырь җыентыклары дөнья күрә. Шагыйрә хатын-кызның катлаулы күңел дөньясын ачып кына калмый, гражданлык лирикасы биеклегенә күтәрелә, зур күләмле социаль, милли проблемаларга да кагыла. Яшь буында әдәбиятка, милли сәнгатебезгә һәм туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләп, Л.Шагыйрьҗан балалар өчен дә китаплар иҗат итте («Канатлы ат» җыентыгы).

Л.Шагыйрьҗан үзен ялкынлы публицист буларак та танытты. Аның иҗатында зур урынны Ватан һәм халык язмышы, әдәбият һәм сәнгать турында уйланулар, тәнкыйди язмалар, замандашлары турындагы хатирәләр алып тора. Мондый әсәрләр аның «Сагынмаклык» китабында тупланган.

Л.Шагыйрьҗан шигъри тәрҗемә остасы да иде. Ул А.Пушкин, Г.Державин, А.Ахматова, М.Цветаева, Г.Мистраль, Р.М.Рильке кебек күренекле рус һәм чит ил классикларының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итте. Аның тәрҗемә эшләре «Аромат цветов мира» дип исемләнгән җыентыкта тупланып бирелгән.

Л.Шагыйрьҗан – әдәби иҗатын җәмәгать эшләре белән тыгыз бәйләп барган әдибә иде. Ул озак еллар Бөтентатар «Ак калфак» хатын-кызлар ассоциациясенең рәис урынбасары булып торды.

Шагыйрәгә үз эшенә бирелгәнлек, зур җаваплылык, кешеләрне ярату кебек сыйфатлар хас иде.

Талантлы шагыйрә, тәрҗемәче, публицист һәм гаҗәеп шәхес турындагы якты истәлек күңелләребездә мәңге сакланыр.

**Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин,**
**И.Ш.Халиков, Ә.Ә.Сәфәров, А.М.Сибагатуллин, И.Р.Метшин,**
**Г.Г.Хәкимов, Д.Х.Салихов, Р.Г.Фәйзуллин, М.Б.Галиев**

### КОНФЕРЕНЦИЯ

Казандагы «Корстон» сәүдә һәм күңел ачу үзәгендә «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең XXVI конференциясе булып узды. Анда 298 делегат, Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе Дәүләт Думасына сайланган депутатлар, «Яшь гвардия» вәкилләре катнашты.

«Бердәм Россия» партиясенең Татарстан Республикасы төбәк бүлеге сәркатибе Фәрит Мөхәммәтшин белдергәнчә, әлеге фирка әгъзалары ТР башкарма хакимиятенең нигезен тәшкил итә. Соңгы елларда аның сафларын ишәйтү максатында байтак эшләр башкарылган. Республикада «Бердәм Россия» партиясенә керүчеләр саны 4 меңгә арткан. Хәзер Татарстанда аларның саны 137 мең исәпләнә.

Конференциядә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. «Партиянең уңышы турыдан-туры заман белән бергә атлаудан тора. Идарәче партия исеме «Бердәм Россия»не халык алдында аеруча җаваплы булырга этәрә. Халыкка якынрак булырга, аның белән аралашырга, иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә кирәк. Бу хезмәттәшлек традицияләргә ихтирам, гражданлык җәмгыяте институтына өлеш кертүгә нигезләнгән булырга тиеш», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов 2018 елда РФ Президентын сайлауларга инде бүгеннән үк әзерләнә башларга кирәклеген дә белдерде.

Конференциядә «Бердәм Россия»нең Татарстан төбәк бүлеге сәркатибе итеп яңадан Фәрит Мөхәммәтшин сайланды. ТР Президенты Р.Миңнеханов янә партиянең Югары Советына әгъза итеп тәгаенләнде.

Конференциядә партиянең Генераль советы сәркатибе, РФ Дәүләт Думасы рәисе урынбасары Сергей Неверов катнашты һәм чыгыш ясады.

Хәзер партиянең төп бурычы – сайлау алды вакытында тәкъдим ителгән программаны тормышка ашыру.

### КОТЛАУ

РФ Президенты Владимир Путин һәм РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев Мәскәү Кремлендә ТРның Беренче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе, ТРның тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фонды попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиевне 80 яшьлек юбилее белән котладылар. Илбашы бәйрәмдарга XVII гасыр картографы, голландияле Виллем Блауның борынгы Тартария картасын бүләк итте. «Элекке елларда башкарылган уртак хезмәт һәм соңгы вакытта, шул исәптән уртак мәдәниятебезне һәм тарихыбызны өйрәнүдәге эшләрегез өчен рәхмәт әйтәсем килә», – диде ул.

### МАТБУГАТ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

«Татмедиа» акционерлык җәмгыятендә ТРның Беренче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев турында «Илбашы» китабы чыгу уңаеннан матбугат конференциясе үткәрелде. 71 хикәядән торган, 14 табаклы әдәби-документаль әсәр турында автор, Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, китапны дөньяга чыгарган Татарстан китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин, мөхәррир Газинур Морат сөйләделәр.

«Дөресен әйткәндә, «Казан утлары» журналыннан тәкъдим килгәч, бу эштән курыккан идем, аннары Аллага тапшырып алындым», – диде Р.Батулла. Ул документлар туплауның авыр булмавын, Минтимер Шәймиев турында материалларның күп булуын да әйтте.

### НӘБИ ДӘҮЛИ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Казандагы Галактионов урамындагы 3А йортта язучы Нәби Дәүли истәлегенә такта куелды. Аны ачу тантанасына язучылар, журналистлар, җәмәгатьчелек вәкилләре җыелды. Әлеге чара ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Эльвира Камалованың язучы үз башыннан кичергән фаҗигале язмыш турындагы чыгышы белән ачылды. Татарстан Язучылар берлеге рәисенең беренче урынбасары Рәмис Аймәтнең әйтүенә караганда, бу йортта тагын Зәки Нури, Шәйхи Маннур, Риза Ишморат кебек язучылар да яшәгән. Киләчәктә алар истәлегенә дә такталар куелыр дип өметләник. Истәлек тактасын ачу тантанасында язучылар Лирон Хәмидуллин, Мөдәррис Вәлиев, Нәби Дәүлинең якташы, Әлки якташлык җәмгыяте рәисе Ришат Хафизов, Нәби Дәүлинең кызы Гөлфия Дәүләтшина һ.б. чыгыш ясады. Чара җырчы Искәндәр Биктаһиров

башкаруында Нәби Дәүли сүзләренә язылган «Татарстан – минем республикам» дигән җыр белән тәмамланды.

### АСТАНАГА СӘФӘРЛӘР

Соңгы вакытта КФУ профессоры Хатыйп Миңнегулов ике тапкыр Казакъстанның башкаласы Астанага сәфәр кылды. Беренчесендә аны «Назарбаев университеты» чакырган иде. Анда ул Казакъстан Республикасы бәйсезлегенең 25 еллыгы уңаеннан «Мәңгелек илнең мәңгелек теле» дип аталган Халыкара симпозиумның пленар утырышында «Казакъ-татар әдәби багланышлары» дигән темага доклад ясады. Икенче сәфәрендә Х. Миңнегулов ике атна дәвамында Астанадагы Лев Гумилёв исемендәге Евразия милли университетының халыкара мөнәсәбәтләр факультеты студентларына, магистрларына, укытучыларына төрки әдәбиятлар (шул исәптән татар сүз сәнгате дә), алар арасындагы бәйләнешләр, хәзерге әдәбият фәненең, тюркологиянең мөһим мәсьәләләре турында лекцияләр укыды, семинар дәресләр уздырды, Казакъстан һәм чит ил галимнәре белән очрашты. Аның Алтын Урда әдәбияты турындагы 50 минутлык лекциясен телевидение яздырды, интернетка куйдылар.

### ШӘЙХИ МАННУР ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Мамадыш районында үткәрелгән татар әдәбияты көннәрендә Казаннан һәм Чаллы шәһәреннән әдипләребез Зиннур Мансуров, Шаһинур Мостафин, Факил Сафин, Айгөл Әхмәтгалиева, Мамадышның үзеннән Рафаил Газизов, Вәрис Гали, Вахит Галиев һәм башка күпсанлы кунаклар катнашты. Ул татар әдибе Шәйхи Маннурны искә алуга багышланган чаралар белән башланып китте. Аның туган авылы Тулбайда каберенә чәчәкләр салынды, рухына дога багышланды. Быел аның китапханәсенә 60 ел тула. Татарстанның халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты Зиннур Мансуров Шәйхи Маннур кебек үз акчасына китапханә салдырган һәм аны китаплар белән тәэмин итеп торган әдипнең Татарстанда башка булмавын ассызыклап үтте. Шәйхи аганың Мамадыштагы һәйкәле янында да аны искә алу митингы үткәрелде. Анда шәһәр мәктәпләре укучылары, татар теле укытучылары, район китапханәчеләре, әдәбият сөючеләр каршында район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Алёна Смирнова, язучылар Зиннур Мансуров, Факил Сафин, Шәйхи Маннурның мирас комиссиясе рәисе Шаһинур Мостафин чыгыш ясап, әдипнең иҗаты бүген дә актуаль булуын, Мамадыш төбәгеннән соңгы елларда бик күп әдипләр үсеп чыгуында аның да йогынтысы зурлыгын билгеләп үттеләр. Композитор Яруллиннар исемендәге балалар сәнгать мәктәбенең актлар залында узган кичәдә Шәйхи Маннур исемендәге премиянең быелгы лауреатлары исемнәре игълан ителде. Мамадыш төбәге талантларын барлауда керткән өлешләре, Мөхәммәт Шәйхинең «Якты чишмә» китабын әзерләп чыгарганы өчен, әдип, «Көмеш кыңгырау» газетасы баш мөхәррире-директоры Факил Сафин; балаларга багышланган күпсанлы китаплары өчен шагыйрь Ринат Нуруллин; матбугат битләрендә дөнья күргән шигырьләре һәм парчалары өчен мамадышлы Люция Губина яңа лауреатлар булды. Район үзәкләштерелгән китапханәләр системасы көче белән әзерләнгән кичәнең икенче өлеше Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы Вахит Галиевнең 90 яшьлегенә багышланган иде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының дәүләти һәм мәдәни үсешенә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе **Вәлиев Разил Исмәгыйль улы** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

***

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» (Иҗат берлеге) иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Хәлимов Борис Нәҗметдин улы** (Айдар Хәлим) Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

***

Массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе үзхәбәрчесе **Диндаров Илдус Гали улы** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

7 гыйнварда 87 яшендә Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, прозаик, публицист, тәрҗемәче, журналист **Марсель Харис улы Зарипов** вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: Р.БАТУЛЛА. «Первый Президент» (продолжение); роман-новелла М.ГАЛИЕВА «Да пусть живёт!»; рассказы И.ГАЗИ, А.ХАЛИМА, Г.ГИЛЬМАНОВА; стихи З.МАНСУРОВА, С.РАХМАТУЛЛЫ, И.БИЕКТАУЛЫ, Р.ГАРИФУЛЛИНОЙ.*
*«100-я страница»: К.КАРИМОВ. «Казнить нельзя помиловать».*
*«Наши юбиляры»: интервью И.ИБРАГИМОВА с академиком Р.ХАКИМОВЫМ; Д.ЗАГИДУЛЛИНА. «Реализм в татарской литературе: проза Рафката Карами».*
*Статья Р.ФАЙЗУЛЛИНА , посвящённая 75-летию со дня рождения К.Сибгатуллина.*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.*
*«Литературное наследие»: А.ХАСАВНЕХ.«Рассказ прославленного, эрудированного Фархада и его возлюбленной Ширин».*
*«Искусство»: А.АХМЕТГАЛИЕВА. «Песня жизни».*
*«Встречая юбилей»: Из дневника татарской культуры.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Лугинино». Картина Баки Урманче;*
*Горкинско-Ометьевский лес. Фото Михаила Фролова.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: R.BATULLA. «First President» (continued); novel by M.GALIEV «Let him live!»; stories by I.GAZI, A.HALIM, G.GILMANOV; poems by Z.MANSUROV, S.RAHMATULLA, I.BIEKTAULY, R.GARIFULLINA.*
*«100th page»: K.KARIMOV. «Pardon impossible to execute».*
*«Our anniversaries»: interview of I.IBRAHIMOV with Academician R.HAKIMOV; D.ZAGIDULLINA. «The realism in Tatar literature: prose by Rafkat Karami».*
*Article by R.FAYZULLIN dedicated to the 75th anniversary of K.Sibgatullin.*
*«Tukay and Tatar literature»: section is conducted by R.RAHMAN.*
*«Literary heritage»: A.HASAVNEH. «The story of the famous, erudite Farhad and his beloved Shirin».*
*«Art»: A.AHMETGALIEVA. «Song of Life».*
*«Meeting the anniversary»: From the diary of Tatar culture.*
*From the photo archives of the magazine.*
*Diary of the social-cultural life.*
*On our covers: «Luginino». Painting by Baki Urmanche;*
*Gorkinsko-Ometevsky forest. Photo by Mikhail Frolov.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Лугинино». *Бакый Урманче картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Горки-Әмәт урман паркы.
*Михаил Фролов фотосы.*